ISSN 0206-4189

# Казан утлары

8.2005



# МЕҢЬЕЛЛЫК МӘҢГЕЛЕК ЯШЬ КАЗАН



# Казан утлары
# Qazan utları

2005

8

(994)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Галимҗан Гыйльманов, Марат Закир, Камил Кәримов, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир— 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары— 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге—43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әхмәт РӘШИТ. Казан. *Поэма.* ........ 5

Вахит ИМАМОВ. Казан дастаны. *Тарихи роман.* ........ 17

Казан турында шагыйрьләребез ........ 100, 133

Илусә НӘБИУЛЛИНА. Миләш тәме. *Повесть.* ........ 103

Әнәс ИСХАКОВ. И гомер агышлары... *Шигырьләр. (М. Хәбибуллинның кереш сүзе белән)* ........ 136

Римзил ВӘЛИ. Татар географиясе. *Шигырьләр.* ........ 141

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Индүс ТАҺИРОВ. Татар дәүләти халык ул. ........ 145

Татарның иле кайда? (Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров белән язучы Марсель ГАЛИЕВ әңгәмәсе) ........ 153

**ДИСКУССИЯ "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Нияз АКМАЛ. Әллә каян эзләп йөрисе юк... ........ 160

**ХӘТЕР**

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Батмаска туган Баттал. ........ 164

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге ........ 170

Җәмил ЗӘЙНУЛЛИН. Телләре төрки, диннәре яһүди. ........ 173

"Татар энциклопедиясе" битләреннән ........ 177

Берлекнең яңа әгъзалары ........ 181

Котлыйбыз! ........ 182

Latin imlasında uqu künekmələre ........ 184

"Казан утлары" архивыннан ........ 186

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 188

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": исторический роман В. ИМАМОВА "Дастан о Казани", повесть И. НАБИУЛЛИНОЙ "Вкус рябины", поэма А. РАШИТОВА "Казань", стихи татарских поэтов о Казани, стихи Р. ВАЛИЕВА, А. ИСХАКОВА (с предисловием М. ХАБИБУЛЛИНА).
"Публицистика": статья И. ТАГИРОВА "Татары—это государственный народ"; беседа писателя М. ГАЛИЕВА с председателем исполкома Всемирного конгресса татар Ринатом Закировым.
Дискуссия "Герой нашего времени": размышления поэта Н. АКМАЛА.
"Память": статья Р. ФАЙЗУЛЛИНА о творчестве поэта Салиха БАТТАЛА.
"Наука": статья Дж. ЗАЙНУЛЛИНА о караимах; А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
Страницы из "Татарской энциклопедии".
Новые члены Союза писателей.
Из архива журнала.
В номере отмечаются 70-летие М. Маликовой и Н. Лаисова.
Навыки чтения на основе латинской графики.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: фоторепродукция С. ИСХАКОВА "Столица моя"; поэтесса Л. Газизова.

## IN THIS ISSUE:

"Prose and poetry": historical novel by V. IMAMOV "Dastan about Kazan", Story by I. NABIULLINA "Taste of mountain ash", Poem by A. RASHITOV "Kazan", Verses of tatar poets about Kazan, verses by R. VALIEV, A. ISKHAKOV (with foreword of M. Habibullin).
"Publicism": article by I. TAGIROV "Tartars are state people";
Conversation of writer M. GALIEV with chairman of executive committee of the World Congress of Tartars Rinat Zakirov.
Discussion "Hero of our time ": reflections of poet N. AKMAL.
"Memory": article by R. FAIZULLIN about creativity of poet Salih Battal.
"Science": article by I. ZAINULLIN about karaims; A. TIMERGALIN. "Dictionary of nation".
Pages from "Tatar encyclopedia ".
New members of Union of writers.
From archive of the log-book.
In this magazine we celebrate the 70[th] anniversary of M. Malikova and N. Laisova.
Skills of reading on the basis of latin alphabet.
Diary of social-cultural life.
On our covers: photoreproduction of S. ISHAKOV "My capital";
Poetess L.Gazizova.

*The magazine edits monthly*

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.07.2005 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А–566. Тираж 7011.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2005 ел.



**Әхмәт Рәшит**

## КАЗАН

ПОЭМА

*Казанның 1000 еллыгына багышлыйм.*

### I

**Утырам Казансу ярында,**
**Дулкыннар тәгәри Иделгә—**
**Аларның шул гамьсез җырына**
**Бик теләп кушылыр идем дә,**
**Нигәдер ямансу күңелдә.**

**Шуңамы керфекләр чыланган—**
**Югыйсә көн шундый кояшлы;**
**Мин бүген мең яшен тутырган**
**Казаным хакында сүз башлыйм—**
**Нигә соң тыелмый күз яшем?!**

**Югыйсә барабан кагарлык,**
**Ил күзе күрмәгән тантана!**
**Бу көндә һәртөрле мактаулар—**
**Данлаулар гына да аз аңа,**
**Ә җанда барыбер ут яна.**

**Күрче, дип юатам үземне—**
**Син чынын белергә зарыккан.**
**Бар, сораш белүче халыктан—**
**Җиләкле аланнар артында**
**Пәһлеван заводлар калыккан.**

Әхмәт РӘШИТ (1936) —*шагыйрь, публицист; "Йөрәк кыңгыраулары", "Иман яңартканда", "Таң илчесе", "Фидаиләр" һ.б. китаплар авторы. Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

Сана да чагыштыр чорларны—
Иң якты хыяллар чынга ашкан;
Мең яшьлек элекке тын Казан
Дөньяви тизлеккә тоташкан—
Тылсымлы сандыгын кем ачкан?!

Үтте баш өстеннән очкычлар—
Эзләре аяз күк йөзендә,
Ясалган Казанның үзендә!
Боргалак фырлады аннары
Һәм күздән югалды тиз генә.

Күрегез, борынгы бабайлар,
Бу сезнең туруннар—варислар,
Куркытмый аларны ярышлар—
Акылны акылга тапкырлап,
Әнә бит җай алган бар эшләр.

Мактаныр нәрсәбез күп, диген,
Данлыклы ул, диген, дөньяда—
Йөзе ак җир шары каршында,
Ул әзер иң җитди сынауга—
Мәдхияң кызганма син аңа.

Син үзең яшәгән йорт та бит
Шул ерак заманнар дәвамы.
Тик алар ярага—дәвамы?
Әллә соң хәтерне болгатып,
Йөрәккә кан булып савамы?

Хәтерлим беренче мәртәбә,
Эчемнән укып бар белгәнне,
Ашкынып калага килгәнне,
Балакны сызганып тезгәчә,
Казансу буенда йөргәнне.

Сай идең, сай идең ул чакта,
Кемнәрдер хәтере шикелле,
Мин дә бит дүрт диеп йөргәнмен
Икегә тапкырлап икене,
Бәясен көтмичә һичкемнең.

Ә ярда, биектә Кремль—
Манара артында манара;
Җилкенде тынгысыз хыялың—
Инде дә күр барын, йә кара—
Әнә ич алдыңда—башкала.

И сабый, и авыл малае—
Урысча дәшәрлек юк сүзең.
Кемнәндер сорарга кыймыйча
Адашып йөрдем мин көнозын...
Эсседә... ач килеш... бер үзем...

Дөньяны күрмәгән малай шул,
Зиннәтен карыйсым килгәндер:
Кызыгып, ниләр бар икән, дип,
Мәчетне эзләүдән элгәре,
Чиркәүгә сугылдым нигәдер.

Әй малай, башыңнан сал, диләр,
Ә кызык—мин алга үрмәлим:
Һәммәсе җыр суза иделәр—
Мин юньләп берни дә күрмәдем,
Бары тик кот очып шүрләдем.

Ярлыка, и Аллам, ярлыка,
Гөнаһка батылды... гөнаһсыз;
Болай да бит инде аларны
Дөньяда бихисап җыйнасы...
Һәммәсе замана зинасы...

Гыйбадәт беткәнен көтмәстән
(Күзгә бит ак-кара күренми—
Тораташ булып тик торыйммы?!),
Кысылып көч-хәлгә чыкканда,
Ишеккә бәргәнмен борынны.

Күлмәктә кан эзе. Чепуха!
Бабайлар аны аз күргәнме?!
Хәтерлим, Казансу, ул көнне
Ничекләр каңгырап йөргәнне—
Юашлык кирәкне биргәнне.

Ә аның каравы күңелдә
Чәчәкләр күзләрен ачтылар;
"Чаян"да эшләүче абыйлар
Мин язган шигырьне бастылар—
Мине зур бәйгегә дәштеләр.

Мин ялан аяклы бер ятим
Ул чакта зур шатлык татыдым...
Һәм менә илле ел йөгәнлим
Шул Пегас аталган атымны,
Бозмыйча балачак антымны.

Үзем дә сизмәстән базганмын
Шигърият диварын шакырга—
Күңелем талына кунган моң.
Колгали, Сараи, "Бакырган"
Мәйданга мине дә чакырган.

Чөнки бер кузгалган куәтнең
Мөмкин хәл түгел һич туктавы.
Үткәннәр гәрчә күп нокталы,
Халкымның мирасы—кояшлы,
Ул—айлы, йолдызлы, Тукайлы.

Шуңа да адашмый бара ул,
Күзләрен текәп күк йөзенә.
Даһилар бүгенге чордан да
Варислар тапмакчы үзенә—
Дәвамчы вәзенле сүзенә.

Бар ул, бар, алда да булачак—
Милләтнең чишмәсе кипмәгән.
Үткәнне бүгенгә ялгаучы
Күперләр сүтелеп бетмәгән—
Талантлар хәзер дә күпләгән.

Утырам Казансу ярында,
Уйларым уйларга чуалган—
Йә шигырь, йә тарих сүз сорый.
Күзләрем алалмый сулардан,
Мин гыйбрәт тапмакчы шулардан.

Карасам Бишбалта ягына,
Чиркәүле Елантау күренә.
Борынгы бу татар җирендә
Ят кавем күтәргән тәреләр
Нигә соң шәһәрнең түрендә?

Нигә соң бабамнар куылган
Шул Татар бистәсе дигәнгә?
Булса да үзләре имәндәй,
Мал-мөлкәт талангач, ач көе
Көн күргән юеш җир идәндә?

Язмыштан узмыш юк, диярләр,
Фаҗига икән бит ул язмыш.
Ходаем, кодрәтең киң булмыш—
Язмышлар язылган мизгелдә
Юлларны күрсәттең ник ялгыш?

Ярларны актарып юл ярып
(Суларның ташыган чагы шул!),
Син мәңге агарсың, Казансу,
Дулкыннар тәгәрәр туктаусыз...
Ә миңа ямансу... ямансу...

II

Актарам хәтерем дәфтәрен—
Риваять, мөнәҗәт, бәетләр...
Ышанмас ирсәләр бик күпләр,
Чакырам Ризатдин казыйны—
Сүземне тәгаен ул җөпләр.

Күтәреп гасырлар пәрдәсен,
Хыялда бер Сылу терелә—
Ул миңа томанга төренгән
Фәрештә шикелле күренә—
Искиткеч сөенеч күңелдә.

И Сылу, су алган чагыңда—
(Кулыңда казаның—алтыннан)—
Ялгышып аягың тайдымы,
Чишмәгә шул казан артыннан
Мәтәлеп төшмәдең чак кына.

Фаразлар тагын да бар алар—
Мин күпләр фикерен тыңладым,
Тик җаным әйткәнгә инандым—
Каланың исеме шуннандыр,
Инде дә какшамас иманым.

Юк әле тынганы бәхәснең
Ул серле атама турында—
Галимнәр теләсә нишләсен;
Теләдем бу ихлас җырымда
Әйтергә Сылу кыз турында.

Кем генә ваемсыз калыр соң—
Мәңге дә чибәр бит ул кызлар.
Үтсә дә ничәмә гасырлар,
Һәркайсы мутланып шагыйрьдән
Мәхәббәт турында җыр сорар.

Кемгә кыз, кемгә каз—галимнәр
Төрлечә юрыйлар һаман да.
Дәлилләр бик саллы булса да,
Яхшы ук түгелдер... яман да...
Мөһиме— ярасын заманга.

Булды бит—ни кушса түрәләр,
Кемнәрдер тик шуны хуплады,
Тарихи дөреслек хакына
Ашкынып көрәшкә чыкмады—
"Фәнни"ләп бер—берсен тукмады.

Борынгы хәерсез көннәрдән
Сабаклар аласы урында,
Кемнәрдер Мәскәүгә әләкләр
Яудырды кемнәрдер турында—
Шуңадыр ямансу җырым да.

Күптәнге хосетлек, көнчелек
Өстендә иссен дип таң җиле,
Җиребез үзе үк куеныннан
Чыгарып күрсәтте дәлилне.
Югыйсә бик мөшкел хәл иде.

Катламнар астында катламнар—
Тарихның серләрен җир саклый;
Акны ак дияргә дәлилләр
Булган бит, булган бит ничаклы—
Тәңкәме, чүлмәкме, пычакмы...

Сөрткәчтен дәверләр тузанын,
Ялтырап балкыды үткәннәр;
Дошманнар юк итмәк булса да,
Халкыбыз барыбер бетмәгән—
Чөнки без бу җирдә күптәннән.

Идел—Йорт чигендә торгандыр
Кальгасы кадими елларның,
Күзәтеп үзән вә үрләрне,
Баһадир егетләр җырлаган
Болгарда ишеткән җырларны.

Казанга инде мең яшь, дибез—
Кемнеңдер эче дә пошадыр;
Татарны соймичә сөйләсә,
Һичшиксез, уйдырма кушадыр—
Янәсе, берәрсе ышаныр.

Бар ятлар ялалар якканда,
Бәхеткә, Илбашы ир булды,
Ил аңа кадерле җир булды.
Мең карыш ялганнар өстеннән
Калыгып, ил белән бер булды.

Хәлиткеч көрәшкә чыкканда,
Акылның юлдашы—йөрәктер,
Халыклар теләге—терәктер;
"Тот та өз..." диюләр урынсыз—
Дипломат булу да кирәктер.

Ә бүген таяныр нокта бар—
Үпкәләр юылыр барсы да...
Ә без бар...
Булырбыз...
Барабыз
Төз атлап Сәйдәшев маршына,
Өченче мең еллык каршына.

III

Иделгә ашыга Казансу—
Таш–бетон ярларга кага су.
Көн аяз, исә җил, ага су—
Дөньялар үзгәрде бит инде,
Күңелдә нигә соң ямансу?!

Әнә ич, хәзинә тапканнар!—
Әйт шуны—бу моңлы сүзеңдә,
И шаулый бар гавам—түз генә;
Ә Казан, чын–чынлап карасаң,
Бәһасез хәзинә үзе дә.

Казылгач күмерле катламнар,
Нәрсәдер табылыр тагын да;
И Казан, искиткеч идең бит,
Син көчле, куәтле чагыңда,
Чорларның бәхетле таңында.

Көнләшеп күзәткән күршеләр
Һаман яу өстерде өстеңә,
Кылларын язмышның уйнатып,
Хәвефле чорларны кичтең дә,
Баш идең бәхетсез бер көндә.

Көрәш бит аяусыз—азактан
Каласың йә аста, йә өстә;
Нечкә кыл өстендә торганда,
Хәл итә бәләкәй ялгыш та—
Сакласа тик саклар фәрештә.

Кем әйтер кистереп—иң элек
Йомырка булганмы, тавыкмы?!
Чуалган һәм надан дөньяның
Абсолют җавабын табыйкмы,
Төзәтеп борынгы тарихны?!

Хәтерлә Ходайның каһәрен—
Гыйбрәтле Вавилон кыйссасын,
Бер телдә сөйләшеп адәмнәр
Күкләргә менәргә кыймасын—
Үзләрен көчле дип тоймасын.

Шуңа да ошбу җир йөзендә
Төрлеләр йолалар, шивәләр;
Тәрәккый итәсе урында
Адәмнәр бер—берсен тибәләр,
Дошманлык агуы сибәләр.

Уйларым еракта—еракта,
Уйларым гасырлар артында;
Аңлаган шикелле җанымны,
Дулкыннар бер ярсый, бер тына—
Ниләр бар гасырлар артында?!

Күрәсем килә, дим, кальгада
Кизүлек итүче батырны;
Ул минем хыялда кул изәп
Янына җайдаклар чакырды—
Болгарга барыр юл такырмы?

Офыкта ят яулар күрәм, дип,
Тиз генә әйтер соң кем генә—
Ә Казан—Болгарның чигендә.
Җилдән дә җитез шул җайдаклар
Хәбәрне җиткерсен көнендә.

Ашыктыр атларны, ашыктыр—
Камчыла аласын, коласын,
Җәяләр, сөңгеләр әзерме?
Болгар тиз шул хакта уйласын—
Кем белә алда ни буласын!

Гыйбрәтнең күрдек ич төрлесен:
Ачылмас капкалар ачылды,
Уяулык йоклаган чакларда
Килмешәк яугирләр баш булды—
Тәндә кан, күзләрдә яшь булды.

Дөнья бу!—исләрең китмәсен.
Без, Тукай әйтмешли, кайчандыр
"Шаярдык вакытлар алмашып".
Һәм теттек кемнәрдер тетмәсен—
Аңа да күз йомып үтмә син.

**Ә болай электән күңел киң:**
**Ниятең изгеме—чит итми;**
**Ничәмә кавемнәр дус булып**
**Торган ич бер—берсен кимсетми—**
**Кемгә соң, кемгә соң ни җитми?!**

**Дөнья бит тар түгел, хәзинә—**
**Байлыклар һәркемгә җитәрлек.**
**Залимнәр азсына ник әле—**
**Таланган малларны барыбер**
**Китәлми кабергә күтәреп.**

**Уйлыйм да вәйраннар буламын—**
**Ганнибал, Атилла яуларын**
**Һәм Алтын Урданы каһәрләп,**
**Ничәмә - ничә чор шаулады—**
**Соңыннан эзләр дә калмады.**

**Заманнар уза да, чал тарих**
**Куя ул бик кызык итеп тә:**
**Европа баш игән изге Рим**
**Сыйган ич бер сыңар итеккә—**
**Җитмәсә бер ягы китек тә.**

**Дөнья бу! Исләрең китмәсен—**
**Күрсәтә бер алдын, бер артын;**
**Масаеп йөрсәң дә "Без—кем!" дип,**
**Үлчәүне, чаманы югалтып,**
**Вәхиләр иңә бит югартын.**

**Җайдаклар Болгарга җиткәндә,**
**Нигәдер кызарып атты таң;**
**Җил хәбәр китерде еракτан—**
**Дәһшәт дип, вәхшәт дип какты чаң:**
**Тәмерләң каланы яндырган.**

**Идел—Йорт бәлагә тарганда,**
**Кирәкме яугирга үгетләр?!**
**Дәррәү шул сугышка катышып,**
**Баш салды баһадир егетләр...**
**Һәм сүнде иң соңгы өметләр.**

**Соңыннан аларны олылап,**
**Мөхәммәт Әмин җыр чыгарыр;**
**Ничәмә гасырлар буена**
**Болгарым тарихтан югалыр—**
**Ул изге җирләрдә көл калыр.**

**Хәрәбә өстендә хәрәбә—**
**Ил—Йортта хәтәрдән хәтәр чак;**
**Язмышка салынган җирәбә—**
**Ни кыла алырсың, Алтынбәк,**
**Ни кыра алырсың, Галимбәк?!**

Тик башын киссәң дә татарның,
Кылычын күтәргән кул калыр,
Өметкә барыбер юл калыр;
Тормышны яңадан башларга
Балалар, оныклар кузгалыр.

И Олуг Мөхәммәт, кил әле—
Тергезче Казанның учагын,
Диварга уратып бар ягын,
Башкала—ташкала ит аны—
Синең бит кодрәтле ир чагың.

## IV

Утырам уйларга уралып—
Көн аяз, исә җил, ага су;
Казансу, елларны санапмы,
Ярларга дулкыннар кагасың,
Ә үзең кайларга чабасың?!

Сумы соң, сумы син, агымсу?—
Кайчакта шик били күңелне;
Син шушы дәрьяга сыймастай
Бабайлар күз яше түгелме?
Әбиләр күз яше түгелме?

Мөлдерәп тора ич Кабан да,
Мөлдерәп тора ич Болак та,
Ниндидер өн килә—шул көннәр
Авазы чыңлый күк колакта,
Гасырлар артында, еракта.

Ул сулар төбендә—чишмәләр—
Алар, дим, дөреслек яклыдыр;
Суларның гомере—мәңгелек,
Хәтерләп бу көнгә чаклыдыр,
Үткәннәр аһ–зарын саклыйдыр.

Ул чорлар дәһшәтен, вәхшәтен
Күрәбез бер Иван Явыздан—
Яңа сүз гел иске авыздан.
Әйе, ул баш бирмәс ирләрне
Сал итеп Иделгә агызган.

Күңелем алдамый—аңа да
Тиң булыр бәдбәхет табылган,
Данга һәм байлыкка табынган,
Илле мең гаскәрле Шаһгали—
Ничек соң ул безнең кавемнән?!

Шул чорны тикшергән кемнеңдер
Кирәктер зиһенен җилләтү;
Янәсе, милләтләр талашкан,
Кирәкми андый буш сүз әйтү—
Золымның юк аның милләте.

Кил әле, сөекле Сөембикә,
Утырчы яныма, чирәмгә;
Идел—Йорт афәткә тарганда,
Кем иде, кем иде тирәндә—
Ник олуг хакыйкать тирәндә.

Утырып сөйләшик бергәләп—
Кил әле, кил әле, Колшәриф,
Килсеннәр баһадир оланнар,
Үткәннәр аркылы юл ярып,
Үлемнәр аркылы юл ярып.

Ишетсен Казансу... буыннар
Үзара уртак сүз тапканны,
Хәлиткеч яу кызган мәлләрдә
Кем ачты, кем ачты капканы?
Кем куйды татарга капкынны?

Кайларга агасың, Казансу?—
Тукталып тор әле беразга;
Чыкмасын хилафлык, чир, каза.
Бу хәлләр тузларга язылсын,
Суларга язылмый елъязма.

Тик тарих хәтере җиткерә
Үткәннең яралы хәбәрен—
Җәлладның дүрт гасыр ярымга
Сузылган золымын, җәберен,
Иләктән уздырып кайберен.

Әллә бу якынча гоманмы,
Дөресен әйтүдән качумы,
"Иго" дип "ачыш"лар ачумы;
Ә бәлки вакыт та җиткәндер
Басарга элекке ачуны.

Тигезли замана һәммәсен—
Ул кая барасын белгәндер;
Буталып, болганып бетсәк тә,
Канунда син дә бер, мин дә бер—
Язмышлар уртак һәм бердәнбер.

V

И Казан, җитте бит, ниһаять,
Тантана итәрдәй таңың да.
Күр әнә, иң хәтәр чагында
Мең еллык даныңны саклаган
Иң затлы кунаклар табында.

Ник читтә торасыз, җайдаклар,
Әйдәгез, узыгыз түргәрәк;
Онытып торыгыз үткәнне—
Чор кичкән табыннар түгәрәк,
Бер бәйрәм итикче бергәләп.

И Олуг Мөхәммәт, уз түрдән—
Казаның әле дә башкала,
Кирәкми ясарга ташлама—
Ул чәчәк аткан чор тарихта
Син тәхет тотканнан башлана.

И сылу Сөембикә, тартынма—
Күр, Сафагәрәең чакыра;
Син тәхет варисы улыңны
Кочаклап утырчы янына—
Күңеле шат булыр аның да.

Колшәриф, син—мәңге хәтердә,
Бу җирдә җәсәдең ята, дип,
Фидакарь исемең олылап,
Гел сөйләп торсын шул хакта дип,
Өр-яңа мәчетне атадык.

Табында—ханнар вә олуглар,
Ил-Йортны зурлаган галимнәр,
Күнчеләр, сынчылар, ташчылар,
Сунарчы-кошчылар, ашчылар...
Саныйкмы?.. Санасаң тагын бар...

Һәммәсе—яхшымы, яманмы—
Бу Казан каласын үз иткән,
Күзләрен өзмәгән өметтән;
Инде без күптәнге үткәнгә
Карыйбыз гел бүтән күзлектән.

Мөхтәрәм борадәр Худяков,
Ялганнар еракта килә, дип,
Син безгә дөресен сөйләдең,
Мең яла ягылган татарны
Гайбәттән сакларга теләдең.

Урының Карамзин янында,
Баскаков, Гумилев кырында;
Сөйлә син кунаклар алдында
Гыйбрәтле язмышлар турында—
Шаһит бул риясыз җырыма.

Бәйрәмчә Казанның табыны—
Эш башка булганга җыр башка;
Күрегез, дус-тату яшәгәч,
Иң матур хыяллар чынгашкан—
Заманнар заманга тоташкан.

Ил-Йортның мөхтәрәм затлары
Эшенә и шаклар катырлык;
Аларның фидакарь җаныннан
Туган ич бүгенге матурлык,
Туган ич бүгенге батырлык.

Тик сатлык–хаиннәр үтмәсен
Бәйрәмчә бизәлгән ишектән,
Юл табып ярыктан, тишектән,
Ә элек яу йөргән көч белән
Уртак сүз табарбыз ничек тә!

И Казан, батырың меңләгән,
Сер бирмәс бер Сабан туенда;
Тик җиңү аларның уенда.
Йөзекнең фирүзә кашы күк
Балкырсың гасырлар буена.

Өстәлләр түгәрәк–түгәрәк,
Түгәрәк өстәлнең түре юк,
Табында һәммәбез бертигез—
Бәйрәмнең яшертен сере юк,
Һичкемнең кимсенер җире юк.

Тәбрикләп мөбарәк бәйрәмне,
Илбашы акыллы сүз әйтсен,
Туасы заманнар хакында
Уйларның матурын уйлатсын,
Бәхетле таңнарны уятсын.

Унитар дәүләт дип шауласа
Һәртөрле сәяси генерал
(Янәсе, биргәнне кире ал!),
Ул булды гаделлек ягында—
Ул булды какшамас федерал.

Мин—Тимер, диде ул көрәшнең
Иң утлы, киеренке мәлендә.
Чор башка, шарт бүтән—аралар
Булалмый элекке хәлендә—
Без тигез Русия илендә.

Кирәкми үпкәләр, рәнҗүләр,
Бәхәстә ярышу—кем кемне?!
Милләтләр даны бер—берсеннән
Аз гына артыкмы, йә кимме—
Тик Вакыт чыгарыр хөкемне.

Язмыш бер, тарихлар кушылган—
Ник аны карага төрергә!
Тырышыйк өр—яңа гасырның
Бары тик Кояшын күрергә,
Чөнки без бу җирдә гомергә.



**Вахит Имамов**

# КАЗАН ДАСТАНЫ

ТАРИХИ РОМАН

1

Алмыш ханның оныгы Габдулла таҗдар бүген ау-сунарга чыга. Иртәдән бирле Биләр өстендә дәртле аһәң йөзә:

—Габдулла хан савыгып аягына баскан!

—Габдулла хан бүген яраннары белән күңел ача!

Бар тарафтан пайтәхет капкаларына ак күбеккә баткан чапкыннар чабып-очып кына кереп тора. Иреннәрдә гел шатлыклы хәбәр:

—Ашлы әмире Сәлман илле мәргәне белән килеп җитә!

—Болгар олугбәге Хаммат кырнакларына чаклы үзе белән алган!

—Кашан олугбәге килеп җитәргә ике фәрсах кына ара калды!

Габдулла ханның күңелендә дә бәйрәм. Узган көздә аны Сарытау яныннан чатырлы арбала, киез өстенә салып кына алып кайтканнар иде. Кыш буе имчеләр өшкерде, табибләр биеде һәм, Ходайга мең шөкер, Габдулла хан янә ияр өстенә менәргә, кулына гөрзи-җәя алырга да әзер. Хәбәр таралмый калмас, дошман белеп торсын. Габдулла хан бүген сунарлыкка гына чыкмый. Габдулла ханның бүген-иртәгә яуга чыгуы бар!

Яңа хәбәр килеп кергән саен Габдулла хан күңелендә сөенеч арта бара. Төп калалардагы олугбәкләр килеп җитә икән, димәк, алар кул астында булып исәпләнгән барсил, ескил, бәрәнҗәр кабиләләре дә Габдулла хан данын зурлый, яклый. Эшләр болай уңай тора икән, алар инде ауга-сунарга гына түгел, хәтта, Габдулла хан әләме астына басып ерак яуларга чыгарга да әзер дигән сүз бу... Тик Нур-Суар каласының олугбәге Талиб Шәмсидән

Вахит ИМАМОВ (1954) *– прозаик; "Нәзер", "Сәет батыр", "Татарлар Пугачев явында", "Тозлы яра" һ. б. китаплар авторы. Гаяз Исхакый исемендәге премия лауреаты. Чаллыда яши.*

хәбәр юк бит әле, менә. Юлда гына тоткарлануымы, әллә килмәвеме? Әллә... әллә һаман киреләнә, санга санамыймы? Суар кабиләсенекеләр гомер буе шулай. Алмыш хан аларны көч-хәл белән генә ипкә-сапка кертә алган иде. Әле ярый, суарлар Алмыш хан җиде дингез, житмеш дәрья аръягындагы Баһдад хәлифе юллаган илчелекне кабул иткән чакта сынатмады. Чит-ят кунаклар алдында үзләрен пырдымсыз, киребеткән аеры кавем итеп танытмадылар, бер гаилә балалары булып күренделәр. Шул илчеләр бар Болгарга ислам динен кабул иттереп китте. Әмма... Алмыштан соң Биләр тәхетенә аның улы—Габдулланың әтисе Микаил менүгә үк, Суардагы әмир Шәмси тагын тәртәгә тибә башлады. Йә йөз хәйлә табып Микаил чакырган яуда катнашмый калды, йә хан белән бертигез кыйланып үзенең Суарында акча сугып ятты. Инде, менә, Шәмсинең улы Талибне дә үзбелдеге белән акча суга диләр. Узган ел бортаслар өстенә яу белән барганда да олугбәкләр арасыннан Талиб үз алайлары* белән гаскәргә иң соныннан гына килеп кушылды. Иртәгә нинди мөгез чыгарыр—моны шайтан үзе генә белә...

Дөрес, максат итсәң, бер Талибне генә тез астына бөтереп салып була инде ул анысы. Әнә бит, бәрәнҗәрләр, барсилләр, искилләр, алардан тыш әле сабакүл, тәмте, чалмат, башкорт ырулары—барысы да Болгар ханы ягында. Ачуың кузгалдымы, хәбәр сал, сызгыр гына. Һәммәсе дә алайлары, нөгәрләре**, чирүләре*** белән килеп житәчәкләр. Ә аннары җир өстеннән хуш бул, тәкәббер һәм киребеткән Суар! Гомумгаскәр көлеңне дә калдырмыйча, ярты көн эчендә тетеп ата сине!..

Ләкин... алай кыланырга һич тә ярамый бит. Көтүдәге ике үгез сөзешә башладымы, аларның һәр икесе бүре тешенә эләгә. Дошманнар болай да хәттин ашкан. Ука елгасы аръягыннан ел да урыс ушкуйлары янап тора. Жаек аръягыннан кара аймыклар белән бәҗәнәкләр, кыпчаклар, угызлар тынгы бирми. Сарытау ягында, борын төбендә генә бортаслар чәбәләнә. Һәм иң яманы—Хәзәр каханлыгы ашый Болгар башын, шул чак кына да тездән күтәрелергә, тураеп басарга чама бирми...

Аһ, онытып торырга кирәк боларны, уйламаска кирәк! Иң мөһиме: Габдулла ханның башы исән-сау бит! Ул савыгып аягына басты һәм ул да ау чыгарга, күңел ачарга лаек ласа!..

Янда Хәдичә бөтерелеп йөри. Яу сәфәренә әзерләнгән диярсең, ул нәкъ ирләрчә итеп, сугыш киемнәре киеп алган. Толымнарын, бөтереп, көмеш очлым астына яшергәндер инде, бөтенләй күренми. Тәненнән-сынынан ялкын бөркелеп тора. Һичкенә дә бишенче дистәсен ваклаган баш хатын диməссең син моны. И-их, онытылган кое төбендәге су шикелле талымлы, назлы күзләрендә моң һәм сагыш чалымнары да булмасамы?! Тик юк бит, юк, күзләрендә сагыш сүнми аның. Шул, Хәзәр каханы Манас кулындагы кызы Бәнат турында кайгыру галәмәте бу. Бәнат, Бәнат... Кахан ятагына аманат итеп озатылган, мәмләкәт иминлеге хакына сатылган жария кыз. Сыер, елкы, сарык урынына Манат харәмханәсенә кертеп ябылган колчура хан кызы... Их, онытырга иде, бүгенгә генә булса да уйламаска иде бу турыда!..

Сарай ишегеннән Борак килеп керде. Борак әле яшь, авыз колакта. Сәрдәр—сәрдәр инде. Ауга түгел, яуга бара диярсең, иңнәренә-биленә бар коралын аскан. Жәя, садак, ятаган кылыч, хәнҗәр, гөрзи... Ике яклап иягенә салынып төшкән мыек чылгыйларын сыйпаштырган була, ә табак кебек жәелеп киткән иреннәрен барыбер жыя алмый.

—Тәмтедән Шөгер бәк килеп житте. Сабакүл, Жүкәтау бәкләре дә монда.

*Алай — полк.
**Нөгәр — отряд.
***Чирү — гаскәр.

һәммәсе жыелдылар. Юлга чыга башласак та була.

Ханның карашында капылт очкын кабынып китте, әйтерсең лә, эчендә шайтан учак якты.

—Ә Нур-Суардан Талиб?

—Әттә... әттә... генәсе,—дип сакауланып торды-торды да Борак борчак сипкән шикелле тиз-тиз тезеп салды.—Аларның нөгәре биш былтыр ук килеп җитте бит инде. Кушкүл буендагы яланда аш пешереп ята.

—Нишләп миңа кереп әйтүче юк?—дип Габдулла хан әүвәл йодрык болгый-болгый Борак өстенә килә башлаган иде дә, кибәндәй олы гәүдәле сәрдәрнең кыл да кыймылдатмыйча, өстәвенә элеккечә авыз ерып торуын күргәч, үзе дә пырхылдап җибәрмичә булдыра алмады.

—Әллә кайчан кереп әйтәләр аны, и, тавык баш!..

Биләрдән сорнайлар кычкыртып, ат уйнатып чыгып киттеләр. Кәрван елга чаклы булып сузылган. Алда хан һәм аның яраннары. Уртада һәркайсы иртәгә үк тәхеткә менәргә хокуклы Суар, Кашан, Ашлы, Болгар калаларының әмирләре. Алар артына үз дәрәҗәләрен белеп кенә зур-зур олысларның мөхтәрәм бәкләре тезелешкән. Артта кубызчылар, пешекчеләр, ат караучылар, сакчы торгаклар, канизәкләр, шоңкар, лачын, бөркет ияләре.

Габдулла ханның күзе күбрәк улы Мөхәмммәттә. Озын буйлы, кин җилкәле, түгәрәк сакал-мыектан. Сарайдагыларның барчасы да аны коры холыклы, каты куллы, диләр. Утызын тутырып килә инде, ә аның кул астына вилаять, бәйлек түгел, хәтта кала яки олысның да эләккәне юк әле. Әтисеннән көнсаен ук булмаса да атна саен сорый:

—Берәр олыс йә кечерәк вилаятькә гади бәк итеп булса да җибәр инде, әткәй? Синең итәктән төшәргә вакыт җитте миңа.

Габдулла хан дәшми. Аның үз исәбе. Бәклек качмый, игенче-сабанчылар белән һөнәрчеләрдән җыйган салым хисабына типтереп яшәү өчен Алланың кашка тәкәсе булу кирәк түгел. Вакыты җиткәч Мөхәмммәтнең дә тәхет дигән "җен"гә утырасы бар. Болгар мәмләкәтендәге бәкләр генә түгел, читтәге ханнар, кенәзләр, барча таҗдарлар белән эш йөртә белгән хаким итеп үстерәсе иде бу малаен. Кайсыдыр ханны алдап-юмалап тотардай, икенчеләре белән солых, берлек төзи белә торган хаким булып җитешсен иде аның улы! Бу Хәзәр каханының тырнагы астыннан ычкынырга, беркемгә дә буйсынмаган, бәйсез Болгар мәмләкәте төзергә иде бит инде!..

Их, тагын уйлар читкә кереп китте!..

Габдулла хан үзе белән кырнак кызлар—жарияләр дә алды. Фани дөньяга бер генә киләсең бит, типтереп, рәхәтен белеп калырга кирәк! Түшәк өстендә кан косып яткан вакытта, әнә, аның беркемгә дә һәм һичкемнең ана да кирәге юк иде. Бөтен теләк—исән калу булды. Ә хәзер ул исән, ул янадан ирдә! Тәндә дәрте, күңелдә дәрманы бар. Талиб, Хаммат, Сәлман ише әмирләр мыскыллап, шикләнеп карарлык булмасын. Аллага шөкер, иллегә җитеп килгән Габдулла ханның мәчесе дә тычканны шәп тота! Күрегез, белегез, минем сезнең борыныгызга чиертерлек кенә дәрманым бар әле!

## 2

Ау барып чыкмады. Кораса елгасы аръягындагы Меңказ дигән күл буена матур гына барып урнашканнар иде, югыйсә. Колчуралар, сакчы, мәргәннәр зирек, шомырт, балан куаклары ышыгына киез чатырлар кордылар. Бәкләр белән әмирләр күлнең вак-вак таллыклар белән капланган почмагында, Хәдичә ханәш җитәкчелегендәге байбичәләр, кызлар, кәнизәкләр—һәммәсе бергә төнбоеклар яткан уйсулыкта су коенып чыктылар.

Аннары, күл буеннан унбиш-егерме адымда әллә ничә учак яктылар да, шулар тирәсендәге уен-көлке, жыр-биюләр, аркан тартыш, көрәш, чыр-чу килгән авазлар ярты төнгә чаклы дәвам итте. Габдулла хан күңеленең һәр почмагы түм-түгәрәк иде, һәммәсен дә елмаеп кына күздән кичереп утырды. Канәгать калырлык, жаны тыныч, ваемсыз булырлык нигезе дә бар иде шул. Чөнки тәхеткә куркыныч янардай әмирләрнең дүртесе дә монда. Талиб, Хаммат, Сәлман, Кашан бәге Ялкын. Болардан башка бәрәнжәрләр, барсил, искил, суарларның бер генә нөгәре дә Биләр капкаларын бәреп керә алмый. Бүтән төрле, көтелмәгән дошман табылса да, пайтәхетнең диварлары бик-йозаксыз түгел. Сәет Хәсәншәех шунда калды. Баш вәзир Миңлебакир анда. Ин мөһиме: бер мең кешелек алпарлары*, газиләре**, угъланнары белән Габдулланың уртанчы малае Галделваһап шунда.

Габдулла хан болай да кыска жәйге төннең калган яртысын хатыны Хәдичә ханәш куенында гына үткәрмәкче иде, таң атып килгәндә үк ашына таракан төште.

—Биләрдән, Габделваһап әмирдән чапкын килде. Яшерен хәбәре бар,— дип, сәрдәр Борак куйган жансакчылар кереп уяттылар.

Чатырлар киездән булса да, алар мең колаклы. Габдуллага, киенеп, күл буендагы яланга чыгарга туры килде. Әле жимешләре ямь-яшел көенчә утырган зур шомырт агачы төбендә ак күбеккә баткан бер ат тора. Янда—тиргә баткан йөзе тузанланып беткән чапкын. Шулай да таныды хан. Узган көздә үк әллә кайдагы Үзи елгасы*** буена, Кияү каласына**** шымчы итеп озатылган Даян мәргән бит бу.

Габдулла хан өлгер, житез атларга тырышып, якындагы калкулыкка таба китте. Даян—түрә сарайлары тирәсендә буталып шомарган таш, күләгә кебек тавышсыз-тынсыз гына аңа тагылырга мәжбүр булды. Калкулык түбәсенә менеп әйләнә-тирәгә күз йөгерткәч, Габдулла хан, гыжлавын басып, кыска гына дәште:

—Нинди утлы хәбәрләр төяп кайттың? Сөйлә, мәргән.

Даян калкулык өстенә ашыгып менүдән бигрәк ерак юллар үтә-үтә талчыккан иде, ахры. Кылыч кынына таянып, бөгелә төшебрәк сүз башлады.

—Утлы дип әйтәсең дә, Габдулла хан, юк, безнең өчен хәвефле яңалыклар юк шикелле. Шулай да, чапкын өчен алтмыш көнлек араны кырык көндә үтеп кайттым әле, менә.

Габдулла хан, мыскыллы елмаеп, бүләргә мәжбүр булды.

—Алай, артыңа ут капкандай чапкач, сәбәбе бардыр инде.

Даян житдиләнде.

—Игорь кенәзне үтереп ташладылар анда. Древляннар. Ике каен агачына бәйләп урталай аерганнар.

Габдулла ханның ияге олы бияләй шикелле салынып төште, борын өстенә жыелган куе кашлары астында ике күзе ялык-йолык килде.

—Ке-нәз-не-е? Игорь кенәзне-е-ме-е? Нич-чек инде үтереп? Ул якын-тирәдәге ничәмә-ничә кенәзне үзенә буйсындырды. Безнечә әйтсән, Игорь аларның ханы лабаса ул.

Габдулла калтыранды, ә Даян мәргән бу өшәнү-шомнарны юлда кайтканда ук коеп калдырган, күрәсең, кабак төше ярган шикелле генә, жинел дәвам итте.

—Ханын хан, мәгәр менә анын да башын тотып ашаганнар бит әле. Дөресен әйткәндә, үз башына үзе житкән инде. Нәфес, нәфес, бүтән берни түгел.

---

* Алпар – тоташ тимер көбәгә төренгән сугышчы, рыцарь.
** Гази – сугышчы, угълан — ныклы коралланган жайдак.
*** Үзи елгасы – Днепр.
**** Кияү каласы – Киев.

Габдулла кырысланды, тешләре шак-шок килде.

—Дилбегәнне кыскарт. Кайда, нигә үтергәннәр аны?

—Игорь салым жыярга чыккан. Дружинасы белән. Нигә шәхсән үзе жыярга алынгандыр инде, анысын Ходай тәгалә үзе генә белә. Бәлки, боярларына ышанып житмәгәндер... —Даян мәргән каш астыннан гына ханга күз ташлады, тегесенен йөзе үзгәрешсез иде.—Древляннар дип аталган кабиләгә барган. Тегеләр карышмыйча, күпме тиеш, шулкадәрле салым биреп озатканнар моны. Күрәчәктер инде, кайтыр юлнын яртысына житкәч тукталган бит Игорь. Болар салымны бик тиз жыеп бирде, мин болардан аз алганмын икән, дип хафага ук төшкән. Аннары ярты дружинасын салым төягән олаулар белән Киевка озаткан да, үзе кире киткән. Древляннар Коростень дигән кала эченә кереп бикләнгәннәр. Кенәзләре котырта башлаган: "Бүре көтүгә бер ияләшсә, барча сарыкларны талап бетермичә тынмаячак",—дигән. Шуннан сон древляннар Киев дружинасы өстенә ташланганнар да барча газиләрне кырып бетергәннәр. Ә Игорьнын үзен ике яшь каенга бәйләп урталай аерганнар.*

Даян сөйләүдән туктады, ә Габдулла ханнын йөзе балавыз шикелле катып калган иде. Авызына вак таш капканмыни, бер сүз дәшми. Анын йөзеннән-кыяфәтеннән һични анларлык түгел. Ул бу жиһаннан бөтенләй аерылган, чонгыл эченә кереп чумган сыман. Зиһенендә, күнел түрендә генә буран кайный.

"Ә мин салымны болгарлардан бик күп талыйм микән? Сабанчылар белән һөнәрчеләр еллык табышларынын уннан бер өлешен мина биреп бара. Сәүдә юлын таптаучылар белән аерым хисап. Тагын... мөселманнар мәчетләргә гошер сәдакасы түли. Шул ук сабанчы белән һөнәрчеләрне яна кала, яна кирмәннәр төзелешенә куалыйлар. Яуны-фәләнне искә алмасан, башка төрле талау юк та бугай. Шул, безнен дингә күчмәгән кара чирмешләргә генә икеләтә салым түләтәм мин. Кыз-зык, кара чирмешләр мине дә шулай, каен ботагына тотып асар иде микән?"

Габдулла хан жиһанга әйләнеп кайтты шикелле, таш чәйнәгәндәге сыман чытырдавык тавышы янгырады.

—Ә син мина моны хәбәр итәр өчен генә кайтмагансындыр ла инде. Жан-фәрман чабулап. Алтмыш көнлек юлны кырык көндә үтеп. Йә, ачып сал, сандыгында нинди еланнар бар тагын?

—Анын калганнары да безнен өчен зыянга түгел бугай,—диде Даян үпкә белдермичә.—Әгәр үгезләр үзара сөзешә башлый икән, сыерлар ял итә. Киев тәхетенә утырырга тиешле Святослав бик яшь, хәзер анын урынына дилбегәне мәрхүм Игорьнын хатыны Ольга үз кулына алган. Ана башка каладагы кенәзләрнен күндәмлек күрсәтеп, бил бөгеп яшәүләре бик икеле. Бүген булмаса, иртәгә баш күтәрә, үзара суеша башлаулары мөмкин.

Габдулла хан калкулыктан бөтенләй читкә, Менказ күле буендагы чатырларга карап тора иде. Янә кырыс тавышы ишетелде.

—Кияү каласындагы байлар, баярлар ул Үлгәгә бер дә терәк-мазар булырлык түгелмени? Ахыр чиктә, дыружинасы диден бит әле, газиләре инде, шулар ни кылмакчы була?

—Бөтен галәмәт тә шунда. Киевтагы байлар да, дружина да тоташы белән Ольга ягында. Дөрес, хак булса, дружинанын сәрдәре Свенельд инде күптән Ольга белән ятак бүлешә, диләр. Очкынсыз гына төтен булмый калмас, Свенельд хәзер Киевтагы ин бай бояр. Ничек кенә булмасын, ире Игорь жыеп калдырган бар салымны төяп, Ольга хәзерләр пайтәхетенә озаттырган, диләр.

---

* 945 елда булган вакыйга.

—Һе-һе! Оста хатын бу. Манас каханны сатып алырга җыенадыр инде.

Габдулланың тавышы бу юлы коры ботак-сатак сынган сыман чытырдап һәм зәһәр яңгыраса да, Даян дәртен кузгатмыйча гына янә тезде.

—Юк, бер дә Манасий каханны сатып алырга җыенмый ул хатын. Миңа Ольга дружинасына ялланган ике угыз сатты. Әтилдә кенәзләрдән качып киткән урыслар бик күп икән. Алар хәзер пайтәхеттә менәр-менәр исәпләнә, диләр. Әтилне үземнең барып күргәнем юк бит. Анда урыслар аерым бистә корып урнашкан, ди. Ольга Киевта тупланган салымны менә шушы качак урысларны сатып алыр өчен озаттырган. Алар Әтилдә фетнә күтәрсен һәм яһүди Манасий каханны алып атсын өчен.

—Әт-тәт-тәт-тә!—дип сузып торды Габдулла хан, үз колакларына үзе ышанмыйча.—Оста гына түгел, елан бит бу!.. Әмма... әмма...

Габдулла хан бермәлгә тукталып калды. Чигәләрен, мангаен бармаклары белән угалады. Даян ягына борылып баскан чакта йөзе инде җитди, уйчан иде.

—Әле кырык көнлек юлдан кайткан гына булсаң да, тагын ияргә менәргә туры килә сиңа, ачуланма, мәргән. Син салырга өлгергән сукмакларны, син үтеп керә алган куыш-ярыкларны беркем белми. Таныш-белешләрең дә инде җитәрлектер. Синең яңадан пәйда булуың да беркемдә шик уятмый. Шуңа күрә, бар, вәзир янына кереп, үзеңә җитәрлек алтын-көмеш ал да яңа баштан Кияү каласына, ул елан хатын янына кит инде син. Кирәк икән, кәләш тап үзеңә, гаилә кор. Ләкин ятла. Урыс пайтәхетенең үзәгендә яткан чакта сине бер йөз, бер мең газиләр дә алыштыра алмый. Бөтен Болгар мәмләкәтенең күзе-колагы син.

Даян җавап итеп бер сүз эндәшмәде. Күренеп тора, тагын ерак юлга, чит-ят җиргә чыгып китәргә күңелендә дәрт-дәрман юк иде. Габдулла хан шуны сизеп алды, күрәсең, калкулык түбәсенә менеп Даян мәргәнне кочагына кысты.

—Мәмләкәтебез иминлеге өчен, Болгар өчен шулай кирәк, мәргән, үпкәләмә миңа. Вакыт җитәр, кайтарырбыз сине. Ышан, кайтарырбыз...

Даян, атлый-юырта дигәндәй, аска томырылды. Бераздан аның армас аргамагы янә Биләр юлы буйлап тузан болыты туздырып чаба иде. Габдулла хан аны агачлар, ерымнар эченә тәмам кереп югалганчы күзәтеп торды да калкулык түбәсенә чүгәләп уйга калды.

Кияү каласының ханбикәсе Әтилдәге урысларны фетнәгә күтәрергә әзерләнә диген. Димәк, Манас кахан тырнагы астыннан чыгарга, салым түләүдән туктарга, аңа баш иеп яшәүдән котылырга җыена инде бу. Каханнан бәйсез булырга җыена, азат дәүләт төзергә хыяллана. Хатын башы белән. Хатын башы белән! Ә соң Габдулла хан бәйсез булырга хыялланмыймыни? Салым түләп, газизләрдән-газиз кызын кырнаклыкка биреп, тез өстенә чүгеп яшәү аңа рәхәтмени? Бу коллыктан, бу хурлыктан ничек котылырга соң?

Менә, урыс ханбикәсе үз кенәзләреннән качкан илдәшләренә таянмакчы була. Ә Хәзәр җирендә болгарлар урысларга караганда биш мәртәбә, ун мәртәбә күбрәк. Андагы пайтәхет Әтил үзе генә дә яртылашы белән болгарлардан тора. Манас кахан—Әтилнең унъяк ярында, ә болгарлар—сулда. Кахан үзенең сараен гына ак кирпечтән төзеткән. Ул унъяк ярда башка бер генә байга да, чит-ят кавемгә дә андый кирмән-йортлар төзергә рөхсәт итми. Аның каравы, сулъяк ярда болгарлар рәхәтләнә. Габдулланың аманат* илтергә, каханга ант китерергә дип пайтәхеткә кат-кат барганы бар. Берочтан дип, бөтен Әтил урамнарын айкап чыкканы бар. Хәзәр

*Аманат—улыңны, йә кызыңны тотык итеп озату мәгънәсендә.

башкаласы, яһүдиләр үзәге булып саналса да, Әтилдәге мәчетләр утызга житеп килә. Өстәвенә, сулъяк ярдагы каланың нәкъ үзәк өлешендә дүрт манаралы Жәмигъ мәчете дә бар. Хак булса, хәзер Әтилдәге болгарларның саны егерме меңләп исәпләнә, диләр. Тукта, нигә шушы хәтле көчне Болгар файдасына, ислам файдасына кулланмаска әле? Урыс ханбикәсе анда үз качакларын фетнә күтәрергә әзерли икән, нигә әле ана кушылмаска? Чит кавемме-түгелме, без икебез дә бер як ярга, азатлыкка таба йөзәбез бит!..

Әйе, әйе, сак булырга кирәк. Яһүдләр бик мәкерле. Габдулла ханның авызы былтыр яман пеште инде. Ничек итеп төп башына утырттылар, бакчы? Габдулла барча кабиләләрдән бердәм курсыбай* оештыра башлагач, бәрәнжәрләрнеке дигән булып, яһүдигә күчкән Балак атлы газине озатканнар. Карап торышка гап-гади бер бәрәнжәр инде, аның асыл динен-фигылен кем казыган? Иллә мәгәр гади генә кеше булып чыкмады бу. Мәргәннәр бәйгесе-фәлән оештырдыңмы, бу гел алда. Ат чабышы кузгатасың икән, янә барча бүләк-санак ана. Өстәвенә, юха. Икмәк белән әвеш-тәвеш сатып ятканга Борак сәрдәр өстенә баскан иде, акланып йә карышып бер сүз әйтми. Шуңа аны Габдулла үзе йөзбаш итеп куйды. Кеше үз гаебен таный, өмете бар, янәсе. Шул, тагын да ышанычны акласын дип, Габдулла аны бортасларның иң олы каласы Бәнжәгә юл жибәрде.

—Бар, Бәнжәнең сакланышын тикшер. Бортаслар корсак киптереп ятсалар, кулга төшерәбез.

Ә Балак атна-ун көннән әйләнеп кайтты да сайрапмы-сайрый! Теле телгә йокмый юха еланның.

—Бәнжәдә бер генә йөз дә сугышчы калмаган. Барысы да Жаек аръягында, кара аймыкларга каршы яуда йөри...

Габдулла хан өстәмә иравыл да озатып маташмады, ике меңләп кенә гази туплады да шундук юлга чыкты. Артларына ут капкандай, алны-ялны белми чаптырдылар. "Каудар эшкә шайтан катыша" диләр, хак, күрәсең.

Бәнжә диварлары аларны унбиш-егермеләп тоткавыллар** белән генә каршы алды. Шәһәрне үләт давылы кырып чыккан диярсең, эчке якта һичбер тавыш, һичбер хәрәкәт юк. Габдулла хан майлы калжа өмет итеп иссрде, күрәсең, алдын-артын карап тормый-нитми бар нөгәрен диварга ташлаттырды. Ялтыравык тәти күргән бала-чагамыни, хәтта үзе дә читтә калмады бит, сантый. Ә бортаслар шуны гына көтеп торган икән. Болгарлар кырмыска күче шикелле булып имән диварларны сырып алуга ук капкалар ачылды да, Бәнжә эченнән буар еланнан да гайрәтлерәк ташкын бәреп чыкты. Болгарлар башына күсәк белән сугып миңгерәтелгән мал сыман өерелеп артка таба ташланганнар иде, ерымнар эченнән тагын бүре көтүенә охшаган чылбыр калыкты. Бортаслар нәфселәрен тыя белмәгән болгарларны уртага алып, чүпрәк карачкы урынына дөмбәсләп һәм изеп киңәнделәр генә!

Габдулла ханның күзләре юха елан Балакта гына иде. Шәһәр капкаларыннан буар елан килеп чыгуга ук алар ягына таярга омтылды ул. Алданган хан күрде: карашында, ирен читләрендә зәһәр мәкерле тантана, бетмәс-төкәнмәс нәфрәт һәм үч чагыла иде сатлык жанның.

—Качма, жасус*** соран!****—дип кычкырып Габдулла хан аның артыннан томырылган иде, кемдер аның муенына арттан күсәк белән орды...

Хан аңына килгәннән соң гына сораштырып белде. Аны чолганыштан Борак сәрдәр, иярен аркылы салып кына алып чыккан икән...

---

* Курсыбай—шәхси гвардия.
** Тоткавыл—тышкы сакчы, капка сакчысы.
*** Жасус—шымчы.
**** Соран—хамелеон.

### 3

Өченче көнне таңда Кораса аръягындагы Кырыкнарат урманына төбәп юл тоттылар. Камышлы күлләре, көмештәй ак сулы чишмәләре белән танылган як. Монда ат тоягы баткан һәр түмгәк астыннан яңа чишмә тибеп чыга, диләр.

Габдулла хан юлга кузгалгач та әмирләрне үз янына чакырып күңел серен ачты.

—Әтил каласында урыс качаклары олы фетнә куптарырга әзерләнә икән. Чит кабилә, чит-ят халык вәкилләре булсалар да, фетнәләре безнең файдага. Мәгәр алар бик аз, Манас каханны чәнчелдереп төшерә алулары бик икеле. Аларга Әтилдәге безнең болгарларны да кушсак начар булмас иде. Анда болгарларны авызына каратып тора торган Мөкътәсир бәгебез бар. Аллага шөкер, андагы Асаф сәет тә яшерен хөтбәләрен Болгар иленә багышлап, безгә азат тормыш тели-тели укый. Алардан кала Әтилдә тагын һөнәркяннарны, сәүдә кәрванын йөртүчеләрне үз учларында тота торган Гали бәк, Рәшит бәк, Күчем бәкләребез дә бар бит әле. Алар янына үгетчеләр җибәрсәк, бәкләргә ияреп, Әтилдәге барча болгар кузгалыр дип уйлыйм. Ә сез нинди рәк фикердә? Безгә дә каханның туймас корсагына көтү-көтү мал озатып ятудан туктарга вакыттыр бит?

Гаҗәп, шаккатмалы! Хаммат белән Сәлман әмир—икесе тиң Талиб тарафына күз ташлады. Ә Ялкын әмир сорауларны бөтенләй дә ишетмәгән сыман ияренә текәлеп бара бирде. Таҗдар күңелендә шом кузгалды, Талиб җавап тотты.

—Вакыт, күптән вакыт инде, Габдулла... хан. Син үз кызың Бәнатны кахан хәрәменә аманат итеп озаттың, минем Саҗидә шунда. Әнә, Хаммат, Ялкын, Сәлман әмирләрнең—һәммәсенең балалары шунда. Шуларны уйлаган саен йөрәктән кан тама... Янә килеп, көз житте исә, көтү-көтү итеп мал куабыз. Салым җыя башлаган саен кара гавам елый. Житәр, мондый хурлыкларга тагын күпме түзмәк кирәк? Бәләкәй эт гомер буе көчек хисабында йөри, диләр. Тешләп күрсәтмәсә, аның эт икәнен кем белсен ди? Бәйдән ычкынырга вакыт инде безгә, вакыт, вакыт...

Габдулла хан һәрбер төге белән тоеп барды. Талиб Шәмси суар гына түгел, барча кабиләләр исеменнән җебегәнлектә, күндәмлектә гаепләргә маташа бит аны. Имеш, син аумакай, Манас каханга азау тешеңне күрсәтерлек тә егәрең юк. Имеш, син кузгаткан яулар гел уңышсыз чыга. Былтыр Бәнҗәдә борын канатып кайтуың шуңа ачык мисал. Имеш, үз илеңне талый-талый син Манас кахан алдында һаман тәлинкә тотачаксың әле. Чөнки сиңа, ярты-йортымы ул, черекме ул, тәхет кенә кирәк... Шулай уйлый, шул рәвешчә кыздырасы килә, әйтеп кенә бетерми бит Талиб. Ә бәлки... бәлки әле башкалар да аны хуплыйлардыр. Авызларына су капкандай дәшми барулары шуны раслый сыман. Габдулла хан ачуын эченә йотып сүзне тәмамларга мәҗбүр булды...

Баткак ялангдагы Дөя күзе дигән күл буена житкәч икегә бүленделәр.

—Монда кабан, җәйран мыжгып тора,—дип шапырынды Борак. Ул, чыннан да, балачактан бирле урман белән ау юлында аунап үскән кеше.—Авыз ачып йөрсәң, әле барс өстенә дә килеп чыгуың бар, вах-ха-ха-ха!

Борак күгәрчен боты чаклы эре тешләрен ыржайтып, башын дөя сыман югарыга чөеп шулай шаркылдады. И-и, беркатлы алабай да инде!

Сакчыларны, ук атарга кыжрап килгән ат караучыларны күлнең таллар, гөлҗимеш, балан, карлыган куаклары каплаган башына җибәрделәр.

—Сез шул яктан чаң сугып килерсез, без камышлар арасына кереп утырабыз.

Габдулла хан күнелендә әллә шик уянды, әллә беркем дә күз алдына китерә алмастай хәйлә-ният корды, ул талгын гына тавыш белән улы Мөхәммәткә әмер бирде.

—Боларның елгырлыгына ышануы кыен. Әйдә, син шул нөгәргә баш бул әле, улым...

Бәла бер дә көтелмәгән яктан килеп чыкты. Берзаманны Габдулла ханның тулпары Борындык әллә нигә генә кәҗәли башлады да уйнаклый-уйнаклый камышлык эченә очып барып керде. Аның артыннан фәкать Борак кына берьялгызы элдереп килеп житте. Ә бәкләр-әмирләр төркеме алты-жиде дилбегә буена артта калган иде.

Менә шул мизгелдә суга ятып торган камышлар арасыннан тана хәтле иләмсез зур гәүдәле кабан килеп чыкты. Әллә балалары белән шунда качып яткан инде, әллә сөяркәсе белән шаярган чак булган—аны кемнәр белсен? Әмма күренеп тора, үзен бимазалап йөргәнгә ярсыган бу. Күзләрен кан баскан, аяклары белән чирәмне бияләй чаклы итеп умырып, күккә алып чөя. Ә авыз читеннән ике якка чыгып тырпайган казык тешләре үткен хәнжәр кебек!

Габдулла хан төртеп уяткан шикелле кабаланып Борындыкның касыгына тибеп карады, теге талпына-чәбәләнә, ләкин арткы аякларын тартып ала алмый. Баткак төшкә туры килгән икән, инде тубыкка чаклы саз эченә баткан. Габдулла хан кабан күзләренә текәлде дә катты. Кабан да жайлы, очсыз корбан таптым, диебрәк сөенгәндер инде, канлы, усал карашы белән гел Габдулланың йөзен генә мөшкәдә тотып тора. Күз алышы башлангач та таждарның зиһенен фәкать бер генә уй яшен шикелле яндырып-телеп узды: "Тәкъдир дигәннәре шушы микәнни соң?"

Борак бәлагә тарган ханның хәлен аңлап-чамалап өлгергәндер инде, камчысы белән кизәнеп-котырынып Борындыкның арт санына сукты.

—На-а, муеның асты-өскә килгере жан!

Борындык жәйрән шикелле капылт сикерде дә сазлык тырнагыннан котылып чыкты. Коры жиргә баскач бик гайрәтләнеп урыннан купкан иде, качып өлгермәде. Бүредән дә әшәкерәк булып котырынган кабан хәнжәр төсле казыклары белән Борындыкның корсагын ярып узды. Габдулла хан капылт алгы сыйракларына тезләнгән ат өстеннән чирәмлеккә очты. Ул аякларына күтәрелеп, кылычын кулына алып өлгергәнче кабан аны да сытып узган иде инде...

Кул сузымында гына калган бәк һәм әмирләр һәммәсен дә күреп тордылар. Алар ярдәмгә ташланган минутта Борак сәрдәр кабанны да икегә ярып салган һәм хәзер инде Габдулла ханның жансыз гәүдәсе каршына тезләнеп баскан иде. Әмир Талиб иярендә утырган көе менә шул мизгелдә аның муенына чукмар белән орды. Өшәнеп калган бәкләр аңа төбәлгән чакта әмирнең усал кысылган иреннәре арасыннан санаулы гына мыскыллы, зәһәр сүзләр сытылып чыкты.

—Ат хәтле атка кул күтәрде, игелексез бәндә!..

## 4

Талибны шушында, Дөя күзе күле буенда ук ак киез өстенә күтәрделәр. Ушсыз-аңсыз калган Мөхәммәт тә аңа ант китерде.

—Сине искил, бәрәнжәр, суар кабиләләренең әмирләре Болгар мәмләкәтенең ханы итеп таный. Мин дә барсил кабиләсе исеменнән сиңа ант китерәм.

—Ә биләрләр?—диде, ярсып, канат жибәргән хан.

—Биләр—энекәшем Ваһап кулында бит. Мәркәзгә кайтуга ук, дивар тышына чакырып аны үзем үгетләрмен. Үзара кан коеп дошманнарны сөендереп булмас...

Талиб сарайга әнә шулай итеп, тавыш-тынсыз гына үтеп керде. Боракны кулларына-аякларына богау кидереп, кол рәвешендә алып кайтканнар иде. Ансат җиңүдән акылын җуйган Талиб мондый гына түбәнсетүләрне дә азсынды, күрәсең. Борак бөтенләй сынсын, урамга чыгып күренерлеге калмасын, дигәндер инде, яңа әмер бирде.

—Борак ат хәтле атны әрәм итте бит. Борындыкның йөгәне белән ияре хуҗасыз көе калды. Хәзер кая куйыйк? Әйдә, аларны Боракның үзенә кидереп урамнарны әйләнегез әле.

Шул минутта ук кичәге сәрдәргә йөгән белән ияр кидерделәр дә, камчы белән яра-яра урам буйлап куалап йөрттеләр. Аннары, шул ияре белән йөгәнен дә салдырып тормыйча, кое шикелле зинданга ыргыттылар. Һаман да шул сарай тарафыннан әмер булды микән, пәһлевандай гәүдәле Боракка сыңар телем икмәк тә кертеп бирүче кеше табылмады. Аның каравы, зиндан авызыннан кочак-кочак печән ташладылар. Талиб Шәмси Суар каласыннан китерткән шыгавыллар* ихахайлап көлде.

—Син хәзер Борак түгел, тулпар Борындык бит. Ияр тагып йөри белгәнсең икән, печәнен дә аша...

Кичә бөтен мәмләкәтне үз кулында тоткан гаярь сәрдәр зинданның балчык идәнендә коры сөяккә калып, кибеп вафат булды. Ул җан биргәнне ишеткәч кенә чышан-пышан килеп хәбәр кузгаттылар:

—Талиб Дөя күзе дигән күл буенда әле Габдулла хан әрәм булганчы ук түнтәреш әзерләгән. Шуннан алдагы төндә, Талиб башка әмирләрне чакырып сөйләшкән чакта, Борак сәрдәр бер үзе генә бу явызга каршы төшкән икән...

Тәхетне эләктереп алган Талиб исә кайчандыр ил терәге булып торган Борак турында баш ватудан бөтенләй туктаган, ул хәзер күл буенда чакта әле исән көе Габдулла хан әйтеп калдырган уй-фикерләр эчендә яна иде. "Әтилдә урыс качаклары фетнә әзерлиләр. Чапкын җибәреп Манас каханны кисәтергә кирәк. Үзенә тугры булган этне барча хуҗа сөя. Мин тугрылык күрсәтсәм, Манас кахан бәһаләми калмас".

Ләкин Талиб ханны эчтән һаман да шул яхшысынмау, умырткасызлык, икеләнү, шөбһәләнү дигән кортлар талады да ул бу ниятен ай буена суздьі. "Болгарларга, хәтта суарларның берәрсенә әйтсәм дә, моның соңыннан тишелеп чыгуы бар. Йә ул чапкынны мәкер белән юк итәсе була. Кул астында гына андый катил дә юк. Йә тегесенә, йә монысына кемне табасы соң?"

Яңа хан, ниһаять, тәвәккәлләп, үз янына ил сатлыгы булып танылган Балакны чакырттырып алды. Балак—майга буяп ташласаң эт яламастай шакшы бәндә, ләкин ул, ни генә әйтсәң дә, мәрхүм Габдулла хан дошманы. Ә дошманының дошманы, гадәттә, сиңа дус була.

Балак—кыйбат, затлы умырткалы кеше түгел, бик тиз ризалашты. Талиб чапкыны булып ияргә бик тиз сикереп менсә дә, Әтилгә барып җиткәнче ул соңарган, Хәзәр каханлыгында Болгар ханыннан башка сатлыклар да табылган иде инде. Чапкын булып барган Балак Әтилгә керүгә үк өстенә кайнар су койгандай куырылып калды. Болгарлар бистәсендәге байтак йортлар өстендә янгын уйный, җитмәсә, урам буйлап кахан сараена таба бер-берсенә бау-арканнар белән бәйләп тагылган мәхбүсләрне сыер көтүе урынына куалыйлар иде.

---

* Шыгавыл – эчке сакчы, сарай сакчылары.

—Манасий кахан яшерен фирка ачкан. Әтилдә, каханның борын төбендә, йөзәрләгән хыянәтче бәндә елан сыман качып яткан икән. Болгарлардагы Мөкътәсир бәк белән урыс Демьян Манасий каханга каршы фетнә әзерләгән. Бүген кичен аларның икесен тин сарай мәйданында дарга асалар, ди.

Чапкын Балак кичкә хәтле көтте. Чынында, Мөкътәсир бәк белән Демьянның икесен дә асып үтерделәр. Мәхбүс итеп алынган башка болгарлар һәм урыслар Үргәнеч базарына сатарга озатылды.

Балак өчен боларны манзара кылу гына берни бирмәс иде. Сарай тирәсендәге сакчылар арасында иснәнеп йөргән чакта жанын җылытырлык сүз ишетте.

—Мөкътәсир бәкнең ундүртме-унбишме яшьлек Айсылу атлы бик тә чибәр кызы булган икән. Кахан Мөкътәсиргә: “Шул кызыңны хатынлыкка бирсәң гафу итәм”,—дип әйтеп тә караган. Бәк сынмаган. Мөкътәсирнең кызы хәзер юкка чыккан, ә кахан аны бик нык юллата, ди. Кем дә кем табып китерә, кахан шуна бер мең динар кадәресе алтын бирә икән...

Биләргә әйләнеп кайткач Балак бер меңне биш меңгә чаклы камыр сыман күпертеп караса да, Талиб хан тәхетеннән тәгәрәп төшмәде шул. Аны хәзер яна кайгы баскан, Зөя буенда утырган Тигәнәш кирмәнен бортас чирүе җимереп киткән икән.

“Шулай, тәхетне эләктереп алу—әзергә-бәзер жигелгән арбага сикереп менү генә түгел ул,—дип уйлады сатлык Балак, эченнән генә каһкаһә белән көлеп.—Хуҗа камытын караклык белән каптыргансың икән, киләсез өй эчендәге шикелле, теләсә кайсы почмакта шылт иткән тавышка да колак салып яшисең бар әле”.

Ләкин берәр кирмәнсез калу Талиб өчен корт чагу кебек тә булмагандыр ахрысы, бер дә кара кайгыга батырга җыенмады. Киресенчә, мәмләкәттәге хәятне ал да гөл итеп күрсәтергә маташуыдыр инде, ай үттеме, яна төрле бәйрәм уйлап таба. Тәүге кар ятуга бар Чирмешән ярын тутырып каз өмәсе оештырган иде, салкыннар зәһәрләнә башлауга бөтен Биләр өчен бердәм фәрман игълан иттеләр:

—Талиб хан дошманнарга каршы яу әзерли. Шуна күрә Алтын капка каршындагы кырда боздан ясап чып-чын кирмән-кала торгызырга! Чирүне икегә бүлеп, ханиябез шунда хәрби күнекмәләр, бәрелеш үткәрәчәк.

Ярты шәһәр халкы алмаш-тилмәш килеп ялан кырда ике-өч атна буена “кала” төзеп ятты. Ханның “бәрелеше” бик тә яман булачактыр инде, гаскәриләр биреп, Кашан тарафына салымчы-казанчыларның яна нөгәрләрен чыгарып җибәрделәр. “Озынколак” бу гамәлнең асылын да бик тиз гоман кылды:

—Дөя күзе дигән күл буенда Талибны Кашан әмире Ялкын бик үк якламаган. Талибны киезгә күтәргән чагында да ул берүзе читтә калган икән. Шуның өчен Талиб хәзер Кашанны талап үч кайтара, диләр.

Гоманлаулар дөреслеккә чыкты. Талиб Ялкын бәкне алып ташлаган да аның урынына Нур-Суардан чакырткан Нуретдинне әмир итеп утыртып та куйган. Яна хуҗа каршы килмәгәндер, хуплагандыр инде, казанчылар пайтәхеткә олау-олау салым төяп кайтты. Ул байлык-зиннәтләрне һаман да шул бозлы кала төзүгә ялланган яһүдиләргә, бортасларга чыгарып җилгәрделәр. Халык тагын астан гына сыкрап җавап бирде:

—Аһ, ул боз алачыкларына сине дә бикләп катырырга иде, ялкау мордар!..*

Талиб ыжлап та бирмәде, бозлы кала калкып чыгуга яна фәрман корды.

—Боз кирмәнен кырык кыздан торган нөгәр саклаячак. Болар өстенә,

* Мордар—юып булмас гонаһ кылган, гадәттә үз-үзенә кул салган кеше.

каланың аерым ханбикәсе дә була. Бәкләр вә морзалар! Олыслардан иң-иң чибәр кызларыгызны сайлап китерегез! Каланы иң якын яраннарым белән үзем яулап алам!

Тышта салкын көннәр дәвам итә иде, бозлы калага бер зыян да килмәде. Ә атна дигәндә Биләргә йомшак туннар өстеннән көмеш шайманнарга* төренгән сылу кызларны китереп җиткерделәр. Шуннан соң адәм ышанмаслык кәмит канат җәйде.

Боларны, кулларына чып-чын кылыч-җәя тоттырып, боз кирмән диварлары артына кертеп бастырдылар. Ханбикә киемнәренә төренгән япь-яшь кызый өчен келәмнәр түшәлгән, кайнар чәйнекләр тезелгән зур бүлмәдә чып-чын тәхетләргә кадәр әзерләнгән иде. Әмма бу яшь кызыйны әллә сөжү, әллә бал белән сыйлап өлгергәннәр инде, ул тәхеткә утырып та карамыйча кирмән буйлап әмер биреп йөрде.

—Диварга якынайса—кемнең кем булуына карап тормыйча, нәкъ яудагыча шикелле сугышасыз! Яудан ярасыз чыккан кызларны олугбәкләр хатынлыкка ала!

Сылу кызларның алда көткән мондый олы бүләкләр хакында ишеткәч акылларына зыян килде, диярсең—шашындылар... Талиб чакыруы буенча Суар каласыннан килеп курсыбай хәтле курсыбайда гази булып йөргән әзмәвердәй ир-егетләрне дә күз чалымына китереп тормадылар алар. Газиләрнең беренче дистәсе боз диварларга килеп җиткәнче үк сәрпи уктан** ауды. Аннары бер-бер артлы яңа дистәләр һөҗүмгә ябырылды. Артта Талиб ханның, әмирләрнең газиләрне кыздырып кычкырган авазлары кат-кат яңгырады.

—Кем ханбикәне беренче булып үбә, шуңа алтын очлым!

—Ханбикә бүлмәсенә үтеп керә алган газиләргә йөзәр динар алтын!

Уйнап башланган һөҗүмнәр чын сугышка күчте. Алапа*** хакына ялланган газиләр арасында да сантыйлар җитәрлек бит. Шулар кызган баштан җиде-сигез кызны турап ташладылар. Томан кебек чип-чиста, үтә күренмәле булып утырган диварлар кызыл канга батты. Кан исе һәм гарьләнү ачысы кызларны ярсытты, күрәсең, болар кылычлары белән унны-сулны күрми айкый башладылар. Диварлардан эре-эре боз кантарлары кубарылып очты. Кайсыдыр газинең сынар кулын чабып төшерделәр, икенчесе йөзен тотып ауды. Кылыч, сөңге очы тиеп җәрәхәтләнгән өчме-дүртме кызый, чыркылап кычкырып, боз диварлар арасында адашып чабып йөрде. Күренеп тора: тагын ике-өч чыра янып бетәрдәй арадан соң боз кирмән эчендәге орыш тукталачак иде. Шул вакытта кирмән каршына Талиб таждар үзе сикереп чыкты.

—Ханбикә үземә! Ханбикәне үзем тотып үбәм!

Уеннан уймак чыга күрмәсен тагын, дигәннәрдер инде, Талибның янъягына сукса үгезне егардай сакчылар тезелеп басты. Талиб әллә күрде боларны, әллә күз чалымына да китереп маташмады, болан сыман сикергәләп диварга ябырылды. Өсләренә кем килүен сизенделәр, ахры—бер-ике кыз чыркылап кычкырган булып читкә йөгереште. Икесе-өчесе, сизмәгәндә сикереп, Талиб ханны кочагына алды. Ләкин юк, ханның сайлаган корбаны болар гына түгел иде инде. Әле бер, әле икенче боз дивар артына сузылганда аның котырган үгез мөгрәвен хәтерләткән котсыз, усал тавышы яңгырап торды:

—Ханбикә кайда? Ханбикәне кая яшердегез? Ул кызыйны үзем тотып үбәм!

---

* Шайман—сугыш киемнәре.
** Сәрпи ук—тигез колаклы, еракка оча торган ук.
*** Алапа—хәрбиләргә түләнә торган хезмәт хакы.

Ниһаять, Талибны чәйнекләр пар бөркеп утырган бүлмәгә этәрделәр. Хан тун изүләрен аера-аера килеп керде дә, тәхеттә утырган чибәр кызны йолкып келәмнәр өстенә сузып салды. Әүвәл талпан сыман кадалып кызның иреннәренә генә ябышкан иде дә, кыргыйлыгы кузгалып китте бугай. Икенче минутта ул инде янда дистәләгән сакчылары барлыгын да онытып, “ханбикә”нең итәкләрен ачып салды...

5

Нәүрүз бәйрәменнән соң Каргатуй, икенче ай ахырында ук Сабантуй үткәргән иде дә, чәчү беткәнен, җыен тантанасын көтеп җиткерергә түземлеге калмады. Шомыртлар, чия, алмагачлар шау чәчәккә күмелүгә үк Талиб колак ишетмәгән “Кызлар туе” дигән бәйрәм уйлап тапты. Монысында күренекле байларның кияүгә бирердәй булып җитлеккән кызлары гына түгел, бәкләр, морзалар, кибет тотучылар, кәрван йөртүчеләр, алачыкка хуҗа һөнәрчеләр үзләре да катнашырга тиеш була икән. Байлар сыкрый-сыкрый олаулар төяделәр, “озынколак” үзенчә фаш итте:

—Бу бәйрәмнең дә гайре кыргый бернинди мөгезе юк. Ялкау Талиб үзенең ятагына яна жарияләр сайлый, шуңа өстәп байлык җыя.

Талиб билгеләгән көндә Биләрдән егерме чакрымдагы Корүзәнгә чатырлар, тирмәләр куя-куя килеп урнаштылар. Минлебакир читкә тибелгәннән соң вәзир булып йөргән Һашим беренче мәҗлескә җыелуга ук игълан итте:

—Туй кадәр туйга әзерләнгән чакта пайтәхет казнасына өлеш чыгармау бер дә савап түгел. Моннан ары җиткән кызларыгыз өчен дә, башка чыгарга җыенган улларыгыз өчен дә салым түләячәксез.

—Имәндә икән чикләвек!—диде һәркайсы эчтән генә.—Болай барса, Талиб-бирән озакламый бездән тәһарәт алган өчен дә салым-ясак түләтәчәк икән.

Телен тыя белмәүчеләр, беркатлылар умарта оясына бикләнгән корт күче шикелле бызылдаган булды, авыз эченнән генә быж-быж килде. Ә асылда исә Корүзәнгә төшкән һичбер кеше халык алдына чыгып гауга күтәрмәде. Һашим аваз салгач, һәммәсе дә олау тутырып килгән зиннәтләрен аның чатырына шыпан-шыпан гына илтеп аудардылар.

Кичен Корүзәнне йөзәрләгән учак каплап алды, күктә тулган ай елмайды. Барча халыкны яланга эндәштеләр. Боландай булып җитлеккән кызлар арасында су тулы чиләкләрне күтәреп узыш оештырылды.

—Беренче булып килгән кызга саф көмештән очлым!—дип кычкырды яп-яшь кызлар күргәч ярсып купкан Талиб.

Үз байлыгы белән сату итә диярсең, Һашим өстәп куйды.

—Икенче булып килгән сылукайга көянтәсен алтын кайма белән үзем бизәп бирәм!

Бәйгедә катнашучыларның әтиләре-әниләре еракка, Корүзәннең Киндер күле буена тезелешеп утырган, ә якында гына анга килергә чакыручы, тыючы-нитүче юк. Яп-яшь кызлар шашындылар инде. Көянтәләренә чиләкләр элделәр дә ак-караны күрми чабышалар. Чаяраклары кеше алды дип тормый, кычкырыша хәтта.

—Син көянтәңне иңбашыңа куймый йөгерәсең!

—Синең суың яртылаш түгелеп бетте, хәрәмләшмә алай!

Ахырда Җүкәтаудан килгән сәүдәгәр Мирасның чем-кара чәчле кызы Сания җинеп чыкты. Икенче урын Ашлы кибетчесе Нурисламның кызы

Мәһитапка булды. Кызларның үзләреннән бигрәк әти-әниләре хан кулыннан бүләк көтә иде. Хыяллары белән җиде кат болыт өстенә менеп киткән бичараларны утлы хәбәр салып җиргә төшерделәр:

—Хан кызларыгызга бүләкләрне үзенең чатырына чакырып өләшәчәк. Ханның алар белән әле манзара-гәп корып утырасы да бар. Комачаулап йөрмәгез, сез кайтыгыз...

Хан бу төндә берьюлы ике яшь кыз белән истирәхәт кичте...

Танда чатыр-тирмәләргә Талиб ханның яңа "мөгезен" илтеп җиткерделәр.

—Барча кызлар өчен ат чабышы була. Бәйгедә хан үзе дә катнашачак. Ханны узган чаптар иясенә саф алтыннан көбә!

Янә барча кызлар котырынып купты. Ханга ничек ярарга белми йөдәгән әллә ничаклы ир көмеш аелларын, көбәләрен, чатырларын сатып яна чаптар алды. Зиһен шөрепләре бушаган дистәләгән ана мич пумаласы да куркып качардай ямьсез кызларының чәчләрен кырыкмаса-кырык толым итеп үрде, иреннәрен, йөзләрен, кашларын иннек, сөрмә, кершәннәргә манды.

Киндер күле тирәли узачак бәйге сызыгына йөзәрләгән чапкын тезелеште. Болгар кызлары ат күрмәгән кыргый бәндә түгел, вәзир Һашим кызыл яулык болгап хәбәр салуга ук житез элдерделәр. Сүз дә юк, Талиб хан иярләп алган байтал* сәрпи ук та куып җитә алмаслык гаярь тулпар иде. Шуны белгәнгә күрә Талиб әүвәл былагайланып, юри атын тыя-тыя барды. Иң беренче булып алга чыккан кыздан ярты күл чамасы артка калгач кына байталның касыкларын искә төшерде ул. Ирек куйгач, Байталга да канат чыкты бугай, лачын сыман бөгәрләнеп алга томырылды. Менә, беренче төркемне узып китте Талиб. Менә, бүре көтүе шикелле өерелеп чапкан икенче төркем арасына килеп керде. Байтал тагын бер ыргылса боларны да куып узачак һәм иң алдагы тулпар эзеннән элдерәчәк иде.

Талиб яна төркем эчендә очып барган чакта гайре табигый бер хәл килеп туды. Күзләрен генә ачык калдырып, йөзен-кашын яулыкка төргән бер кыз әүвәл ханның үз янәшәсенә килеп басуын көтеп-шәйләп барды. Ә Талиб аңа кул сузымы ара якынлашуга, кыз кизәнеп торып камчысы белән ярсыган байталның мангаена сукты. Байтал көтелмәгән чокырга килеп эләккән сыман шундук алгы аякларына тезләнде, Талиб аның башы аша җир өстенә очты. Икенче мизгелдә җайдак кызый аргамагын дала ягына борды. Һавада ул ачыргаланып-ярсып кычкырган тавыш яңгырап калды.

—Менә сиңа көмеш очлым өчен! Менә сиңа бүгенге төн өчен!..

Талиб ханның умырткасы сынган булып чыкты. Интегә-интегә, газапланып кына җан бирде ул. Соңгы сүзен аны тирәләп баскан күпләр ишеттеләр.

—Саниядан, берүк, үч алмагыз. Аның гаебе юк...

## 6

Әмир Мөхәммәт бу минутта Корүзәннән бөтенләй бик еракта, Кәлтә елгасы буендагы биек тау башында басып тора иде. Бүген ул монда зур сынау үткәрә.

Аста үзән. Мөхәммәт әүвәл шунын түмгәк булып утырган бер җиренә хәнҗәр көйләп куйды. Үткен йөзен күккә таба каратты, сабын җиргә күмде. Хәзер менә шуңа тау башыннан текәлеп карап торды-торды да, янәшәгә баскан уникe яшьлек улы Тимер-Мөэминнең муенына сукты.

—Җан-фәрманга йөгер! Шул хәнҗәргә күкрәгенне ач та капланып ят!

* Байтал—өч яшьлек ат.

Беренче кат кына интектерүе түгел иде инде бу. Тимер-Мөэмин хәзер дә бизгәк тоткан шикелле калтырана башлады, ләкин этисенең йөзенә күтәрелеп бөтенләй карамады. Анын ие-ихтыяры бу минутта аста үлем дәһшәте бөркеп торган хәнҗәрдә генә иде. Менә, ул ярдан сикерергә җыенган кеше сыман кисәк этенде дә кулларын канат шикелле итеп болгый-болгый аска томырылды. Алда—аннан каһкаһә белән көлеп торган, мәңге җиңелү белмәс, котсыз, явыз хәнҗәр. Юк, хәнҗәр генә түгел, әтисенә тиешле тәхетне оятсыз рәвештә, нахак юл белән эләктергән Талиб дошман бит бу! Чәнчелдереп төшерергә кирәк аны, чыраена барып ябышырга кирәк! Ана хәтле унбиш адым чамасы ара калды, ун адым, биш...

Тимер-Мөэмин түмгәк өстеннән сикереп узып китте. Баш түбәсенә китереп суккандай, өстә әтисенең котырынып кычкырган тавышы яңгырады.

—Имгәк! Җебегән! Куркак! Мондый юаш бозау булып үссән, синнән тәхет яуларлык хан чыгачакмыни? Тәхетне калтырап торган, җебегән куллар белән яуламыйлар аны. Әнә шул корыч хәнҗәрләрне сындырырдай кансыз булу кирәк. Мин сиңа юкка гына Тимер дигән исем кушканмыни?!

—Юк, мин хан булам, булам, булам!—дип Тимер-Мөэмин әүвәл аста ачыргаланып елый башлады да, аннары ярсый-ярсый янә өскә йөгереп менде.

—Юк, мин курыкмыйм! Бар, куй хәнҗәреңне. Бу юлы капланам. Мин берзаманны барыбер хан булам!—дип тәкрарлады ул әтисеннән бигрәк үзенең җанын-ихтыярын ышандырыр өчен. Һәм әтисе янына менеп басуга ук, ярсу колын сыман сикергәләп, янә тау башыннан аска томырылды.

Унбиш адым ара калып бара, унау, бишәү, өчәү. Тимер-Мөэмин чебеш алырга ташланган карчыга шикелле кулларын ике якка җәеп хәнҗәр өстенә сикерде. Ләкин... ләкин нинди галәмәт соң бу? Нишләп очы гына Тимер-Мөэминнең тиресен тырнады да хәнҗәр йөзе сап эченә кереп юкка чыкты? Әтисе аны нинди ялган хәнҗәр белән алдый? Нигә мәсхәрәли?

Тимер-Мөэмин гарьләнүдән әүвәл ярсый-ярсый хәнҗәр кереп чумган түмгәкне төя башлады, аннары сикереп торып әтисенә карап чәрелдәде.

—Мин курыкмадым. Мин хәнҗәр өстенә капланып яткан идем. Син алдадың гына. Ә мин барыбер хан булам. Барыбер булам! Син алдадың гына. Син... син...

Тимер-Мөэмин гарьләнү ачысыннан тыела алмый үкси ук башлады. Аска төшеп җиткән Мөхәммәт аны күкрәгенә кысты.

—Булды. Ниһаять, син дә чын ир булып үсеп җиттең, улым. Шулай кирәк. Тәхет хәтле тәхетне өмет иткәч, менә шундый ихтыяр, көч кирәк. Син расладың. Болай барса, валлаһидыр, син чын хан булачаксың...

Иярләрне-иярләргә терәп кайтыр юлга борылганнар гына иде, Биләр тарафыннан тузан болыты куптарып чапкан җайдак пәйда булды.

—Берәр нинди бәла килеп чыкмады микән? Юкка гына болай котырып чапмас. Болгарга берәр яктан дошман бәреп кермәгән булса ярый инде тагын.

Әтисенең шулай хәвефкә төшеп сөйләнүе тәэсир итте бугай, Тимер-Мөэмин атын тыя төшеп кынысыннан нәни кылычын ук суырып алды. Юкка булган икән, чапкын килә-килешкә үк, ияреннән төшеп тормыйча да яңалык чыгарып салды.

—Талиб вафат. Ат өстеннән егылып әрәм булды. Болгар иле— хансыз. Әмирләр Изге чишмә янына җыелып сине көтә.

Мөхәммәт бер генә сүз белән дә җавап-мазар кайтарып маташмады, аргамагының касыгына типте.

## 7

Даян мәргән ничәнче ай инде Киев буйлап киләп сарып йөри. Жаны ятардай шөгыль тапмый жәфалангач, Евсей атлы бер боярга сакчы булып ялланырга туры килде ана. Бояр башта ук ошатты бугай үзен. Ошатмаслык түгел. Түшәмгә житкән, пәһлевандай буй-сын. Үзенә тартып торган, эчкерсез жылылык бөркегән күз карашы. Түгәрәк, пөхтә итеп кискән сакал-мыек. Һәркайсына дәү-дәү ирләр утыртып йөртердәй мәһабәт инбашлары. Шуна карамастан егет пешекчеләр янына адым саен ризык сорап керми. Көмеш жепләр белән бизәлгән йөгән-иярле бик шәп тулпары бар. Бүтәннәрдән бер тиенгә артык та түләү таләп итми. Хужа кеше моннан да кулайрак хезмәтчене кайдан гына, ничек кенә эзләп тапсын инде?

Очсыз ялчы отышлы, шулай да шикләндерә. Евсей бояр беренче ай узып барганда ук кызыксынып сорап куйды:

—Элек бер дә күзгә чалынганың юк иде. Син Киевка каян гына килеп чыктың соң? Атың, дирбияләрең бик кыйммәтле. Аларын каян таптың? Байчура нәселеннәнме син, әллә юлбасармы?

Егет хужаның күзләренә текәлеп, бөтен соравына берьюлы жавап бирде.

—Ярәшкән кызым бар иде. Бер бай тартып алды. Аны тотып суйдым. Шуннан бирле монда.

Егетнең үз күңелен уч төбедәй ачып салуы телсез итте бугай, ике арадагы анлашулар шундук тәмамланды. Ә хәзер бояр кай тарафка гына юнәлмәсен, Даян һәр урында колак салып йөри. Кенәз сарае эченнән хәтәр яман хәбәрләр дә саркып чыга тора.

—Хәзәр каханы Манасий Ольга янына Әкбәр атлы илче жибәргән. Әкбәр мөселман булса да, боярларның һәрбер кинәшмәсенә кереп утыра, ди. Ул, илче димәктән бигрәк, әллә шымчы, әллә толбикәнең күңелен күреп торучы нәсел айгыры итеп озатылган инде? Икесенең тиң тәкатьләре коргаксыган бугай. Кинәшмәгә-нигә карап тормыйча күрше бүлмәгә йөгереп чыгалар да, ух-вах килеп акыра-бакыра эсселәрен басып керәләр, ди бит. Шушы хәтле оятсызлык буламыни инде, кит, атакай!..

Сарайдагы мондый әкәмәтләр гомер-гомергә Киевта яшәгән байтак боярларның үзәгенә үтте, күрәсең. Даян бер кичтә, инде тәмам карангылык төшкәч, Евсей боярның сәер юлга жыенуын шәйләп сискәнде. Евсей тезгә житкән озын, киндер күлмәк астыннан жинел көбә киде. Әле куккә, әле мич авызына карапниләрдер укынды. Боярның нинди юл сайлавын, ниләр ниятләвен чамалау читен иде.

Читтән генә күзәтчелек итеп йөрү кирәкмәгән икән. Озын, кара жилән астына кылычын, хәнжәрләрен дә таккач, Евсей аны үзе дәшеп алды.

—Синең безгә кирәк булуың бар. Коралларынны яшеребрәк так та, әйдә, ияр әле.

Бояр "безгә", диде. Ничәү алар, кемнәр? Итәк астына яшергән кораллар белән нәрсә кылмакчылар? Берәрсеннән үч алырга жыенамы болар, саклык чарасымы? Даян юл буена менә шулар турында гоман корып барды, әмма авыз ачып бер сүз эндәшмәде. Барыр, күрер. Ни генә булмасын, Даян мәргән бер чүкүдә сугып ала торган ангыра карга түгел.

"Мыштым" дигән инеш аша салынган тәбәнәк күпер янында аларны бер төркем боярлар көтеп алды.

—Мин белештем,—дип телгә килде берсе.—Ольга Свенельд йортында кәеф-сафа корып утыра. Әкбәр сарайның беренче катында котыра-котыра су жылытып йөри. Үзенчә, гөнаһларын юып алырга исәбе бардыр инде.

—Бик хуп,—диде Евсей.—Су коена икән, коралы янда булмаячак. Безнен өчен аерата кулай. Әйдә, киттек.

Кенәз сарае янына барып житкәч Даян мәргәнне капка төбендә үк калдырдылар. Даян аптырады. Ихата эчендә булмасын, урам якта булмасын, бер сакчы юк. Гажәп! Йә акчага сатып алганнар инде боларны, йә Ольга белән Әкбәрнең уйнашлары, чынлап торып, сакчы ирләрнең дә үзегенә үткән. Болай булса, яраннарына таянып яшәрдәй өметен-ышанычын бер дә юк икән бит синең, кенәзбикә!..

Боярлар сарайдан берсен-берсе уза-уза, йөгерешеп чыкты. Кайсылары кылычын үлән белән сөртә, кайсылары чаптар аттай гыж-гыж килеп сулый. Капка төбендә берсе генә шапырынып-очынып телгә килде:

—Гаурәтен дә чабып өздем әле теге пакыч жанның. Ольга, кәнтәй, муенына тагып йөрсен шуны!..

Өенә кайтып кергәч тә Евсей жылы бишмәтләрен, зур-зур биштәрләрен барлый, жыештыра башлады. Дәшми йөрүне артыксынды бугай, Даян мәргәнгә дә әмер бирде.

—Безнең өчен бермәлгә читтә югалып йөрү хәерлерәк булыр. Ут белән кат-кат шаяра башласаң, сакалсыз калуың бар. Суздаль ягында үзара кан коюлар, суеш юк, ахрысы. Шул тарафка киттек.

Берәр айдан адәм ышанмаслык хәбәр куып житте.

—Ольга биш мең кешелек гаскәр туплаган да древляннар өстенә үч алырга барган. Древляннар башта: "Менә, безнең Ямал дигән кенәзебез буйдак, мәрхүм Игорең урынына шуны ирлеккә ал",—дип ялынып караганнар. Толбикә боларның үтенечләрен жиргә салмаган, Ямал белән бер сарайга кереп бикләнгән, ди. Аннан йөгереп чыккан да әйткән: "Сезнең кенәзегезнең исеменнән бигрәк жисеме бик бәләкәй, минем көймәдә андый калак белән ишеп ерак китеп булмый". Шуннан соң Ольга яраннары древляннарның ин мөхтәрәм кешеләрен сарай эченә чакырып керткәннәр дә, тышкы яктан бикләп ут төрткәннәр. Коростеньдагы йөзәрләгән бүтән кешеләрне Ольга, кәнтәй, тере көе жиргә күмдерткән. Аннары сугышчылар, котырган эт көтүе шикелле, якындагы авылларны турап чыкканнар, ди. Ольга ире Игорь жәсаде яткан урынга гына да биш мең древлянны суеп салган...

Евсей боярның чәче үрә торды. Каткан кар өстенә капланып, жирне тоя-тоя шашынды ул.

—Биш мең ирне тураган, биш мең ирне! Үзенең туганнарын. Тырнак очына да тормас Игорь өчен. Имгәк! Иблис! Кәнтәй!..

Качакларны сыендырган Аю бистәсендәгеләр әллә кайда, жиде кат жир артында, һәлак булган билгесез кардәшләрен шул көнне үк юа башладылар. Әче бал, көмешкә, төнәтмә ише агулар атна буена елга булып акты. Агач чүмечләрне бер-бер артлы күтәреп эчәләр дә елашалар болар. Исерешеп алгач, йә түшәм сайгаклары арасыннан туфракса коелырлык итеп биешәләр, йә бер савыт-сабаны, бер өстәл-урындыкны исән калдырмыйча үзара сугышалар.

Даян мәргән беренче төн кергәч, бәләдән баш-аяк дип, мич өстенә менеп яткан иде. Таң сызыла башлагач, сәке ягыннан килгән ухылдау-гыжлау авазларын ишетеп ияк калкытырга мәжбүр булды. Текәлебрәк караса, йорт хужасы Аким үзенең килене Варвараны көйләштереп ята.

—Әй, минем Ефим артына ут төртсәң дә берни сизми лә ул. Карт алаша буразнаны бозмый, дигән сүзне тикшереп бак, менә. Биатайның күңелен күреп алу савап кына булыр, каршы торма, килен.

Болар эшләрен тәгәлләгәч, йомышларын йомышларга дип ихатага чыгып югалганнар гына иде, сәке буенда, идәндә Ефим карман-сәрмән килә башлады. Бер-берсенә ябышып каткан керфекләрен ачардай куәте юк, әмма барыбер дә сынар кулы белән таныш итәк эзли. Кармалана торгач,

хатынының әнисе Лукерьяның ботларына барып төртелде бу. Ни галәмәт, әби кешенең тәнендә ике кат итәктән башка иоткарлык юк икән. Ефим тегене аю сыман сытып ятканнан соң астан канәгать ухылдаган авазлары гына ишетелеп торды. Кияү идәнгә шуып төшкәч түгел, ишектә Варвара күренгәч кенә айныдылар болар. Ефим теш арасыннан черт итеп төкереп нәтиҗәсен әйтте:

—Аерма юк икән...

Даян мәргән шуннан соңгы төннәрен толып бөркәнеп сәндерәдә кунды. Таң аткан саен Евсей боярның колагына бер үк сүз тукыды.

—Бу мәхшәрдә безнең эткә дә кирәгебез юк. Киевтагы йортың җимерелеп беткәнче, әйдә, кайтыйк.

Ниһаять, чираттагы таңда Евсей авызына төнәтмә дә ала алмас булды. Чыгара да коса, чыгара да коса. Куллары салам да күтәрә алмаслык булып дер-дер килә, йөзе ап-ак.

—Баста!—диде ул Даян мәргәннән бигрәк үз-үзенә.—Тагын эчәм икән, кәкрәям дә үләм.

Аннан итәк очы сыман яргаланып-сыпылып беткән иреннәрен ачып, гыж-гыж килеп, йортның хуҗабикәсенә әмер бирде.

—Мичснә як! Шунда юынып чыгам.

Даян күптән игътибар итеп килә. Бу йорт эченә җыелып эчүчеләрнең бик күбесе су коенып юынуны белми. Су белән танышрак булган кешеләрнең дә гадәтләре сәер. Мондагы хуҗаларның, кунакларның барчасы да мич буена куелган бердәнбер ләгән эченә тыгылып юыналар. Кайсы тамак чайкап төкеренә шунда, кайсысы култык асларын гына түгел, борынын да юа. Әле шул суны алыштыруны да ике-өч көн буена оныталар.

—Их, шәрекъ мунчасына куалап кертергә иде сине! Каен миллек белән ике-өч кат чабынсаң, өр-яңадан туып чыгар идең!—дип, Даян көчкә тын алып утырган Евсейның хәленә керергә мәҗбүр булды.

—Ишеткән бар. Юк, андый мунчалар безгә төс булмастыр. Без үзебезчә, мичкә генә кереп юынабыз.

—Ничек инде мичкә?

—Шулай, мич эченә. Теләгең бар икән, кара да тор.

Даянны инде болай да кызыксыну комары биләп алган иде. Күзәтә башлагач гел шаккатты. Сәер икән болардагы гадәт.

Олы мич эчендә дугаланып тезелгән ташлар кызара башлагач та, хуҗабикә учактагы күмерләрне алды. Ут очкыннары уйнаклап торган көл өстенә икеме-өчме такта ташладылар. Анадан тума чишенеп өлгергән Евсей бояр балык шикелле шуып шулар өстенә чумды. Аннары хуҗабикә кызыл ташлар ягына олы бер тустаган җылы су тондырды да, шул мизгелдә үк мич авызын капкач белән япты. Эчке яктан Евсейның дию, җен-пәриләр шикелле үкереп аваз салган тавышы ишетелде.

—Ачыгыз, чыгарыгыз мине! Юкса, янып үләм!

—Пычагым булсынмы сиңа, дөмекмәссең!—дип кенә җавап кайтарды хуҗабикә хатын, аннан мич капкачын ачып янә су тондырды.

Мичне йортның бер почмагыннан икенчесенә күчереп йөртердәй дулап-сикергәләп, эчтән кабат-кабат Евсей аваз бирде.

—Коткарыгыз, коткарыгыз, үләм!..

Кызган ташлар чышлаудан туктаганнан соң гына Евсейны идән өстенә тартып чыгардылар. Даян инде боярның җиде кат тиресе кәбестә катламнары сыман салынып төшкәндер, дип хафаланган иде, хуҗабикә әйтмешли, пычагым да булмаган бит мона. Кул-аяклары да шул көенчә, тәне дә сау. Ләкин Евсей бөрлегән шикелле кызарып-янып чыккан, өстеннән кушучлап су ага.

—Менә хәзер Киевка кайтсак та була инде,—дип телгә килде ул, ниһаять, ике чүмеч куәс эчеп куйганнан соң.

Даян да шат иде. Ирләр шул көнне үк иярләргә менде.

8

Кенәзбикә Ольга Киевка әйләнеп кайткач та һаман котыруын дәвам итте. Тагын бер кат гафу үтенмәкче, тугрылыкка ант итмәкче булып, древляннар инде пайтәхеткә илче ирләр дә юллап карадылар. Башлык булып килгән сәүдәгәр Никита зал түренә әллә никадәрле алтын-көмеш савытлар тезеп чыкты, кенәзбикә каршына якынаеп тезен чүкте, ләкин жылы караш белән хәерхаһлык дигәннәрен сатып ала алмады.

—Дарга, дарга! Агач ботагына!—дип чәрелдәде Ольга, төкерекләрен чәчеп.—Олег бабам әйтеп калдырган васыять—һәр кабилә өчен тайпылышсыз канун. Киев—барча шәһәрләрнең анасы, бар кабилә—безнең өчен коллар! Кем буйсынмый, шуна үлем, үлем, үлем!

Кенәзбикәнең куллары-аяклары тартыша башлады, күзләре акайды, ирен читләреннән селәгәй агып чыкты. Сакчыларның аны башкача газаплыйсы килмәде, ахрысы, Никитаны залдан сөйрәп чыгып киттеләр дә, сарай каршындагы беренче өянке ботагында гомерен очладылар. Гәүдәсе әле өч-дүрт көн буена дәһшәт бөркеп торды, аннары югалды. Дөньяда Никита атлы сәүдәгәр булганлыгын сарайдагылар гына түгел, шәһәрдәге кара халык та онытkan иде инде. Аның исемен кәтмәгәндә-нитмәгәндә нәп-нәни кыз уятты.

Ул көнне дә кенәзбикә коллар базарын әйләнеп кайтырга ният иткән иде. Базарга үзенең сак башлыгы Ермолай белән янәшәдә барып керде ул. Тол хатынның соңгы айларда хасил булган яна гадәте бар. Тән сакчылары сайлыйм, дигән булып, Ольга ялкын чәчеп торган тол хатын эссесен басардай махсус ирләр эзли. Кибән чаклы олы гәүдәлеләр дә, карчыга борынлы, уйнаш карашлы чибәрләр дә кирәк түгел аңа. Ольга баганага бәйләп куелган ирләрне... чишендереп сайлый...

Тол хатын булса да, ачыктан-ачык күренеп йөрергә кыенсына бугай. Ольга базарга чыккан чакта яулыгын күзләренә чаклы төшереп бәйли, аны гына да азсынгач, борын өстенә челтәр киеп куя. Барыбер таныйлар, кенәзбикәгә сиздермиләр генә.

Менә, бүген дә, ак-караны күрмичә, коллар сатыла торган инеш буендагы рәткә атылды ул. Ольганың аты да гаярь, аннары ул бикәсенең сукмагын яттан белә инде, әллерттә генә. Ермолай аның артыннан житешер өчен үз атының касыкларын тәяргә мәжбүр булды.

Ольга, корбан тапкан карчыга шикелле томырылып, кысык күзле, киң яңаклы, биленә чаклы шәрә бер дала ире бәйләнгән баганага төбәп бара иде, сәләмә киемле кол кызлар арасыннан чәрелдәгән тавыш сискәндерде.

—Кенәзбикә, кенәзбикә! Зинһар, безне жәллә? Яраннарына әйт, мине энекәшемнән аерып сатмасыннар?

Ольга чытырманлык ерып барганда сынган ботакка килеп төртелгәндәй куырылып калды. Нинди хәерсез кыз бу? Коллар арасыннан кайсы мәхлук аны яулык, челтәр бөркәнгән көе дә яхшы таный? Саф урыс телендә эндәште бит, ничек итеп колга әверелгән?

Ихтыярсыздан, кенәзбикә тезгеннәрен тартып атын тыйды. Челтәр арасыннан аермачык күренеп бетмәсә дә, коллар рәтен ялт-йолт айкап чыкты. Әнә, кайсылары аякларын сузып, кайсылары бөкләп, йөзгә якын кыз бала

тезелеп утыра. Биш-алтысында гына яулык күренә, күбесе яланбаш. Чәчләре тузгыган, киемнәре теткәләнеп беткән. Берничәсенең ертык сәләмәләре арасыннан имчәк очларына тикле тырпаеп тора, капларга дип уйлап та карамыйлар. Аякларындагы, кулларындагы богаулар астында өр-яңа җәрәхәт эзләре. Димәк, болар әле ерак юллар үтеп күнекмәгән, кичә-бүген генә Киев базарына куып китерелгән коллар. Мөгаен, древляннардыр. Днепр өстендәге дулкыннарда кораблар уйнаклап тора, озакламый шуларда бу кызлар да хәзәрләр, юнаннар*, гөрҗиләр** кулына канизәкләр булып китәр инде...

Баягы бичара кыз тавышы янә ишетелде.

—Кенәзбикә, мине энекәшемнән аерып сатма инде.

Ольга очкынлы күз карашын шул тарафка атты. Тезләренә күтәрелеп, ике кулын алга сузган бер кыз ялвара. Яше әлләни түгел, күп булса, унунбердер. Чәче җитен сыман сап-сары, төскә-биткә чибәр. Ә күзләре... күзләре чишмә суында чайкап алган фирүзәләр сыман. Эчкерсезләр, сафлар, аларга күпме генә төбәлсәң дә, төбен күреп булмый. Моның ише нарасый сабыйны өстәленә аш-су китереп йөргәндә очратып та сөенерлек кенә. Җитмәсә, сарайда пешекче, тукучы, җыручы кызлар әледән-әле сакчылардан, кунаклардан буйга узып тора, яңа алмаш атна саен кирәк.

—Моны богауларыннан азат ит, үзем белән алам!—дип кычкырды башта Ольга коллар кәрванбашына, аннан янә кызыйга күз атты.—Кайсысы синең энекәшең, әйдә, күрсәт!

Күз ачып йомганчы богаулардан азат ителгән кыз пар-пар итеп баганаларга бәйләп куелган малайлар тарафына ияк какты.

—Әнә, дүртенче багана янындагы җирән—минем энем. Исеме Добрыня. Үзе юаш булганга гына тагылган кушамат-мазар түгел. Бу аның чын исеме.

Мондый тәфсилле анлатмадан елмаеп куйса да, малай тарафына күз ташлау кенәзбикә кешене шундук сискәнергә мәҗбүр итте. Малай куркыныч түгел, җиде-сигез яшьтә. Әмма моның бөтен төсе-кыяфәте уч төбе шикелле таныш бит. Кайда очратты мондый кешене Ольга? Кемнең туганы бу?

Кенәзбикә яшь кызыйга төбәлеп сорау бирде.

—Сине ничек дип йөртәләр?

—М-М-Малуша.

—Сез кайсы яктан монда килеп эләктегез? Әтиегез кайда?

—Коростеньнан без, кенәзбикә, Коростеньнан,—диде Малуша, иннәренә таш салгандай янә авыр сулап.—Әтиебез Никита синнән гафу үтенмәкче, бүләкләр бирмәкче булып чыгып киткән иде дә, аны сакчыларың дарга тотып аскан. Яклаучысыз калгач, колларга әвереләдек тә куйдык инде менә.

Малуша сөйләменнән соң кенәзбикә елан өстенә баскандай куырылып калды. Менә сиңа махмырдан соң тозлы кәбестә! Сарайда берсе пешекче, икенчесе сакчы булырга ярамасмы, дип Ольга ике колны азат иткән иде, алары да кичәге дошманының балалары икән. Бу минутта базардагы йөзәрләгән күз аңа төбәлеп тора, ничек хәл итәсе?

Шулчагында сабыйлар самимилеге белән телгә килгән Малуша базарны ду китерде.

—Сез курыкмагыз, изге кенәзбикә. Без сезгә тырнак очы хәтле дә этлек эшләмәбез, гомер буе тугры хезмәт итәрбез. Сез мине энекәшемнән аермагыз гына.

Дистәләгән ирләр ихахайлап көлде. Алар тынгач, Ольга һәркайсына ишетелерлек итеп, җитди төстә дәште.

—Этлек эшләргә чос түгелсең икән, моннан ары минем түшәк сакчым булырсың, Малушакай...

* Юнаннар—византиялеләр.

** Гөрҗиләр—грузиннар.

Шулай итеп ятимә кыз бала кенәзбикә сараенда үз кешегә әверелде дә куйды. Ә ике-өч ел үткәч, кенәзбикә кочагыннан аерылган чакта, сак башлыгы Ермолай аны сәер яңалык белән кисәткәндәй итте.

—Синең улың Святослав Малушаны ала да гел урман-яланнарга чыгып олага. Беркөн аларны Гордей сәүдәгәр Янгантау буенда шәп-шәрә көенә күреп кайткан. Син Святославны һаман бала-чага, малай-шалай, дисең, кенәзбикә. Уеннан уймак чыкмаса ярый да бит.

Ольга ике кулын селти-селти көлде.

—Уйдырма! Уйдырма! Анамы соң?.. Хәер, хак булса да, зыян түгел. Шәрә кызлар янында күбрәк йөри икән, тизрәк чын ир булып житлегер...

Шулай да, кенәзбикә ул кичне караңгы төшүгә үк үз янына Асмуд атлы боярны чакырттырып алды. Төсе-кыяфәте тагын тол калган еллардагы шикелле нурсыз, кара иде. Асмуд бусаганы атлап кергәч, Ольга карчыга шикелле аңа ябырылды.

—Яу сәфәренә-мазар йөргәнең юк, Киевтан чыкканың юк. Инде шул көе дә күз-колак була алмагач, ни пычагыма дип кенә мин сине Святославка аталык бояр итеп билгеләдем? Минем малай канизәкләр белән өегә башлаган, ә син ни карыйсың?

Асмуд күзгә күренмичә бызылдаган чебен-черкидән арынган шикелле генә итеп кулларын чәбәләде.

—Читкә йөрү ир-атларга осталык кына өсти, нигә кайгырасың, кенәзбикә? Кәләш әзер. Святославка унбиш кенә тулсын. Аннары муенына камыт кидерәбез дә, ипкә утыра ул.

—Юк, юк, унбишен дә көтеп тормыйбыз, хәзер үк өйләндерәбез,—дип, янә теге еллардагы шикелле төкерекләрен чәчә-чәчә кычкырды кенәзбикә.—Ялчы кызыйның итәккә бала салып кайтканын көтеп ятып булмас...

Өйләнү турындагы сүзне ишетүгә үк Святослав хәзәрләр ягындагы далага чыгып качты. Арканнарга урап кире алып кайттылар. Ашык-пошык итеп туй ясалды. Аннары берничә айдан соң сарайдагылар төн йокыларын калдырып бала көтте. Сарай, әлбәттә, иң беренче чиратта, кенәз дәвамчысына өмет баглый иде. Ләкин Святославка тәүге угылны, барыбер дә, Малуша бүләк итте.

—Малайга атны Владимир дип куш. Мин аннан беркайчан да баш тартачак түгел,—дип пышылдаган булды яшь ата, бәхетсез Малуша янына качып кереп кенә.

Ә кенәзбикә Ольга үзенчә хәл итте.

—Безгә синең уйнаштан тапкан балаңның кирәге юк. Коростенына олак!..

Котырынган Святослав, биш йөз кешелек кенә дружинасын алып, әнисенең шәхси утары булып исәпләнгән Вышегород каласы өстенә ябырылды. Агач кирмәнне өч мең яугир саклый, ләкин аларда Святославтагы ярсулык юк иде шул. Яшь кенәз әнисенең утарыннан көл калдырып узды.

—Әй, сабыйлыгы чыгып бетмәгәндер әле. Тузынып да тынар,—дип кул селтәде Ольга.

Чынлап баксаң, кенәзбикәнең күңелен башка кайгы басты. Соңгы айларда аны кендегеннән астарак ниндидер чир газаплый, шуннан котылу өчен Ольга хәзер юл чыгарга ниятләп йөри иде. Берничә атнадан соң гына каладан калага яңа хәбәр таралды.

—Ольга юнаннар янына Кайсаркалага* киткән. Гөнаһларын юарга җыенадыр инде. Чукынырга ният кылган, диләр...

* Кайсаркала – Царьград, Константинополь.

## 9

Мөхәммәт ханның кәефе юк заман. Шәрекъ яктан, Жаек аша, Болгар жирләренә кара аймыклар бәреп кергән, диләр. Исәпкәсанга алырлык кала-кирмәннәрне жимерү-кырулары турында хәбәрләр юк-югын. Ләкин Идел, Кондырча, Сакмар буенда утырган дистәләгән авылларны талаганнар, яндырганнар инде. Анда—бортаслар белән чиктәш, ерак төбәк. Пайтәхетнең үзенә дә, мәмләкәтнең сенерләре булган олысларга да һичбер куркыныч юк. Әмма, менә, аймык жайдаклары аерым ханлык корырга маташкан бортас кабиләсен энәсеннән жебенә чаклы айкап-актарып талаганнар икән. Хәтта, ике дистә мең кешеле Бәнжәне дә умарталыкка төшкән аю сыман пыран-заран китереп чыкканнар, ди. Шул кирәк ул умырткасыз, аумакай бортасларга! Йомшак иренле бозаудай кыйланып, тагын күпме еллар буе ике сыерны—болгарларны да, хәзәрләрне дә имеп яшәргә, икейөзлеләнергә була инде?

Иң әүвәл, әле Алмыш хан ук үз әләме, үз тирмәсе янына чакырып караган боларны, баш тартканнар. Имеш, Алмыштан да куәтлерәк хакимнәр бар әле жир йөзендә, Хәзәр каханы бар. Аннары Микаил бабасы үз ягына аударырга тырышып карады бортасларны, монысына Мөхәммәт тә шаһит. Һаман бер үк төрле жавап ишеттеләр.

—Сез безнең шикелле үк мөселман-мөселманың. Икебез бергә кушылсак, яңа мәмләкәт симертергә япкан үгез сыман көрәеп, гайрәтләнеп китәчәк, моны без аңлыйбыз. Иллә мәгәр... ни бит... болайрак бит... Безгә үз ханыбыз белән аерым тирмә корып яшәү кулайрак. Аннан... кахан да бар. Сез жиде дәрья, кырык катлы урман артына кереп качкан кавем, Әтилдән бик ерак. Ә без кул сузымында гына. Үгез эзләгән сыерлар шикелле сезгә ияреп китсәк, каханның безнең көтүне кырып чыгуы бар...

Шул каханнан өркеп Бәнжәдә туплаган аманат, салымнарын Әтил каласына елга буйлап, сал белән генә озатып яткannnар иде дә, менә бит, ерактагы дошман бәреп кергәч якламаган Манас. Бортасларга ярдәмгә хәтта бер генә йөз дә гази бирмәгән, ди. Алай гынамы соң? Бортасларның тоташ таланганын күз чалымына да китереп тормыйча еллык яңа салым, сараена яшь егетләр таләп итә ди бит, нинди хәлдер? Соңгы елларда кахан үзенең харәмханәләрендәге жария кызларны яңартып торуны ташлады, аның каравы, сараена һаман-һаман яшь малайлар даулый. "Кахан хәзер малайларны мунчасында кызтәкәгә әйләндерә икән", дигән сәер хәбәр йөри. Ләкин аманат итеп озатылган угылларның берсенең дә кабат әйләнеп кайтканы юк. Алар жир тишегенә убылган шикелле гел югалып тора. Ә дөресен генә, тәгаен итеп кенә һичбер тарафта, һичкем белми.

Мөхәммәт үзе тәхеткә менүгә үк Минлебакир бәкне яңа вәзир итеп күтәреп куйган иде. Кичә кичен әнә шул вәзир кереп әйтте.

—Ошбу Манас кайсы кыйблага төбәлеп, нинди сәясәт алып барадыр, аңламыйм. Сәмәндәрдән Ахияр бәк кайтып төшкән иде. Әтил аша, әйләнеч юлдан кайткан. Шул сөйләде. Манас кахан Әтил илә Сәмәндәр арасындагы чик сызыгын ачкан да Тын дәрья* белән Көбә үзән** ягына бәҗәнәкләр чируен үткәреп жибәргән, ди. Бәҗәнәкләр Тын дәрья эргәсенә барып житүгә үк Саркел атлы каланы кулга төшергәннәр. Хәзер шул куна тактасы шикелле шыр-ачык далада да әллә каян бүрәнәләр илә ак таш табып, кирмән диварларын ныгыталар икән. Ул бәҗәнәкләр алдында тәлинкә тоту Манас каханга ник кирәккән инде? Артык көрәеп алсалар, шул ук бәҗәнәкләр Манасның үз сыртына пычак китереп батырачак ласа.

* Тын дәрья – Дон.
** Көбә үзән – Кубань.

Мөхәммәт каршы төште.

—Менә, бәҗәнәкләрне Манас ник үз жирләре аша үткәреп жибәргән инде, дип баш ватасың икән, Бакир агай. Бер дә кырык карта шикелле катлы-катлы сере юк бит моның. Манас Кияү каласының көчәеп китүеннән, аннан ары юнаннарның һөжүменнән курка. Ул якта тагын безнең туганнарыбыз—кара болгарлар да бар бит әле. Янә килеп, янәшәдә алан илә чиркәс кабиләләре яшәп ята. Таулар арасында ингуш, чәчән, ләке дигән кабиләләр гомер сөрәләр, ди. Кахан бәҗәнәкләрне Тын дәрья буена үткәреп, әнә шул кабиләләрнең һәммәсенә берьюлы жим ыргыткан. Нәфсегез бик кыжраса бәҗәнәкләрне тотып ашагыз, мина гына тимәгез, янәсе.

—Бу—Кияү каланыкылар, юнаннар, кара болгарлар илә ике арага калкан корган, дигән сүз була бит,—дип эләктереп алды вәзир.—Акылы кот икән.

Мөхәммәт ничарадан бичара кыяфәттә өстәп куйды.

—Каханда мәкер бетмәс-төкәнмәс. Шушы чаклы этлек аңа каян гына килеп бетә икән?..

Бүген Мөхәммәтне таң атканда кереп уяттылар.

—Бәнжәдән чапкын бар. Башка берәүгә дә бер сүз әйтми, сине генә сорый.

Тәхеткә менгәннән бирле Мөхәммәтнең күз алдыннан Балак дигән сатлык китми тора. Нинди шома еландыр инде бу, һич тоттырмый. Бәнжә диварлары янында Габдулла ханның кулыннан чыгып качкан иде, Мөхәммәт Изге чишмә буеннан пайтәхеткә хан булып кайтып кергәнче Биләрдән дә табан ялтыраткан. Тагын кай яктан килеп чыгар да, кайчан чагып алыр, бар, чамалап кара.

Мөхәммәт хәнжәрен кынынан алып жин эченә яшерергә мәжбүр булды, аннан гына ишек сакчысына дәште.

—Чакыр, керсен.

Көтелмәгән кунак кызу мичкә тыгып киптерелгән сыман какча, ябык гәүдәле, каратут йөзле бәндә булып чыкты. Әллә шул ябык булганга инде, буе да, муены, куллары да галәмәт озын шикелле тоелалар моның. Сузылса, ул дәү өстәлнең икенче башында утырган дошманын да жинел генә буа алыр кебек. Аллага шөкер, жилән канатлары ике якка ачык, билбавында һичбер коралы юк.

—Мин хан чапкыны да, Бәнжә әмире дә түгел,—дип тиз-тиз сүз башлады ул. Үзе Мөхәммәт хан каршында тезгә чүгеп яки бил бөгеп вакланмады, бүреген генә баш түбәсеннән йолкып култык астына тыкты.

—Мин гап-гади бер бәк. Атым Шонкар. Бәнжәдә азат, тигез хәят буллдыру яклы гавамның атап озаткан бер илчесе булам.

Мөхәммәт борын очына олы шөпшә килеп кунган сыман нык сагаеп калды. Тукта, ошбу илче Бәнжәдә түнтәреш әзерләргә йөри түгелме соң? Мөхәммәтнең хыялы—Бәнжә каласын үзенеке итү. Әлеге бәндә дә шул сәясәт яклы. Алай булса, моннан йөз чөерү килешеп бетмәс. Су тегерменендәге куласага инеш-ерганаклар кайсы яктан гына килеп өстәлмәсен, һәммәсе дә хужа файдасына бит.

—Гавәм үшән сыер хәлендә яшәүдән тәмам гарык. Бәжәнәкләр талап үтеп китә, Манас кахан бертуктаусыз сава. Инде, менә, аймык чирүе дә талап чыкты. Ә яклап калучы, сакка басучы юк. Калабызда Минай хан бар, тик ул бертуктаусыз йоклый. Аңа үгез үлсә—ит, арба ватылса—утын. Тәхете генә исән булсын да, аңа жил тимәсен. Без, бүре өере уртасында калган көтү сымак, таланудан туйдык. Әйдә, чирү жыеп бар да изелүдән коткар. Без син корган тирмә каршында баш иярга әзер.

Мөхәммәт хан вәзир Минлебакирны чакыртты. Кашандагы әмирлектән

алып курсыбайга сәрдәр итеп куйган Нуретдинне дәште. Аннан соң гына бер-бер артлы сорауларын тезде.

—Минаӣ кул астында бүген күпме гази?

—Даими чирүдә йөргәне алты менләп бардыр. Арттырам дисә, шул, авыллардагы сабанчыларны гына кыйнап җыйса инде.

—Аймыклар кая китте?

—Икегә бүленделәр. Бер нөгәре Каф тау ягында гөрҗиләргә каршы яуда йөри. Икенче яртысы Кондырча буенда угызларга очрадылар бугай, әлегә тик торалар.

—Син үзең кара гавам арасыннан никадәрле чирү җыя аласың?

—Санап караган бар, ныклап котыртсаң дүрт-биш меңгә житә. Вәләкин безнең күбебездә көбә, очлым юк бит. Коралы да шул, колгага таккан балта, чалгыдан ясаган сөңгеләр генә инде. Дөрес, кылычлар бар. Ханҗәрне әйткән дә юк.

—Сез үзегез башлап фетнә куптарырга җыенасызмы, безне көтәсезме?

—Башлап сез килсәгез, кулайрак булыр сыман. Ялгыз көе кузгалсак, хан чирүе безне печән чүмәләсе урынына тетеп кенә ата...

—Йә, нишлибез?

Шулай диде дә Мөхәммәт хан Бакир вәзирне, Нуретдин сәрдәрне күз карашы белән көйдереп чыкты, тегеләр дәшмәделәр. Бүлмә буйлап әрле-бирле йөри-йөри хан үзе сүз башлады.

—Нуретдин бәк! Кашандагы энекәшең Елкыга үзең чапкын җибәр. Алайлары белән безне Зөя тамагында көтеп торсын. Аннан ким дигәндә өч мең газиле чирү, колагына киртлә... Аннары син төп Суар кешесе, туган калаңа да үзең барасың. Мин сине юкка гына сәрдәр итеп күтәреп куймаганмындыр, әйдә, расла. Нур-Суардан янә өч мең газилек чирү. Очрашу урыны шул ук.

Нуретдин ишеккә таба кузгала башлаган иде, Мөхәммәтнең кырыс тавышы кадаклап куйгандай итте.

—Ашыкма, көт, әле сүз бетмәде.

Мөхәммәт хан вәзир тарафына борылып басты.

—Олуг вәзир, сиңа Ашлы каласына төбәп чыгарга туры килә. Искил кабиләсен кузгату синең өстә. Аларга бертуктаусыз Урыс елгасы буендагы вятич ушкуйлары янап тора, ул хәтлесен беләм... Иллә мәгәр Җаек ягыннан кергән аймыклар да һәммәбезгә, шул исәптән Ашлыга да дошман. Гел үз тирмәсе, үз тиресе өчен генә калтырап яшәмәсен, Сәлман да башка әмирләрдән калышмыйча өч мең җайдак бирсен. Син аларны Идел буйлап алып төшәрсең. Сәлман тимер калкан япкан зур каеклар биреп җибәрсә дә начар булмас иде. Синең белән Зөя тамагында кушылабызмы, беркадәр түбәнрәкме, анысын күз күрер.

Ниһаять, Мөхәммәт хан үзе турында да сүз кузгатты.

—Ә миңа Биләр, Җүкәтау белән Болгар яугирләрен җыештырып барырга туры килә. Мәгәр...

Мөхәммәт хан авызына су капкан шикелле капылт туктап калды. Тешләре шыгырдады, янак сөякләре уйнаклады. Сизелеп тора, аны эчтән яман бер корт кимерә, талый иде. Кабат телгә килгәч тә, тавышы сынып, калтыранып чыкты.

—Мин... беренче тапкыр яуга... хан буларак барам... Миңа җинелергә ярамый... Җинелеп кайтсам, Болгар халкы йөз чөерә миннән. Аннары бер генә юл—тәхетне ташла да кит... Шуңа күрә мин болай хәл иттем. Нуретдин бәк, яуны син әйдисең! Мин чирүдә менбаш булып барам. Исемем Әхәт булыр. Яуда миңа ил хакиме итеп эндәшү юк!

## 10

Болгарлар Бәнҗә каласына барып житкән чакта жир өстенә тәүге ак кар төшкән иде инде. Тышта салкын, ачы жил исә. Иярдәгеләр дә, каектагылар да эчләре китеп жәфаланган шикелле бөгәрләнеп бара. Ләкин жил-салкыннар каладагылар өчен дә бер үк бит ул. Бәнҗә янына тәүге иравыл нөгәрләрен озатуга ук ачыкланды. Кала тулысынча мәрткә киткәнмени, диварларында бер йөз чамасы да токавыл юк.

Сәрдәр Нуретдин утлы таба өстендә, ни кылырга белми. Аптырагач, шыпан-шыпан гына Мөхәммәт янына килеп житте.

—Диварда жүнле сак күренми. Ни кылабыз хәзер, меңбаш Әхәт?

Мөхәммәт Нуретдин йөзенә карап елмайгандай итә, әмма үзенең эчендә тоташ ут яна.

—Монда минем атайның авызы пеште инде. Ул күргәнне кабатлыйсым килми. Кул астында унбиш мен гази бар лабаса, яңа иравыл жибәр.—Бераз баргач янә өстәп куйды.—Чирүне икегә бүл. Берсен хәзәр даласын ышыкларга жибәр. Алла сакласын, Манас этләренең килеп төшүе бар. Икенче нөгәрен төн ягыннан килеп каланы тулысынча камалышка алсын. Ул-бу килеп чыкмасын дип тозак алайлары калдырсак ярар иде дә инде, мәгәр көне салкын. Кала диварларына ташлансак, алар барыбер түзеп тормаячак.

—Ә каеклар? Каектагылар, дим. Аларны нишләтәбез?

Нуретдин шушы сорауларны тезеп салгач кына Мөхәммәт иләсләнеп маңгаена сукты.

—И-и, томана! Каекка утырып яу йөргән бармыни? Бөтенләй оныткканмын. Аларның бурычлары күптән билгеле инде. Жайдаклар каланы урап алуга ук елга яклап диварга ташланалар. Арабызда каекчылар булу безнең өчен аеры отышлырак. Мондый кара көз көнендә яр ягыннан һөҗүм итүне һичкем көтми...

Мөхәммәт белән Нуретдин юкка гына бу чаклы тәфсилләп әзерләнде. Чынында исә болгарлар Бәнҗәне яусыз-нисез диярлек кулга төшерделәр. Бортаслар әле яңа гына аймыклар тарафыннан таланган да булгач, кичке энгер-менгер төшеп барган чакта әллә каян гына янә утыз алайлы дошман килеп чыгар дип каладагы һичбер түрә уйламаган, ахры. Сакка куйган токавыллар мәрт йокысыннан айнып оран сала башлаган чакта болгар жайдаклары эреле-ваклы калкулыклар арасындагы уйсулыклар, тирән ерымнар эченнән атылып чыгып, кала диварларын буар елан сыман чолгап алган иде инде. Тимер белән тышланган капкаларын да янда әзер торган ком-таш тулы арбалар белән терәтергә өлгерә алмадылар. Болгарларның алты-жиде дөя өстенә салып алып килгән очлы бүрәнәләре имән капкаларны атланмайга кадалган хәнҗәр шикелле генә урталай ярып узды. Ә Бәнҗә урамнарына бәреп кергәч, болгарларга кылыч айкарга, ук очырырга язмады да бугай. Монда Минай газиләре өстенә Шонкар кул астындагы кара гавам нөгәрләре очып кунган, алар ярсыган әтәчләр шикелле үзара кыйнашалар, чукышалар иде. Болгарларга шул Минай хан сарае янында гына җансакчылар белән әүмәкләшеп алырга туры килде. Берзаманны киемнәре бүре талаган сарык тиресе кебек умырылган, теткәләнгән ханның үзен дә сарай ишегеннән сөйрәп чыгардылар.

—Хатыннары ягына кереп качкан. Яшь кәҗәсе яткан сәке астыннан көчкә сөйрәп алдык!—дип каһкаһәләп һәм олы бүләк өмет итеп кычкырды бер гази.

Нуретдин сәрдәр инде сарай баскычы өстенә сикереп менгән, Мөхәммәт

исә ияреңдә утырган килеш мәйдан почмагында гына тора иде. Корбаннарсыз гына җиңү яулау Нуретдин сәрдәрнең күзен томалаган, күрәсең, ул мәйдандагылардан киңәш сорагандай кыланып, тизрәк хөкем карары чыгарырга ашыкты.

—Яр башыннан этләргә ыргытабызмы моны, дарга асабызмы?

Менбаш Әхәт булып йөргән сыбайның* асылда кем икәнен һәркем яхшы белә, аннан узып кем сүз әйтсен инде?

Мөхәммәтнең авазы ишетелде.

—Син тавык лапасына кергән көзән сымак, сәрдәр. Гел кан исенә кыҗрап торасың. Хан суярга сузып салган мескен тавык түгел, ашыкмале алай. Кирәк тапсак, аның гомерен соңыннан да кыярга өлгерербез. Ханнар саугатлыкка** көн дә эләгеп тормый. Аны колчура ясап Биләргә алып китү үзе бер дан.

—Ю-у-ук! Саугат булырга да, колчура булырга да теләмим! Андый хурлыкка төшкәнче, ичмаса үтерегез!—дип Минай янда торган бер-ике газинең сөңгесенә сикереп караса да, тоткын ханны бик тиз эләктереп, тез астына бөкләп салдылар.

—Зынҗырларга утыртыгыз моны!—дип кычкырды "менбаш Әхәт".— Аннары сак куегыз! Минай ханның сыңар гына чәче коелса да, башың белән җавап бирәчәксең!

Нуретдинне ярсуыннан тоташ тир каплады, кием астында бала йоннары кабаргандай булды. "Исемне дә әйтеп мәшәкатьләнми бу. Сәрдәр дип исәпләнеп йөргән булам тагын".

"Менбаш Әхәт" янә телгә килде.

—Миңа сатлык Балакны табып китерегез! Тере көе, анысының да чәчен йолыкмыйча. Менә мин аны, ичмаса, рәхәтләнеп асам!

Ирләр Бәнҗә урамнары буйлап таралганда Мөхәммәтнең соңгы әмере дә куып җитте.

—Йортларны, кибетләрне талауларны тыям! Хәзер инде Бәнҗә—безнең шәһәр. Җинаять өстендә каптырсам, асачакмын!

Моны гына да азсынды, күрәсең, Мөхәммәт Нуретдин тарафына борылып өстәп куйды.

—Һәммә урам буйлап йөзбашларны җибәр. Талау яки көчләү оештырган бәндәләрне кызгану юк!..

Мөхәммәт үзе Идел буендагы урамнарга таба төшеп китте. Артта яна-кабалана җансакчылар йөзе тезелеште. Бәладән баш-аяк, кыйналудан качкан дошман сугышчыларының килеп чыгуы бар.

Монда күбесенчә салчылар, балыкчылар гомер сөрәдер инде, урамнар тын. Ихаталарда, сарай артларында сумалалары купшакланып беткән көймәләр аунап ята. Кайбер сарай түбәләрендә кышкы ялга кайткан ятьмә, сөзгеч өемнәре күренештерә. Лапас-келәтләр тирәсенә ярымсынык ишкәкләр бастырып куйганнар, күрше белән ике арага тезгән коймамыни!

Мөхәммәт сунарчы елгырлыгы белән күзәтеп бара иде, ярымачык бер йорт ишегеннән үзенә төбәлгән карашны тотып алды. Яулыгын иягенә төшереп бәйләсә дә, гүзәллеген яшереп булмас сылу, яшь йөз, очкын бөркеп торган карлыгандай күзләр!

Угрылык өстендә тотылгандай булды, ахрысы, чибәр кызый тиен сыман сикереп юкка чыкты. Мөхәммәт тә үзенең комарлы уенга кереп чумганын тоймый-сизми калды, ияреннән капылт сикереп төште. Аның артыннан ук тагын ике-өч җансакчы да коелып төшкән иде, Мөхәммәт усал әмер белән шып туктатты.

---

* Сыбай—гаскәр, отряд башлыгы. Офицер мәгънәсендә.
** Саугат—әсир, сугыш тоткыны.

—Иярәсе булмагыз, артка!..

Ишекне ачып керсә, кызый бер ялгызы. Өстенә тагын бер шәл, иске җилән ябынып өлгергән, битенә корым сөрткән. Ул йә шушы йорттагы ир хатыны, йә сазаган кыз, янәсе. Аһ, хәйләкәр!

—Ару гына яшисенме, әбекәй?—дип эндәште Мөхәммәт, авыз ерып җибәрүдән көч-хәл белән тыелып.—Су эчереп чыгармассын микән?

Мич буенда дәшми генә басып торды-торды да, ахыр чиктә кызый чүмеч белән әйләнеп килергә мәҗбүр булды. Үзе йөзен шәл астына яшерә, ә куллары елгадан гына йөзеп чыккан каз канаты шикелле ап-ак, йомшак.

Мөхәммәт аны әүвәл әнә шул йомшак кулларыннан эләктереп тартты, аннары инде кочагына состы. Юк, каушамады кызый. Мөхәммәтнен кочагыннан балык кебек кенә шуып чыкты, янә тиен сыман сикергәләп бер почмакка качты. Әмма, ниһаять, телгә килде.

—Битләренне тырнап бетерәм, якынаясы булма!

Менә шулчагында гына Мөхәммәт рәхәтләнеп, тутарылып көлеп җибәрде.

—Минем өйләнәсе бар әле. Юк, син мина тимә.

Жаны утка очкан күбәләктәй уйнаклаган кызый тел очыннан нинди сорау ычкынганын бөтенләй сизмәде дә.

—Кемгә?

Гыйшык хисләре җәйге чиллә сыман кызган Мөхәммәт тагын-тагын рәхәтләнеп көлде.

—Кемгә булсын, сина инде, сина.

—Абау, норсыз!

Мөхәммәт мич буендагы урындыкка барып утырды. Кызый каш астыннан гына күз ташлады. Башында көмеш очлым, билендә алтын аеллы каеш. Үзен дистәләгән җайдак саклап йөри. Кем булыр бу?

Мөхәммәтне дә байтак сорау утлы күмер сыман көйдерә иде. Инде җитдиләнеп сүз башлады.

—Уен беренче тапкырында гына күнелле ул. Шаярдык, көлдек, булды. Хәзер яшерми әйт. Син кем кызы буласын, атын нинди?

Кызый янә азау тешен күрсәтеп җавап бирде.

—Син Газраилме әллә, нигә сораштырасын? Әүвәл үзен сөйлә. Син үзен кем?

—Мин менбашы,—дип, Мөхәммәткә ялган белән капларга туры килде.—Биләр каласыннан. Әхәт булам.

—Сез Бәнҗәне бөтенләйгә алдыгызмы инде? Әллә талыйсыз да кайтып китәсезме?

—Юк, таламыйбыз да, китмибез дә. Бәнҗә—безнен шәһәр. Ләкин синен кебек чибәр кызлар өчен аермасы юктыр. Кай якка кияүгә чыгасыз, сезгә Ватан шулдыр.

Кызый оялды шикелле, йөзенә алсулык йөгерде. Мөхәммәт элекке сорауларын янә кабатлады.

—Йә, син дә әйт. Атаң нинди кеше? Үзеңнең атын нинди?

—Атам юк инде минем,—диде, ниһаять, кызый, монсулана калып.—Мөкътәсир бәк иде минем атам. Әтилдә яшәдек без. Былтыр аны кахан шымчылары эләктереп дарга асты. Мине кахан хатынлыкка алмакчы иде, качып котылдым. Бер ел була инде монда килгәнемә. Урамга да чыгып күренгән юк. Куркам.

Мөхәммәт башын чайкый-чайкый уйга талып утырды, ара-тирә йодрыгы белән тез капкачларына да суккалап-суккалап куйды. Бераздан гына ятимә кызга тутырып күз атты ул.

—Исеменне ничек диден әле?

—Айсылу ла.

—Ярар,—диде Мөхәммәт, аягына кубып.—Әйдә, җыен. Мин сине үзем белән Биләргә алып китәм.

—Ә син өйләнгәнме соң?

—Миңа биш мәртәбә өйләнсәм дә ярый.

Янә сүз әйткәнче Айсылуның ияге дерелдәп торды.

—Хаҗга бардыңмыни?

—Юк, бармадым... Мин хан булам, сылу.

—Нинди хан ул тагын?

—Мин бая сиңа ялганладым гына. Мин меңбашы түгел, ә Мөхәммәт хан булам...

Айсылу шул минутта артка авып китте. Мөхәммәт аны нечкә биленнән эләктереп алырга чак өлгерде.

11

Ул, Айсылуны иярenә утыртып, кабат хан сарае янына әйләнеп кайткан чакта хыянәтче Балакны да тотып китергәннәр иде инде. Мөхәммәт күренүгә, сарай баскычына тезелешкән төркем эченнән күптәнге танышы Шоңкар алга чыкты.

—Синең сүзне көтәбез, меңбаш Әхәт. Баулар әзер. Бу сатлыкны ә-әнә теге каеннарны бөгеп икегә аерыбызмы, атларга тагабызмы?

—Син дә Нуретдин шикелле канга сусадыңмыни?—дип кычкырды Мөхәммәт көтмәгәндә, кайнар суга салган кысла кебек кызарып.—Сиңа да шул кан кою, баш кисү, кеше турау гына кирәкмени? Адәм рәтле генә, ипле генә яши белмисеңме?

Мөхәммәтнең яшелле-зәңгәрле тавышыннан шомга калды, күрәсең, азат хәят сакчысы Шонкар акланырга ашыкты.

—Соң... соң, әле бая гына үзең бу сатлыкны дарга асам, дидең ләбаса. Үзең шулай дигәч, без ни... без ни...

—Мин ни әйтмәм. Үз башыгыз кайда?

Һәммәсе тын калдылар. Мөхәммәт хан кулларын бәйләп бер чаптар иярenә тагылган Балакка текәлде. Каз талаган сыман тишкәләнгән чалбар, җәрәхәткә батырып тукмалган йөз. Күзләре каш астында ялык-йолык килә, берәүнең дә карашын күтәрә алмый. Селтәнеп суксаң түгел, битенә төкерсәң дә авачак бу. И-и, шушы хөрәсән дә кайчандыр аның әтисе Габдулланың башын ашамакчы иде ләбаса. Тф-ф-фү, нәҗес! Шушы хөрәсән канына ничек кул буйыйсың? Моның ише маймыч белән ваклансаң, хурлыгы ни тора!

Мөхәммәт карашын Шонкарга күчерде. Монысы җиңү яулады, тантана итә инде. Шоңкар дигән исем йөрткән була, ә үзе үләксә чукыган козгын төсле. Тапкан корбан! Әле Минай хәтле Минай ханны әйләндереп төшерергә үрелә бу, әле Балак кебек эт-бетне дә кабып йотарга әзер. Мондый сайлап тормас, туймас тамаклы козгын аламасы булса, иртәгә Мөхәммәтнең башын да чукыячак бит бу. Юк, сабак бирергә кирәк мондый мәнсезләргә. Боларга гына түгел, Мөхәммәт хан ни кылыр дип көткән менә бу меңнәргә дә. Сабак алсыннар, гыйбрәт алсыннар, ә хәбәре мәмләкәтләр, олыслар, бәйлекләр буйлап китсен...

Мөхәммәт авызын ачты.

—Гали, Әкрәм!—дип кычкырды ул үзенең йөзбашларына.—Шоңкарны да кулга алыгыз! Аннары икесен дә кала читенә алып чыгыгыз да далага җибәрегез.

Бөтенесе күзләрен шакмак итте. Телләрен кайнар эскәк белән көйдергәннәрмени, көрмәкләнә-көрмәкләнә сүзләрен чак әйттеләр.

—Нич-чек, Бал-лакны ирекккәме? Ш-шул с-сатлыкны далага ж-җибәрикме?

—Ә Шонкарны нигә? Нинди гаебе бар?

Мөхәммәт ятлап куйган сыман, тукталышсыз тезде.

—Үч алу ул—кеше жанын ялт итеп кыеп ташлау гына түгел. Бу Балакны тотып астын икән, ул күз ачып йомарлык ара эчендә генә интегә дә котыла. Ю-у-ук, аны гомер буе газап чигеп яшәрлек иттерергә кирәк. Барып сыеныргга куыш тапмасын ул. Батса, үрелеп таяныргга яр тапмасын. Йорты, хатыны, балалары булмасын. Һәрбер кабым ашамлыкны үзе эзләп тапсын. Ахырда, инде дөмеккәч, хәтта кабергә индерерлек тә якыннары, туганнары булмасын аның. Гәүдәсен-башын этләр ашап китсен. Менә шул чагында катиллегенә, хыянәтенә жәза алачак ул!

—Ә Шонкарны, ә Шонкарны нигә куасың соң?—дип акылга килергә чакырып карадылар, Мөхәммәт тайпылмады.

—Хужасын бер мәртәбә сөзгән сыер иртәгә дә сөзә. Анын мөгезен сындырып кына яман гадәтеннән биздереп булмый. Ә бәйгә утыртылган этне әйткән дә юк. Бүген бер хужасын таласа, иртәгә янасына да килеп ябыша ул. Эт котырса, менәр төрле гоман корып тору артык. Димәк, бүре теше тигән ана, зәхмәт йоккан. Атай, мәрхүм, хикмәтле бер сүз әйтеп калдырган иде. "Бүре теше тигәнне бүрегә бирү фарыз". Шуна күрә менә мин Шонкарны бәйдән ычкындырам. Әйдә, ирекккә очып карасын. Теше сынгач кире кайтыр әле...

Балак жайдаклар кала читенә куалый башлагач ук күз яшенә батты. Шонкарның гына йөзендә төк тә селкенмәде. Ул мәйданнан тәмам чыгып югалганчы фәкать ханны гына усал, нәфрәтле карашы белән бораулап-ашап барды. Хушлашкандай, тыкрыктан кычкырган сүзләре ишетелде.

—Тугры этне кугач, өйгә угъры керә торган була.

Кешеләр теге якка да, бу якка да карап шаккаттылар. Бу көнне Мөхәммәт бик сәер, анын һичбер хөкемен аңлап булмый иде.

Шул ук Идел буендагы бер урамга күз-колак булырга жибәрелгән йөзбашлары Суардан килгән үзләренең үк туганын эләктереп кайтты.

—Унике яшьлек кызны егып тапалаган,—дип бәян итте ирләр.—Сабый өстеннән моны көчкә сөйрәп алдык.

Жинаятьче дер калтырап елый, ә үзенең гәүдәсе—кысып тотсаң жаны чыгардай ябык. Шушы өтекнең ишкәгенә дә көймә кирәккән бит!

—Ике каен ботагына моны!—дип үкереп жибәрде хан.—Монын ише ыштан бетләренең нәселе корысын!

Өтек ирне жиргә кадәр бөгелгән каеннарга бәйләп икегә аердылар...

Бәнжәдән чыгып китәр алдыннан бортасларны мәйдан уртасына жыйнап, Мөхәммәт хан аңлаешлы, усал итеп әйтте.

—Минаегызны саугат ясап Болгарга алып китәм. Яңаны утыртсагыз, тагын киләм. Моннан ары сездә таждар ханнар мәңге булмаячак. Сезгә ике генә юл. Йә Болгар тирмәсе янына килеп баш иясез дә гомерлек вә ышанычлы терәк табачаксыз. Йә... Манас кахан пычагы астына ятачак сугым маллары сез... Манас яклар, ул коткарыр, дип уйлап алданмагыз. Ул яһүди, анын сезнең белән уртак казан асып яшисе юк. Ә без мөселманнар. Манас ике авызлы түгел. Иңгә-иң кушылсак, кабып йота алмас.

## 12

Нуретдин сәрдәр әле Бәнжә каласыннан чыгып киткәнче үк Мөхәммәтнең колак итен ашый башлаган иде.

—Яулап алынган каланы жиңелеп хур булган халык кулына кабат ташламыйлар бит ул, бер әмир утыртып калдыр.

Кайтыр юлга чыккач ялга тукталган саен, ханның яшь хатыны өчен корылган чатыр авызына килеп, Нуретдин чебен сыман һаман безелдәде.

—Дилбегәсе бушатылган ат йөкне читкә сөйри. Бәнҗәгә әмир китереп утыртырга кирәк.

Мөхәммәт хан яшь хатын кайнарлыгыннан исереп өлгергән иде, берзаманны сынды.

—Ярар, син дигәнчә булсын. Минем малайлар бәләкәйрәк әле. Кемне утыртабыз?

Менә шул вакытта гына битлеген салды сәрдәр.

—Минем Рахманга егерме биш яшь тулып килә инде, әле һаман үзенә аеры сөяк кимереп караганы юк. Бүгенгәчә минем учактан калган күмер эчендә генә актарынып ята. Малай кешене вакытында тездән төшермәсәң, атасының сакалын йолка, диләр. Минем Рахманга да үз казанын асарга вакыттыр бит инде.

—Соң, сине сәрдәр итеп куйгач, болай да энекәшең Елкыны Кашан каласына утыртып калдырдым ла инде. Бәнҗәне Рахманның авызына каптырып, сезнең нәселгә ярты ханлыкны бүлеп бирикмени?—дип Мөхәммәт әүвәл каршы чыккан иде, Нуретдин пычакны икенче кабырга арасына китереп тыкты.

—Син Кашанга хәйлә белән чакырып Нур-Суардан коры калдырганчы, мин дәүләтнең иң бай әмире булып утыра идем. Биләр, Биләр, дисәң дә, пайтәхеттәге казнаның байлык-зурлык ягыннан Суар казанын узганы юк әле. Аннары Рахманга да, барыбер, гел минем табактан ашап, миннән калган киемнәрне киеп яшәргә димәгән бит. Алма ашыйсы килде дип кенә аның агачын җимеше яшел көе селкетмиләр бит ул. Пайтәхеткә киләчәктә хезмәт итәрдәй угылларны, агачка-гөлгә су сипкән шикелле, бүгеннән үк сыный-сыный үстерү хәерлерәк. Биләрдәме, Бәнҗәдәме, ул барыбер синең табаның астында олтан булачак кеше. Мин картаеп барам. Ходайныкын белмәссең, иртәгә аның минем урынга вәзир булуы бар.

—Әй, ник чукынып китмисез! Чапкын җибәр. Аллага шөкер, яусызнисез көенчә бортасларны куштык. Болай барса, мин Биләрдә озак утырам әле,—дип Мөхәммәт хан һаваланып-юмартланып кул изәде. Шушы беркатлылыгы белән үз башына никадәрле афәт чакырганын ул, әлбәттә, күзалламый иде.

...Инде тәмам ир булганнан соң гына әтисенең куенынннан чыккан Рахман Бәнҗәгә башта ук бер мең газилек нөгәр белән килде. Аерым вилаять хуҗасы булып алгач, беренче эше итеп, тирә-юньдә йөргән угызлардан, бәҗәнәкләрдән, кыпчаклардан янә ике мең газиле чиру туплап куйды. Моның чаклы гаскәрне, билгеле ки, кораллaндырырга, ашатырга, йоклатырга кирәк. Рахман озак-озак итеп баш ватмады, үзенең вилаятенә буйсынган барча кала-олысларга өстәмә салым җиткерде.

—Ике морҗа саен берәр елкы йә дүрт сарык! Зөлхиҗҗә ае кергәнче фәрман үтәлмәсә, олысларны үзем айкап чыгам!..

Акбүләк калачыгы вилаять чигендә, аның хуҗасы Арыслан бәк күбесенчә, карт каен кәүсәләре астына поскан җиләк үсентеләре, абагалар кебек, йә хәзәр яубашларына, йә аймык тарханнарына ышыкланыбрак яшәргә тырыша иде. Бәнҗәдә хасил булган яңа әмир фәрманын ишеткәч һич тә тәгәрәп төшәргә ашыкмады. Ә ул арада инде зөлхиҗҗә ае аяк атлады да, аяз көнне суккан яшен сыман, Акбүләк олысына Бәнҗә газиләре килеп керде. Чиру башында әмир Рахман үзе килгән икән. Арыслан бәк, меңәрләгән елкы көтүен куалый-куалый, яраннары белән шома гына итеп далага чыгып качты. Юк, Сакмар, Җаек елгалары буендагы бәләкәй урманнар артына кереп яшеренергә ирек бирмәделәр. Җаенке янаклы,

кысык күзле бәҗәнәк йөзләре куып китте дә, Арыслан бәк белән аның яраннарын мал көтүе урынына чыбыркылап, янә Акбүләк урамнарына алып кайтты.

—Әмир Рахман Бөтерчек Таш чишмәсе янына чатыр корган, синең баш иеп килгәнне шунда көтә,—диделәр.

Арыслан бәк тәгаен чамалады: яна әмиргә качак бәк кирәк түгел, ул Акбүләк хуҗасыннан икеләтә бүләк көтә инде. Бәйләнчек Саз буена күмгән алтын-мәрҗәннәр монда харам булыр, Акбүләктәге иң сылу кызларны җыеп илтсән дә өне тыгылмас микән?

Олыс бәге әзерләткән кәрван атларына илле кызны тезеп утырттылар. Кызкайларның күлмәкләре-җиләннәре ука җепләр белән чигелгән, чәчләрен кырыкмаса-кырык төрле вак-вак толымнарга аерып үргәннәр. Кыйгач кашлары, озын керфекләре сөрмәле, битләрендә иннек. Берсеннән-берсе чибәррәк шушы кызлар да ярамаса инде!..

Әмир Рахман аны ап-ак киез чатыр алдында, ак бәз япкан артлы кәнәфигә утырып каршылады. Алдан ук сөҗү әзерләп салганнардыр инде, ул әледән-әле керәч чәйнек борынын имеп-имеп куя. Күзе тонган, изүләре ачык, күкрәген йон баскан. Арыслан бәк тезеп куйган кызлар ягына караш та ташламады.

—Алар болай да минеке, соңрак өлгерермен,—ди.

Ә аннары инде Арыслан бәкнең бөтенләй ис-акылын алды.

—Синең яшь хатының бик чибәр икән бит, шуны апкил. Шәхсән үзең, үз кулларың белән китереп бир, аңладыңмы мине?..

Арыслан бәк вәлидә хатынын әмир Рахман чатырына кертергә мәҗбүр булды. Ләкин азгын белән убырның нәфесен бер йотым су белән генә басып буламы соң? Кайсы сатлыгы ничек итеп житкергәндер инде, чатырдан чыгуга Рахман иярго сикерде дә Актүбәгә, Арыслан бәкнең унбиш яшьлек кызы Ләйләны эзләп китте.

Гайшә исемле хезмәтче кыз мунча яккан икән. Ләйлә белән Гайшә икесе дә мунчада булганнар. Рахман шуларның өстенә барып кергән. Әүвәл ләүкә өстенә салып Ләйләне көчләгән ул, Гайшә ачыргаланып елый-елый читтән карап торган. Аннары: "Ә-ә, кызыгасыңмыни?"—дип кычкырган да, сикереп торып Гайшә өстенә күчкән...

Чатыр янына кире әйләнеп кайткач, ат шикелле кешнәп көлә-көлә, Арыслан бәккә боларны үзе сөйләде ул. Шушы килеш кенә калган булса, Арыслан бәк әле ычкынмас та иде. Ахырда әмир Рахман шыксыз тешләрен ыржайтып әйтеп салды.

—Яшь хатының да, Ләйләң дә, ай-яй, кайнар икән! Син мунча ягып, бал китереп торырсың, ә мин аларны, икесен берьюлы, берәр атна чамасы тагын кытыклармын.

Менә шул чагында, йодрыкларын төйнәп әмир өстенә ташлангач, Рахман сакчылары кылыч белән сынар кулын чабып өзде аның... Арыслан бәк беркадәр савыгып аягына басуга ук, ат атланып, далага чыгып китте. Әүвәл аны Бәйләнчек Саз буенда күреп калганнар, аннары кара аймыклар җәйләве ягында...

Биләргә хәбәр кайтты. Әле шул Акбүләк олысында чагында ук әмир Рахман белән ул үзенең баскын гаскәренә сәрдәр итеп куйган Булат арасында бик тә каты җәнҗал купкан икән. Сабанчыларның, елкы, дөя, сарык көтүе тотучыларның үкереп елавына түзә алмыйча сәрдәр Булат үзе башлап тавыш кузгаткан, ди.

—Өстәмә салым түләү турындагы фәрманыңны кире ал, болай булмый. Иртәгә бөтен гавам сиңа сөңге очына күтәрә бит.

—Юк, байгуралар бер фәрманны ике кабат кабатлар өчен дә, кире алыр

өчен дә тумыйлар,—дип җавап тотты нык кәпрәйгән Рахман.

—Син, әнә, үз артыннан биш йөз җарияле харәмханә сөйрәп йөртәсең. Гавамнан талап җыйган бөтен байлык шул җарияләр илә газиләргә китә. Дошман пәйда булса, чиру хәстәрләргә казнада бер динар юк. Сиңа ил кайгысына караганда харәмханә ятаклары кадерлерәк икән, алайса, бар инде, җарияләреннең итәк-чабуына каплан да ят.

Булат шулай тузынган-тузынган да үзенең йөзен иярتеп Бәнҗәгә кайтып киткән. Акылга утыртмакчы булып, Рахман аның артыннан өч йөз җайдаклы нөгәр юллаган, ди. Әмма тегеләре Булат әләме астына барып кушылганнар. Хәзер Булат Бәнҗәдә утыра, Рахман олыслар буенча типтереп йөри. Ни белән бетәр бу?..

Яз житүгә, шәрекъ ягыннан болыттай тузан куптарып, Болгар җиренә аймыклар чирүе бәреп керде. Юл йөртүчесен сынар куллы качак болгар карты, диделәр. Бу, чыннан да, Болгар илен яхшы белә бугай, аймыкларны иң яшерен инкүлекләр, үзәннәр арасыннан Биләргә таба алып килә башлады. Мөхәммәт янә тиз арада унбиш менлек чиру туплады да җайдакларны дошманнарга каршы алып китте. Тук Елга буендагы таулы-чокырлырак урында очраштылар.

Мөхәммәт хан алдан ук бер инкүлеккә кайсы ефәк, кайсы киез чатырлардан ыстан корып куйды. Ышанычлырак булсын дип, дистәләгән казан астылар, учак тергезделәр. Янда ике-өч йөз генә шәп тулпарлар белән сакчылар калдырдылар. Имеш, бу хәрби ыстан түгел, ә азык-төлек, корал, шайман, ганимәт* җыйналган олау һәм аны саклап йөрүче нөгәр генә.

Аймыклар шул кармакка эләкте. Меңбашлары, йөзбашлары камчы белән яра-яра тыюга карамастан, гади җайдаклар берсен-берсе сыта-сыта, меңәрләп-меңәрләп чатырлар эченә ябырылды. Үзара ызгыш-талаш, сугыш купты. Мөхәммәт нәкъ менә шул минутта тозакка куелган меңнәре белән аймыклар өстенә ташланды.

Болгар җиренә керергә җөрьәт иткән кадерсез кунакларны аяусыз турадылар. Аймык меңбашлары калдык-постык йөзләрен алып качарга мәҗбүр булды. Мөхәммәт каршына сынар куллы дәрвишне тотып китерделәр.

—Кем буласың?—дип кенә сорады тимер битлек киеп алган сыман кырыс йөзле хан.

Дәрвиш һич тә коелып төшмичә җавап тотты.

—Элек Арыслан бәк идем, хәзер колчурамын. Синең җәлладларың йортсыз калдырдылар.

—Кем рәнҗетте сине?

—Синең язгы боздай ышанычсыз вәзиреннән улы.

Мөхәммәт хан бераз вакыт кына ияр өстендә уртларын уйнаклатып утырды да уттай көйдерерлек карашын янә Арыслан бәк йөзенә күчерде.

—Мин хата җибәргәнмен, мәгәр ул төзәтердәй. Ә синең гаебеңне, менә шушы чулак кулың кабат үсалмаган шикелле ук, төзәтә торган түгел, Арыслан... бәк. Син сынар кулыңны дәүләт тикле дәүләткә алыштыргансың. Сиңа үлем җәзасы тиеш, гафу кылу кәтмә...

Бераздан чатырлар артында кисәк кычкырып җибәргән тавыш ишетелде дә бер мизгелдән тынды. Мөхәммәт җансакчыларына борылып әмер бирде.

—Бәнҗә илә Кияү каласына чапкыннар җибәрегез. Булат сәрдәрне Бәнҗәгә әмир итеп куям. Ә атам юллаган Даян мәргәнне алыштырырга вакыт. Чит мәмләкәт йөрәгенә үтеп, аларның бар серен аңлый белә торган сәйяхчеләребез бик күп түгел безнең. Нуретдин вәзир, әнә, бер улын да

* Ганимәт—трофей.

йөгәндә тота алмый, нык картайды. Бәлки, Даян мәргән анын дилбегәсен үз кулына алыр. Тизрәк кайтарыгыз...

Болгар гаскәре һаман бер урында таптанды, ә аймыклар далаларына кайтышлый чик буендагы авылларны кырып узган икән. Жаек ягыннан килгән ул хәбәрләр бер дә сөенечле түгел иде.

—Сиксән авылны яндырып юк иткәннәр. Кыр-яланда карт-корылар гына утырып калган. Яшьрәкләрнен барчасын да Хорасан базарына колчура итеп сатарга алып киткәннәр, ди.

13

Шәрекъ яктан искән ачы җилгә каршы кәрван бара. Кол итеп алынган болгарларны Хорасанга илтүче аймыклар кәрваны ул. Болгарларнын кулларында зынжыр, муеннарына озын бау тагылган. Көчле жил, дала буйлап куып, әллә нинди тозлы ком алып килә. Ул күзләргә, борынга, колакларга тула. Ышыкланырлык әмәл табып булмый. Бер-берен артына ельыша башладынмы, кәрванбашка сакчы булып ялланган угызлар сыртына камчы белән сыдыра, йә сөнге очы белән китереп кадый. Сакчыларнын һәммәсе дә ат яки дөя сыртына атланган, аларга тубык тинелтен ком сазлыгын ерып жәяү атлыйсы түгел. Рәхәтләнеп йокымсырап баралар-баралар да, күзләрен ачтыларвы, жен алыштырып куйган шикелле акырып, алга куалыйлар. Һәммә колнын сыртында камчы эзе, сөнге ярлары. Киемнәре телгәләнеп беткән, умырылып төшкән. Мондый мохтажлык, жәфа, кимсетелүләргә түзәрләр иде әле. Ин яманы—эчләре сыртка береккән, тамак төпләре ут яккандай корыган. Һәммәсенен су эчәсе килә. Бер генә йотым булса да су бирсеннәр иде. Су кирәк аларга, су, су, су...

Байдар инде ничә көннәр буе аяк астына карамаска тырыша, янда ятып калган тауларны, чокырларны, үзәннәрне күзли. Аяк астына төбәлсән, баш әйләнә, егылуын мөмкин. Егылдынмы, сакчылар сөяк күргән ач эт көтүе шикелле котырынып өстенә ташлана. Жаек, Иләк, Үр елгалары буенда инде ничәмә-ничә дистә болгар ятып калды. Кәрванбашка Хорасан базарында сатарга таза ирләр, чибәр кызлар кирәк. Чирлеләр, ябыклар, гарибрәкләр ана берни түгел. Сакчылар аяктан егылган хәлсезләрне кыйный-кыйный куалап карыйлар да, өмет булмадымы, үләксә урынына ташлап калдыралар. Ярамый монын ише юлда егылырга, ярамый, ярамый.

Ә тирә-юньне ятлап, хәтер сандыгына салып калдырырга кирәк. Кол итеп базарда сатылуга кадәр барып житмәс Байдар, барыбер качар. Кол хәленә калып, тез өстендә йөреп, адәм хуры булып яшәү өчен туып үсмәде ул. Ул гаиләдә берденбер бала иде. Әтисен әле Байдар сабый чакта ук хәзәрләр белән яуда үтерделәр. Әнисенен күзе кылый иде, аны янадан кияүгә сорап килүче адәм табылмады. Шул, әнисенен йөзендәге кыек өчен малайлар бәләкәй чактан бирле үртәп йөргәннәр иде дә, Байдар алар арасында ин эре гәүдәле, усал йодрыклы малай булып үсте. Бер-икесен егып чирәм ашаткач шундук тукталылар. Байдар әле аннан сон да гел сугыш чукмары булды, ташбаш булды. Ауга чыккач берәр авыл егетләре белән туры килделәрме, кадрәклеләр аларны дөмбәсләргә гел Байдарны алга чыгардылар. Олыскүләм кубып уздырылган бәйрәмнәрдә аркан тартыш, көрәш, баганага менү, таш ыргыту буенча бәйге оештырдыларвы, күп очракта Байдар жинеп чыкты. Арттан баш түбәсенә күсәк белән китереп ормасалар, аймыклар кулына да төшми иде ул, унын-егермесен тал чыбыгы урынына турап ата иде. Хәер, базарга юл ерак, ана хәтле барыбер качачак ул...

Тугыз коймак дигән тәбәнәк кенә таулар ышыгына килеп егылгач,

торгаклар-кушчылар* саксыз-күзәтүсез калдырдылар аны. Шушы урынга житәрәк кенә ике җәйран атып алганнар иде, ялга тукталгач, шуларның тиреләрен тунаганны, казан асканны аю биеткәндәй карарга җыелдылар. Берәве ит турый, икенчесе корыган карама, чаган, зелпе ботакларын сындырып ташый. Гел җәйләүдә, гел елкы көтүе көтеп үскән бер яшь аймык кубыз чиртергә дә тотынды хәтта. Чирәмгә тезелешеп утырган колларда гамьнәре юк.

Тыныч, ямьле урын бу. Бер якта түбәтәй шикелле бәләкәй генә, йомры таулар. Икенче якта өстен яртылаш тәнбоеклар каплаган озынча күл. Исемен Акборын диделәр, туры килә. Әнә бит, очлаеп торган бер башы тоташ ак ташлардан гына хасил ярымтүгәрәк ярга килеп төртелә. Житмәсә, яр өстендә тагын ялтыравыклы укалар белән катнашкан ап-ак ташлы озын калкулык бар. Валлаһи, Акборын бу.

Торгаклар болгарларның бауларын-зынҗырларын төнгелеккә дә салдырмаган иде. Байдар баудан ычкыну жаен күптән уйлап тапты. Янындагы ике колны алмаш-тилмәш итеп култык астыннан үткәрәсең дә, үзең ычкынасың. Дөрес, алай иткәч теге ике күршеннең муен тирәсендәге төеннәре тагын да тыгызланыбрак, өелеп кала. Ләкин аларны да яндагы янә күрше белән әвеш-тәвеш китереп ычкындырып була. Чылбыр буенча шул рәвешчә китсәң, барлык әсирләрне дә "муенчак"тан азат итү мөмкин. Тик һәммәсе дә риза булалармы әле әсирләрнең, куркып калалармы? Уен-муен түгел, эләксәң, кылыч астына ятуың да бар бит...

Төнлә чышан-пышан килеп уяткач, ике яктагы ир дә Байдар тәкъдименнән куркып баш тартты. Берсе сүгенүдән дә тыелып тормый.

—Ычкынып, ананның итәк астына кереп качасыңмыни? Ул да юк, ичмаса. Ә монда бөтен тирә-якта дала. Уч төбе шикелле, ун чакрым ара аермачык көе күренеп тора. Куып житәләр дә тураклыйлар. Аннары гәүдәңне йә чүл бүресе, йә козгыннар талый. Пычагыма кирәк. Харәземдәме, Бохарадамы, кем генә сатып алмасын, кайда да барыбер мич салам мин. Бохарада салдын ни дә, минем кечтеки Сарсазда салдың ни, мина аерма юк, шул ук кирпеч. Син теләсә нишлә, ә мин качмыйм.

Икенчесе егетнең бала башы кадәр булып кысылган йодрыкларыннан шөлләп калды, ахры, анысы сугым малы сыман бөтенләй дәшми ятты. Байдар берүзе купты. Төнге торгаклар божрасыннан шуышып чыккач ерак качмады ул. Акборын ярыннан әүвәл сөяк төсле каты булып кипкән көпшә сындырып алды, аннары чупылдатмый-селкетмичә су төбенә чумды.

Иртән, иң беренче булып, әлбәттә инде, төнге торгаклар оран салып гаугa кузгаттылар.

—Болгар пәһлеваны качкан! Бер кол качкан!

Тирмәдән сикереп чыккан кәрванбашы кул астына эләккән бер-ике торгакны тотып ярды.

—Ул пәһлеван—дөя бәясе торырдай кол иде. Тапмасагыз, мин сезнең үзегезне базарга чыгарып сатам!

Торгаклар күл тирәли йөгерешә башлагач, шул ук кәрванбашы дөя шикелле үкерә-үкерә әмер бирде.

—Иягә менегез дә, әнә, Карагач үзәненә таба элдерегез! Бу якта адәм качып калырдай башка инкүлек юк. Качса, шул якка гына китә. Тапмый кайтсагыз, асам!..

Әлбәттә, чапкыннар Байдарның эзен дә тапмый кайтты. Кәрванбашы күңелен бушатыр өчен генә тагын икеме-өчме торгакның сыртына камчы белән сыдырды-тамызды да алга кузгалырга әмер бирде. Шулай да, киткәндә

* Торгак—сакчы, кушчы—кәрвандагы хезмәтче яки кол.

үкенеп, ярымсыкрап дәшкән сүзләре күл өстендә янгырап торды әле.

—Дөя бәһасе байлыкны кулдан ычкындырды, кадалгыры сукбай!..

Байдар төнбоек яфраклары астыннан чыккач та байтак вакыт буе дала өстен, офыкны күзәтеп утырды. Бер якта да тузан күренмәгәч кенә тәвәккәлләп яр өстенә чыкты. Ярты төн буена су эчендә утыру нык тундырган иде. Башта керпе сыман йомарланып барырга мәҗбүр булса да, ул бераздан җылыну өчен йөгерүгә күчте. Ничә тәүлек буе юньле ризык күргәне юк, җеп өзәрлек тә хәле калмаган шикелле, ә барыбер ашыгырга кирәк. Дала-дала дисән дә, сәүдә юллары бу. Әллә нинди этләр-сыртланнарнын иснәнеп йөрүе мөмкин. Кулларына килеп каптынмы, беттен. Янә зынҗыр синен кулларына, янә камчы.

Ике тәүлек чамасы алпан-тилпән килеп атлый торгач, ул тоташ вак ташлардан гына хасил ике тау арасына качып урнашкан бер бәләкәй алачык өстенә барып чыкты. Киртә-казыкларны элдe-ялды гына бәйләп ясалган ихатада иярләнгән ике чаптар әллә солы, әллә арпа чемчи, шулардан кала алачык тирәсендә бер җан иясе дә күренми. Нинди сәер ыстан бу, хуҗалары кайда? Ачыгавызлы сукбайларны коллыкка эләктерергә йөрүче кушчылармы болар, әллә аймык, угыз, кыпчак яубашларынын шымчы чапкыннарымы? Болгар өстенә яна каза чакыручы саесканнар булмаса ярый тагын.

Байдар чокыр-чакырлар эченә кача-поса киртә ихатага таба якынлашты. Көтмәгәндә борынына кыздырган ит исе килеп бәрелде анын, башы әйләнеп китте. Их, бер генә кисәген булса да эләктерәсе иде шунын, тик кайда ул?

Киртәләр артыннан гына калкып чыккач, ике чаптар да өркенеп ялгаш аламасыннан читкә сикерделәр. Өзәнге-авызлыклары чынлап куйды. Байдар янә бер таш артына посты. Юк, алачык эченнән һичбер төрле аваз ишетелми, үләт кырганмыни?

Байдар ихата эченә сикереп керде. Алачык нигезе янында урталай чабып ташланган эт гәүдәсе ауный, янда ит белән дөге боткасы салынган агач җамаяк тора. Нишләп ризыгын да ашарга өлгермәгән бу мескен, нигә юк иткәннәр? Дүрт аяклы хайваннар беркатлы һәм эчкерсез сантыйлар бит. Ике аяклы җанвар бер кабымлы ризык күрсәтсә дә, шуна алданып, койрыкларын болгый-болгый чабып килергә генә тора. Бу бичаранын да шул нәфсе, тәгам дигәннәре башына җитте микән?

Уйланып, баш ватып торырдай ара юк иде. Капылт сикерде дә Байдар әүвәл җамаякны эләктереп алды. Икенче мизгелдә ул инде өзәнгеләргә дә басып тормыйча бер чаптарнын иярено менеп алган иде. Киртәләр аша сикереп кузгалырга җыенгач, яшен төсле уй көйдереп узды.

—Икенче чаптарны да иярмәсәм, болар куып житә.

"Нигә әле мине сайламадын?"—дигән сыман үзенә томырылып карап торучы икенче чаптар йөгәненә үрелгән генә иде, артта кырыс дәшкән аваз янгырады.

—Нәфесен тишек капчык кебек икән синен, угры. Ә мина ни кала?

Өшәнеп артына борылса, кызлар кебек нечкә билле бер ир басып тора. Өстендә күлмәк тә юк, ә кулында угын корган җәя. Әлеге юлчы берәр чишмәгә йә якындагы күлгә барып юынгандыр инде.

—Төш, җанынны орыйм!—диде ул усал итеп.—Адым саен ат өләшеп йөрергә син мине хан дип белденме әллә?

Сөйләндереп уяулыгын йоклатырга кирәк, дип уйланды Байдар. Сынар аягын өзәнгедән ычкындыруга ук телгә килде.

—Көмешләнгән иярле икешәр ат тоткач, бик үк хәерче дә түгелсендер инде. Син минем сымак бер җамаяк эт ашына калган мескен сукбайга охшамаган алай.

—Ха-ха-ха!—дип көлде күнеле булган җайдак.

Икенче мизгелдә ни булганын ул аңламый да калды. Әүвәл аның чыраена ботка тулы җамаяк килеп бәрелде, аннан угры сукбай, аю сыман сытып, өстенә менеп ятты.

—Син кияүгә бирәсе кыз түгел лә, юха телгә нигә алданасың?—дип сөйләнде Байдар. Һәм әллә каян гына бау кисәге тартып чыгарып, атлар иясенең кулларын бәйләп куйды. Җәяне иңбашына киеп алган Байдар бераздан инде янә ияр өстендә утыра, баягы хуҗа тузан эчендә аунап ята иде.

—Үпкәләмә,—диде Байдар хушлашкандай.—Бер атыңны алам. Мин син уйлаганча ук убыр түгел. Берсе сиңа кала... Куа чыкма. Ханны озаткан сымак иярәп йөрүләрен җенем сөйми.

## 14

Җаек елгасын кичеп Болгар чигенә кергәндә, таудагы куакларга ышыкланып барган җайдакны шәйләде ул. Ара шактый ерак, шулай да, җайдак япа-ялгыз, моңа шик юк. Ашыкканы-көйгәне сизелми, аты кунактан кайтып килгән шикелле юыртып кына бара. Җайдак үзе зур гәүдәле түгел, өзәңгеләр ат корсагы астына асылынып тормый. Иңбашына җәя генә элеп алган сыман, һәрхәлдә сөңге очы, чукмар ише коралы күренми. Нинди пошмас сукбай бу? Нишләп бер аягын атлаганчы икенчесен эт ашардай үшән?

Байдар чаптарын куләгә яткан инкүлек эченә төшерде һәм, җеп белән тагылгандай, сәер җайдакның эзенә басып бара башлады. Чаптарын аз гына кыздырып алган иде, ара якынайды. Бу кеше белән уртак казан асасы юк әле, дип уйлап, атын тыя төште. Карашын аермыйча гел күзәтте. Әллә нинди сәер, әкәмәт кеше бу. Тау итәгендә түтәлдәй укмашып утырган миләүшәләр, кыңгыраулар, кызалаклар янына килеп җиткән иде, иярennән сузылып, алты-җиде чәчәк өзеп алды. Шуларны әүвәл исни-исни иләсләнеп барды, аннары юргасының ялына үреп куйды. Әллә хатын-кыз инде бу, каһәр суккан?! Гәүдәсе дә кечкенә, коралы юк. Алай дисәң, нигә ирләр киеменнән? Ни өчен ялык-йолык килеп торган көмеш очлым кигән? Ул кәрванынnан адашып калган берәр байчура кызымы соң әллә?..

Үзәнлекләр эченнән сузылып бара-бара, көзге сыман ялтырап яткан күл буена җиттеләр. Тирә-юненә эреле-ваклы балан, чикләвек, чаган куаклары тезелеп киткән. Яр буенда камыш, сарут, кыяк. Әз генә җил истеме, күлнең өсте су анасы тараган сыман шадраланып китә. Ә суы күк йөзе шикелле зәп-зәңгәр, чип-чиста, үтә күренмәле. Ара-тирә балыклар да сикерешеп куя. Җәннәт бакчасы дигәннәре менә кайда икән!

Сәер җайдак яр буена килеп җитүгә үк, як-ягына каранып та тормыйча, өстен салып атты. Чит көтүгә иияргән бәрән сыман тагылып килгән Байдар чаптарын зирек агачлары ышыгына кертеп яшерергә өлгергән иде инде, үз күзләренә үзе ышанмыйча, авыз ачып калды. Менә хикмәт!

Алты-җиде дилбегә арасы ераклыкта бер кыз басып тора. Өстендә тасма да юк. Толымнарын иңбашыннан төшереп күкрәгенә салган. Түм-түгәрәк, нәни күкрәкләре алма шикелле тырпайган. Ике учка сыеп бетәрдәй бил. Җәйрәннәрнекенә биргесез озын, матур ботлар. Уртада йөрәгеңне күкрәгеңнән суырып алырдай булып ымсындырып торган гөлҗәннәт... И-их, сылулык! И-и, бетмәс-төкәнмәс, әкияти зиннәт!..

Кыз бишектәге сабый баланың күз яшьләредәй керсез, чиста сулы күл төбенә чумды. Балыкмыни, ничек оста йөзә! Су өстендә әле ап-ак мендәрләре ялтырап ала, әле нәни алмалары калкып чыга. Байдар йөрәген учына кысып ята. Алгысынма, түз, егеткәй, түз! Син юлбасар түгел. Шулай да, и-их, тагын бер мәртәбә су өстенә калыксын иде бит инде! Аһ, бу каһәр!..

Яр өстендә аның киемнәрен кочаклап торган чит-ят ирне күргәч, сылу кызый чирәм өстенә чүгәләде дә чәр кычкырып җибәрде.

—Әй-яй-я-ә-әй!

Бер мизгелдән кызый яна төрле кубыз җыры кушты.

—Аб-бау, аб-бау!

Байдарнын авыз ера башлавын күргәч, кешечә сүз катты.

—Әллә коралы юк дип, тотып көчләргә җыенасыңмы, норсыз? Килеп кенә кара, менә сиңа!

Кызның кулында нәни генә хәнҗәр пәйда булды, Байдарнын күзләре мангаена менде. Кайдан суырып чыгарды, кая яшергән ул?

—Курыкма, мин сиңа кагылмыйм,—дип Байдар үз тавышын белдерде.—Сине кызык итмәкче идем, киемнәреңне шуна гына алдым.

Кызга да җан керде, тавышы юньсез кайнаналар мырлавына охшап, хәтәр усал чыкты.

—Нигә үзеңнеке сыман кочаклап торасың соң? Бир алайса.

Киемнәрне алга сузып килгән егетнең ерык авызына карап алданды кыз. Күнеле су өстендәге балык шикелле уйнаклаган Байдар аны болан баласы урынына каптырды да күкрәгенә кысты. Карашында бернинди этлек, явызлык, мәкер юк иде бу егетнең. Тик эчкерсез, самими хисләр генә дә, назга сусау. Шуны тыя алмыйча, гөлгә кунган бал корты шикелле, аның сусыл иреннәренә капланды егеткәй. Җир чайкалып китте...

Айныгач, чирәм өстенә сузылып яткан көенчә таныштылар алар.

—Сания,—диде сылу үз исемен.—Җүкәтау каласыннан. Шундагы Мирас атлы кешенең кызы булам. Әткәй-әнкәй янына гына кайтып булмый. Әллә ничә айлар буе качып йөрим инде. Гел-гел берьялгызым. Син минем янымa сиздерми якынайган тәүге кеше. Нигә качам? Анысын син сорашма. Мин би-и-ик хәтәр кеше. Сиңа минем белән янәшәдә йөрү ярамый. Тоттылар исә, сиңа да, миңа да йә дар агачы, йә караңгы зиндан.

Байдар кычкырып көлде.

—У-һу-һу! Алай бик куркыныч булгач, мин синнән калмыйм да калмыйм инде. Синең ише хәтәр кеше белән бергә яшәү үзе бер юаныч, үзе зур дан. Аннары, мин синең мондый татлы иреннәреңнән ничек аерылыйм ди?

Күләгәдә үскән гөл шикелле җылылыкка һәм назга сусаган иреннәр тагын-тагын бергә кушылдылар. Күл буендагы мамыктай чирәмнәр дә яшь кияү белән киленнең тән җылысын, назларын таратмаска, сакларга тырыша иде сыман. Хәтфә үлән сабаклары әле байтак вакыт буе бер дә турaеп басарга ашыкмыйча ятты...

Бауга бәйләнгән шикелле һәрчак бергә йөргән бу ике җайдакны соңыннан йөзәрләгән чапкыннар, дәрвишләр, сәйяхчеләр күрде. Ләкин берчакта да алар янына якын килә алмадылар. Болар офыктагы өрәк сыман иде. Сәер риваять туды.

Имеш, бер явыз хан нindидер сылуны очраткан да аның фирүзәдәй зәп-зәңгәр күзләрен күреп сихерләнгән, кулын сораган, ди. Кызның читтә сөйгән егете булган, ул баш тарткан. Шуннан хан бу чибәрнең күзләрен чокып алырга боерган, ди. Җәлладлар кызның кулына ябышып өлгергәнче, күк йөзеннән канатлы атка атланган егете килеп төшкән. Кызны алган да янә күккә, ак болытлар өстенә менеп киткән. Хан сихерләп өлгергәндер инде. Кызга чит-ят кешеләр якынаеп йөзенә текәлсәләр, сылуның күзләрендәге фирүзәдәй гүзәл зәңгәрлек юкка чыгачак та, бу кәләш шул минутта сукыр әбигә әйләнәчәк икән. Менә шуңа күрә бер дә кешеләргә якын килми ди алар. Хәвеф-мазар туса, егет кызны канатлы атына утырта да күк йөзенә күтәрелә икән. Шулай да бик бәхетле булып яшиләр, ди...

## 15

Көннәр, сау-сәламәт кеше сулыш алган төсле, сизелми дә узып тора. Тау сыртларын каплап алган имән-өрәңгеләр, чөкердәшеп утырган яфракларын койгач, кылыч-сөңгеләрен тырпайтып дошман чирүен каршыларга әзерләнгән яугирләр төркеменә охшап калды. Ерактан күзәткәндә яугир-агачларның кыяфәте хәтәр. Аларның һәммәсе дә йөзәр куллы, мең бармаклы сыман...

Җиһанга көз керә. Ул фәлән еллар буе сәйяхлыкта йөргәннән соң гына кәләш изүенә борынын төртү бәхетенә ирешкән яшь кияү шикелле бөтенләй акылдан ычкынды, күрәсең. Әнә, бүген дә җил әле җиргә ятып исә, әле тәртә арасына тәүге тапкыр җигелгәч арт аякларына күтәрелеп чыгымлаган ярсу байтал кебек өермә ясап дулый. Шәрекъ яктан, Җаек дәрьясы буеннан купкан пырдымсыз җил инде бу. Ә җил-давыл мондый чакта кояш чыгышы тарафыннан истеме, бетте диген. Болай булса, көз бик озакка сузылачак икән. Шундый сынамыш бар, картлар шулай диләр.

Байдар бөтен тәнен борча талаган шикелле кыбырсына, бер урында утырып тора алмый. Әле быелгы җәй уртасында гына бастырып куйган алачык тирәли ничәмә-ничә кабат урап чыкты инде. Бу—алачык кына түгел-түгелен, Кадрәктәге байтак кешенең борынына төртерлек өй инде ул, ләкин Байдарның алай олыдан кубып сөйләнергә бер дә теле бармый. Шунын карындык тарткан тәрәзә аламасына бара да төртелә, бара да төртелә. Әмма алачык-өй ишеген ачып эчкә уза алмый. Аны бүген казан тирәсендә комачаулап йөргән ялкау килен урынына сыпырып чыгардылар. Хәзер дә әле рөхсәт бирүче юк. Аннары... иң мөһиме... эчке яктан тилмереп көткән сабый тавышы да ишетелми һаман. Байдарның хатыны бала таба бүген. Сания бәгырькәе ана бүген сабый бүләк итәчәк!

Яландагы җил-давылга төкерми дә Байдар. Аның үзенең күңелендә ут давылы, үз эчендә туфан. Мичкә ташлаган әрдәнәләр инде күптән янып беткәннәрдер. Күбесенчә усак утыны ыргытып чыкты бугай. Ә усак—айлар буе киптерсәң дә мәңге чи инде ул. Ирдән уңмаган хатын шикелле яшереп кенә, чыш-пыш килеп кенә елый-елый, күз яшьләрен агыза-агыза әллә кайчан юкка чыкканнардыр. Җитмәсә, әнә, җиле дә бик усал, салам түбәнең итәкләрен кыз-кыркын янында бөтерелгән шук малайлар шикелле күтәреп-йолкып исә. Сания салкын сәкедә аунап интекмәсә ярый әле тагын.

Байдарның хәтер сандыгы бала бишеге шикелле уйнаклап-биеп ала. Өй эчендә башка төрле китек-җитешсезлек юк та сыман. Елан-чаян үтеп кермәсен дип, Байдар әле җәй уртасында ук нигез тирәли ат кылыннан үргән аркан сузып чыкты. Сәке өстенә, мич башына печән түшәгәнче, ямь-яшел көенчә кычыткан чабып салды. Болай иткәч, печән астына тычканнар гына түгел, таракан-кондыз да үтми. Карындык тәрәзә, ишек ярыклары бәрән тиреләре белән томаланган. Җылы сулар, зур җамаяк әзер. Кендек бәйлим дисә, кыл өстәлдә... Күз алдыннан кичергәндә ямалмыйча калган ертык бетте бугай инде. Мәгәр Саниянең тагын кайсы яклап җаеннан торырга кирәген ничек белмәк кирәк?

Болай да иртәдән бирле сытык чырай белән генә йөзгән кояш катлы-катлы болытлар арасына кереп качкач, янгыр җир өстеннән әүвәл имче карчыклар шикелле төкеренгәләп кенә үтеп киткән иде. Ә аннары шәрекъ яклап ялтыраган яшен кылычы күктәге күлнең төбен урталай ярды бугай, дуамалланып-шашып, тоташ су дәрьясы коярга тотынды.

Байдар бүген дә шул җил-янгырдан качып, тәүге айларда үзләре яшеренеп яткан тау куышына кереп поскан иде. Шуның авызыннан галәмне күзәтә-күзәтә онытылган, ахры. Аяклары бер оя кырмыска ябышып талагандай

кымыржый башлагач кына, оеган тәнен яза-яза урынынннан купты. Аh, син, жансыз бүкән! Ә Сания анда ярдәмгә чакырып ятса?

Үзе алачык дип мыскыл иткән тәбәнәк өй каршына йөгереп килүгә үк тайгак боз өстендә калган нәни бозау сыман коелып төште Байдар. Ярабби, Ходаем! Тәрәз аша дөньяга менә мин дә тудым, дип, аваз салып яткан сабый бала тавышы ишетелә. Елавы да "ник кермисең, ник күрмисең, атай?" дип, шелтә белдереп чакырудыр сыман.

Тупса аша шөлләп кенә узса, Сания күптән аягына баскан, агач жамаяк өстендә бала юып йөри. Үзе чиксез өзлеккәндер, талчыккандыр инде, ә йөзе тәүге кар каплаган жир өсте шикелле тик елмаеп тора.

—Безнең улыбыз бар,—диде Сания, күз карашы белән наз һәм бәхет сибеп.—Беренче булып, сина иш булырга тугандыр инде ул.

Байдар әле һаман телен йотып, зәхмәт суккан сыман кымшана алмый басып тора иде. Баш түбәсендә, әйтерсең, ут кайный, кайнарлыгы бөтен тәнне көйдерә. Яланга йөгереп чыгып, яшь тай, ярсу ат урынына тузынасы, иләсләнеп-илереп кычкырасы, сикерәсе килә. Ә анын, ни гажәп, кыл кыймылдатырлык та куәте-жегәре юк.

Янә Саниянең иплэп әйткән тавышы ишетелде.

—Йә, улынны тотып кара, кулына ал инде.

Байдар, гомер буе балчык чүлмәк ясаучылар янында йөреп, хәзер менә бәллүр касә, алтын каурыйлы кош тотарга әзерләнгән өйрәнчек малай сыман, уч төпләрен күлмәк итәкләренә тиз-тиз ышкып алды. Аннары сонга калудан курыккандай ашыга-ашыга, кулларын алга сузды.

—Авыр ул,—диде Сания, мактангандай итеп,—валлаhи, баhадир бу, үзенә охшаган инде.

Күзгә шомырт яфраклары шикелле кып-кызыл, йоп-йомры тәнле нинди матур сабый! Үзенен жир бәhасе, галәм бәhасе икәнен белеп торамыни, әле дымы да кипмәгән нәп-нәни иреннәре арасыннан телен чыгарып елый. Ата кулын, ата кайнарлыгын сизгәч кенә жиhандагы бу мизгелнен никадәрле мөhим, никадәр жаваплы булуын анлап өлгерде диярсен, беравык авызын йомып, Байдар күкрәгенә таба борынын төртеп алды. Аннары "йә, артык сикеренмә, житеп торыр сина", дигән сыман, түшәм күтәрердәй итеп элекке жырын сузды. Ләкин тилмереп көтеп алган газиз баланнын елавы мич артында сайрашкан чикерткәләр тавышы гына түгел, ул күпме тынласан да туйдырмый икән бит, и-и, әкәмәт!

—Ун кадак чамасы бардыр, валлаhи, авыр бит бу,—дип, ниhаять, Байдар да авыз ачты.

—Сон, син баhадирдан баhадир тумый инде,—дип, Сания дә форсат чыгудан файдаланып ирен үсендерердәй сүзләр табып алды. Аннан кулын сузды.

—Йә, житте, бир. Малаенны имезергә вакыт.

Сабый әнисенен күкрәгенә чәчәк тажына кунган корт шикелле ябышып байтак чупылдады. Күнеле булгач, белеп торыгыз, мин менә болай да итә беләм әле, дигән сыман әнисенен итәгенә сытык күз яшьләредәй чишмә челтерәтте дә, икенче минутта ук бер якка янтаеп йокыга да талды. Байдарнын инде дә түземлеге коргаксыган иде. Ялан уртасына колын шикелле уйнаклый-уйнаклый, кушаяклап чабып чыкты да, бар жиhанны уятырдай итеп, иләсләнеп-янып кычкырды ул.

—Минем ма-ла-ем ба-а-ар! Минем улым туды-ы-ы! Бүгеннән башлап мин дә атай хәзе-е-рр!..

Кич житкәч, өй нигезенә салган коры зирек бүрәнәсе өстенә Сания белән житәкләшеп чыгып утырдылар. Яңгыр-давыл үткән, бөтен ялан тып-тын. Гөнаhларын-керен юган чирәмлек өстеннән яна сауган сөткә охшаш

бу күтәрелә. Һава барча кунакларын озаткан мунча эчедәй жылы. Күк йөзенә эреле-ваклы йолдыз тутәлләре сибелешкән. Егетләре утырмага килүгә үк шаяруга күчкән мут кызлар шикелле үзара күз кысышып уйнаганнары да байтак кына. Ком белән ышкып чистарткан жиз табак шикелле яп-якты, түм-түгәрәк ай да бүген үзенең сагышын онытып торган, ахры. И-и, дөньяның илаһи һәм камил минутлары!..

—Улыбызга Зәбир исемен кушарбыз инде,—ди Сания, иренең кочагына сенеп.—Шундый бер бәхетсез көтүче турында ишеткән бар. Ул күрше кабиләдәге Зөбәржәт атлы сылуга гашыйк булган, тик теге кызның абыйлары мона каршы төшкән икән. Егет Зөбәржәтне көн саен күрер өчен аларның авылына килеп ялланган та риза булмаган аның абыйлары. Зәбирне әүвәл чыбыркылар белән тотып ярганнар, ди. Егет ниятеннән кайтып ант итмәгәч, далага чыгарып, ялгыз чаганга бәйләп куйганнар, ди. Өстән кояш кыздыра, һәрьяктан жил талый, ә мона бер йотым да су бирмичә озын көннәр буе жәфалаганнар, тилмерткәннәр. Ул гынамы әле? Берзаманны, һәр кич саен, әллә нинди гриф дигән явыз кошлар килеп, монын күкрәген тишкәли, йөрәген кисәк-кисәк итеп чукый башлаганнар. Зөбәржәт бу хакта ишетеп килеп житкәндә Зәбир инде соңгы сулышларын алып яткан булган. Барыбер дә, соңгы сүзе итеп, сине генә сөям, сине күктә көтәм, дип әйтергә өлгергән, ди, бичаракай. Бәхетсез Зөбәржәт шуннан соң киек казга, ап-ак кыр казына әверелгән дә, күк йөзенә ашкан. Ә-ә-ән-ә, күрәсеңме, чишмә суындагы чуерташлар кебек бер-бер артлы тезелешеп киткән йолдызлык бар. Әнә, башкалары арасында алар яп-яктылар. Киек Каз Юлы, ди аларның исемнәре. Зәбирнең жаны аны эзләп менсә адашмасын, таба алсын өчен, Зөбәржәт үз каурыйларын күз яшьләре белән сөртә-сөртә шул рәвешчә чәчеп барган икән. Бер-берсен эзләп табып кавыша алмаган бәхетсез ярлар әле хәзер дә шул Киек Каз Юлына карап табыналар икән...

Пәһлеван гәүдәле Байдар да көтелмәгән риваятьтән ару гына тәэсирләнде бугай, сүз кайтара алмыйча озак тын утырды. Ә авыз ачканда ир-атның шул, үз кырыгы кырык иде инде.

—Юк, Зәбир турындагы хикәят безгә ябышмый, хатын. Зәбир белән Зөбәржәт кавыша алмаган мескен ярлар бит ул. Ә без елдан артык гомер бергә көн күрәбез. Артабан, безнең уртак малаебыз да бар бит әле тагын. Юк, без улыбызга бәхетсез Зәбирнең атын кушалмыйбыз инде. Безнең малайның авырлыгы гына да бер пот. Юк, безнең малай бөтен Болгарынны дер селкетә торган ир булырга тиеш. Аңа тояклары белән лас-лос атлап йөри торган яу атыныкы сыман исем кирәк. Бәйләнергә, сорашып йөдәтергә монда кешеләр юк бит. Син ашыкма, уйлашырбыз әле.

## 16

Чәчкә төшкән чал шикелле, кыш айлары да сиздерми генә килеп житте. Бер таңда ишек ачсалар, ялан өстен, агачларны-тауларны ап-ак кар каплаган. Дөрес, эреле-ваклы ерымнар, чокырлар, чишмәләр белән ергаланган тау итәкләренә, агачлар арасына ярлы-ябагай юрганы шикелле тишекле-тошыклы булып төшәлгән ул.

Кар катламы юмарт килен тәбикмәгә калынлыгы гына булып төшәлсә дә, аның әле яна туган бала сыман керсез һәм гөнаһсыз чагы. Аңа сокланмыйча һәм ят күз белән карап буламыни?!

Байдар белән Сания дә яна дөньяны тын алырга куркып, тан калып күзәттеләр.

—Менә, яна кышка да аяк бастык бит, этисе,—диде Сания, иренен

тәртәләргә биргесез беләкләренә кайнар йөзен терәп.—Аллага шөкер, быел үзебезнең йортта үткәрәбез аны.

—Сез өйдә калырсыз, ә мин ауга китәм,—диде Байдар, үзенчә уй сөреп.—Куяннар, көртлекләр яна карга ияләнмәде әле. Аларны каптыру авыр булмаячак.

Һәм вакытны тартып-сузып тормый жыенды да Байдар шул сәгатьтә ауга чыгып китте. Ләкин үзен нинди хәтәр капкын сагалавын ул күз алдына да китерә алмый иде әле.

Карашар белән Йомрытау дигән ике биек, түгәрәк калкулыклар арасыннан үтеп барган чакта ачыгавызлы бала-чага урынына эләктерделәр аны. Байдар, пошмас сантый, менә шушы калкулыкларның исемнәре турында уйлап бара иде.

Каян гына, кайсы халыклардан үтеп кергән риваять-хикәяттер. Имеш, элеккерәк заманнарда Алтын дигән бер хан яшәгән, ди. Монда булмаган, ди аның пайтәхете. Тулпар менеп чапсан, утыз-кырык көнлекераклыкта, жиде катлы таулар, житмеш дала аръягындагы олы дәрья буенда булган аның иле. Берзаманны Алтын хан картайган да үлем түшәгенә менеп яткан. Үз янына ике улын чакыртып китергән бу. Тегеләре Дансыз белән Сансыз дигән гажәп сәер исемлеләр икән. Мөгаен, алар андый сәер атлы булмаганнардыр да инде, ләкин халык хәтере аларны шулай саклап калган.

Алтын хан боларның кулына ике алма тоттырган.

—Менә шуларны пычак белән урталай кисегез әле,—дигән.

Тегеләр кискәч, яңа әмер биргән.

—Хәзер яртышар алмагызны үзара алышыгыз да янә бербөтен итеп кушып карагыз,—дигән.

Уллары ике алманың ике яртысын ябыштырырга тырышып караса да, әлбәттә, тегеләр зурлыклары белән бер-берсенә тиң килмәгән инде. Шуннан малайлар олырак кисәкләрне пычак белән юна, кыра башлаганнар. Берсен кечерәйтсәләр, икенчесе зуррак булып кала, инде аларын да кискәләргә туры килә икән. Ахыр чиктә ике малай кулындагы алмалар кечерәеп, кырылып юкка чыккан.

—Бер-берегездән аерылсагыз, мин төзегән илне үзара бүлешсәгез, сезнең икегезне дә менә шундый язмыш көтә, балакайлар,—дип кисәткән дә жан биргән, ди боларның әтиләре.

Ләкин әлеге сүзләрне колакларына киртләмәгән шул аның малайлары. Аерым-аерым хан булырга маташып, бер илдән ике кабилә ясап бүлешкәннәр. Боларның көчсезләнеп калуыннан файдаланып, дошман ябырылган. Менә шушы урында әүвәл өлкәне, Дансыз атлысын дошман чолгап алган. Жинеп чыга алмасын алдан ук сизенгәндер инде, энекәше Сансыз янына чапкын юллаган ул.

—Тәнре шулай каргагандыр инде, атай васыятын үтәми ялгыштык без. Мин синең колың булырга да риза. Тик ярдәмгә килеп жит тә, әйдә, илне генә коткар,—дигән Дансыз.

Ә кечесе Сансыз "синең башына житсәләр, мин ике кабиләгә дә берьюлы хан булам", дип сөенеп ята икән. Ярдәмгә килмәгән ул. Баскын дошман Дансызны үтергән, ди. Жиләк кебек сылу кызларын, яп-яшь егетләрне коллыкка алып киткәннәр. Кабилә урынында ап-ак чәчле карт-карчыклар гына торып калган.

Аннары Сансыз угылга да чират житкән. Дошманнар анысының кабиләсен жиде күчеш артындагы Туксу дигән инеш буена барып туздырганнар. Сансыз хан ике-өч яраны белән генә качып котыла алган. Менә шул чагында үзен ярдәмгә чакырган мәрхүм абыйсын исенә төшергән ул. Гөнаһасын юмакчы, сәждә кылмакчы булып, Дансызның кабере янына

килгән. Ул җиргә тезләнгәч, моның алтын очлымына кызыккан яраннары “син барыбер илсез калдың инде, сиңа кирәге юк” дип, кече Сансызның да башын кыеп төшергәннәр.

Ахырда ак сакаллы картлар, яшь-кыркыннар җыелып, итәкләре, учлары белән ташый-ташый ике туган кабере өстенә курган төзегәннәр. “Илне бүләргә ярамаганлыкка, бердәмлеккә чакырган һәйкәл булып торсын”, дип әйткәннәр ди картлар. Дансыз белән Сансызның исемнәре тора-бара онытылган инде. Узгынчылар аларның курганнарын хәзер Караташ белән Йомрытау дип кенә, үзләренә яраклаштырып йөртә. Ә Алтын ханның ике башбаштак, ике бәхетсез улы турындагы риваятьне барыбер онытмыйлар. Менә бит ул язмыш!..

Һавада әрлән сызгыруына охшаш тавыш ишетелүгә үк чаптарының муенына сеңгән иде Байдар. Йә сәрпи ук тавышы инде бу, йә биек тау түбәсеннән айкап ыргытылган кыл-аркан очкандагы аваз. Кай тарафта сагалап торган иде микән инде аны дошман? Нишләп сабый бала сыман исәңгерәп барган?

Сызгырып очкан әйбер ат кылыннан үргән ятьмә булып чыкты. Байдар кыныннан кылычын алып өлгергәнче, аның өстенә аюдай ирләр ябырылган иде инде. Кымшанырга да ирек бирмичә, баһадирны кыл “биләү”гә төреп, көмеш иярләрдә утырган җайдаклар төркеме алдына китереп ташладылар. Байдар кыл ятьмә челтәрләре арасыннан гына карап ятты. Бай, тәкәббер һәм бик гайрәтле иде ап-ак тулпар өстендә утырган баш хуҗа. Агачтан ясалган битлек кигән сыман хәрәкәтсез-хиссез йөзе белән Байдарга таба иелеп, бик аз гына вакыт карап торды. Тоткынга эндәшкән чагында да иреннәре, ияге селкенмәде. Әйтерсең лә, сүзләр аның түгәрәк, пөхтә итеп киселгән сакал-мыеклары арасыннан сытылып чыкты.

—Атың нинди? Кем буласың, сукбай?

Байдар ап-ак тулпар тояклары каршында аунамаска теләп урыныннан калкынган иде дә, янга баскан сакчы касыгына типте.

—Хан үзе сиңа сүз кушарга түбәнчелек итте. Тик кенә ят, эт җан!

Хан, хан? Кайсы хан икән бу, Мөхәммәт ханмыни? Угыз, кыпчак яки аймык кабиләләренең башлыклары монда, Болгар җәйләүләренә килеп, үз биләмәләрендәге шикелле илле-алтмыш җайдак озатуында гына йөрмәсләр бит инде? Мондый нөгәр озатуында, житмәсә аткы җәя белән ук садагы гына асып йөри икән, димәк, Байдар шикелле ауга гына чыккан Мөхәммәт хандыр инде бу.

—Атым Байдар минем,—дип, ниһаять, телгә килергә булды тоткын пәһлеван.—Ягъфәр бәк олысындагы Кадрәк авылыннан.

—Байдар, Байдар, аңлашылды мина.—Мөхәммәт хан сәер рәвештә ирен читләре белән көлемсерәп куйды.—Ягъфәр бәк мәңгелеккә күчкәнгә ике җәй, ике кыш узып бара бит инде. Бу хәтле гомер буена өнгә чумып, әллә аю белән бергә йокладыңмы, сукбай?

Хан җавап та көтеп маташмады, тулпарының касыгына типте. Ятьмәдән арындырсалар да, кулларын богаулаган бау очын ияр аелына тагып йөгерттеләр. Хан ыстаны Эре Колмак яланы дигән инкүлектә икән. Монда чатырлар, тирмәләр чиксез. Тыз-быз килеп пешекче яшь кызлар, йөзәрләгән сакчылар йөгерешә. Ыстан уртасында дистәләгән учак яна, казаннар быгырдап кайный. Таганнарда тимер таякларга кидертелгән бәрән, куян, җәйрән түшкәләре утлы күмер өстендә бөтерелә.

Хан гап-гади кушчы сыман кыйланып бер учак янына барып утырды да, майлары тамып торган түшкәдән иң шәп калҗаны кисеп, хәнҗәр очына алды. Аны тегеләй, болай иттереп боргалады, иреннәренә китереп өф-өф өргән булды. Шулчагында гына телгә килде хаким.

—Азат итегез әле бу тоткынны.

Сакчылар кыл-арканнарны кисканнәр генә иде, ханның һичбер кол яки гади яугир акылына кереп тә карамаслык әмере яңгырады.

—Әй, сукбай! Менә монда кил дә минем каршыма утыр.

Байдар оеган кулларын ышкый-ышкый аның каршына килеп чүгәләүгә, Мөхәммәт хан кызарып пешкән калҗа кадалган беләк буе хәнҗәрен пәһлеванның иреннәре арасына китереп тыкты.

—Миңа дигән итне агуламадылар микән? Әүвәл син ашап кара әле, әйдә.

Байдар бер мизгел эчендә шабыр тиргә батты. Бөтен тәне, беләкләре буйлап борча-кырмыскалар көтүе чабышкандай булды. Каз тәне чыкты, бала йоннары да кабардылар бугай. Зиһене аша казандагы кайнар су шикелле уйлар кайнап узды.

"Нинди мөгез чыгарырга тели, ниләр кыйлана бу? Агу хакында сүз кузгатуы төтен генә инде. Ханның кайсы түшкәгә килеп ябышасын хыянәтче яран ничек белеп торсын? Ни өчен нәкъ мине сайлап алуы да аңлашыла сыман. Мин элмәккә килеп эләккән кол, мин тулысынча моның карамагындагы тоткын. Мине эт урынына куеп сынасаң да була. Ләкин беләк буе хәнҗәрне минем авызга терәп куюы бер дә уен, сынау гына түгел. Авызны ачтыммы, моның хәнҗәрне минем бугазга китереп кадавы бар. Сабына бер сукса, үпкәгә, йөрәккә хәтле телеп төшәчәк. Ни эшләргә, нәрсәне ачыкларга тели соң бу Мөхәммәт? Мине болай эт хәленә кую ана нигә кирәк? Исән калырга язды микән миңа, әллә... әллә инде соңгы сулышыммы?.."

Мөхәммәт ханның эчендә дә тоташ ут ялкыны.

"Ыстандагы барча пешекчеләр, сакчы ирләр, ауга ияреп килгән бәкләр текәлеп каткан. Тоткын Байдар нишләр? Тыңлармы ул хан әмерен, әллә куркуыннан елан кебек тез астына төшеп сарылырмы? Бүре күргән сарык бәрәне шикелле бәлтерәп төшсә, ышаныч юк моңа. Ул чагында, иң яхшысы, йә хәнҗәрне бугазына батыр, йә кылычтан чаптыр. Әгәр инде курыкмыйча, шикләнмичә хәнҗәр очындагы калҗаны каба икән, моңа киләчәктә дә гомер буе таянып һәм ышанып була. Кирәк булса, сине яклап, утка да керәчәк бу. Ләкин... ләкин моның кыяфәтендә, карашында кирелек, үҗәтлек дөрләп кабынган бит. Көч-гайрәте сынар ханны гына түгел, бер дистә жансакчыны ботарлап атарлык. Ә көтмәгәндә, буар елан сыман сикереп, өстенә ыргылсамы? Жансакчыларың моның башын-кулларын чабып ташлаганчы, ул синең биленне-умыртканны жиде тапкыр сындырып өлгерәчәк. Һаман авызын ачмый. Йөзләгән күз көтә. Йә, нишләргә инде?.."

Байдар сөекле хатынын, газиз нарасыен үбәргә омтылган сыман иреннәрен очлайтты һәм хәнҗәр очын авызына капты. Икенче мизгелдә ул инде жылы калҗа чәйни, ә Мөхәммәт хан иңбашыннан авыр йөк төшкән шикелле уфылдап янә кайнар түшкәне каезлап утыра иде. Таш баганадай катып калган жансакчылар, бәкләр бүтән учаклар, казаннар тирәсенә ябырылгач кына, Мөхәммәт хан сер әйткәндәй пышылдады.

—Хатының белән малаең минем чатырда бит. Без аларны синең эзенә басканчы ук эләктергән идек инде. Әгәр хәнҗәрне капмасаң, мин аларның да гомерен кыя идем.

17

Мөхәммәт ханның кәефе чамалы чак. Вәзир Даян кереп сәер бер сер чиште.

—Синең Тимер-Мөэмин нишләптер гел яшь ханәш бүлмәсе янында буталып йөри. Узган атнада да икесе генә Сенертау буена ялан

өйләнергә чыгып киткәннәр иде. Син ул көнне Жүкәтауда кунып калдың, ә алар таң атканда гына кайтып керде. Ярый әле, Айкапуда* торган тоткавыллар тавыш куптармаган...

Мөхәммәт хан вәзир барында йөрәген көйдереп алган утны сиздермәде. Ә ул чыгып китүгә, әллә ничә урындыкны, комганнарны, гөл савытларын әйләндереп атты.

—Соран, кабих, җәллад!—дип сүгенде ул, йодрыклары белән диварларны, ишекләрне ярсып кыйный-кыйный.—Төпчек анасына килеп ябышмаса, хатын беткәнмени?

Аннан уйга калды. Тимер-Мөэмингә егерме яшь тулды. Югыйсә, Мөхәммәт аны өйләндерде дә инде. Әмма үз казанын асарга аерым кала, вилаять бирмәде. Чөнки аның бу өлкән малаен гадәләтсез, кансыз, вәхши, диләр. Бала атасы булырга җыена бугай, ә үзе һаман Биләр буйлап этләр-мәчеләрне үтереп йөри. Урамда бер җан иясе калмаган, иясез мәче-фәлән күренде исә, Тимер-Мөэмин аны шундук тураклый, ди. Мона ышаныч бик аз. Шул уртанчы малае Ибраһим белән төпчек Габбасына таянса гына инде. Габбасы бераз аумакайрак сыман, ә Ибраһим һәрнәрсәне бизмәнгә салгандай үлчәп эш итә, уйчан, салмак, төпле. Шуңа күрә унсигез яшьтә генә дип тормады, хәтәр калкып, ыспайланып килгән Болгар каласына озатты аны Мөхәммәт хан. Дөрес, ялгызын гына түгел, таянып эш йөртергә вәзир Даянның малае Насыйрны да бирде. Тегесе дә бик яшь, әмма урыс мәмләкәтендә канат ярган, әллә ничә милләт күргән егет. Йөкне бергә-бергә жигелеп тартсалар, зуррак эшләр майтарырга да өйрәнерләр әле. Төпчеге Габбас та күз ачар. Мөхәммәт хан аны Жүкәтаудагы Илбуга бәк канаты астына илтеп куйды. Илбуга—заманында Микаил хан гаскәрләрен яуга йөрткән сәрдәр. Мең кат сыналган. Акыл казанындагы хәйлә-тәҗрибәсен чүмечләп ташысаң да коргаксымас. Габбас белән Ибраһим хәзер әтиләренең тирмәләреннән читтә, абына-сөртенә, тирләп-пешеп акыл җыйсыннар. Ә Тимер-Мөэмин?.. Аһ, ул сатлык затны! Мөхәммәт аны кортлаган тәкә урынына тотып печмәсәме?!.

Хан яшь хатыны Айсылу янына төнлә белән генә, ажгырып барып керде. Нык тузынып, тавыш куптарып атлагандыр, ахры. Мөхәммәт ишеккә типкәндә бүлмә эчендә ниләрдер шак-шок килә, ә ул бусагадан узганда урам яктагы тәрәз шыр ачык, чиккән пәрдәләр генә җилдә җилфердәп дулкынлана иде.

Айсылу ярымшәрә. Мунча ләүкәсеннән сикереп төшкән шикелле кызарынып чыккан. Чем-кара толымнары тузгып беткән, ботлар ачык. Этлек өстендә тотыла язгач курыккандыр инде, ике якка салынып төшкән тыгыз күкрәкләре дер-дер килә.

—Фәхеш оештырып ятасыңмы минем йортта? Ыштыр жирең мунча ташы сыман кызып життемени, кәнтәй елан?—дип үкереп Мөхәммәт хан камчы белән ярырга тотынгач, вәлидә Айсылу ефәк тасма сыман бөтерелеп, аның аяклары астына шуышып төште.

—Минем гаебем юк. Ул үзе мине көчләргә азапланды. Мыскыл итмә мине, газиз ирем?..

Аһ, хатын-кызда тимерне эретердәй юха тел булмасамы?! Газиз, ди бит, ирем, дип тора бит, ничек алданмыйсың? Мөхәммәт тә сынды. Берничә минуттан соң ул инде бөтен тәне буйлап шуышкан ирен кайнарлыгыннан онытылган иде...

Тимер-Мөэминне икенче көнне дә, бер атнадан соң да таба алмадылар. Аннары гына хәбәре кайтып житте. Жүкәтауга, Габбас ышыгына, энекәше

* Айкапу—Алтын капка. Өсте алтын белән бизәлгән өчен шулай атаганнар.

куышына кереп качкан. Берьюлы ике малаена каршы кузгалып, ил көлдереп булмый бит инде. Мөхәммәт бөтенләй, язгы ташкыннан котылгач үз ярларына кайткан елга сыман тынды. Ә ул арада Ашлы ягыннан давыл:

—Идел буйлап вятич ушкуйлары бәреп керде!

Нигә кирәккәндер, Билэрдәге бар гаскәрен җыеп, Мөхәммәт хан ашлыларга ярдәмгә үзе чыгып китте. Ә азгын Тимер-Мөэмин биләрлеләрнең кораб-каекларга утырышып, Чулман дәрьясыннан Зур Идел суына төшкәннәрен генә көтеп йөрде. Аннары Илбуга бәктән "ханга кушылам" дигән хәйлә белән биш йөз җайдак талап алды да, котырынган әмир Биләр каласына кайтып керде. Каравылчысыз калдырылган умарталыкка төшкән иләмсез аю шикелле кыйланды бу! Капкаларда торган сакчыларны әүвәл җир өстенә салып таптаттырды. Исән калганнарының колакларын кисеп, күзләрен чокып, буш далага куды.

—Теге чакта, үги анасы белән уйнап яткан чакта, хан аларның өсләренә килеп кергән өчен үч ала бу,—дип сүз йөртте "озынколак".

Ләкин әле биләрлеләрнең күрәсе гыйбрәтләре алда булган икән. Кичке шәфәкъ якынлашып килгән чакта, әүвәл хан сарае эчендә ачыргаланып елаган тавыш купты, аннары дуңгыз суйгандагыдай чинаш-үкереш ихатага күчте. Тыкрыкларга поскан, келәт-мунча артларына качкан кешеләр ишетеп-барлап торды. Вәлидә ханәш тавышы иде бу, азгын Айсылуның җан авазы иде. Аны үгездәй мөгрәгән Тимер-Мөэминнең үкерүе генә күмеп-күмеп алды.

—Бу кәнтәйне әнә теге арбага бәйләп, ботларын аерып салыгыз да, көмеш эретегез тизрәк, көмеш эретегез! Юха еланның җан җиренә коябыз аннары, җан җиренә!

Беркадәр арадан соң Айсылуның илереп-шашып кычкырган авазы гына яңгырап ишетелде дә, күк күкрәгәннән соң бушанып калган җиһан сыман, бары да тынды. Таң атканда Тимер-Мөэмин инде Биләрдә юк иде...

Мөхәммәт хан кайткач, Айсылуның каберенә барып өзгәләнде.

—Теге имгәк үзем үстергән агач җимеше бит. Ачысы, агуы, йөрәкләрне телә. Терсәк якын да соң, тешләп булмый. Ниләр кылыйм? Сыкрыйм, түзәм инде.

## 18

Вәзир Даянның итәгенә дә утлы күмер төште. Тимер-Мөэмин белән Габбас Болгардагы Ибраһим янына чапкын җибәргән, ди.

—Бөтен мәхшәрне Даян гына китереп чыгарды. Ул сатмаса, безнең атай берни сизми иде. Даян урыслардан әллә никадәрле этлек өйрәнеп кайткан. Атай белән араны бозып, безне тәхеттән коры калдырырга җыена ул. Үзенең малае Насыйрны утыртмакчы була.

Ибраһимның колагына менә шундый сүзләр җиткергәннәр. Ибраһим исә нинди бизмәнгә салып үлчәгәндер инде, Биләргә килеп, әтисенә әйткән.

—Мине дә үз якларына аударып, түнтәреш ясарга йөрми микән болар? Нинди, дип, шул, сине еккач үзләре хан булырга җыеналардыр инде. Мәгәр тәхетне бүлешә алмый алар. Сине ексалар да, үзләре яшь этәчләр сыман чукышып бетәчәкләр.

Мөхәммәт хан төпчек малае Габбасны чакыртты. Вәзир Даян ялган ишек артына качып тыңлап торды. Габбасның авызында гел тозсыз сүз.

—Нишләп Тимер-Мөэмин котыртсын инде мине? Ибраһим янына җибәргән нинди чапкын ди ул? Ибраһим, эт җан, үзе чапкын юллап, мине вәзиргә каршы чыгарга өстереп ятты ласа. Күрәләтә торып атайга каршы күсәк күтәрергә мин соң тинтәкмени?

—И-и, минем аптта, әнә, никадәрле елан күче җыелып яткан икән,— дип шаккатты хан.—Җүкәтауда Илбуга бәк ике еланны куенына яшереп асрап ята. Болгарда Ибраһим теш чыгарган. Юк, болай булмый. Утлы кисәү белән туздырып атарга кирәк сезне!..

Нәтиҗәдә ил өстендә фәрман яңгырады.

—Әмир Ибраһим илә Илбуга бәкне Чулман буйлап, югарыга таба озатырга! Чулманга Туймас елга килеп кушылган төштә, тау башында, яңа кирмән-кала төзесеннәр!..

Даянның улы Насыйр Биләргә кайтып төште. Вәзир пайтәхеттә күп тотмады аны. Бер кичтә, тәмам караңгы төшкәч, Даян үзенең улын урамга дәшеп алды.

—Иң кирәкле коралларыңны җыйна, юлга чыгачаксың.

Насыйр коралланып ияргә менгән чакта аны капка төбендә тагын ике җайдак көтә иде инде. Берсе—әтисе, икенчесе элек күргән-белгән кеше түгел. Шәһәр капкасыннан далага чыккач кына әтисе аның иненә кулын салды.

—Учакка якын утырсаң, утка пешәсең икән, улым. Ә без, сантыйланып, учакның уртасына ук барып кергәнбез бит. Күкерт шикелле янып көлгә калуың бар. Монда туфан. Ата улны, ана кызны белми. Ил тынганчы берәр якка китеп, чит гыйбрәтне мыегыңа чорнап йөрү күпкә хәерлерәк. Әнә, Әтилгә бар. Манас кахан олыгайды хәзер, иртәгә анда нинди мәхшәр кубасын беркем белми. Ә безнең мәмләкәткә һәр төбәктә үзеңнен күз-колагың булу кирәк. Сарай тирәсендә сайрап яткан кеше түгел, күп йөргән кеше күп белә, моны сизгәнсеңдер.

Даян читтә торган җайдакка таба баш изәде.

—Монысы сиңа юлдаш. Чит җирдә әнә шундый иптәш булмау нык үтерә. Исеме Байдар аның. Без аны таулар арасындагы алачык янынннан эләктереп алып кайттык. Хатыны бала тапкан да, шунда төпләнеп калырга уйлаганнар. Мәгәр әүвәл гади Әмин качса, алар артыннан Дәмин белән Мөхәммәтәмин дә качса, ил кем белән калсын?.. Ә үзе бик тә балалар ярата икән. Үзенең йодрык чаклы Сал-Салы турында сөйләп, колак итенне ашаячак әле.

Соңгы тапкыр кочаклашып аерылгач кына, ата кешенең ерактан эндәшкән тавышы ишетелде.

—Сина да вәзир булып кайтырга насыйп итсен, улым.

## 19

Вәзирлектән колак кагуга ук Нуретдин Җаек белән Кондырча арасында каңгырап йөргән улы Рахман янына чыгып качты. Аның артыннан бик озак иснәнеп барырга туры килде аңа. Бактың исә, Рахман Үтәтишек кыясы артына, юлчылар, кәрванчылар мәңге аяк басмас Тозлы күл буендагы камышлыклар арасына ук кереп поскан икән. Кайчандыр меңәр җайдак белән исәпләнгән нөгәре хәзер инде сасы көзән кырып чыккан тавык өере шикелле сирәкләнеп калган. Кичәге әмир өчен махсус корыла торган ефәк чатырлар да, җарияләр өчен чигү җепләре белән нәкышьләнгән аеры тирмәләр дә юк инде биредә. Иске кәвеш хәленә төшкән кадерсез җайдакларның күбесе хәзер җиргә чокып ясалган кысан куышларда яшәп ята. Әле ярый, Рахманның үзенә тишек-тошык киезләрдән корган ике тирмә калган.

Рахманны сакал-мыек баскан, карашында нуры юк. Әтисен күргәч тә тәгәрәп төшмәде ул. Ирен читләрендә мыскыллы кеткелдәү пайда булды.

Аннары күнелендәге үч-каһкаһәне яшереп тормыйча әйтеп салды.

—Нәрсә, сине дә болгап аттыლармы? "Озынколак" житкерде, ишеттем мин. Мөхәммәт чуклы пумала белән куган сине.

Нуретдин ярсуын көч-хәл белән тыйды.

—Газиз атанның бәхетсезлек сазлыгына кереп батуына нигә сөенәсеңдер? Алайга китсә, күреп торам, син дә күлнең төбен күккә аскан Искәндәр Зөлкәрнәен* түгел әле.

Зәһәрлек укалары көзге кырау суккан кычыткан яфраклары кебек шәлперәеп төшкәч, бергәләп уй йөрттеләр.

—Чит-ят жирдә аяк сузып булмас,—диде ата кеше, Рахманның яраннары керткән сөҗүне суыргалап.—Болгар җиренә кайтып, янә тамыр җибәрүне чамаларга кирәк. Әнә, Бәнҗәгә һаман әмир куелмаган. Булат батыр каланы үз кулына алса да Мөхәммәт ханның аны олугбәк иткәне юк. Нишләп итсен? Булат—кара гавам арасыннан калкып, балчыктан көрәк булырга маташкан колчура бит. Мөхәммәтнең үз малайлары арасыннан да һичкайсына таянмалы түгел. Берсе бозау булып сөзә үз атасын, икенчесе буар елан сыман. Ю-у-ук, Мөхәммәт аларның берсен дә тиз арада гына үзенең тагарагына якын китермәячәк әле. Ә безгә йоклап калмаска кирәк. Сугым вакытында ач этләрнең кисеп ташлаган талак тирәсендә ни рәвешле бөтерелеп йөргәнен шәйләгәнең бармы? Алардагы әрсезлек! Алардагы елгырлык! Безгә дә әнә шул ач этләр шикелле ташланып эләктерергә кирәк бер калҗаны!

—Ә Бәнҗәне каптырып булыр микән?—дип, бик шикләнеп кенә сүзгә кушылды Рахман.—Анда мине бер дә сөймиләр бит. Үч алырга кыжрап йөрүчеләр дә йөзләгәндер, баксаң.

Нуретдин янә зәһәрләнеп кул селтәде.

—Аларга төкерәсе. Йөгәненнән иң беренче булып кем каптыра, атка да шул менә. Ә сыртына менгәч, һәр ат буйсына ул. Бер ишенә солыны, икенчеләренә камчынны гына кызганмаска кирәк. Иң алама, аксак бүре дә ачыгавызлы корбанын үзе эзләп таба. Әйдә, жыен, сиңа баш ия белмәгән Бәнҗәнең умырткасын сындырырга киттек!..

Алар күзгә төртсәң күренмәслек караңгы төн уртасында калага якынайган иде. Диварларга тавышсыз-тынсыз менеп, әмир сараена соңыннан бердәм ташлануда иде исәпләре. Ялгыштылар. Рахман башкисәрләренең айлар буе сукыр тычкан сыман жир куышында яшәп яту хикмәтедер инде. Дошман ыстанында аерата уяу, сизгер булу, дигән кануннарны оныткан булар. Рахман нөгәрендә унбашы булып йөргән бер пошмасы имән манара баскычында черем итеп утырган үз ишедәй икенче боламык сакчыга килеп төртелгән. Йокы аралаш тегесенең бөтенләй өне алынгандыр инде, әүвәл манара басмаларына дан да дон килеп бәрелә-бәрелә аска калканы очты, аннары суярга салган дуңгыз сыман чинап үкергән тавыш купты.

—Карау-у-выл, шайтан, шайтан!

Казан астына ут куярлык та ара үтмәгәндер, барча дивар өсте торгак сакчылар чылбыры белән тулды. Әллә кайдан гына сөйрәп чыгарып, очларына житен чорналган дистәләгән кисәү кабыздылар. Дивар өстендә лас-лос китереп орган чукмар, кылыч авазлары ат иярләрлек вакыт буе гына яңгырап торды да Рахман башкисәрләренең мәетләре каланы урап алган чокыр төбенә очты. Төн караңгы дип тормадылар тагын, Рахманны таныдылар. Кала өстен каһкаһә белән, илереп кычкырган аваз күмеп китте.

—Бәнҗәне элек үзең тотып көчләгән мескен кызлар сымак итәк ачып ятыр дип уйладыңмы әллә? Моннан ары якын-тирәдә иснәнеп йөрисе булма! Тагын килсәң, печеп җибәрәбез!..

* Искәндәр Зөлкәрнәен – Александр Македонский.

Ак-караны күрми, атларын жан-фәрман камчылый-камчылый, әллә никадәрле вакыт буе дала буйлап юырттылар алар. Рахман ияре астындагы чаптар янып аугач кына, ирексез тукталдылар. Рахман әле жирдә гыжлап яткан атны типкәләде, әле камчысы белән яман болгый-болгый әтисенең ботларын көйдереп-көйдереп алды.

—Бер сакчысыз калдым. Син генә әрәм иттең аларны, син котырттың!..

Тынычлангач, янә Нуретдин акыл биргән булды.

—Булат безнең арттан эзтабарлар жибәрмичә калмас. Алар безне янә тау-таш арасына поса, дип көтә инде. Бәнжәнекеләр Жаек буеннан, буш даладан эзләп иза чиксен, ә без Нур-Суарга киттек, илнең үзегенә! Анда минем бажай, Аксак Әхмәт әмир. Анда безнең Ватан! Үз кабиләләренең үксез балаларын алар кадерсезләп читкә типмәс әле!..

Кичә генә ил тоткан вәзир белән вилаять чаклы вилаятьне дер селкетеп йөргән аталы-уллы Нуретдин һәм Рахманның кайтып төшүе Аксак Әхмәт өчен бәйрәм булды. Иш янына куш табылмый димени? Аксак Әхмәт үзе дә инде байтак айлар буе Мөхәммәт ханга каршы теш кайраган икән. Эчләре үч тулы качаклар аның сараенда пәйда булуга ук, чатан әмир агуын ачып салды.

—Тәхеткә ни өчен Алмыш хан нәселе генә хужа булырга тиеш ди соң әле? Нәрсә, минем Нурый бабам колчура булганмы да, Алмыш мөгезлеме? Безнен Нурый бабай да кабилә юлбашчысы булган, Алмыш та бәк. Моннан утыз-кырык ел элек Алмыш бердәм хан итеп сайлап куелган дип кенә без соң хәзер таждар тәхетеннән гомерлеккә колак кагыйкмыни? Үзебез әле бер хәл. Ә артыбызда урман сыман үсеп килгән угъланнар илә оныклар ничек итеп гафу кылсын безне? Юк, ул хан сайлап куя торган горефләрне кабат кайтарырга да оланнарга юл ярырга кирәк!..

Мөхәммәт хан каршында бил бирмәүне аерым акча сугудан башлап жибәрделәр. Biләрдәге хан өч бәрәнне бер алтын динарга сатып ала, ә Нур-Суарда Аксак Әхмәт ике бәрәнгә дә шул ук хакны түли. Хәзәрләрдән, аймык-угызлардан килгән күпчелек сәүдәгәрләр Суар базарына сукмак салды. Мөхәммәт хан Биләрдә шартларга житешеп котыра, ди. Ә Нур-Суарда инде яна әмер.

—Биләрдә Аллаһны, динне олылый белүче дә юк бит анда. Адәм рәтле мәчет тә төземиләр. Чит дәүләтләр алдында хурлык, оят. Хан нәфсесе туймас. Үзебезнең Нур-Суарда дүрт манаралы мәчет күтәрәбез. Ханлыктагы ин олы Жәмигъ мәчет Нур-Суарда булыр!..

Әйткән сүз—аткан ук. Бер жәй эчендә күз нурыңны алып торырлык мәчет күтәрделәр. Аксак Әхмәт Биләрдәге Хәсәншәех сәетне чакырып чапкын куган.

—Ин олы Жәмигъ мәчет безнең калада хәзер. Динне мыскыл итмә, Суарга кил.

Хәсәншәех сәет Мөхәммәт тыйганга, тешен кысып кына бармый калды. Ә Аксак Әхмәт ыжлап та карамады.

—Алай икән, без үзебездә яңа сәет булдырабыз инде. Мөхәммәтнең әтисе Габдулла хан Миңлебакир вәзирне читкә типкән иде, менә шуны чакырып китерәбез.

Мөхәммәт хан моны ишетүгә, чынлап торып, тиресенә сыеша алмыйча, ярсып купты.

—Аһ, икейөзле, аһ, мәкерле соран! Миңлебакир вәзирне минем әткәй түгел, ә шул Нур-Суардан килгән Талиб куды. Әхмәт шуны белә торып, юри нахак гайбәт тарата бит, аксак тәре!..

—Әхмәт салымны үзенә башка жыя. Аның сина салым китереп йөрергә исәбе юк,—дигән хәбәр дә килеп ирешкәч, Мөхәммәт ханның түзем чиләге корыды.

—Чапкыннар жибәрегез! Ашлы, Кашан, Жүкәтау, Бәнжә әмирләре икешәр меңле чирү жыеп килсен!—дип, тәрәзә пыялаларын дерелдәтерлек итеп үкерде ул.—Өй келәмен буйый торган юньсез мәчене нәжесенә борыны белән төртеп ипкә китерәләр. Мин бу аксактан кан костырам әле!..

Юк, аксак әмирне кыйнап ипкә кертү кирәкмәде. Анын кул астындагы вилаять чигендә ун мең жайдаклы гаскәр күренүгә үк, Аксак Әхмәт качак Нуретдин белән Рахманны гаярь хан кулына илтеп тапшырмакчы булды. Тегеләр да азау тешен чыгарган эт жаннар, чатан әмирнең мәкерен алдан ук сизенеп, Нур-Суардан качып өлгергәннәр. Аксак Әхмәткә Мөхәммәт ханны япа-ялгыз гына, кала читенә чыгып, тезгә чүккән көе каршыларга туры килде. Олау-олау, кәрван-кәрван байлык туплап куюы гына житмәгән, хәйләкәр әмир вәлидә ханәш Айсылу урынына сайлап алу өчен илле сылуны да жыеп куйган иде. Бу кадәрле күндәмлек, басынкылык күрсәтү күзен томалады, Мөхәммәт хан жариәләр чатырына кереп онытылды.

Соныннан, шәһәрдән чыгып китешли качак Нуретдин ташлаган сүзне әйтеп көлдерделәр:

—Кәжә—хайван түгел, бажай—туган түгел. Мона ышанып килгән жүләр икән мин.

20

Мөхәммәт хан, пайтәхеткә кайтып барышлый, нәкъ Биләр белән Суар уртасында яткан уйсулыкта бәйрәм оештырды. Йөзәрләгән тәкә суйдылар, атта узыштылар, уклар атыштылар. Кичке шәфәкъ якынлашып килгәндә өлкәнрәк ирләр-агайлар учак тирәсенә жыелып гәп куертты, яшьләр су коенды.

Чирмешәннең суы май шикелле жылы, сихерле чак. Аксак Әхмәт биреп жибәргән жариәләр, Мөхәммәт хан белән әмир-бәкләрнең күнелләрен күреп йөргән канизәк-сылулар әүвәл артыш, зирек куаклары, кызыл тал ышыгында йөзеп-чумып азапланганнар иде дә, бер үзләре генә чыркылдашудан ямь тапмадылар, күрәсең, берзаманны болар егетләр өере янына килеп житте. Ә сынар ук та очырмыйча жину яулап кайткан газиләргә нәрсә? Болай да йөрәкләре былбылдай очынып торган егетләргә бу сылулар затлы бүләк сыман! Су төбенә чумып шаяралар, "теге төшенне тотам, бу төшенне тотам", дип кычкырып өн алалар, ат урынына пошкырып куалыйлар. Чирмешән өсте казан кебек кайный, чыр-чу килгән авазлар чакрымнарга ишетелеп тора. Яр башында утырган ирләр дә күз салгалый. Юк, "тотам-тотам", дип шапырынса-янаса да, егетләр кызларның бер генә жиренә дә кагылмыйлар. Хәрәмләшү, азыну-тузыну юк Болгарда.

Булат батыр башта Мөхәммәт хан казаны янында утырып торган иде. Монда Болгар иленең ин абруйлы түрәләре генә жыелышкан. Ашлыдан—әмир Сәлман, Кашаннан—Мөхәммәт ханның энесе Габделваһап. Жүкәтаудан ябашы Мөбәрәк бар, анын каравы, хан угыллары булып йөргән Габбас әмир белән Тимер-Мөэмин юк. Шулай, ышаныч югалткан, ханга каршы өргән бәндәләрне чакырмыйлар монда. Булат та, менә, хан казаны, хан чатыры янына тәүге тапкыр чакырылган кеше. Ничәмә-ничә айлар буе Бәнжә башында Булат утырса да, әле шушы Аксак Әхмәткә каршы күтәрелгәч кенә Мөхәммәт хан аны әмир итеп таныды, тулы хокуклы хужа ясап куйды. Анлый, чамалый Булат. Үз тәхетен ныгыту өчен шулай кыйлана хан. Аңа әле бүген менә шулай кирәк. Ә иртәгә ни кыйланыр икән дә, ниләр кылыр—моны Мөхәммәт

хан үзе белә микән? Иллә мәгәр син хан кунагы бүген, хан яраны, шунын кадерен бел.

Янда Сәлман сайрый.

—Нуретдин, каһәр, бигрәк ышанычсыз бәндә икән, сатлык. Теге чакта, Минай ханны алып ташларга барган вакытта да, мине чак кына төп башына утыртмады, кабих. Мөхәммәт хан өч мең җайдаклы чирү таләп итте, хәзер үк бир, ди. Ә үзе, өстәвенә, корабларга, каекларга ишкәкче итеп утыртырга яңа нөгәр сорый. Мин Ашлыны басу сымак ачык капкалы итеп, бер сакчысыз калдырып китиммени инде?..

—Аксак Әхмәт тә ике яклы пычак. Үзе алдына юаш маэмай сымак шуышып килгән була. Ә үзе һаман олаулардагы байлыктан күзен алмый. Көзән дә шулай, бер тавыкны буа башласа, икенчесеннән күзен алалмый, ди. Ә-ә-әй, бигрәк саран соң бу, Аксак Әхмәт!..

Моны хәтта Мөхәммәт хан да тыңлый-тыңлый туеп бетте бугай. Ул берзаманны чатыр авызына табарак шуышып күчкән иде, шуннан файдаланып, Булат батыр да урыныннан купты.

—Булмаса, мин дә Чирмешәнгә төшеп, юынып меним әле. Юлда гел юыртып йөреп, тузанга батып беттем.

Артта ялагай Сәлманның чыш-пыш килгән сүзләре яңгырап калды.

—Бу да юха елан. Нуретдин илә Рахман әмирне сатып кына кеше булды. Моңа бик ышанма...

Булат сөзәк яр читендә, су эченә аякларын тыгып утырган бер сылуны инде күптән күз уңына алып куйган иде. Туп-туры шунын янына төбәп китте. Булат өчен сер түгел, Мөхәммәт ханның кыпчаклардан алып кайткан хатыны Зөбәрҗәттән туган Зөлфия бу. Яшь әле ул үзе, чынлап санасаң унбише тула микән? Ләкин җиләк сыман тулып ташкан инде. Әнә, килмәгән бер җире юк. Каен сыман зифа, озын гәүдә. Тыгыз, матур ботлар. Очына чия төше кунган түгәрәк, мул күкрәкләр. Карлыгач канаты шикелле кыйгач кашлар. Уйчанлыгын яшерә алмаса да, нур бөркегән карлыгандай күзләр. Аны йөзәрләгән болгар кызлары арасыннан да җиңел аерып була. Зөлфия—бишектән төшкәннән бирле кояш астында йөргән кеше шикелле каратут йөзле. Әмма болгар кызлары кебек салмак, үшән түгел. Күр әле, Булатның янына килеп җитүен шәйләүгә җәйрән шикелле ничек сикереп торды! Ни әйтсәң дә, дала кызы шул бу!

Зөлфия ике учы белән күкрәк очларын каплап баскан булган, ә көмеше шыр-ачык! Булат ирексездән елмаеп, карашын яшерергә мәҗбүр булды. Әйе, сез кайвакытта шулай ачык авызлы да, нык юмарт та була беләсез инде ул, кызлар!..

—Йә, син нишләп су кермисен, кызый? Нигә болай ялгыз утырасын?—дип, теленә килгән тәүге сүзләр белән авыз ачты Булат.

Ә Зөлфия ник коелып төшсен!

—Менә, берәр батыр егет урламасмы, дип көтеп торам әле,—ди.—Юкса, арпа басуына куйган карачкы урынына мине һәммәсе дә урап кына үтә.

Зөлфиянен мәрҗән шикелле ялтырап торган тешләренә карап, Булат та елмаймый түзмәде.

—Һе-һе! Ханәкәгә килеп орынырга берәүнең дә башына тай типмәгән инде.

—Сиңа типкәнмени?

Бу юлы инде талир тәнкә тавышлары белән зеңләп, тыелмый көлештеләр. Булат батыр хан чатыры ягына караш ташлап алды. Мөхәммәт хан да авыз ерып тора. Болай булгач, эшләр пешә дә пешә икән!

—Әйдә, ятим баладай калтырап торма инде, суга сикер, кызый!—диде дә, икенче минутта Булат әүвәл Зөлфияне төртеп төшерде, аннары айгыр

сыман, бөтен байлыгын күрсәтеп, елга суына чумды. Янә дөньяларын онытып көлә-көлә йөзә башладылар.

Алар хан чатыры янына иртән генә кайтты.

## 21

Нуретдин белән Рахман дәрья яры буйлап, Әтил каласы ягына качкан иде. Бәнҗәне урап үтеп Сарытауга житүгә, көтелмәгән тозакка тап булдылар.

Авыш тау итәгенә берегеп үскән каен, зелпе, чаган, юкә агачлары арасыннан сузылган юл. Артта калган Болгар мәркәзе ягыннан энгер-менгер төшеп килә. Алда, жайдакларны ымсындырып, шәфәкъ яктысы гына уйнаштыра. Ботаклар, яфраклар арасыннан уйнаклап, юл өстенә саран яктылык төшкән. Жәнлек, кош-корт кычкырган авазлар ишетелми, урман тып-тын. Һава җиләсләнде, тәмам күз томаланганчы юыртсаң да була. Болгар чигеннән тизрәк чыгып ычкынырга кирәк.

Тирә-яктагы табигатькә алданып, алны-артны чамаламый бара иде алар. Бермәлне үзләрен әүвәл яндагы агачлар өстеннән сызгырып очкан кыл-арканнар чорнап алды, аннары икесе тиң ат аяклары астына капланып төште. Искә-анга килеп өлгергәндә Нуретдин белән Рахман икесе дә бауларга чорналган көенчә юл өстендә ауный, ә күкрәкләренә инде теткәләнеп беткән киемле юлбасарлар менеп баскан иде. Баягы жайдаклар белән юлбасарлар бер-берсенең йөзләренә текәлделәр дә шаккаттылар.

—Нуретдин вәзир? Әмир Рахман? Кит, жаныгызны орыйм! Безнең кармакка мондый асылкошлар килеп эләгер, дип кем уйлаган? Әй, юлбасар Балак! Әй, егетләр! Боларны күрәсезме?

Ике качак түрә дә, билгеле ки, шундук таныдылар. Берьялгызы ташкирмән яулаган сыман оран сала-сала кычкырганы—кайчандыр Бәнҗә каласында Минай ханны чәнчелдереп төшерергә жыенган колчура Шонкар инде. Икенчесе—әле Талиб хан, әле яһүдиләр тәлинкәсен ялап йөргән пычрак жанлы Балак. Боларның артларына тезелеп баскан өч-дүрт ирне генә танып булмый. Ләкин болары да илсез-йортсыз калган юлбасарлар инде, моңа шик юк.

—Азат итегез, ычкындырыгыз безне!—дип үкерде Нуретдин, гарьлегенә түзә алмыйча жиргә тибә-тибә. Әмма сиздe, ат кылыннан үргән арканнар ул чәбәләнгән саен тәнгә ныграк үтеп керә, бәдәннәрне кисә башлый икән.

—Кемгә кул күтәргәнегезне күрмисезме әллә? Азат итегез, дим!

Шоңкар керфек тә кагып тормыйча, ирен чите белән көлеп сүз ташлады.

—Ник күрмик, ди, шәп күрәбез, Нурый. Әле кайчан гына син олуг вәзир Нуретдин дигән түрә булып хисаплана идең. Бармак башы белән селкетүгә, әллә ничаклы олысларны, калаларны аякка бастыра идең. Бездәй бичара колчураларны гына түгел, зур-зур олыс тоткан бәкләрне дә дар астына, зинданнарга озаттыра идең. Ә хәзер үзең дә кол син. Нәкъ безнең шикелле үк илсез-жирсез калган бичара кол! Жүнле хужаның ертык жиләненә дә ярамас ямаулык син! Сатлык ишәк!

—Боларны аяк сөртеп, тәкереп ташлаганчы, чишендерик әле,—дип сүзгә кушылды Балак.—Икеләтә файда. Без дә киенәбез, алар да шәрә көе качып китә алмый.

Махсус әмер биреп тору кирәкмәде алай. Жәягә ук корырлык та ара үтмәгәндер, артта торган ирләр качакларны анадан тума хәлгә калдырып ташладылар. Жиргә чокып ясаган куышлары да янда гына икән. Кичә генә вәзир белән әмир булып йөргән ике түрә кыл-арканга уралган көенә атна буе балчык идән өстендә хәрәкәтсез ятты.

## 22

Беркөнне кич Камышлы күл ягына җибәрелгән шымчы—сакау Хәлим кайтып, бутый-бутый тезде.

—Олы к-к-кәрван к-к-күл буенда төн к-к-кунарга к-к-калды. К-к-кырыктан артык дөя. С-с-сыртларына тау к-к-кадәрле төргәк төягәннәр. К-к-куйлар, бәрәннәр бар. Унбишләп к-к-кенә кушчы. Өч с-с-сәүдәгәр. К-к-камыш арасында яткан чакта тәгәл ишетеп к-к-калдым. Әтилдән К-к-кашанга бара торган яһүдиләр болар. К-к-кәрванбашының исемен Юзикәй, диделәр бугай.

—Юлга җыенызыз!—дип шундук әмер бирде Шоңкар. Нуретдин белән Рахман да инде күптән иректә йөри иде. Алар тарафына да кырыс карап алды.

—Әзергә бәзер корсак үстереп ятарга хан түгелсез әле. Кәрванны талауда сез дә катнашасыз.

—Әгәр кәрванбашы Юзикәй атлы булса, ул мине таный ла!—дип карышып карады Нуретдин, әмма Шоңкарның кылыч сабына ябышуын күрүгә үк, шым калгандай булды...

Юлда хәтәр ашыгып барсалар да, күл буена төн уртасы узгач кына килеп өлгерделәр. Кәрван корып урнашкан ыстан уртасындагы кисәүләргә карап, иң беренче, Балак тота-каба сөенгәндәй булды.

—Учаклары сүнеп бара. Кушчылары йоклагандыр инде. Бигрәк әйбәт.

Вакыт төн уртасы булса да, куна тактасы шикелле тап-такыр дала өсте бит, байтак шәүлә ерактан ук шәйләнеп, күзгә ташланып тора. Шуңа күрә ашыкмыйча гына ыстан өстен кабат-кабат күздән кичерделәр. Дөяләр аякларын янга сузган көе күши. Куй-бәрәннәр җылы саклау өчен бер-берсенә терәлешеп яткан. Уртага корылган өч тирмәнең берсеннән дә тавыш ишетелми. Төнгелеккә торгак булып калган биш кушчының өчесе учак янына сузылышкан, икесе күл буендагы агач төбендә йокымсырый сыман.

—Вакыт!—диде Шоңкар, тәвәккәлләп.—Сакчылар биш кенә. Шундук бәйләп атабыз.

Юлбасарлар гаярь болардай сикереп ыстан уртасына ташланганнар иде, бик нык ялгыштылар. Аларның ерактан төнге сакчылар дип санаган шәүләләре карачкы булып чыкты. Җансыз курчакларны бәйләп азапланганда дөяләр артына, камыш арасына поскан кушчылар болгарларның өстенә ябырылды.

—Артка, артка!—дип оран салды Шоңкар.

Ул үзе, урыннарыннан дәррәү сикереп кузгалган дөяләр арасыннан ыргылып, ыстан читенә очты. Аңа тагын ике-өч шәүлә иярде. Ләкин ыргаклы сөңгеләр тотып йөгерешкән сәүдәгәрләр белән кушчылар берничә юлбасарны эләктереп өлгерделәр. Артта юхаланып кычкырган Балакның тавышы ишетелде.

—Мин яһүди бит, мин яһүди! Сезнең туганыгыз! Үтермәгез, зинһар?

Аны таш өстеннән тәгәрәгән буш мичкәнеке сыман иләмсез каты аваз күмеп китте.

—Аһ, син яһүдимени әле, сатлык шайтан?! Юлбасарлыкта йөреп, безнең динне мыскыл итәсеңме? Менә сиңа, үз хәйләсе белән икмәк таба белмәгән үләксә җан! Эткә—эт үлеме! Менә сиңа, менә!

Ыстан уртасында әллә сөңге сабына, әллә тимер кисәгенә дан-дон килеп бәрелгән кылычның зыңлавы гына янгырап торды һәм күз ачып йомарлык арадан соң барысы да тынды. Шоңкар үзеннән аерылып читкә чапкан Нуретдиннең курка-курка сөйләнгән ике-өч җөмләсен генә ишетеп калды.

—Юзикәй танып өлгергән булса, эшләр харап, улым! Хәзер каханы ягына

юл бикләнде. Юзикәй каптырса, дарга аса безне. Инде хәзер кай тарафка качыйк?

23

Насыйр белән Байдар каханат башкаласында көннәр буе авыз ачып йөрде.

Этил дигәннәре, и-и, зур икән! Хак булса, монда сиксән меңләп кеше яши, диләр. Бардыр, бардыр. Ястык сөйгән килен күәсеннән ташыган әче камырмыни, дәрьяның ике як ярына да җәелеп урнашкан ул. Унда—әниләренең канаты астына томшыкларын төрткән каз бәбкәләре шикелле бер-берсенә сыенып утырган өйләр, сулда—учтан качарга җыенып чәбәләнгән кәлтә кебек боргаланган вак-вак урамнар. Таштан, бүрәнәләрдән салган йортлар, сарайлар күзгә бик ташланмый. Күбесе—балчык белән тирес катнаштырып суккан саман йортлар. Байтак йортларның бөтенләй түбәләре дә юк шикелле. Алар урынына—йә бүрәнәләр өстенә өйгән туфракса, йә үгез, дөя тиреләре белән аралаштырып салган камыш. Мондый йортларда ничек янгыннардан исән каласың да, дошман чирүе капкалар, диварлар аша үтеп керсә, баскыннарның акыртып талавыннан ихатанны ни рәвешле саклый аласың инде?!

Ә шулай да матур, тыныч Этил. Гөлбакча диярсең, һәммә яктан яшеллеккә чумган. Урамнарда, таштан салган зуррак йортларның ихаталарында сәрви, элмә, зәйтүн, хөрмә куаклары күкрәп утыра, арада керпе сыман бөгәрләнгән күгән-сырганаклар*, күккә үрелгән карагайлар, кипарислар да күп.

Манасий каханның сарае сарай гына түгел, олы кирмән. Диварлары гына да өч катлы. Эчтәгеләре күренми, ә ап-ак таштан биек итеп салынган тышкы диварны дилбегә озынлыгы ара саен икешәр торгак саклый. Насыйр барып бер-икесенә сүз кушып караган иде, аптырашка калды. Калкан, кылыч аскан сакчыларның һәммәсе дә йә Хорасан ягыннан килеп ялланган, йә болгар-бортаслы мөселман булып чыкты.

—Олы сөнге асып, озын көн буена чеддәдә пешеп йөрергә яһүдиләрнең башына тай типкәнме әллә?—дип аңлатты дөя ияртеп баручы бер сәүдәгәр, бу хакта сүз кузгаткач.—Алар дивар артына качып, Каф тау ягыннан, Көбә үзәннән китерелгән шәрабләрне озын чәйнек борыныннан чөмереп ятарга гына оста.

Диварлар артына качкан дөнья—серле, хикмәтле ул. Анда нинди мәкер, хыянәт, угърылык кисәүләре көйрәп ятканын узгынчы сәүдәгәр, йә булмаса капка төбенә бөкрәйгән угыз, төрекмән сакчысы каян белсен?..

Ә кахан сараендагы хәлләр, чынлап, шәптән түгел. Манасийның төпчек малае Иосифка да егерме яшь тулды. Казан тирәсендә, атлар ябылган лапасларда, мунчаларда яраннары белән калган саен телендә гел бер үк төрле агу:

—Минем атайга озакламый җитмеш тула ласа. Ата-бабайлардан килгән йоланы да исебезгә төшерергә вакыт.

"Анысы нинди йола икән тагын?"—дигән сыман яраннар аның йөзенә текәлсәләр, Иосиф читкә карап кына зәһәрлеген сибә.

—Соң, Овидий атлы ерак каханыбыз ук шундый йола калдырып киткән ләбаса инде. Җитмеше тулган кешенең акылы алышына. Ана сабыйлар зиһене әйләнеп кайта башлый. Вакытында тәхет чистартмасаң, каханатка бәла килүе бар. Овидий менә шуларны алдан ук күреп торган да, әтисен

* Күгән – терн, сырганак – облепиха.

тотып суйгач, бөтен ил буенча фәрман тараткан бит. "Житмеш яшькә житкән кешеләр йә үзләренә үзләре кул салырга тиеш, йә мин аларның гомерләрен кыям!" Минем атайдан да берәр төрле хикмәт корып арынмый булмас...

Бәла аяк астыннан килеп чыга, дигәндәй, Әтилдәге хәлләрне утка эләнгән казан шикелле кыздырып җибәрердәй сәбәп тә табылды. Әтилгә терәлеп утырган төрекмән сәүдәгәрләре бистәсенә котмәгәндә-уйламаганда мең кешелек угърылар чиргә бәреп керде. Таларга ярардай бар байлыкны кырып-себереп алып киткәннән соң гына бары да ачыкланды.

Булыр-булмас оранчылар Әтил урамнары буенча болай кычкырып йөрде:

—Киев каласыннан җыелышып килгән юлбасарлар алар. Башлыклары—бөлгенлеккә төшкән бояр Савилий, ди. Алар Дон белән Идел елгаларының бер-берсенә иң нык якынайган ике араны иннәренә көймә күтәргән көе узып килгән икән. Менә шуңа күрә аларның кайсы яклап килүен дә шәйләп өлгерүче кеше табылмаган. Кала диварларының дала ягына шул нисбәттән сакчылар да куелмаган икән.

Хактырмы бу хәбәр, әллә юкмы, ләкин кансыз Иосиф әлеге вакыйгага бик тиз рәвештә үзенең камыт-ыңгырчакларын атландырып куйды.

—Кахан картайды, кахан җүнсез,—дип котыртты ул янә яраннарын.—Үзенең чалбар бөрмәсен төймәләрлек тә рәте калмаган карттан ничек итеп ил чикләрен биктә тотуны таләп итәсең ди? Илне саклап калыйк дисәк, котылырга кирәк карт каханнан, котылырга кирәк...

Яшь Иосиф янында биеп-ялагайланып йөргән яраннарның һәммәсе дә берәм-берәм күнде. Кап-караңгы төн уртасында йокы бүлмәсенә үтеп кереп, Манасий каханның йөрәгенә пычак кададылар. Таң атканда Иосиф алтынланган түбәле биек баскыч өстенә чыгып күренде. Әлеге алтын чатыр-баскыч алдындагы җирләр инде әллә кайчан ук юри туфрагын алып чокырланган иде. Читтән карасаң, шәп бит! Кахан үрелеп буй житмәс биеклеккә, әйтерсең лә, болытлар өстенә менеп киткән. Ә кирәк чакта, фәрман тыңлар өчен җыеп ала торган сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, колчуралар аста. Шулай, син сарык көтүе, кара гавам, урыныңны бел!

Менә бүген дә үзенең йөзен күрсәтергә түбәнчелек иткән яңа кахан чокыр эченә тезелгән ун мең гаскәригә тәүге фәрманын ишеттерде.

—Манасий каханның ачыгавызлыгы аркасында урыс угърылары пайтәхетнең үзәгенә тикле үтеп керде. Хәзәр каханаты көчсезләнгән, дигән хәбәр таралмасын өчен ул угърылар чирүен тоташы белән юк итәргә кирәк. Яков, Абрам, Савва меңлекләре! Урыс угърылары артыннан куа чыгыгыз да миңа атаманнары Савилийны тере көе тотып китерегез!

Чокыр эчендәге мәйданнан өч мең җайдак чыгып югалуга, аларның урынын яңа гаскәр алды. Болытлар канаты белән бер биеклектә торган алтын түбәле чатыр эченнән яшь каханның яңа бер фәрманы яңгырап ишетелде.

—Манасий кахан дилбегәне кулдан ычкындырган, казна буп-буш. Каханат чигендә, ялгыш, берәр йөз генә дошман күренсә дә, сынар алайны киендерерлек тә сәрмая юк. Аланнар, чиркәсләр инде алты-җиде ел буена ясак китермәгән. Авызына китереп тондырган йодрыкны эт шикелле каптырып алмасаң, бер дошман да тешең барын белмәс. Хәзер үк, шушыннан ук юлга чыгыгыз да ул колларны тезгә чүктерегез! Манасий сыман баштан сыйпап йөри торган заманалар үтте, хәзер мәмләкәт тәхетендә яңа кахан!..

Урыс угърылары артыннан җибәрелгән меңнәр бер тәүлек дигәндә кире әйләнеп кайтты. Хәбәрләре мактанырлык булгач, чокыр эченә янә башкаланың һәммә почмагыннан куып китерелгән җаннарны тутырдылар.

Алтын түбәле чатыр астына баскан кахан алдында өч меңбашы да берьюлы җавап тотты.

—Угърыларны Жидеколак елгасы ярында чолганышка алдык. Һәммә угъры кылычтан үткәрелде. Синең тез алдына китереп салу өчен атаманнары Савилий белән дүрт йөзбашларын гына исән калдырырга туры килде.

Мәйданга арканнарга чолгалган йөзбашлары белән Савилийны чыгарып бастырдылар. Һәммәсендә күкрәкләренә чаклы салынып төшкән сакал, барчасының йә кулында, йә тәнендә яра. Кайберсеннән һаман да кан саркый, аларга өшәнмичә каравы да читен.

Яшь каханның гына төге дә селкенмәде, әмере кансыз чыкты.

—Йөзбашларын кисәкләргә чапкалап үтерегез!

Айгырдай тап-таза, яп-яшь угъры йөзбашларны "ә" дигәнче турап ташладылар. Инде чират ана житкәндер, дип Савилийга күз атканнар иде, һәммәсе "аһ" итте. Атаманның әле генә бөдрәләнеп торган, саламдай чәчләре күз ачып йомган арада көл төсенә кергән.

—Мине дә үтерегез,—дип эндәште ул Иосиф тарафына текәлеп, бер дә курыкмыйча.

Иосиф болытлар өстеннән көлеп җавап бирде.

—Ә-ә, ю-у-ук! Сине үтермибез. Яһүдиләргә каршы кул күтәрергә ярамаганлыкны гомерең буе сөйләп йөрергә тиешле тере балбал итеп калдырабыз сине. Без синең күзләреңне генә төртеп тишәчәкбез!

Җәллад шул минутта ук Савилийның ике бәбәгенә утта кыздырылган ике пычак тыкты. Кичен сукыр Савилийны кала диварлары артына чыгарып ташладылар. Икенче таңда ул инде юк иде. Кала буйлап байтак көннәр бу сәер хәбәр йөрде.

—Иосиф бу төрекмән бистәсен талауны үзе башлап оештырмады микән? Угъры дигәннәре Иосиф акчасына ялланган бичаралар гына түгел микән?..

Әлеге сорауларга җавапларны беркем белә алмады...

Иосиф озаткан икенче гаскәр, ике-өч айдан соң, кире кайтып төште.

—Аланнар да, чиркәсләр дә христиан диненә күчкән. Хәзер аларның артында юнаннар кайсары калкан булып тора. Алан-чиркәс җәйләүләренә таш ыргытсаң, кайсар безнең каханатка яшен сыман бәреп керәчәк, ди...

Иосиф гаскәрләргә яңа фәрман бирде.

—Безнең Идел буенда да бурычын оныткан колчура бар. Болгар өстенә барып ташланыгыз! Харәмханәдәге аларның аманат кызлары әби булды инде. Биләрдәге Мөхәммәт яңа кызлар биреп җибәрсен безгә, соңгы ун ел буена җыелган ясакларын бирсен. Ул гына да житми. Этне чылбырга утыртсаң, юаш, күндәм була. Аның үз кызын алып кайтыгыз сез миңа, үз җанашын. Аны шулай ипкә китерербез!..

Насыйр белән Байдар вакытында кайтып кисәтсә дә, Мөхәммәт хан сугым малы сыман калтырап төште.

—Йосыф кахан безгә каршы егерме меңлек чирү юллаган бит, аланнарга каршы җибәргән кебек кенә түгел. Житмәсә, без барып ышыкланырдай, безне яклап калырдай кайсар да юк. Ә ялгыз көе генә ни кырасың? Сынар бармак белән чокыр казып та, җәя корып та булмый. Юк инде, тәкәбберлек күрсәтеп, һаваланып кына мәмләкәтне канга батырып булмас. Иелгән башны кылыч кисми, диләр. Өне тыгылсын, тиешле ясакны да, аманат та бирәм.

Мөхәммәт хан үз йортыннан унбиш яшьлек кызы Зөлфияне аманат итеп озатмакчы иде. Бәнҗә каласыннан, шаша-котырына, Булат батыр очып килеп житте.

—Мин Зөлфиягә күптән гыйшык тотам. Каханга озаттырма, миңа хатынлыкка бир. Мин аннан башка бер көн дә яши алмыйм,—дип, әүвәл

ипле генә итеп ханәкәнең кулын сорады ул.

Мөхәммәт боз шикелле үзгәрешсез калды.

—Юк инде, ил өстенә яу чакырып булмый. Алмаш кызым да юк. Зөлфия булгач, Зөлфия, шуны озаттырам. Бик кыжрасаң, ул әйләнеп кайткач ярәшерсең әле.

Булат Болгар тарихында монарчы күрелмәгән тәкъдим ясап карады.

—Зөлфияне бирмә. Каханның өне тыгылсын дисәң, мине сатып җибәр. Зөлфия хакына мин кол булырга да риза.

Мөхәммәт ирен читләре белән генә көлемсерәп, һаман мыскыллавын дәвам итте.

—Ә син болай да минем колым түгелме соң инде? Бер тәкәне ике кат печмиләр бит.

Бәгыре-җаны күбәләк канаты кебек утка пешкән Булат батыр тешләрен шыгырдатып, сыкрый-сыкрый әйтте:

—Ханнар колагына колчуралар ялваруы барып ишетелсә, йә еланнар тез өстенә чүгәр, йә гөләп чәчкәләре энәләрен коеп бетерер, ди. Кызыл кар яуганчы көтсәң дә, алай булмый икән. Мәгәр бик белеп тор, син бүген бер әмиреңне югалттың, саңгырау хан. Сиңа колчура шикелле гомер буе бушка бил бөккәнче, мин, ичмаса, бер көнгә генә булса да бөркет булып калам...

## 24

Кахан гаскәрләре Сарытауга килеп житкән төшләреннән кире борылдылар. Үз әләме астына баскан биш йөз җайдак белән Булат батыр аларны үзәннәргә, чокырларга ышыклана-ышыклана гел озатып барды. Күзәтүгә җибәрелгән иравыл җайдаклары әледән-әле хәбәр итеп тора.

—Ялга туктаган саен Зөлфия ханәкә сәрдәр чатырында. Сәрдәр чирүләрне таркатмый тота әле.

Ниһаять, күңелне җылытырдай тәүге хәбәр килде.

—Сәрдәр олы чирүне өч канатка бүлде. Ике нөгәр китте, сәрдәр үзе өч мең җайдак белән Идел буенда ыстан корып ята.

“Кахан әмере үтәлгәч кайгырмый бу сәрдәр. Моңа адым саен туктап күңел ачса да була”,—дигән уйлар яндырып узды, әмма батыр үзен бик тиз кулга алды.—“Эчтән көя торган вакыт түгел. Зөлфия чатырын ачыкларга кирәк”.

—Үзем белән унбиш-егерме генә юлчы алам,—дип кырт кисте ул үзенең йөзбашларына.—Башкаларыгыз тын да алмый посып утырыгыз.

Кечке энгер-менгердә, Сарытау итәгендәге аю баланы, бүре юкәсе куаклары артына качып, озаклап күзәттеләр. Сәрдәр сәфәр ыстанын да, кахан сараеның диварлары сыман, өч кат итеп корган. Һәрбер чылбыр саен дистәләгән учак, йөзәрләгән сакчы. Сәрдәр—үзе кереп бикләнгән чатыр зурлыгындагы алтын бәһасе тора микәнни, кит, куркак җан!..

Гаскәр калган үзәнлеккә кайткач, йөзбашларын җыеп, Булат батыр сүзне кыска гына тотты.

—Сәрдәр чатырына сынар күсе дә үтеп кермәле түгел. Адашкан бозау сымак арттан ияреп йөреп, вакыт әрәм итмик. Моннан алты-җиде фәрсах ераклыкта ике тау арасына кысылган инкүлек бар. Ике якта кыя. Ишетеп тә беләсездер әле, Пар-Чукмарташ, диләр. Әйдә, сәрдәрне урап үтик тә шунда көтеп карыйк. Әгәр сәрдәр анда килеп керсә, чирүне сузып алып бармыйча булмый. Ике яклап тау башыннан ук яудыру, таш яудыру өчен иң-иң кулай урын...

Шул сәгатьтә үк кузгалып, таң атканчы юлда юырттылар. Менә ул—сихерле Пар-Чукмарташ. Ул инкүлекнең ике ягына билгесез пәһлеван аягурә бастырып калдырган гөрзиләрне хәтерләтә. Дөрес, ул дәү гөрзиләр артына әле тагын вак-вак таулар сузылып яшеренгән. Болары—үсеп кенә килүче, инкүлек суына күбенергә салган чукмарлардыр инде.

Кыялар өстенә менгәч, эреле-ваклы ташларны ташый-ташый, тау-тау итеп өя башладылар. Шулчагында сынар Чукмарташ өстенә торгаклыкка баскан йөзбашы хәбәр салды.

—Без килгән юл өстендә ялгыз жайдак йөри. Безнең ниятне сизеп алган шымчы булмаса гына ярый инде тагын.

Дистәләгән кеше, чуерташлар артына кача-поса, кат-кат күзәтteләр. Валлаһи да, ялгыз жайдак бит бу, һичбер юлдашы юк. Барып сыенырга куышы булмаган сукбай сыман бер урында бөтерелеп йөри. Сөңгесе, җәясе дә юк шикелле. Килеш-килбәте болгар кешесенә тартым кебек. Һәрхәлдә, аймыклар, угызлар сыман, баш түбәсенә киез эшләпәләр элмәгән бу. Ләкин ара бик ерак бит, тәгаен гына ничек ачыклыйсың?

—Игътибар итмәгез,—дип кул селтәде Булат.—Хәзәрләр кырып-талап үткән далаларда нинди генә юлчы киләп сарып йөрмәс? Берәр кәрваннан адашып калган, йә юл белергә җибәрелгән чапкындыр әле, баксаң.

Ялгыз жайдак берзаман юкка чыкты. Өйлә намазы үтеп барган чакта Сарытау ягында тузан болыты күтәрелгән иде. Сәрдәр гаскәре бу, башка берни түгел.

Салкын таш өстенә ятып озак көтте алар. Һәр яугирнең күзе юлда гына. Сәрдәр гаскәре буар елан сыман сузылып, ашыкмыйча атлый. Боларның тамагы тук, шул рәхәтлектән хәзер йоклый-йоклый баралар булыр.

—Теге жайдак ияртеп килә бит боларны, карагыз әле, кара!—дип хәвефләнеп кычкырды кинәттән генә, сакта яткан йөзбашы.—Безнең эзгә баскан шымчы булып чыкты бит бу каһәрең, сатлык булып чыкты!

—Тавыш-гау куптарма!

Кыя түбәсендә шундый кыска гына әмер яңгырады, аннары һәммәсе дә бер булып, дошман гаскәр өстенә текәлделәр. Әйе, алда, тәвис каурыйлары белән бизәлгән көмеш очлым кигән яубашы янәшәсендә, таныш жайдак килә. Кулларын бутый-бутый нидер сөйләп бара, авызы ерык. Моның белән янәшә атлаган җайдакларга да кызык, ахры, вакыт-вакыт, атларны сискәндерердәй итеп, кешнәп көлешәләр.

Дошман ташкынының беренче рәтләре ике тау арасына килеп керүгә үк, Бәнҗәнең үзеннән чыккан яугирләрне корт чаккандай булды.

—Бәрәч, бәрәч! Бәнҗәдән Мөхәммәт хан куган Шонкар бит бу!

—Фетнәче, гыйсъян Шонкар!

—Шоңкар? Шонкар!..

Һәммәсе аһ иттеләр. Илдәшләрен сатлык, хыянәтче, дип тамгаларга әле берсенең дә теле әйләнмәде. Шулай да, Шоңкар—дошманнар арасында, ә буар еланны утлы божра эченә алырга кирәк иде. Булат батырның күк күкрәгәндәй көчле оран салган тавышы яңгырады.

—Хәзәрләргә үлем!

Ике кыя арасына нечкә тасма булып сузылган тар инкүлек эчендә кисәк кенә гарасат һәм туфан купкан сыман булды. Чукмарташ кыялары өстеннән, ике яклап та, тоташ үк яңгыры яварга тотынды. Зәһәр тузан болыты, коточкыч тавыш куптарып, аска казан, чүлмәк, тәгәрмәч, камыт олылыгындагы ташлар очты. Кыя билендәге баскычларга, терсәкләргә эләгеп, чүендәй ул ташлар йөзәрләгән кыйпылчыкларга әверелде, дошман жайдакларын, чаптарларны хәнҗәр урынына кисте, тураклады. Аста дистәләгән чаптар иселде, йөзәрләгән жайдак ияр астына ауды.

Ышыкланырдай-качардай куыш эзләп, кешеләр кыя баскычлары астына ташландылар. Шашынган һәм котырынган атлар, кая туры килсә шул якка сикереп, берсен-берсе изә, таптый башладылар. Иңкүлекне өшәнеп кешнәгән ат, ачыргаланып кычкырган ирләр тавышы күмеп китте...

Игътибарсыз калдырылган Шоңкар кайсыдыр кыя астындагы куышка ташланган иде дә, артта хәзәр яубашының илереп үкергән әмере яңгырап ишетелде.

—Әнә теге болгар еланын качырмагыз берүк! Шул соран елан гына безне шушы үлем үзәненә алдап алып керде!

Хәзәр яугирләре качкан куышлар, чокырлар, ташлар арасыннан Шоңкар өстенә ук давылы очты. Алар качак егетнең арык гәүдәсен бер минут эчендә карбыз урынына теткәләп ташладылар...

—Шонкар өчен үч!—дип кычкырды бәнҗәле бер болгар, җәясенең тәтәсен ычкырдырган чакта.

—Зөлфияне, Зөлфияне алып качалар бит!—дигән икенче бер аваз һәммәсен сискәндерде.

Аска текәлделәр. Хәзәрләрнең яубашы, чыннан да, ханәкәне ияренә аркылы ташлаган көе читкә качып котылмакчы була.

Булат батырның өшәнгән тавышы, әйтерсең лә, таш кыяларны да уятып, ярып үтте.

—Зөлфияне, Зөлфияне коткарыгыз тизрәк! Аска! Һөҗүмгә! Аска!

Иллегә якын ир, өермә сыман кузгалып, кыя өстеннән аска ташландылар. Алар ясаган чөй әүвәл дошман җайдакларының сафын хәнҗәр кебек икегә ярып керде.

Чөй башында Булат батыр үзе. Җилән итәкләре ике канат сыман як-якка аерылган. Кулындагы кылыч ялт-йолт килеп тора. Күзләрендә бетмәс-төкәнмәс дәһшәт. Тагын биш-алты гына адым. Аннан... аннан ул Зөлфия җанашын кочагына эләктереп читкә ычкыначак. Зөлфия ханәкә. Җанаш...

Өлгермәде егет. Яннан килеп чыккан бер угыз пәһлеванының кылычы аның гәүдәсен икегә телеп атты...

## 25

—Чулман буйлап дошман төшеп килә!

Ак Идел тамагындагы Каракүл ямыннан ак күбеккә баткан чапкын килеп шушы хәбәрне әйткәч, әмир Ибраһимны аяз көнне яшен суккан кебек булды. Кисәк кенә бөтен тәне калтырап чыкты аның, зиһене томаланды. Ак Идел белән Иж елгалары аръягында Болгар хәтле Болгарга каршы чукмар күтәрә алырдай көчкә ия бер дәүләт тә юк бит. Ул якта шул, урманнарга кереп качкан мукшылар, арлар, чирмешләрдән кала, хәтта, берәр куәтлерәк кабиләнең дә күренгәне, булганы юк әле. Каян чыккан дошман чирүе бу? Сиздермәстән килеп талыйм дисәләр, Идел буенда Ашлы каласы бар. Аннан түбәндәрәк, Чулман тамагында Кашан бар әле тагын, Болгар каласы бар. Нигә болар Чулман буйлап килә? Монысы кем, кайсы сатлык өйрәткән яңа сукмак тагын? Иң мөһиме, нинди дошман соң бу?

Әмир Ибраһим яңа кирмән төзелешен саклаучы гаскәр башлыгы итеп җибәрелгән Илбуга бәкне дошман чирүенә каршы озатырга мәҗбүр булды.

—Сина бер йөз генә яугир бирә алам,—диде ул Илбуга бәккә, аның сорау тулы карашыннан качу өчен Чулман өстенә борылып.—Иж тамагы каршында камышлы бер утрау бар. Дошман каекларга, корабларга утырып төшә, диләр. Чулман уртасында тырпаеп утырган утрау үткен хәнҗәрдән

бер дә ким түгел. Ана җиткәч, дошман кәрваны кавын сыман ике өлешкә бүленмичә калмас. Ачыкла, бел. Нинди яна дошман бу, кайсы яктан килә, ничаклы яугире бар? Аннары аларга сиздерми генә кире борылырсын.

Илбуга ияр өзәнгесенә сул аягын куйгач, "онытма, мин кисәттем" дигән шикелле, Ибраһим өстәп куйды.

—Кара аны, яуга керәсе булма...

Күзәтче булып озатылган ирләр арасыннан егермеләбе камышлы утрау эченә кереп яшеренгәч тә, тирә-яктагы табигатьне күреп, шундук сихерләнде.

Күк йөзе зәп-зәңгәр. Анда-санда гына ак каурый шикелле вак болытлар йөзә. Бөтен тирә-якны, Чулман өстен тургайлар, былбыллар сайравы күмеп киткән. "Иң зифа тавыш миндә генә! Арада мин оста!"—дип узышалармыни?! Ике як ярны каплаган тал-тирәкләр артында ялгыз ләкләк кычкырганы да ишетелгәләп куя. Ярдан дулкыннар өстенә шомырт, балан, гөлҗимеш ботаклары сузылып төшкән. И, гөлҗәннәт! Дөньяны онып та сокланып ят. Ә монда, шушы оҗмах бакчасын җимерергә, туздырырга дошман килә, диләр. Нинди миһербансызлык, вәхшилек, гаделсезлек хөкем сөрә соң бу җир йөзендә?! Нишләп адәм балалары тилергән әтәчләр шикелле үзара чукышалар? Нигә алар ипле генә, тыныч кына яшәп ята алмый?

...Чулман өстендә икешәр-өчәр катлы киндер җилкәннәрен корып килгән каеклар пәйда булды. Бишәү, тугыз, унбиш. Артта тагын, тагын... Биегәйтеп ясалган диварлы каек саен кырык-илле яугир. Качып яткан берәр шымчыфәләннен сизмәгәндә генә сәрпи ук очыруы мөмкин, дип тә шикләнми бит болар. Өсләрендә көбә киемнәр юк, һәммәсе тезләренә җиткән киндер күлмәк кигән. Аякларында илне-көнне күргән юкә чабаталар. Арада кара сакаллылары да күренә, әмма күбесенеке җиз төсендә, алар себерке сыман җәеләп күкрәкләргә яткан. Юньле ризыкны байтак көннәр буе күргәннәре юктыр инде, ахры, корсаклары сыртларына ябышкан, beләкләре ап-ак. Ә җырлыйлар! Әнә берсе каек башындагы мичкә өстенә менеп утырган да салмак кына суза. Калганнары ара-тирә генә кушылгалый.

> Ты беги, мой конь, к моему двору,
> Ты беги, конь мой, все не стежкою.
> Ты не стежкою, не дорожкою,
> Ты беги, мой конь, все тропинкою,
> Ты тропинкою, все звериною...

—Аһ, каһәре, урыслар бит болар!

Илбуга үзенең янәшәсендә көтмәгәндә телгә килгән юлдашының авызын каплап япты.

—Шыбырдама, Гата, үзем дә күреп торам.

Утрауга кәрван ахырынарак баскан, борыны, ян-яклары көмеш япмалар белән бизәлгән каек якынлашты. Каек кына түгел, дингезләргә дә чыгарып җибәрерлек олы кораб инде бу. Биек дивар артына поскан борынында, әнә, биек итеп ясалган күперчеге дә бар. Дивар асларыннан берсе-берсе биш каз канатыннан да зуррак итеп ясалган ишкәкләр чыгып тора. Корабның арткы өлешендә авызы-борыны бөкеләнгән агач мичкәләр катлы-катлы булып тезелешкән. Ризык-зиннәтләре шушында боларның, димәк. Чирүнең авызы шушы корабка текәлеп каткан инде. Их, моны ничек итеп күккә очырасы?!.

Илбуга кораб күперчегенә менеп килгән ике ир тарафына күз атты да авызы кайнар ашка пешкән шикелле куырылып калды. Берсе—кәрванны җитәкләп килгән угърылар башлыгыдыр инде боларның. Ә менә икенчесе...

Бәнҗәдән, Биләрдән, ахыр чиктә бөтенләй Болгар жиреннән сасы пумала белән куылган әмир Рахман бит бу! Аһ, кабих җан! Аһ, иманы-дене коргаксыган бүкән! Ничек кенә җир йотмый моны?! Шушы эт җан, аяк табаннарын ялау өчен, ничек итеп яна хуҗаларны юллап тапкандыр?

—Яңа корган кирмәннәренә төшеп җитәргә күп калмады инде,—дип телгә килде сатлык.—Ханның үз малае төзегәнгә күрә "Ибраһим кирмәне" дигән булалар да, исеме юк әле. Иллә мәгәр хан малае төзи бит, анда байлык муеннан инде ул. Рәхәтләнеп, эченә чумып йөзәргә дә була!

Сатлык Рахманның ялагай сүзләреннән соң угъры баскыннар башлыгының күңелендәге өмет-хыял рәшәдәй уйнаклый башлады, күрәсең, тегесе тәнен шүрәле кытыклаган төсле кеткелди-кеткелди көлеп үк җибәрде.

—Кулга гына төшерик, сине буш калдырмам.

Илбуга чит-ят баскын белән качак болгар кыяфәтен күздән кичереп чыкты. Теге ир үз өстенә тимер челтәрләр белән бизәлгән кыска, күн бишмәт шикелле япма киеп алган, әмма җиңнәре юк. Башында—артына тимер челтәр тагылган көмеш очлым. Аннан нәкъ борын өстенә туры китереп тимер тел асылынган. Үгез күненнән ясалган киң каеш астында беләк буе хәнҗәр. Янда—уч төбе кадәр киңлектәге, ике ягы да үткен, озын кылыч.

Рахман—уйнашчыга күннән теккән япма тәтемәгән. Бил каешына кыстырган пычагы да картайган сугымчы кулыннан төшеп калган сыман. Баш түбәсендә бәрән тиресеннән генә теккән мескен бүрек. Үзенә калдык сөяк сыныгы ыргыткан баскыннарның табан асларын ялавын-ялыйдыр ул, иллә мәгәр кадер-хөрмәт дигәннәрен барыбер дә күрми бит бу йолкыш! Ә җиләне кабарып-бүртеп тора. Бу хәйләкәр, җилән астына җиңел көбә яшермәдеме икән?..

Кичен болар Мәләкәс дигән кечкенә бер елга тамагына төнгә тукталдылар. Яр тулысынча ак ташлардан хасил, шуңадырмы елга өсте учак яккан шикелле гел яктырып тора. Илбуганың ирләренә, чаптарларны каршы як ярдагы наратлар эченә яшереп, баскыннар ыстанына елан-кырда кибән шикелле калкып торган таулар итәге аша урап якынаерга туры килде.

Болар чатыр, тирмә корып азапланмый икән. Бер-ике урында гына ботак-санакларны җыештырып, сөңгеләр өстенә җәеп куыш ясаганнар. Яубашлары, сатлык Рахман, күннән теккән җилән аламасы кигән меңбашлары—һәммәсе дә шул куышлар янына корылган казан тирәсендә. Ә бүтән баскыннарның күбесе, әнә, үз учакларындагы утлы кисәүләрне читкә типкәннәр дә көл өстенә тәгәрәшкәннәр. Яр өстенә, каеклар тирәсенә генә кырык-илле торгак утырышкан.

Илбуга унбашларын чакырып киңәш-уңаш тотты.

—Егерме-утызлап ирне атаманнарының корабына юлламыйча булмас. Анда—баскыннарның ризык мичкәләре, тимер көбәләр, саугатларга әзерләнгән зынҗыр. Суга гына батырсак, баскыннар иртәгә аларны, көне буе чумып булса да, кире ала инде. Шуңа күрә ул явыз корабны яндырырга кирәк.

—Ач эт ярсу була, соныннан боларның кирмәнгә котырган шикелле ташланулары да бар,—дип сүз кыстырды Гата.

Илбуга аны җөпләгәндәй дәвам итте.

—Ярсысыннар, әйдә. Аның каравы, боларның җегәре бик озакка бармас. Ә без... ә без, менә, Гатаның унлыгы белән баскыннар ыстанының үзәгенә үтик. Ә-әнә теге, куыш корылган җиргә. Анда безне зәһәр бүләк көтә. Рахман сатлык җанны тере көе элэктерергә кирәк. Кирмәнгә алып кайтып җәза кылачакбыз без ул сатлыкка, үзебезнең җирдә!..

Баскыннар ыстаны уртасына елан шикелле шуыша-шуыша гына якынайдылар. Дошман озын көн буена урман кисеп кайткан диярсең,

гырлый-гырлый йоклый. Ботаклардан ясалган куышлар янына куелган ике сакчы да сүнгән учак тирәсенә бөгәрләнеп сузылган. Урманнар артыннан тан сызылып килә.

—Син әнә теге яклап шуыш, әнә теге яклап,—дигән шикелле, Илбуга Гата тарафына кул изәде. Үзе куышлар авызына таба шуышып китте. Менә, болгарлар ясап кидергән күн читекләр. Менә, сакал-мыек тирәсе токмачларга укмашып беткән сатлык Рахман. Авызын тавык йомыркасын бөтен көе йотарга җыенган сыман олы итеп ачкан. Тамак төбеннән бер генә аваз суырылып чыга.

—Гы-ыр, гы-ыр.

Илбуга әүвәл киерелеп анын бугазына хәнҗәр сабы белән тондырды да, теге камыт бавы сүтелгән ат шикелле туарылып төшүгә, авызына йодрык чаклы чүпрәк тыгып куйды, кулларын-аякларын кыл-арканнар белән бәйләп алды. Монысы хәзер тын чыгарырлык түгел, аны Илбуга эзеннән килгән пәһлеван яугир сөйрәп чыгып китте. Ә Болгар жиренә елан сыман качып кына, шуышып кына кергән баскыннарнын башлыклары кайда?

Гата белән икәүләп яндагы куыш авызына ташланганнар иде, аннан бер-берсенә терәп тезелгән казан төпләре генә чекрәеп карап тора. Илбуга белән Гата куыш тирәсен тагын-тагын капшап карадылар. Әллә нинди иске чабаталар, ертык күлмәк чокып чыгардылар, ә баскыннар яубашынын эзе дә юк. Әйтерсен лә, аннан җилләр искән...

Илбуга Чулман аръягындагы наратлыкка әйләнеп кайткан чакта егетләр сатлык Рахманны ару гына изгән иде инде. Атаманны таба алмаган кызудан, Илбуга үзе дә теге хыянәтчегә бер-ике мәртәбә "сылап" алды. Яман усал кысылган иреннәре арасыннан берничә генә сүз сытылып чыкты.

—Синдәй нәҗесне дә күтәрә бит туфрак, и-их, үләксә!..

Ирләр ияр өстенә менеп алуга ук, үзенен дә, баскыннарнын да бөтен серен сатып бетерде очсыз Рахман.

—Растуфныкылар алар. Нәрә дигән олы күл буенда шундый бер кирмән бар. Атай алып барып керде мине анда, атай алып барды. Кияү каласына төбәп киткәч Кәлҗәмә дигән суга житкән идек. Урыслар аны үзләре Келәзмә, дип йөри. Болар Болгар илә алу-сату итә торган кавем түгел, безне белүче юк, әйдә, шуларга сыеныйк, дигән булып, атай мине шунда алып китте. Растуфка житсәк, тегеләрдә ачлык. "Өсләренә барып таларлык кем бар? Давай, юл гына күрсәт", дип атайнын бугазына пычак терәделәр. Күрә торып үләсе киләмени? Атай юл өйрәтеп жибәрде инде менә.

—Ә үзе кайда сон әле ул, кабих жан?—дип, түзмичә, бүлдерергә мәжбүр булды Илбуга.

—Ул Растуф ушкуйларына ияреп, Кияү каласы ягына төшеп китте.

—Аһ, пычак кергере жан! Растуфларга Кияү каласы урысларын да кушып, бөтенесен берьюлы Болгарга каршы өстермәсә ярый әле тагын,—дип сүгенде Илбуга, һаман ярсый төшеп. Ләкин бераздан кышкы буранлы далада янә каты сукмак тапкан юлчы сыман үз эзенә кайтты.

—Бөтенесе ничә юлбасар?

—Өч мен кеше жыелып чыккан иде, бер-ике йөзе чирмешләр ягындагы сазлыкта батып калды. Ямансаз, диләр икән аны чирмешләр үзләре дә...

Рахман Туймас елга тамагына кайтып житкәч артына ава язды. Егет чакта бу якка да ауга килгәннәре бар, элек монда Чулман белән Туймас арасына кысылган Шәрә таудан гайре берни дә юк иде бит. Ә хәзер?

Чулман елгасы сыенып аккан биек тау сыртына ап-ак таштан кирмән күтәргәннәр. Дүрт почмакта түм-түгәрәк итеп ясалган дүрт манара утыра. Һәркайсында дошман гаскәре өстенә уклар яудырырлык, сумала, кайнаган су, утлы күмер коярлык итеп уелган озынча, тар "күзләр". Манаралар бер-

берсе белән җитмеш-сиксәнешәр адымлы таш диварлар аша тоташканнар. Диварларның бер ягында гына күтәрмәле капка калдырылган, башкалары кыя сыман тоташ. Эчке яктан кирмәнне янә бер мәртәбә карагай, имән, нарат бүрәнәләр белән ураганнар. Ак диварлар белән бүрәнәләр арасына ком-таш тутырылган. Бүрәнәләр ягы тәбәнәгрәк, аның өстенә берьюлы өчәр-дүртәр рәт сакчы тезелерлек киң басмалар корылган. Менә хәзер, шушы гына минутта кирмәнгә хәвеф тудырырдай бер дошман юк, ә торгаклар, барыбер дә, бөтен тирә-якны күз уңында тота. Боларга утлы кояш та, җил-яңгыр да комачауларлык түгел. Диварлар өстенә тәртә юанлыгы чеп-чи каеннарны, усакларны тезеп түбә ясаганнар.

Саклык чаралары әле шушылар белән генә бетсә икән! Юк, кирмәннең дүрт ягы буйлап та алгы якта йөзәр-йөзәр җайдак кереп чумардай чокыр казыганнар. Ул чокырның дивар астындагы як-ягында баш-башларын сөңге сыман очлап тезгән кат-кат бүрәнәләр. Кирмәннең бердәнбер капкасы каршына гына күпер көйләгәннәр, ләкин анысын да теләсә кайсы минутта сүтеп ташлап була. Кирмәннән илле-алтмыш адымнар ераклыкта текә тау итәге, анда махсус китереп аударылган ком өемнәре дә хәнҗәр йөзе сыман үткен вак таш өемнәре. Бар, сиздермәстән генә һөҗүм итеп кара син боларга. Әле шушы текә тау итәгенә дә үрләп менә алмыйча, никадәр ат корсагын ярачак, ничаклы баскын гарип калачак. Менә, ичмаса, кирмән дисәң дә кирмән! Рахманның үз гомерендә сыңар йорт булса да төзегәне бармы соң? Эх, син, каһәр суккан, эт талаган язмыш!..

Кирмән артындагы уйсулыкта әле тагын дистәләгән йорт күтәргәннәр. Болары шул, гадәти нарат, каен, усак бүрәнәләрдән генә. Урманы да Чулман ярына терәлеп тормый бит әле аның. Һәр агачны әнә теге яктагы, Иж елгасы буендагы карурманнар эченнән сайлап китертергә кирәк. Ният иткәч, бары да тырышканнар. Кирмән әзер, өстәвенә, яндагы агач бистәдә ике яңа урам тернәкләнеп килә. Моны озакламый йә калачык, йә шушы яктагы олыс үзәге итәрләр инде. Исемен, мөгаен дә, Ибраһим кирмәне-мазар дип тәгаенләрләр. Ибраһим хан булса, кала аты Илбугага күчәр. Шулай, илмәмләкәт файдасына тырышып бил бөккәч, ташларга язылып та кала кеше исеме, халык хәтереннән дә озак онытылмый. Ә Рахманнан бу җиһанда нинди эз калсын ди? Уйнашчы, дигәнме, сатлык йә баскынмы?..

Рахман белән сүз алышып, тел пычратырга теләмәде әмир Ибраһим. Моңарчы әмир чаклы әмир булып йөргән бу бәдбәхет тоткын бүген аның өчен черек агачтан каерылып төшкән сыңар ботак кына. Ул бәйләп салынган көенчә җирдә аунап яткан Рахманның янына да килеп карамады. Тоткынны иyргә аркылы салып кайткан җайдакларга текәлеп әйткән усал тавышы гына яңгырап ишетелде.

—Сатлыкларны нинди тәкъдир көткәнен баскыннар да белсен. Сабак алмаслармы? Әнә, кирмән диварына илтегез дә шуңа бәйләп куегыз бу имгәкне. Үзе Болгар өстенә ияртеп килгән баскыннары теткәләп бетерсеннәр. Моңа шул тәс.

—Юк, үтертмәгез мине, үтертмәгез? Мин синең аяк астында тузан булырга риза, Ибраһим, кол булырга риза. Диварга гына бәйләттермә мине? Моннан ары Болгар хакын гына хаклап яшәр идем. Үтертмәгез мине?— дип Рахман җир өстендә тәгәрәп-аунап йөрде. Колак салмадылар.

Дивар өстен кирмән сәрдәре Илбуганың кырыс әмерләре күмеп китте.

—Казаннар астына ут элегез! Ике йөз җайдак бистәне саклап кала, бүтәннәр кирмән эченә! Соңгы сакчы әрәм булмый торып, капканы төшерү юк!..

Әле төш вакыты житкәнче үк баскыннар чирүе Чулман ярын кырмыска өере төсле тоташ сырып алды. Әллә болар таш кирмәнне курчак өе сыман гына кабул итте инде, көймә-каекларын сакларга торгаклар да калдырып

тормыйча өскә ябырылдылар. Баскыннарны сафка-рәткә тезеп торучы юк, күзәтү йә сынау йөзлекләре җибәрү юк, хуҗасыз кәрван очраткан чүл бүреләре шикелле, ак-караны күрми алга ташландылар. Чулман өстендә берсен-берсе әйдәкләп кычкырган тавышлар гына яңгырап-яңгырап ала.

—Нигезен дә калдырмыйбыз бу кирмәннен, тетеп бетерәбез!

—Растуфта балалар ачка кырылып ята, энәсен-җебен дә калдырмыйча талап чыгачакбыз!

—Син ни кишеремә дип төрткәлисен, Сидор? Көймәләрне тутыргач бергә кайтасы бит, шул чагында муеныңны өзәм!..

Ком-таш сибеп чыккан текә тауга менә башлауга ук борыннары белән җиргә капландылар. Әллә ничәсенең мангае ярылып чыкты, йөзләбенен сакал-күлмәкләре тоташ канга батты. Бише-уны аска очты бугай, кылыч, сөнге, калкан тавышлары зеңләп купты, ун-унбише хуҗасыз хәнҗәр-кылычларга кадалып яраланды. Сүгенә-жикерә, әйтерсең лә, гарасат кузгаттылар.

—Аһ, каһәреңне өшкерим! Болгар еланнары безне тозак корып көткән!

—Шушы тауның түбәсенә менеп җиткәнче үк кырылып бетәбез бит!..

Иллеләп ир кабат Чулман ярына ташланып, каек-көймәләрдән алдан ук әзерләп килгән баскычларны сөйрәп чыгарды. Бу эшләре унышлырак булды, ике-өч дистәләбе генә, кардәшләрен изеп, өскә менеп өлгерде. Бүредән өреккән маллар сыман этешә-төртешә алга йөгерсәләр, тагын кискен упкын, тагын сөңге булып тырпайган очлы бүрәнә башлары. Ул арада таш диварлар ярыгыннан шөпшә күчедәй сызгырып очкан ук давылы. Дистәләгән, йөзәрләгән мәет. Дуңгыз тавышлары чыгарып чиный-чиный артка томырылдылар. Ә көймә-каекларда каткан ипи дә юк. Озын мөгезле, әмма инде яралы үгезне тотып ботарларга җыенган ач бүреләр кебек шуыша-шуыша, янә кирмән ягына борылдылар.

Һөҗүм иртәдән кичкә чаклы, өч көн буе барды. Янда, уйсулыкта калыккан агач бистәдән олау-олау күмер һәм кисәү башлары гына өелешеп калды. Якын-тирәдәге яланлыкта авызга алырдай ни бар, һәммә үләнне тел белән ялап алгандай кырып бетерделәр. Кирмән тирәли казылган чокырлар мәет белән тулды. Баскыннарның сафы бозлы яңгыр чүкегән суган кыякларын хәтерләтеп анда-санда гына тырпаешып калды. Көймә-каекларын Илбуга сәрдәр кирмән тышында калдырган җайдаклар урлап китте. Ә кирмән диварларына бер тапкыр да менә алмадылар.

—Шайтан каласы бу! Шайтан үзе ярдәм итә явыз болгарларга. Исән чакта ычкынырга кирәк!—дип, ниһаять, өченче кичтә акылга килделәр дә, Чулман тамагына таба чигенделәр.

Илбуга аларны атна буе эзәрлекләп барды. Куе чытырманлыклар арасына яшеренеп, көн-таң атса ук яудырдылар. Болгар чигеннән чыгып ычкынган чакта баштагы өч мең ирдән өч йөз өрәк кенә торып калган иде. Аларын да чирмеш урманындагы Ямансаз үз эченә йотты. Ростов ушкуйлары Чулман юлын дистә еллар буена бөтенләй онытты. Аның каравы, Болгар җирендә "Шайтан каласы" дигән өр-яңа кушаматлы кирмән яшәп калды.

## 26

Тол кенәзбикә Ольганың инде битләре җыерчыкланып бетте, чәчләре агарды, ә үзе һаман яшь Святославка мөстәкыйль рәвештә идарә итәргә һичбер ирек бирми, этлек артыннан этлекне эшләп кенә тора. Святослав яслар* белән касогаларга** каршы яу сәфәренә чыгып

---

* Яслар—бүгенге осетиннар.
** Касогалар—черкеслар.

киткән иде, "чукынган әбекәй" ике сөекле оныгына "ачтан үлмәскә" дип шәхси биләмәләр өләшергә тотынган.

—Үз корсагыгыз турында үзегез кайгыртырга да, идарә итәргә дә өйрәнерсез,—дип, Ярополк белән Олегны әүвәл Новгород каласына озаткан бу.

Новгороднықылар гажәп вәсвәсәле, вәкарь, эре көрпәле халык. Алар борын аслары да кипмәгән бала-чаганы санга сугамыни?!

—Без үзебезгә-үзебез баш та, түш тә. Киев этләренен поты бер тиен!—дип, кенәзләрне куып та жибәргәннәр.

Лышык-лышык борын тартып әйләнеп кайткан Ярополкка "изге әби" аптыраудан үзенен өр-янадан калыккан биләмәсе—Вышегородны биргән. Ә Олегы древляннар башкаласы исәпләнгән Коростеньда туенып яшәргә тиеш икән.

Әгәр карт толбикә Святославнын сөекле улы Владимирны да искә алган, санга суккан булса, яу сәфәрендә үлем белән качышлы уйнап йөргән тәкәббер кенәз, бәлки, шулкадәре котырынмас та иде. Ләкин кенәзбикә Ольганың ике оныкны үсендереп, өченчесен күз чалымына да китереп карамавы Святославны чыгырыннан чыгарды, тырнак астына кайнар энә кадагандай итте.

—Нәрсә, Ярополк белән Олег—аксөяк кенәзләр дә, Владимир минем өчен чит-ят баламыни?—дип ажгырып кайтып кергән улының сүзләренә каршы карт толбикә ыжлап та карамады.

—Владимир—колчура Малуша баласы, уйнаштан туган нәстә. Ә Ярополк белән Олег—никахлы кенәзбикә дәвамчылары. Аермалары—жир белән күк арасы. Син кайда гына, нинди генә канизәкләр тотып измәгәнсендер дә, синең аска яткан кайсы гына хатын бала тапмагандыр? Нәрсә, хәзер шул жилдән туганнарның барысына да кала-кирмәннәр бүләк итикмени?

—Никахлап кавышмый яшәсәк тә, Малуша—минем икенче хатыным. Владимир—өчесе арасында иң яраткан, иң акыллы улым. Ярополк белән Олег шикелле үк ул да кенәз, ул да тәхеткә һәм биләмәгә лаек!—дип Святослав чигенмичә тәкърарлагач, карт толбикә бик тә жинел генә хәл итте дә куйды.

—Кенәз буласы килә икән, әйдә, исбатласын!

—Ничек?!

—Ишеткәнен бармы, Хәзәр дингезе арьягындагы сәхраләрдә мондый бер йола яши. Андагы ханнарның балалары бик тә күп булып, хан шуларның берсен генә өстен күрә, үзенә тарта икән, башка туганнары аны йә кул-аягын бәйләп коега салалар, йә башын гына калдырып комга күмәләр, ди. Күктәге Тәнре яклыймы бу ала карганы, әллә кире кагамы—менә шулай ачыклыйлар икән. Әйдә, синен ала карганны да шулай сынап карыйк. Моны мин генә түгел, дистәләгән боярлар таләп итә.

Кабилә хәтле кабиләләрне буйсындырып, кала артыннан кала яулап йөргән Святослав әнисенең шушы сүзләреннән сон коелды да төште.

—Нәрсә, Владимирны да тере килеш күмәргә жыенасызмыни?

Ольга керфеген дә какмый тезеп китте.

—Юк, үтермибез дә, күммибез дә аны. Без Владимирны кулына бер корал, бер пычак та тоттырмаган көе урманга жибәрәбез. Ул нинди генә хәлгә төшсә дә, үзенен кем баласы икәнен әйтергә тиеш түгел, авылларга-бистәләргә ризык-ярдәм сорап керергә тиеш түгел. Менә шундый кыргый шартларда ул үзенең гомерен саклап кала ала икән, димәк, анда—синен кан, синен акыл. Исән-сау әйләнеп кайта икән, әйдә, чукын, теләсә кайсы калага утырт аны, үз урынына калдыр. Ул чакта бер сүзем йә үпкәмне ишетмәссен.

—Владимирның сынавы күпме вакыт сузылырга тиеш була инде?

—Топ-төгәл бер ел.

Святославның күзләре әйләнеп чыга язды, теле көрмәкләнде.

—Б-б-бе-е-ер ел?

—Әйе, төгәл бер ел.

Бик озак вакыт буе ишекле-түрле килеп йөргәннән соң Святослав, ниһаять, кул селтәде.

—Ярар, өнегез тыгылсын. Җибәрәм мин Владимирны.—Святослав әнисенә төбәп бармак селкеп алды.—Мәгәр сездән курыкканга түгел. Мин Владимирның исән-сау көе әйләнеп кайтасына ышанам. Владимир—минем бала, ул җиңәчәк!..

Владимир әбисе белән этисенең таләбенә күнде, карышмады. Үзен кызгандырып күз яшьләре түгеп тә азапланмады, бер сынык икмәк тә алмады. Баскыч төбендә яткан тал таягын гына эләктерде дә, сынау, читят җирләр, билгесезлек эченә сызгыра-сызгыра чыгып китте.

Аны озатканнан соң Святослав атна-ункөн чамасы түзде әле. Аннары сарай эче тарайды, әнисенә, хатыны Евпраксиягә күтәрелеп карый алмас булды. Читлеккә ябылган арысландай дәшми йөрде-йөрде дә, Киев боярларын җыеп, аларның өнен алды.

—Безнең кенәзлектә кемнәргәдер биләмәләр җитми башлаган, җир тарайган икән. Шуна күрә мин сезгә яңа яу сәфәре игълан итәм. Кемгә яңа җирләр янсә байлык кирәк, кулына корал алсын. Дошманнар алдында куркып тору бетте. Көнчыгышка карап юлга чыгам. Моннан ары минем үземнән алда һәр дошманга менә шундый кисәтү барып ирешәчәк. "Сезнең өскә барам!" Мондый кисәтү кай тарафка гына барып ирешмәсен, дошман алдан ук белеп һәм калтырап торсын. Димәк, Святослав килә, җиңү өчен килә!

27

Әмир Ибраһим янына Биләр каласыннан чапкын килеп житте. Идел буйлап дошман бәреп керде. Яуны Кияү каласының олуг кенәзе Святослав үзе җитәкләгән, Мөхәммәт ханга "синең өскә барам" дигән мәсхәрәле кисәтү җибәргән, ди. Святославка ияреп егерме меннән артык баскын килә икән.* Урысларның элгәре безнең җиргә мондый олы чиру илә, ә иң мөһиме, кенәз кул астында кергәне юк иде. Мөхәммәт хан зур хафага төште. Ул һәрбер улының үз янына басуын таләп итә.

—Нуретдин эше бу,—диде күкерттәй кабынган Ибраһим, ияр өзәңгесенә басканчы ук тоташ кара көеп.—Шул эт җанның эше. Нуретдин түгел бу, дөресе Нурый этдин. Эттән туган нәрсә! Шул гына ияртеп килгән инде тегеләрне безнең ил өстенә. Һаман Җир йотмый бит, ичмаса, шул хәсисне!..

Әзерлек чыра телеп ут куярлык арада тәмам булды.

—Сина ике йөз генә газине калдырам, өч йөз ирне үзем белән алам,—диде Ибраһим Илбуга каршында гафу үтенгәндәй.—Растуфларны кудык, бу тарафта хәят күк йөздәй аяз булып калды. Мәгәр растуфлар безнең уяулыкны йоклатырга җибәрелгән төлке генә булган. Ә ханлыкны таларга чыккан бүре көтүе Идел буенда хәзер, мине дөрес аңла.

Илбуга белән кочаклашып аерылганнан соң ияр өстенә менгәч, Ибраһим ашыга-кабалана янә өстәп куйды.

—Син Иж аръягындагы арлар вә мукшылар белән бозылыша күрмә. Алар белән дус яшәргә тырыш. Җай чыккан саен аларга шайман, тауар,

*Киев кенәзе Святослав Болгарга яу белән 964 елда килә.

икмәк, ярма юлла. Хәвеф-мазар туса, соңыннан ярдәмгә чакырырсың. Урман бәндәләре булсалар да аларда мәргәннәр күп. Таянырга була. Ә мин Нократ буендагы авыллардан ирләр җыям. Чиру таләп итеп ул тарафка барма.

Инде тузан болыты күтәреп Нократ ягына таба юнәлгәндә Ибраһим өзәңгеләренә күтәрелеп, борылып аваз салды.

—Ә кирмәнне моннан ары үз исемең белән ата. Йә Илбуга каласы булсын, йә Албуга булсын! Буга—"үгез" дигән сүзне аңлата бит. Болгар иленең чик буендагы үгезе, дигән атаманы ала икән, бик хуп, бик урынлы. Ул моны аклап өлгерде дә инде. Киләчәктә дә тезгә чүкмәс үгез булып калсын. Хуш, Илбуга!..

Нократ, Нырсы, Бәтке елгаларын үтеп Кашан каласына житүгә үк бары да ачыкланды. Әмир Ибраһим чишмә төбенә карагандай дөрес әйткән икән—Үзи, Тын, Урыс дәрьялары* буендагы халыкларны Болгар иленә качак вәзир, сатлык мәхлукъ Нуретдин ияртеп килгән. Яубашлары—Кияү каласының үзеннән үк чыккан егерме җиде яшьлек Святослав, ди. Ерак яу сәфәренә әле тәүге тапкыр гына чыгуы икән. Жинелеп кайтудан шүрләгәндер инде, кул астына егерме мең кешелек гаскәр туплап килгән. Боларның бер өлеше Ука, Идел буйлап көймә-каекларда төшкәннәр, ди. Аның өстенә Иделнең ике ярыннан җидешәр-сигезәр меңле ике олы нөгәр басып кергән. Шунысы гаҗәп: нөгәрләрнең берсе ат өстендә, икенчесе бөтенләй җәяү килгән. Җәяү булганнары ул икешәр-өчәр айлык юлны ничек үтте дә, ни ашады икән? Хәер, ниятләре-ысуллары мул булгандыр инде. Әнә бит, урманнарга качып өлгермәгән чирмеш ыруларын-авылларын тоташы белән талап чыкканнар, ди.

Болар Атабай авылына килеп җиткәч, Чулман суына да бик очынып-җилләнеп кенә барып кермәкче булганнар. Ләкин Атабай белән Болгар урнашкан ике як яр арасындагы су өстенә йөзәрләгән көймәләрне тезеп, аларның һәркайсына күкерт, сумала, житен, мамык төяп, Мөхәммәт хан Чулман тамагын тимер йозак белән бикләп куйган. Урысларның өч-дүрт йөзләп ташбашы әле шуңа да игътибар бирми борыннарын сузып караганнар. Әмма ут эленгән уклар янгыры астында көймәләрдә тоташ янгын купкач, һәммәсе дә шундук күккә очкан. Аннары араларында мондый дуамаллар табылмаган инде. Аптырагач, шул, үзләренә күптән таныш элекке юлга—Ашлы каласына карап төбәлгәннәр. Ә Ашлыдагы әмир Сәлман сакалына ут капканчы йоклап ята торган ачыгавызлардан, үшәннәрдән түгел. Ул каладагы бар халыкны күтәргән дә, Зөя буендагы чытырманлык эченә кереп качкан. Дошман инде ничәмә-ничә көннәр буе буп-буш Ашлы каласында бер кабымлык ризык таба алмыйча аптырап йөри икән.

—Урыслар хәзер анда кышкы өнгә яткан аю сыман аяк табаннарын гына суырадыр инде.

Болгар яугирләре шулай көлә. Күз тимәсен, кәефләре әйбәт.

Ибраһим әтисе Мөхәммәт ханның ыстанын Чулман уртасындагы утрауда эзләп тапты. Элек бу утрауда зур-зур ярминкәләр генә үткәрәләр, су уртасында булганга күрә исеме дә "Ага-базар" иде. Әтисе һаман да шул, һәрьяклап су саклауны сәбәп иткәндер инде, менә, үзенең яу ыстанын да шушыңа кертеп корган. Дөрес, чирүнең бер өлеше Болгар кирмәнен сакларга озатылган, ә төп гаскәр Ашлыга капма-каршы ярда, Баллы Арка дигән калку җирдә тупланып тора икән.

Мөхәммәт хан ничә айлардан соң тәүге тапкыр улын кочагына кысып каршылады. Сере тиз ачылды.

* Үзи, Тын, Урыс дәрьялары—Днепр, Дон, Рось елгалары.

—Теге ике имгәкнең берсе дә килеп күренмәде әле,—диде Мөхәммәт хан Ибраһимнын йөзенә туры карамыйча. Сизелеп тора, ул хурлана иде.

—Тимер-Мөэмин белән Габбас турында әйтәм... Ничә чапкын җибәреп карадым, бер җавап юк. Минем дөмеккәнне көтәләрдер инде.

Ибраһим сүзне читкә борырга ашыкты.

—Никадәрле чирү җыя алдын, атай?

Ханнын инбашлары бу юлы да сугып имгәтелгән каз канатлары кебек салынып төште.

—Газиләрнең саны уникө меңгә дә тулмады шул әле. Сәлман Зөя аръягында качып йөри, ашлыларга өмет баглап булмый. Яу башланса, Сәлман шул, арткы яктан килеп кенә ярдәм итсә инде... Җукәтауны әйттем. Тимер-Мөэмин белән Габбас анда яткан чакта җукәтаулар иманга килмәсләрдер... Бәнҗәгә дә таянырдай түгел. Аларны Йосыф кахан, елан сыман авызын ачып, йотарга әзер тора. Ә монда, минем кул астында, Биләр белән Кашан гына.

—Ярар, ияр өстендә йөргән баһадирга ясин чыгарга ашыкмыйк әле, атай,—дип Ибраһим тизрәк әтисен юатырга ашыкты.—Менә мин дә меңнән артык гази туплап килдем. Җан биргәнгә җүн бирер, ди Ходай. Дошманны пайтәхеткә барыбер үткәрмәбез.

Мөхәммәт ханнын да кәефе күтәрелде, ул Ибраһимның салпы ягына салам кыстырып алды.

—Улларыннын барысы да синең сымак таянырдай булса иде дә бит! Юк шул, әйгенәм, юк шул...

Ибраһим каударланып янә сорау бирде.

—Мин мин инде ул. Ә менә таянырдай, ышанырдай җүнле сәрдәр бармы?

—Балларкадагы чирү өстенә Даян вәзирне башлык итеп куйдым. Урыс арасында йөргән шымчы бит ул, дигән булып күпләр яратмый. Аларга сатылгандыр, арткы яктан пычак кадамасын, дип сөйләнүчеләр дә байтак кына. Мәгәр аның нәкъ менә шул урыслар арасында яшәгән булуы бәһасез өстенлектер. Чөнки ана урысларнын дуамаллыгы да, яу алымнары да күптән таныш. Ахыр чиктә, ул аларнын китек якларын да, мөгаен, сина-мина караганда шәп беләдер. Менә шуна күрә мин Даянны төп чиругә сәрдәр итеп куйдым. Йә, син хуплыйсынмы?

—Хуплыйм, атай,—диде Ибраһим, икеләнүгә шик калдырмастай вәкарь тавыш белән.—Эт өрә тора, бүре йөри тора. Читтә өреп яткан һәр көчеккә каршы таш ыргытып булмас. Иллә мәгәр, андый көчекләрнең авызлары томалансын өчен, Даян вәзир янына, әйдә, мине дә җибәр.

Мөхәммәт хан мондый җылы сүзгә күптән сусагандыр инде, Ибраһимны янә кочагына алды.

—Алай да син бар. Синнән кала тагын кемгә генә таяныр идем, улым?!

## 28

Даян Ибраһимны сөенеп каршы алды. Сәгате-минуты белән Баллы Аркадагы ыстаннын буеннан-аркылысына уратып алып чыкты. Үзенең теле-телгә йокмый, бертуктаусыз сөйли. Аңлашыла, бергәләп җавап тотардай яна иптәш табылуга ихлас сөенә бу.

—Газиләрне бишәр йөзлек алайларга бүлдек. Монда, Балларка өстенә өч мең генә ирне бастырып куйдык. Биш меңләп гази әнә тегендә, күл буенда ята. Күз күремендә өч мең генә ирне ялтыратып йөртсәк тә, урыс баскыннары һаман һөҗүм белән килми. Аптырагач, теге ярга ике йөз җайдакны иравыл итеп кудык. Башлыклары Байдар. Теге, атан Йомрыташ яныннан җәтмә белән эләктереп кайткан батыр, беләсеңдер инде. Ул уңъяк

ярга чыгуга ук Кашкатау түбәсен эләктерде дә алды. Әнә, кып-кызыл балчыклы бүрекне күрәсенме? Кашкатау ул. Ашлыдан бер фәрсах тикле дә ара юктыр, урысларның борын төбендә генә. Әй, ул Байдар хыялый да инде! Үзе урысларның күзләренә сукыр чебен булып кергә белә, үзе сабый бала төсле хыялый. Авыз суларын корытырдай булып, гел малае турында лыбыр-лыбыр сөйли. "Сал-Сал, Сал-Сал". Әй, тапкан соң исем!

Ибраһимга да кызык булып китте. Ул иреннәре буйлап таралган елмаюны да тыеп маташмады.

—Нинди Сал-Сал ул тагын? Йә, мина да сөйлә.

—Һе, аны Байдар пәһлеваннын үзе булып сөйләргә кирәк ләса,—диде Даян.—Ә андый осталык минем ишедән киләмени? Бер кичкә кер мичкә, әй лә, сөйләп карыйм.

Даян ирен тирәләрен ялмады да, яңакларын күпертеп, Байдар төсенә кереп, тезеп китте:

—Сания дә качак, мин дә качак, урлап ятак бүлдек. Ә урлап ашаган мал татлы була икән. Сания шәпле минем. Бер ел көттереп йөргәч, ниһаять, малай тапты. Әйтергә генә ансат, авырлыгы бер пот. Бер пот инде, бер пот, валлаһи, малайкаем. Кочакка да сыймый. Өнгә кереп чумган аю сымак бу, ими суыра да йоклый, суыра да йоклый. Ике яше тулганчы имидән башка бернине дә авызына алып карамады. Сания коры сөяккә калып бетте, жаный. Кочаклап ятарлыгы да калмады мескенкәйнең. Шуннан малайга әйттем. Житте, шайтан, хатын минем үземә дә кирәк, ботка аша, ипи аша, дидем. Бәрәч, бәрәч, малаең шулай ятак, никах турында да сөйләшә беләмени, дип сорыйбыз тегеннән. Байдар авыз ера. Юк, ди, ике яшенә житкәнче авыз да ачмады, ди. Аннан тагын сөйли. Ике яше тулгач, көчкә беренче мәртәбә әннә, диеп әйтте. Әле анысы да шул, имидән аерып ач тотканга гына. Бермәлне түшәм сайгакларын селкетерлек итеп үкерә бу, малай. Вә-ә дә вә-ә, авызына мендәр каплап та туктатырлык түгел. Хатын елый, мин тик утырам. Үз балаң тавышы туйдыра димени? Мин түзәм. Ә хатын, чыдамыйча, ботка пешереп бирде. Бармак башы хәтле эре ярмадан, арпаныкын. Агач жамаякны чүмәкәй итеп тутырдым да алдына китереп куйдым. Үземнең чүмеч хәтле кашыкны тоттырдым тегенә. Хәзер инде үз көненңне үзең күр, аша, мәйтәм. Күз ачып йомган арада ялт иттереп куйды. Кашык белән өстәл төя-төя янә сорый, шайтан. "Фал, фал!" "Әннә"дән кала әйткән икенче сүзе шул булды малайның. "Әттә" дип тә күңелне күрмәде бит, ичмаса, уйнаштан туган нәрсә! Фал, ди, тагын ботка фал, ди. Менә шуннан соң аңа Сал-Сал, дигән исем берегеп калды.

Ирләр, утардан кин яланга качып чыккан кыркымыш тайлар шикелле, кешнәп көлештеләр. Идел аръягындагы Байдар өчен дә, үзләре күрмәгән-белмәгән сабый Сал-Сал өчен дә бәхетле иде алар бу минутта. Күнел юаткач, беренче булып, әмир Ибраһим болытлардан жир өстенә төште.

—Бүген кичкә тагын бер-ике йөз жайдакны юлга әзерлә әле син, Даян сәрдәр. Ашлы каласының тирә-юнен үз кулларыбыз белән капшап кайтмый булмас. Караңгы төшүгә үк Идел суын кичеп чыгачакбыз. Ходай язган булса, бәлки, әле урыс ыстаны эченә дә үтеп кергә алырбыз. Бер-ике менбашларын чәлдереп, баскыннарының өнен алсак, ярап торыр иде.

## 29

Караңгы төн уртасында бугазына килеп терәлгән хәнжәр салкынлыгын тоеп күзен ачкач, Евсей бояр тынсыз-өнсез калды. Алтынчы дистәсен тутырып килгән чакта беренче мәртәбә Болгар дигән илгә каршы яу сәфәренә ияреп чыкты. Аеры бер биләмә, биштәр-

биштәр алтын-зиннәткә өметләнеп ничаклы юл үтте, газап чикте. Дошманнардан бигрәк үзенең туймас тәгамьле юлдашларыннан сакланып чатырын да кала читенә, хәвефсезрәк җиргә корып яткан иде. Әмма һәр бармакка уймак кигән сыман саклану да ярдәм итмәде шул. Төн уртасы узгач, аның чатырына аю шикелле иләмсез гәүдәле шымчы үтеп керде. Җан кыярга килгән Газраилгә тиң мондый катил нигә дип нәкъ менә Евсей боярны сайлаган соң?

—Шыбырдама, бояр!—дип телгә килде аның күкрәгеп тезләре белән сытып баскан карачкы иясе. Әллә үтелгән юлы кайнар булып чыккан, әллә дулкынлана бу—моның тавышы гыж-гыж килә иде. Барыбер дәвам итте.

—Син мине беләсең, минем кул ялгышмый. Тын чыгарсаң, шундук суеп атам. Ләкин иплә генә килешү икебезгә дә файда. Давай, акыллы бул.

—Әт... тәч!—диде Евсей бояр, тик бераздан гына.—Даян? Даян түгелме соң? Каян килеп, ничек? Мин сине моннан ун-унбиш еллар элек үк югалттым ла инде.

Даян Евсей боярның күкрәгеннән төште, әмма утын әрдәнәсе чаклы зур хәнҗәре әле һаман ялык-йолык килеп тора иде.

—Бөтен тирә-юньдә аяклы колак йөри, иплäп кенә сөйләш,—дип кисәтте Даян.—Әйе, сине ташлап кайтканыма ун ел чамасы гомер үтеп китте. Сезнең Киев каласында яшәсәм дә, болгарлы идем бит мин. Үз иләмә чакырып кайтардылар. Хәзер вәзир. Ханның уң кулымын.

Евсей үз колакларына үзе ышанмыйча күтәрелә төште. Ирен кыймылдатып әйткән ике-өч сүзе генә ишетелеп калды.

—Кит, әкәмәт, булмас. Кит, әкәмәт.

Даян исә җеген-җеккә китереп сөйләвен генә белде.

—Илнең иминлеге өчен ханнан кала, иң беренче чиратта, мин җаваплы. Святослав безнең гаскәрне тар-мар итә, калаларны талап чыга икән, минем урын дарда. Ярар, минем гомер алай, тау-тау алтын бәһасе тора торган бик зур байлык түгел. Хәер, синеке дә. Яу башланса исән чыгасыңмы әле син, ятып каласыңмы—гүпчем билгесез бит. Ә исән калырга да, баеп кайтырга да форсат житәрлек ул. Ил вәзире булган танышларың синең сукмагында гел-гел очрап тормас. Менә моның кебек малга риза буласың икән, уртак сүзгә юлны эзләп була.

Даян өстенә киеп килгән кап-кара чикмән астыннан кин каеш суырып чыгарды. Чатырның ярымачык торган ишегеннән төшкән яктылык та җитәрлек, каешның саф алтыннан коелган аелы ялт-йолт уйнап күзне камаштыра иде. Житмәсә, Даян каешның эчке ягына яшерелгән унлап кесәнең берсен ачып җибәрүе булды, аннан җир өстенә салган киезгә дисталәгән алтын тәнкә чылтырап килеп төште. Юк, кызыкмаслык түгел иде бу зиннәтләр. Евсей боярның күзләренә шундук шайтан уты кунды, кулын бизгәк тотты.

—Миңа нинди әмер җиткерәсең? Бурычым нидә?—дип сорады ул, кайнар чәй эчеп авызы пешкән кешедәй хап-хоп һава сулап. Аннары "тартып ала күрмә" дигән сыман кин каешны бер мизгел эчендә яшереп тә куйды.

Даян хәзер инде дөя сыртында утырган килеш кенә хезмәтчесенә аяк юарга боерган кәрванбаш тавышы белән Евсей колагына таләпләрен тезде.

—Кенәз Святослав хозурына барып колагына тукы. Бу—аның Идел буена төбәп оештырган беренче яу сәфәре. Җинелә калса, болгар гына түгел, мукшы, чирмеш, башкорт, вотяк халыклары, Ростов кенәзләре алдында да гомер буе юып булмас хурлык. Иртә унмаган кич унмас, ди, алдагы яулары да хуш буламы әле? Шушыларны уйласын-үлчәсен дә Биләр өстенә барып маташмасын. Җир йөзендә Святослав кылыч күтәрергә бурычлы, ул үч

алырга тиеш хакимнәр бар. Әнә, хәзәр каханы Йосыфка сезнең вятич кабиләсе дә, Ростов, Смоленск кенәзләре дә дистә еллар буе ясак түли, кахан хәрәмханәсенә иң сылу кызларны озатып ята. Без дә каханның олтаны астыннан котыла алмый иза чигәбез. Сөяк бүлә алмаган сукбай этләр сыман талашканчы, Святослав белән Мөхәммәткә үз сыртларыннан Йосыф каханны чәнчелдереп төшерү дан. Менә шушы җырны җырла кенәз колагына, шундый юлга күндер.

Евсей боярның юл чатында хәер сорашып утырган дәрвишнеке кебек талымсыз һәм ач карашын күргәч, Даян үзенең кашларына хәтле төшереп кигән кара башлыгын салып ташлады. Чүпрәк астында саф алтыннан койган очлым ялтырап китте.

—Бу хан бүләге түгел, минем очлым гына,—дип аңлатты Даян.—Кенәз күнә икән, хан да әҗерле булып калмас-калуын. Ә җавап хәбәрең әзер була калса, менә сиңа бәләкәй көмеш аел. Моны күрсәтсәң, юлдагы һәр болгарлы минем чатырыма чаклы озатачак сине. Шүрлй күрмә, сиңа тырнак очы белән дә кагылучы булмас.

Тулган айдай балкый башлаган Евсей кулын күкрәгенә куеп ант сулары эчәргә тотынды.

—Син теге чакта, урыс җирен Әкбәр уйнашчыдан азат иткән чакта минем гозеремне аяк астына салып таптамадың. Шуннан бирле синең каршыңда бурычлы йөри идем. Моннан ары бер сүзеңнән чыкмам. Миңа ышан.

Боярның тавышы әллә нишләп шундук ясалма һәм төче булып ишетелде Даянга. Шуңадырмы, чатыр ишегенә кулын сузган чакта кире борылып ирен арасыннан ысылдарга барыбер онытмады.

—Кенәзеңне кисәт. Башны култык астына кыстырып кайтуга караганда алтын очлым киеп киту күпкә шөһрәтлерәк.

30

Икенче көнне Кашкатау буена урыс ыстанынннан чапкын килеп житте. Даян шундук тойды: егерме җиде яшьлек Святослав үзен күрше ихата тавыклары янына барып кергән әтәч урынына бик тәкәббер тота һәм тез чүгәргә исәпләми иде.

—Кичә алтын очлым биреп, и-их, сантыйга калдым!—дип сүгенде Даян, әле чапкын янына каршы чыкканчы ук.—Бездә сәрдәр дә менә шундый алтын очлым кия дип, сандык капкачын ачып салдым бугай. Хәзер баскын кенәз базар халкы сыман сатулашып, үз бәһасен арттыру ягын гына карап торыр инде.

—Кенәз язмышны сынап карамакчы була,—дип белдерде чапкын.—Ул Ашлы каласы белән ике арадагы кырда батырлар алышы үткәрүне таләп итеп куя.

Батырлар алышы үткәрү—Болгар иле өчен аяз көнне уйнаган яшен шикелле кыргый күренеш түгел. Монда бишектән сикереп төшкән һәрбер бала-чага сабан туе саен, бәйрәм саен бил алышулар, аркан тартыш, ат чабышы, мәргәннәр бәйгесе сыман ярыш күреп үсә. Чапкын каршына да, сафны бозып, уннан артык җайдак чәчрәп чыкты.

—Һи-и, аңа гына калса, үткәрәбез аны!

—Ярар, алышабыз, батырыгыз чыксын!

Урыс чапкыны каршына Даян сәрдәр чыгып баскач кына артка чигенделәр. Даян карашы белән үтәли көйдерерлек итеп текәлде. Тешләрен усал шыгырдатып сорау бирде.

—Кенәз эргәсендә Евсей бояр бар идеме, юкмы?

—Янында торып калды.

—Димәк, синең кулга көмеш аел эләкмәгән инде?

Чапкынның аптырап калуын күргәч, янә тешләрен кыса-кыса сүгенергә булды.

—Вәт, туймас тамак! Вәт, имгәк җан!

Аннары гына үзенең ил-яу өчен җаваплы сәрдәр булуын исенә төшерде, ахры, тыныч кыяфәткә кереп аваз салды.

—Алышның шарты бармы? Батырлар нинди корал белән сугышачак, дип әйтүем.

—Юк, бернинди дә таләп куймадылар. Алыш алыш инде. Кем ничек булдыра, ничек җинә ала—анысы батырларның үз карамагында.

—Аңлашылды,—диде Даян сәрдәр.—Харәмләшүсез генә алышсыннар иде...

Урыс чапкыны Ашлы кала ягына китеп барды. Берәр сәгатьтән соң дошман гаскәре шәһәр капкасыннан ургылып чыкты да тере дивар булып тезелеп басты. Даян сәрдәр белән Ибраһим икесе дә кызу-кызу күз йөгертеп чыкты. Ун мең чамасы ир-ат кына монда. Ярты гаскәр Ашлы эчендә калган. Димәк, болгарларның андый-мондый этлек эшләвеннән бик нык шүрли болар.

Урыс төмәненең бер канатында көбә-очлым урынына кайры тун һәм арткы як итәге муенга асылынган тирән бүрек кигән, беләкләренә сагыз кушып катырылган күн калканнар элгән ике мең чамасы җайдакның аерымрак оешып басуын шәйләгәч, Даян үз күзләренә үзе ышанмыйча башын чайкап куйды.

—Әмир, әмир!—дип тиз-тиз эндәште ул шөбһә, хәвеф белән.—Әнә теге, бер як читтәрәк аерылып торган нөгәрне күрәсеңме? Бәҗәнәкләр бит болар, валлаһи, бәҗәнәкләр!

Ибраһим да теше сызлаган сырхау шикелле йөзен чытты.

—Менә монысы инде бик яман фал, Даян,—диде ул да әрнеп.—Башка халыкларны болай итеп үз кубызына биетә башласа яисә сатып алса, урыс кенәзләре безне дә берзаманны аяк астына бөкләп салачак бит...

Даян белән Ибраһимга ияреп Иделнең уңъягына йөзеп чыккан ирләр саны бер меңгә дә тулып җитми иде. Шуна күрә, сәрдәр әмере буенча, сулъяк ярда калган барча җайдак Баллы Арка өстенә тезелешеп басты. Ундагылар Кашкатауның бар итәген каплап таралдылар. Янәсе, менә күр, бәһалә, баскын кенәз, синең безне җиңәрдәй-тузгытырдай көч-куәтең бармы? Тик онытма, биредә сәрдәр генә. Ханның кул астында син күрмәгән-белмәгән тагын бер чиру яугирләр сакта тора әле!..

Ингә-иң торып баскан урыс сафы арасыннан чем-кара айгырга атланган җайдак аерылып чыкты. Болгарлар күз белән ашардай булып аңа текәлделәр. Аты гаярь. Күкрәк тирәсе дә, ботлары да баудан ишкән сыман. Ялы-койрыклары кояш яктысында ялт-йолт килеп тора. Мангаенда ап-ак йолдызы бар. Бәкәлләре дә тоташ актан. Тояклары нәни чүлмәк кебек. Айгыр аз гына кымшанса да, тирә-якка белен калдәр чирәм кубып оча.

Җайдак үзе, карап торышка, әле яшь күренә. Башына тимердән чүкеп ясалган олы очлым кигән. Салам кебек сап-сары чәчләре эскәк белән кыздыргандай бөдрәләнеп тора. Сирәк-мирәк үскән сакал-мыегы да сары. Йөзен күгәрчен күкәе белән рәттән куярлык бар, аны эреле-ваклы тәкәрлек басып киткән. Олы гаскәр исеменнән алышка үзен чыгаруга сөенәдер инде, сап-сары мыегы астында шундый ук сап-сары тешләре ялтырап күренеп тора. Бер карасаң, ул әннән, әнисеннән качып уенга гына чыккан бала-чагадан әлләни кайтыш түгел. Әле ярый, тимер тәңкәләрдән ясалган озын көбә өстеннән иңнәренә кызыл җәймә япкан. Шул җәймә генә аның кыяфәтенә җитдилек һәм мәһабәтлек өсти...

Даян сәрдәр Кашкатау итәгенә тезелеп баскан болгарлар өстенә караш

ташлап алды. Әнә, кылычын кынынnan суырып чыгарган көе Ибраһим урынында алгысынып тора. Аның артына Кашан бәге Габделваһап баскан. Алардан арырак—болгарларны тәүге булып дошманның борын төбенә, Кашкатауга алып чыккан Байдар. Янәшәдә—Даян сәрдәрнең үз малае Насыйр. Тагын дистәләгән гаярь ир-егетләр. Һәркайсы да үгез хәтле үгезне бер сугуда аяктай егардай гайрәтлеләр. Әмма... Болгарның йөз аклыгын саклап калуны кайсы пәһлеванга гына тапшырырга соң? Кем сынатмас? Илне тоташ кан коюдан, кара яу михнәтеннән кем коткарыр?..

Ибраһимның аргамагы алга сикереп чыкты.

—Үзем орышам! Минем атайны аның улыннан да алда кем якласын?

—Артка чиген, әмир!—дип, үзен-үзе белештерми кычкырып җибәрде Даян.—Бәйләп салган малны чалып ташлау берни тормый. Атаң илә син дә харап булсаң, без бәйләп ташланган бичара мал хәленә калачакбыз. Аннары болгарлар кайсы таждар өчен генә яуга керер икән?

Сафлар арасыннан авыр чукмарын чөеп уйный-уйный Байдар калкып чыкты.

—Мин Иделне беренче кичеп чыктым. Син нәүбәтне болай итеп бозма әле, әмир. Кемгә орыш язган тәкъдирендә, кемгә тәхет. Мин бит синең тәхетеңә бер дә борын тыкмыйм. Син дә орыш-алышларга, әйдә, борын тыкма.

Байдар бәхәсләшергә урын калдырмастан урыс сафына таба юырттырып китте. Ирләр күзәтеп калды. Алмачуар аты ерак юлда йөреп гадәтләнгән. Моның берчакта да хуҗа-җайдакны ташлап качасы юк. Байдар үзе дә, күз тимәсен, аргамак өстендә коеп куйган кебек. Инбашлары кибән өярдәй таза. Муены симертелгән үгезнеке сыман. Куллары имән кәүсәләре, йодрыклары бәләкәй чүлмәк чаклы. Мондый пәһлеванны кемнәр генә җиңә алсын инде? Чукмарының җиле тиеп китсә дә, теләсә кайсы ирне карачкы урынына тетеп ата бит бу!..

Җайдаклар анда-санда әрем сибелеп үскән киң яланның калкурак урынына житкәч тукталдылар. Ике җайдак тынмас дошман булып, бер-берсенә каршы килеп басты. Икесе дә ике якка күз йөгертеп көчләр тикшерделәр. Әнә, урыс гаскәренең уртасына кып-кызыл япмага төренгән кенәз чыгып баскан. Сәер, моның аргамак өстенә ябылган җәймәсе дә кызыл, очы өскә бөгелгән итекләре дә шундый. Әйтерсең лә, ул гаскәр уртасында канга сусаган, канга баткан сөзгәк үгез сыман. Янында яраннары. Әллә кемнәр түгел. Иле белән халкы читкә типкән сатлык Нуретдин. Карашында ачлык, нәфсе уты сүнә белмәс Евсей. Кәләш сорап килгәч кулларына черек кавын чыгарып тоттырылган кияүләр шикелле каушап калган менбашлары, бояр, пәһлеваннар.

Болгарлар ягында да башын горур тоткан ирләр әлләни күп түгел. Ибраһим Әмир ияре өстенә кылыч салган булган, ләкин өзәнгеләренә хәтле дер-дер килә. Байдар белеп тора, яуга, орышка атлыгудан туган шаукым тәэсире бу. Даян сәрдәр дә эче тулы ут булганга күрә бер урында басып тора алмый, елан куган сыман әрле-бирле йөри. Калган менбашлар да бер-берсенә туры карамыйлар. Болар да хәвефле. Һәммәсе дә алыш-орышның нәтиҗәсен көтә.

Ниһаять, батырларга бер-берсен сынарга да чират килеп житте. Урыс баһадиры кулына тәртә чаклы юан сөңге тоткан, билендә кылычы, хәнҗәре бар. Байдарның да бил каешында кылыч, ә кулында үгез боты хәтле олы чукмар. Аргамаклар алда ни көткәнен сизенәләр бугай, борын тишекләре дөянеке сыман киерелгән, кайнар сулыш бәрә.

—Алеша, Алеша! Алга ыргыл, алга! Бүкән сыман бәреп төшер болгар карачкысын!—дип урыс баһадирын дәртләндереп кычкырган сүзләр ишетелде.

Болгарлар да бурычлы калмадылар. Ялан өстен күк күкрәгәндәй тавыш каплап китте.

—Урыс аламасын кавын сыман тетеп ташла, Байдар! Үләксәсен дә таба алмасыннар!..

Ике баһадир да айгырларның касыгына типте. Бер мизгел эчендә ялан өстендә явыз туфан, гарасат үзе купкан сыман булды. Атлар сөлек кебек сузылып капма-каршы оча. Ялларь тузгыган, койрыклары кипкән камыш себеркесе төсле тармакланган. Борын тишекләре дәү ирләрнең йодрыклары сыярдай булып киерелгән. Икесенең дә тояк астыннан бияләй-бияләй чирәм чәчрәп оча.

Байдар әле бер дилбегә кадәр ара калганда ук күрде: урыс пәһлеваны сөнгесен дошман айгырының күкрәгенә төбәп килә иде. Аһ, мәкерле! Ул Байдарны атсыз калдырмакчы, ялан буенча куып йөртеп, көтүдән аерылган бәрән урынына изеп таптамакчы! Акылың кот икән, таптамый тор әле!

Байдар йөгәнне кисәк каерып аргамагын читкә тайпылдырды, үзе ул арада дошманының сөңгесенә олы чукмар белән орып узды. Ару эләкте бугай, Алешаның сөңгесе кызыл балчык өстенә чәчрәп очты, егет кырт тукталды. Байдар аргамагын кире боргач кына үкереп аваз салды.

—Ат хәтле атка кул күтәрәсеңмени, имансыз җан? Мин сине моның өчен эт урынына тотып ярмасаммы!

Алеша сөңгесен кабат кулына эләктергән иде инде, ярсый-ярсый янә Байдар өстенә очты. Ләкин никтер ул сөңгесен сул кулына күчергән, ә уң кулының учын нәни кошчык тоткан сыман бик сак кына йомарлап килә иде. Урыс баһадирының нинди этлек әзерләп өлгерүен Байдар тоймады да. Ике аргамак бергә тигезләнүгә үк Байдарның йөзенә соскыдан сибелгәндәй бер уч ком килеп бәрелде. Пәһлеванның ике күзе дә шундук томаланды, кулыннан чукмары төшеп кала язды.

Байдар кул аркасы белән күзләрен ышкылаган чакта янда янә дошман аргамагының тояк тавышлары ишетелде. Байдар башын селки-селки күзен ачты. Бөтен дөнья куе томан, кара төтен эченә кереп чумган кебек. Шулай да, әнә, ниндидер тау килә аның каршына, зур карачкы килә. Байдар чукмарын югары күтәрде, ана бәрелеп кылыч тавышы дан-дон килде. Көндәшен чукырга ябырылган әтәч сыман кыйлана бит урыс, зәһәр кылыч тавышы һаман тына белми.

Ниһаять, аерылдылар. Урыс чирүе ягыннан эт өстергән сыман тавыш килә.

—Алеша, кылыч белән тура, кылыч белән!

—Алеша, сөңгең белән болгар карачкысын урталай яр!

Байдар әле алышка керешкәнче үк сайлаган калку урынга янә барып басты. Әнә, мәкерле урыс та яңа һөҗүмгә әзерләнеп тора. Ләкин аны юньләп күреп булмый. Ике янак буйлап та яшь тәгәри, бөтен ялан көймә өстенә сузып салган сыман чайкала. Ничек кенә, нинди генә чара табасы соң?

Байдар сул иңбашына капланган җиз калканны җиргә тотып атты. Авырлыгын янә үлчәгән төсле кулындагы чукмарны кат-кат сикертте дә, котырынып-ярсып, анысын да читкә болгап атты. Юньләп күреп булмый. Дошманны бер сугуда йә имгәтергә, йә бетерергә кирәк. Байдарның кулы ялгышса, бу мизгелдә Алешаның аны урталай өзүе бар. Ул чагында хурлык. Ул очракта җиңелү. Илне тоташ талап чыга алмасалар да, урыс гаскәре барыбер ясак таләп итәчәк, ир-егетләргә, хатын-кызларга коллык янавы бар. Юк, ярамый! Дошманының бугазын чәйнәп булса да өз, әмма җиңелә күрмә! Өеңдә газиз улың Сал-Сал да бар бит әле. Ул синең хурлыгыңны ничек күтәреп яшәр?..

Байдар ияр артына тагылган бер аршын озынлыгы гына сөңгесен сөйрәп

чыгарды да, аның ыргаклы ягын дошманына төбәп, калкулыктан түбән томырылды. Ун дилбегә озынлыгы ара калып бара, биш дилбегә, ике...

Менә, аргамаклар күкрәкләре белән бәрелеп үрә торды. Ике кыя бербересенә бәрелеп чәкәштеләр диярсең, ике якта ике гаскәр шау килеп купты. Ике аргамак өстеннән дә ялан чирәменә ике пәһлеван мамык сыман очып килеп төште. Ә аннары яшүсмер Алеша җир өстеннән иң беренче булып сикереп кузгалды да күрәк йөзедәй киң, иләмсез кылычын богауланган шикелле кымшана алмый яткан Байдар пәһлеванның бугазына тыкты. Канга баткан Байдар авызыннан тик бер генә сүз сытылып чыкты.

—Сал-Сал...

## 31

Святослав өчен күк капусы ачылгандай булды.

—Безнең батыр җинде, Алеша өстен чыкты! Мәрхәбә, мәрхәбә!— дип ярсып кычкырды ул, иңнәренә канат үскән сыман.—Без изге юлда, сугыш алласы безнең эшне хуплый!

Урыс гаскәре инде болай да чик-чаманы белмәгән кыргыйлар төркеме урынына тантана итә, шашына, котырына иде. Берәүләр очлымнарын салып күккә чөя, икенчеләре кылыч-сөңгеләрен калкан йөзенә бәрә-бәрә дөңгерди. Тилебәрән орлыгы ашаган сыман һәммәсенең күзе акаеп чыккан, авызларын бүрек йотардай ачып үкерәләр.

—Безнең батыр җинде! Алеша, Алеша!

—Болгарларны турап бетерәбез!

—Боларны шәрә калдырганчы таламыйча торып, кире борылмыйбыз!

Бер-берсен ишетүче, берни анлаучы юк. Үзара кочаклаша-кочаклаша биилэр, сикерәләр.

Святослав үзенең фәрманын көч-хәл белән генә ишеттерә алды.

—Алга, болгарлар өстенә! Миңа Мөхәммәт ханны тотып китерегез!

Ашлы диварлары тышында торган ун мең кешелек урыс гаскәре бер мең болгар яугире өстенә ябырылды. Тоташ ташкын булып купкан дошманны күрүгә үк Ибраһим әмир белән Даян сәрдәрнең кабаланып кычкырган әмерләре яңгырап узды.

—Кашкатауга, Кашкатау өстенә чигенегез!

—Дошман Иделгә юлны бикли алмасын, ике як итәккә ике чылбыр булып тезелегез!

Даян белән Байдар инде әллә кайчан ук Иделнең бу як ярына йөзгә якын арба чыгарып куйган икән. Күз ачып йомган арада әнә шул арбалар артына кереп яшеренделәр. Һәммә арбалар да янга яткырылды, өсләренә киез ыргыттылар. Урысларның беренче сафы кул сузымы арага якынайгач, ыстаннар артыннан аларның өстенә ук яңгыры очты. Беренче рәт чалгы белән чабып ташланган шикелле кырылып ауды, икенчеләре кыяга килеп төртелгәндәй капылт туктады.

—Алга, алга!—дип кычкырды котырынган кенәз.—Алар биш-алты йөз генә бит, кырып бетерегез!

Урыс белән бәҗәнәк сугышчылары берсен-берсе таптый, изә-изә, өрянадан алга томырылды. Күбесенең кыяфәтләре үк өн алырлык иде. Атналар-айлар буе җылы су күрмәгән сакаллары себеркегә охшаш. Кайсыларының киндердән суккан ыштан балаклары эт талаган кебек сипелеп беткән, чабаталары тишек, кайсылары бөтенләй яланаяк. Ярты гаскәрнең кулында сөңге-кылыч, калганында тәртә озынлыгындагы ике япьле сәнәк йә булмаса чалгы.

Арбалар ышыгында яткан бер мең болгарлы ук яңгыры очырып та, кылыч

болгап та каршы торып карады. Егылганнар урынына яңалары басып, чылбырдагы өзеклекләрне ялгарга тырыштылар. Артка чигенүче яки яу кырын ташлап качучы җебегән күренмәде. Ләкин урыслар күп, бәҗәнәкләр дә шулар арасында. Алар тау башыннан ычкынган таш өермәсен хәтерләтеп, юлда очраган бар нәрсәне сытып килә иде. Берзаманны алар тау итәген каплап яткан ике чылбырны да өзеп-йолкып узды. Әле аягүрә калган болгарлар да, яралылар да яубашлары ягына борылып кычкырдылар.

—Без боларны тыеп торачакбыз. Син кач, әмир, син кач!

—Сәрдәр, сәрдәр! Идел аръягына качып котылыгыз!

Тагын бер талпынса, урыс явы болгарларны тетеп атачак иде. Монысы көн кебек ачык. Ниһаять, Даян сәрдәрнең карары ишетелде.

—Булды, бетте. Каекка сикер, әмир!

Ибраһим әле һаман кулына кылыч тоткан көе дошман сафларын каршыларга әзер тора иде. Аның кымшанмыйча басып калуын күргәч, Даян инде ярсый-ярсый килеп ябышты.

—Безгә синең Тимер-Мөэмин бораләрең шикелле ханнар кирәк түгел. Синең хакың безнең өчен Тәңре хакына тиң. Чиген, әмир!

Яу кырына соңгы тапкыр караш ташлады да Ибраһим җинел каек эченә сикереп керде. Шул мизгелдә үк ике ир Идел уртасына төбәп ишкәк ишәргә тотынды. Бау белән тагылган шикелле, аларга Даян сәрдәр каегы ияреп чыкты.

Бераздан Кашкатау өстендә орыш-алыш тавышлары тынды. Урыс яугирләре арбаларны әйләндереп-җимереп болгар ыстанын айкап карадылар да, эскәк очына каптырырдай да ганимәт-зиннәт таба алмагач, кенәз ягына борылып үкерделәр.

—Без ни хакына дип кенә кан койдык соң? Монда пычак та юк.

—Байлык Иделнең теге як ярында. Болгарларның чын лагеры шунда,— дип кычкырды Святослав, кылычы белән каршы якка төбәп.—Идел суын йөзеп чыгабыз да, Болгар илен талап бетерәбез!

Яңа кан һәм тәүге җиңү күреп, урыс ирләре дә, бәҗәнәк җайдаклары да шашкан иде инде. Меңбашлары тарафыннан әмер ишетелүгә үк, йөзәрләгән ирләр суга сикерде. Кемдер арба, бүрәнә, каек калдыкларына ышыкланып акты, кемдер көбәсен, коралларын салмый гына йөзде. Идел уртасындагы чоңгыллар эченә җитүгә, дистәләгән ирләр үлем ятьмәсеннән котыла алмыйча, су төбенә китеп югалды. Исән калганнары дәһшәтләнеп-шашып сулъяк ярга чыкты.

Урысларга чит-ят ярда сафларга, чылбырларга тезелеп торырга ирек бирмәделәр. Баллы Арка өстеннән аларга әүвәл ук яңгыры яуды, аннары җайдаклар төркеме айкап-турап узды. Ике меңгә якын юлдашларын югалтуга ук, исән калганнары кабат Идел суына чумды. Яралылар, чукмар йөзе күреп миңгерәгәннәр янә чоңгыл төбенә китеп югалдылар. Ашлы кирмәне ягына йөзеп чыга алганнар, ярга баскач, Святослав йөзенә текәлеп сүгенделәр.

—Ни пычагыма дип син безне үлем авызына алып килдең?

—Кырык дала аръягындагы Болгарга килеп әрәм булганчы, борын төбендәге Галич, Волынь кенәзлекләре юк идеме әллә?

—Шушы кадәр ерак җиргә килеп, сынар алтын кисәге дә таба алмыйча, буш кайтабызмыни?!

Кара янып чыккан Святослав кенәз айгыр касыгына тибә-тибә җавап тотты.

—Юк, кире чигенү юк! Болгарлар, барыбер, безгә каршы торырдай гаскәр туплый алмый. Бәнҗәгә таба күчеп Иделне кичәбез дә, Җукәтауларын, Биләрләрен талап мал җыябыз. Яңа сәфәргә, яңа яуга җыеныгыз, руслар! Зиннәт һәм дан безне алда көтә!..

## 32

Мәгъфур Иделнең ике як яры да күкрәп-яшьнәп, дөбердәп килгәннән соң янгыр тамчыларын күрмичә алданган җиһан сыман булды. Әйтерсең лә, ике гаскәрнең дә очып китәр канатлары сынды.

Урыс ыстанында тынычлык юк, күмәк аптыраш, хәвеф, тәшвиш хөкем сөрә. Пәһлеваннар орышында Алеша җиңеп чыккач, алар әүвәл күк күкрәвенә тиң тавышлар куптарганнар, шашып сикерә-сикерә тантана иткәннәр, кылыч-сөңгеләрен, калкан-очлымнарын болгый-болгый Святослав кенәзне күмәк яуга әйдәп масайганнар иде. Кашкатау буендагы ансат җиңүдән соң да, ай-яй, очындылар. Ләкин Идел аръягындагы Баллы Арка янында утта янгач, кикрикләре шинде. Җен башка, пәри башка, дигәндәй, дошманны тыеп үз оянда сугышу белән үзең дошман өстенә ташлану, һөҗүм ясау җир белән күк аермасы икән шул ул. Ә бөтенләй читят булган Болгар җирендәге яуларны, сәфәрләрне дәвам итсән, син бу илдән исән-имин кайтып китә алырсыңмы, әллә инешләр, сазлыклар эчендә ятып калырсыңмы? Өстәвенә, болгарлар әле һаман, мөгаен дә, барча гаскәрне дә күрсәтеп бетермидер. Алар үз илендә. Алар сафына сәгать саен яңа нөгәр, яңа алайлар өстәлеп торуы бар.

Святослав кенәз капкын авызына килеп басканмыни, һични кыла, йә кузгала алмый. Зиһенендә умарта күче шикелле мең төрле уй.

Болгар өстенә килгәч, ул аю өненә башын тыккан мескен аучы хәленә калды бугай. Ни Киев ягыннан өстәмә гаскәр кәтәрдәй бер әмәл юк, ни Болгар аюы якасыннан тоткан көе һич җибәрми аны. Коллар һәм ганимәт хакына ялланган бәҗәнәкләр дә язгы боз шикелле ышанычсыз. Аларның теләсә кайсы минутта урысларны ташлап китүе йә, булмаса, дошман ягына качып чыгуы бар. Ә нинди дә булса катгый карарга килми мөмкин түгел, түгел! Бу—Святославның беренче яу сәфәре, җиңелеп йә ташлап кача икән, моннан ары сукбай эт тә ияреп чыкмаячак аңа. Яусыз китү хурлык. Ни кылырга хәзер?

Уйлар арба тәгәрмәче шикелле әйләнә-әйләнә дә, һаман бер үк эзгә кайтып төшә. Моннан тавыш-тынсыз гына чыгып качам дисән, Болгар ханы исән-имин җибәрәме сине? Ай-һай, дошманың хакында бик тә беркатлы һәм мокыт уйлый торган сантый булма алай! Капкындагы Святославны тотып тунамаска ул җүләрме әллә? Әле Киев ягына таба чигенсәң дә, Мөхәммәтнең сине юл буена шөпшә күче сыман талый-талый озатуы мөмкин. Үтерүен дә үтермәс ул, бәлки, иллә мәгәр калҗа-калҗа итеп умыра-умыра шыр сөяккә калдырыр, желегенә үтәр. Ә кысыр сарык хәлендә кайтып егылган мескенне Киевта кем жәлләсен? Анда, әнә, Рюрик нәселеннән булган Мстислав, Олеглар бар. Җиңелеп кайттыңмы, ат караучы кол урыны сиңа! Саубул, тәхет!..

Святослав Ашлыдагы Сәлман әмир йортына кереп оялаган иде. Батырлар алышыннан әйләнеп кайтканнан бирле күрше капка төбендә Евсей бояр белән сатлык Болгар эте Нуретдин да, тагын бер-ике меңбашы бөтерелеп йөрде. Болар инде "җиңү" юарга керешкәннәр бугай, төсле керәч корган тәрәзәләр аша һаман саен көчәя генә барган кычкырыш-көлеш авазлары янгырап ишетелә. Святослав түземи йөзен чытты. Әллә бөтен каласына ут элдереп ычкынырга инде? Янгын мәхшәрендә, ичмаса, исән-имин качып булмас микән? Ә бу Евсей ише, Нуретдин ише этләр ник кадалып китми, аларга төкерәсе!..

Болгарлар ыстанында тынлык хөкем сөрә. Чатырлар-тирмәләр янында да, юлларда да һичбер хәрәкәт юк. Яугирләр дә, яубашлары да үләт

афәтеннән качып, үз почмакларына кереп сыенганнар. Һәрбер ирне үзенчә уй, үзенчә шеш талый.

Байдар пәһлеван орышта оттырды, әрәм булды. Бик яман фал иде бу. Ходай тәгалә ярлыкамый безне, дигән кайгы басып китте. Болгарлар яна бәрелешләрдә дә җинелү һәм хурлык көтә иде. Кашкатау өстендә тар-мар ителгәч, тагын өшәнделәр. Димәк, Ходай тәгаләнен бездән борылуы рас икән бит. Димәк, безне янә коллык, янә хурлык көтеп торуы бар. Ходайның рәхмәте белән, әле ярый, дошман гаскәренә Иделнен сулъяк ярына күчәргә ирек бирмәделәр. Дошман менәрләгән ирләрен калдырып, кабат иске оясына кереп бикләнергә мәҗбүр булды. Ләкин сугыш төгәлләнде, дошман безне ташлап качачак, дип тынычланырга, шатланырга, ай-һай, иртә әле. Шымчылар кайтып әйтте, урыслар Бәнҗәгә таба яна көчеш ясарга әзерләнә, диләр. Аларны туктатырдай көч-куәт юк. Тимер-Мөәмин белән Габбас әмирләрнен чирүе һич күренми. Өстәмә гаскәрләргә өмет тотып булмый. Кумәк орышлардан, бу сазлыктан ничек кенә исән чыгарга соң? Урыс гаскәре белән яна бәрелештән ничек котылырга?

Ибраһим әмир читлеккә ябылган җанвар шикелле тыз-быз бәргәләнә. Телендә гел бер үк төрле зар, бер үк кайгы.

—Аһ, әрәм булды бу Байдар дигән батыр, аһ, сынатты! Шунын аркасында гына Кашкатау өстеннән тар-мар ителеп качтык. Безнең язмыш һаман кыл өстендә. Ул баскын кенәз ачудан Ашлыга ут төртеп китмәсә генә ярар иде!..

Түзем канатының каурыйлары тәмам коелып беткәч, Даян сәрдәр дә чатыр почмагыннан кузгалып, житди аваз салды.

—Ярар, алма пеш, авызга төш, дип көтеп ятып булмас. Көн кичке якка авышты, бүген яна һөҗүм белән килмәячәк болар. Аларның яртысы хәзер жинелү кайгысын хәмер мичкәсенә төшеп юа булыр. Ибраһим әмир юраган шикелле, боларның Ашлы каласына ут ташлавы мөмкин. Каланы әрәм итмик, аны без төзисе. Иң яхшысы, әйдә, бал белән ширбәт төйик тә үзебез кенәз янына кунак булып барыйк.

—Ни сөйлисен, сәрдәр? Нинди кунак тагын?—дип әмир Ибраһим изүенә килеп ябышса да, Даян вәзир һич тә каушамады. Кысла сыман артка шуышыпмы, елан шикелле тартылып-сузылыпмы—мона фәкать алга бару булсын.

—Син урысларнын күңелләрен анлап кына бетермисен, әмир. Ә мин ун ел буе алар арасында яшәп кайткан кеше, байтак галәтләрен яттан беләм. Күңелләре яраланган чакта да, шатлык барында да күкрәкләрен сабый бала имезгән ана төсле ачып куя алар. Ә инде берәр тустаган да кабып алдылармы, ул чагында туарылып елый башларга да бик күп сорамыйлар. Мондый чакта авырткан сөялләренә һәм мин-минлекләренә генә кагылырга ярамый аларнын. Киресенчә, аларны үсендерергә, күңелләрен күтәрергә кирәк. Шулай итсән, урыс иртәгә үз дошманы белән дә килен төшерешә ул.

Ибраһим, көпә-көндез яна ай күргәндәй, аптырап уйга калды. Әле Даянның күзләренә килеп текәлде ул, әле баш чайкады. Элек шымчы булган, аннары вәзир хәтле вәзиргә әверелгән Даян, кара, ни өйрәтә?! Сыный гынамы соң бу, чынлап сөйләвеме?

—Кунакка барып керсәк, тотып та суймыйлармы?—дип, түзмичә, янә очып килеп житте Ибраһим берзаманны.

Даян элеккечә суза-суза тәкърарлавын белде.

—Суй-мый-лар, валлаһи, суймыйлар, дим. Алар хәзер үзләре үк ни кылырга белми. Кашкатауда бер мен болгар ирен кырып бетерсәләр дә, Иделнен бу ягында алар икеләтә-өчләтә корбан бирде. Болгар уртасына килеп кергән көе алар бүген тоташ камалышта утыра. Яна һөҗүм, яна яу

башларга куәтләре, дәрманнары бетте. Алар хәзер мәкер-хыянәттән, безнең көтелмәгән һөҗүм ясавыбыздан дер калтырап тора. Шуңа күрә хәзер хәмер чөмерә инде алар. Кайгы-шөбһәләрен шулай бушаталар. Мин аларны беләм... Аннан, аннан, туктале син, әмир... Син кунак булып үзең барырга җыенмыйсыңдыр ла инде, туганкаем?

—Ә нигә? Ник бармаска әле?—дип Ибраһим Даян сәрдәрнең каршысына килде.

Даян, әүвәл кычкырып көлде, аннары каршысында мөгезле кеше күргәндәй тораташтай калды.

—Туктале, туктале син, әмир. Бу бит уен түгел. Урысның аның исерек чакта акылы кирәле-чыгалырак. Син хан малае. Исән-имин качып китәр өчен сине аманат итеп алулары мөмкин. Ул чагында нишлим? Әле гел аманат итмәгән очракта да бәла. Сине урыс кенәзе янына алып чыгуымны белсә, Мөхәммәт хан мине беренче каен ботагына асып кына куя. Ю-у-ук, Ибраһим, алай шаярмыйк без. Сиңа да гомерең җәл, миңа да җәл.

—Ә мин әмир булып чыкмыйм,—диде Ибраһим берзаманны.—Минем атай да меңбаш булып йөргән бит әле Бәнҗә каласында. Мин дә меңбаш булып барам, йә йөзбашы булам. Миңа урысның чын йөзен аның ыстанына кереп күрү кыйммәт. Алдагы язмышны кемнәр белгән әле? Тәҗрибә бөкре түгел, ул җилкәгә ятмый. Киләчәктә һәр сабакның кирәк булуы бар.

Ниһаять, хәл иттеләр. Ибраһим гап-гади йөзбашы булып киенде, Даян үз урынында, сәрдәр көе калды. Кичке шәфәкъ яктысында ияр өстенә кыю менсәләр дә, ут офыкта түгел, гүя боларның күкрәк читлегендә дөрләп яна иде.

33

—Кунаклар, кунаклар бар!—дигән хәбәрне ишеткәч тә, Святослав кенәз аптырауга төште. Чит-ят мәмләкәттә, чолганыш уртасында нинди кунак тагын? Мескен хәлдә яткан Святослав кемгә кирәккән дә, үз тиненә санап кайсы бәндә аның янына килергә җөрьәт итте икән?

Святослав болдырга чыгып баскач, авыз ачты да калды. Нинди галәмәт, кайсы әкият бу? Мондый могҗиза Ашлы урамына кай тарафтан ингән?

Әмир Сәлман йорты каршындагы зур мәйданның һәрбер почмагында вак-вак учак яна. Якынлашып килгән җәйге, җылы төн кала өстенә куе, кара шәлен дә ябып өлгермәгән әле. Әмма кичке энгер-менгердә дә мәйдандагы утлар сихри сәйлән сыман чәчелеп җемелдиләр.

Мәйдан читенә ян-яклары аллы-гөлле ефәк һәм бәз тукымалар белән бизәлгән өчме-дүртме бөркәвечле арба кереп баскан. Шуның икесеннән чәң, кубыз, сорнай* тавышлары яңгырап ишетелә. Ә уртадагы арба япмалары астыннан мәйдан уртасына аккош сыман тезелешкән кызлар чыгып килә. Йә, илаһи Тәңре! Жир йөзендә шушындый да сылу, шушылай да ымсындыргыч кызлар буламыни?!

Егермегә якын кызның һәркайсы да ярымшәрә көе. Сылуларның кайбер төшләрендә генә җептәй нечкә, нәфис каплавыч бар. Аларның камыштай озын һәм зифа аякларын, аккош канатыдай йомшак беләкләрен ялтырап торган ефәк каплап алган. Ләкин ефәк япмаларның һәммәсе дә үтә күренмәле. Ефәк аша сылуларның барча кайнарлыгы, чибәрлеге, даны чәчрәп тора.

Кызлар арбалар арасыннан йөзеп чыгуга ук, бар мәйданга таралып бии

* Чәң – кыллы, кубыз – тынлы, сорнай – озын жиз торбадан хасил музыка кораллары.

башладылар. Һәркайсы да чәчләренә калфак калаган, кул очларында беләзек һәм уймак. Жил искәндә жилфердәгән чәчәк тажы сыман аз гына селкенделәр исә дә, уймак-беләзекләр чәлт-челт килеп, чәк-чек итеп аваз биреп тора. Боларның хәтта тубыкларында да нәни кыңгырау бар. Аяк баскан саен алар әле көмеш тәнкә сыман зең-зең итеп, әле ярсу чишмә тавышы белән челтерәп тора.

Ә кызларның биюләре инде! Йә, илаһым! Жир йөзендә шушындый гүзәл биюләр дә булса була икән!

Сылулар күзгә күренмәс жепкә тагып куйган шикелле бөтенесе бергә хәрәкәтләнә. Йомшак мендәрләрен әле бер, әле икенче якка сикертеп котырталар. Болай да менә өзеләм, менә өзеләм, дип торган камыштай нечкә билләре утлы күмер өстенә эләккән елан тәне сыман боргалана. Өреп кабарткан шикелле тулы күкрәкләре тасма япмалардан сикереп чыгардай булып уйнаклый, бөтерелә. Әй, ул сирәк-мирәк кенә ялтырап киткән сихри чиякәйләр! Әй, ул тезләренә генә утыртып тотардай зифа сыннар!..

Салмыш урыс ирләре инде тагын да түзеп тора алмыйча, киемнәрен ерта-ерта мәйдан уртасына сикереп чыккан иде, әллә каян гына ике-өч дистәгә якын сакчы пәйда булды. Аркылы китереп тоткан сөңгеләреннән тыгыз бӧжра ясап куйдылар да, сылуларны нәкъ уртага алып, Святослав баскан болдыр каршысына озата башладылар. Ул арада мәйдан читендәге арбаларның ефәк япмалары астыннан ике мәһабәт ир сикереп килеп чыкты. Мәйданны түгәрәкләп баскан урыс ирләренең һәммәсе "аһ" иттеләр. Святославка төбәлеп атлаган беренче ир үзенең алга таба сузган кулларына саф алтыннан коелган нәни казан күтәреп килә иде!

—Монысы сиңа тагын яна бүләк, олуг кенәз,—дип телгә килде йөзбаш киемендәге мәһабәт ир.—Сиңа нәкъ менә казан бүләк итүебезнең яшерен сере дә бар. Казанны һәрчак үзара килешеп яши белгән, бер-берсенә ярдәмгә ашыккан дуслар белән генә бергә асалар бит. Ошбу казан—икебез өчен тугра. Моннан ары үзара яу йөрүләр, кан коюлар бетсен. Болгар белән урыс халыклары гомер буе уртак казан асып, аш бүлешеп, бер-берсенә кунакларга йөреп кенә яшәсеннәр иде.

—Иншалла, машалла!

—Ярабби Ходаем! Амин, амин!—дип эләктереп алды болгар сакчылары.

Көттеребрәк булса да, урыс ирләре барыбер кушылдылар.

—Бик хуп, бик хуп!

—Үзара яу йөрүләр, кан коюлар бетсен!..

Махсус бояр килеп болгар вәкилләрен кунакка чакырып алды.

—Олуг кенәз сезне үз йортына, кичке ашка дәшә.

Ибраһимның йөзе борыч капкан төсле сытылды, йодрыклары усал йомарланды. "Үз йорты, имеш, үз йорты, каһәрен генә өшкерим! Басып керү тәтегәч, Ашлы каласын да, Сәлман бәк йортын да үзенеке итеп исәпли бу. Без, болгарлар түгел, ә килмешәк кенәз үзен безнең жирдә хужа итеп тоя. Оят, хурлык!"

—Борчылмагыз,—дип тынычландырырга ашыкты Даян сәрдәр үзен урап алган кардәшләрен.—Урысларның кунак агулый торган яман гадәте юк. Дөрес, исереп алсалар, болар ду китереп үзара сугышмыйча калмый. Кунак булгач, безгә тимәсләрдер.

Өстәл артына утырышкач, Ибраһимның ымы буенча зал түренә янә биюче яшь кызлар тезелешеп чыкты. Тагын чәң, кубыз моңнары сибелде, кызлар ярымшәрә күкрәкләрен, ботларын уйната-уйната өр-яңа биюләр биеделәр. Святослав кенәзнең, барча боярларның күзләре корбан эзләп тапкан ач бүренеке төсле уйнаклады.

Руслар беренче тустаганны бушаткач, Ибраһим туганлашу, дуслык турында сүз кузгатып, Святославның кылын тартып карамакчы иде.

—Нинди киленнәр алмашу, туганлашу хакында сөйлисен син?—дип кырт кистереп каршы төште кенәз.—Көчсезләр һәм җинелгәннәр белән килен алышырга, солых төзергә мин сезнең алда колчурамы әллә? Сезнең ише басымчак халык түгел, хәтта үз туганнарым—Ростов, Галич, Новгород кенәзләре белән дә килен алышканым юк. Киев—барча урыс җиренен башкаласы, ростовныкылар мина тиң түгел. Мин бүтән якка карап табынам бүген. Әнә, кул сузымында гына юнан кайсары бар, ахыр чиктә хәзәр каханы бар. Ичмаса, шулар каршына барып бил бөгәм дә килен төшерәм мин. Ә синең болгар кызларың... Әнә, күрәсеңме, берьюлы ничә дистә бии. Алар барысы да минекеләр бүген. Килен итеп төшереп тә тормыйча, бөтенләй бушка гына.

Ибраһимның битенә төкерделәрмени, башын аска иде. Үз ватаны өчен гарьләнүдән бөтен тәне ут булып янды. “Мескен булма, җинелмә, коллыкларга төшмә,—дип үз-үзенә әмер-сабак биреп утырды ул. Җавап кайтарырдай, иленне яклардай куәтең булмаса, сине менә шулай, сөяк көткән эт хәленә калдыралар икән.”

Әмма мин-минлеген учына бөтереп тыкды да, Ибраһим бөтенләй көтелмәгән яктан китереп сукты.

—Мөхәммәт хан янына илчеләр килеп китте. Йосыф каханнан, хәзәрләрдән инде,—дип кайнар чәй эчкәндәй тарта-суза гына, Святославның йөзенә дә карап тормыйча сөйли башлады ул.—Йосыф үзара берлек төзергә чакыра безне. Тигез, гадел берлек. Аманатларыбызны да кире кайтарачак.

Святославның ияге соскы шикелле салынып төште, күзен черки кергән сыман челт-челт йомгалады. Телен, кышкы зәмһәрир салкында пычак йөзенә тидереп өттергән шикелле, көч-хәл белән кыймылдатып дәште.

—Берлек... Берлек... Аннары нишләмәкче?

Ибраһим һаман кенәз ягына борылып карамыйча да тезде.

—Нәрсә булсын, яу сәфәренә чакыра инде. Әйдә, Киевны тез астына бөгеп салабыз, ди. Яулап алгач, гадел бүлешмәкче. Киев, Вышегород, Переяславль калалары—миңа, Чернигов белән Осколны сезгә калдырам, ди.

Святослав чыгырыннан чыкты. Эчендәге ярсу, нәфрәт ут урынына талый иде, ахры, ул изүләренә тикле йолкып ачты.

—Килмәгән, яуламаган, ә үзе шулай, инде алдан ук, калаларга чаклы бүлешеп куйдымыни?

—Әйтеп торам бит, бүлешә инде, менә.

—Ә сезнең ханыгыз нишләмәкче? Мөхәммәт кушыламы?

—Элек исәбе юк иде, хәзер уйга калды. Чөнки, ин беренче башлап, Мөхәммәт ханга син китереп суктың.

Святослав ике чигәсен тотып уйга калды, кара янып чыкты. Бераздан карашында шәм яктысы кебек кенә җылылык бөреләнде.

—Әгәр Әтил каласы өстенә үзем очып кунсам?

—Ә мин сина шуны киналәп утырам бит инде.

—Йосыф каханны җинеп булырмы соң? Сез дә миңа кушылмассыз инде?

Сүз ике малай-шалайның йодрык сугышы турында барган кебек, Ибраһим кулын селтәп кенә урыс кенәзен котыртуын белде.

—Ә-әй, син каханны бер үзең дә сытып үтәсен бит. Йосыф—Манас түгел, бу булдыксыз. Ул хәрәмханәдәге җарияләренең итәгеннән аерылып урамга чыгуны да белми. Манаска ялланган бәҗәнәкләр, аланнар күптән качып бетте. Йосыфның сарай сакчыларыннан башка гаскәре юк.

Святослав казаннан яна гына алынган кайнар итне бүләргә әзерләнгәндәй җиннәрен сызгана, иреннәрен ялмый башлагач, Ибраһим кабалана-кабалана тезде.

—Каханны чәнчелдереп төшерсән, үзенә дан. Ясак түләүдән, аманат кызлар озатудан азат булачаксын. Вятичлар, Ростовныкылар кахан коллыгыннан котылачак. Кичә каханга озаткан байлыкларын аларнын иртәгә сина түләве бар...

Святослав чыраена да, ниһаять, жан керде. Ул бер-бер артлы ике-өч жамаяк шәрабны әйләндереп куйды. Ә исереп алгач, үз янында болгар кунаклары барлыгын да күз чалымына китереп маташмады.

—Әнә теге, зәнгәр ыштанлы кыз үземә бүген!—дип төкерекләрен чәчеп кычкырды да, өстәл-урындыкларны аудара-аудара чыгып, кенәз биюче кызларга таба кулын сузып китте.

—Ә-ә-әй, бәләкәч! Син минеке бүген!

Аю сыман алпан-тилпән атлап килгән кенәзне күргә үк унике-унөч яшьләрдәге болгар кызы коелып төшкән иде. Святослав аңа ушка килерлек тә ара калдырмады, әзмәвердәй гәүдәсе белән сытып тал чыбыгыдай нәфис сылукай өстенә сузылып ятты.

## 34

Яна таңда Мөхәммәт хан вәкилләре Святославның Идел ярында корылган яна чатырына вак-төяктән хасил бүләк китерделәр. Саф көмештән ясалган ике чәйнек, көбә, тәпси*, алтын сәдәфләр тезелгән йөгән, асыл ташлы хәнҗәр. Мөхәммәт бүген төнлә генә кенәз белән аның боярлары кочагында яткан биюче кызларны да кабат урысларга кайтарып бирде. Сер бирәсе килмичә, юмарт кыйланып сөйләнгәләп куйды.

—Бүре теше тигәнне бүрегә бирү хәер. Чит ир назын татыган кызкыркынга ышаныч юк. Алар инеш суына утыртып агызган чүмеч төсле. Теге якка, бу якка янтаеп чөмерә-чөмерә, барыбер, батмый калмый.

Әмир Ибраһим әтисеннән тартынмый-нитмичә, иреннәрен кысып, усал сүгенеп торды.

—Дошман алдында тез чүктек. Иминлекне сатып алабыз. Бүре булып бүреләр дә кулга иярләшми. Ә без үз-үзен дә яклый алмаган мескен хатын төсле. Кем иренми, шул килә дә баса. Дәүләтебез көчсез. Кайчан гына тураеп басарбыз да, башкаларга тиңнәр булырбыз без?..

Көндез Святослав күркә сыман кабырынып, барча Болгар кунаклары алдында игълан итте.

—Сезнен белән бүтән сугышмыйбыз. Идел тамагында уртак дошманыбыз, Иосиф кахан икебезне тиң сыер урынына савып, тантана итеп ята. Хәзәр каханатын жимермичә торып, беребезгә дә бәхет киләсе юк. Мин Әтилгә юнәләм. Үземнән алда менә мондый хәбәр жибәрәм дә, тәкәббер каханның яңагына ялтыратып, ушын алып куям. "Синең өскә барам!" Кахан, ханнар ханы, мин бердәнбер, дип масаеп яшәмәсен, калтырап торсын әле...

Шул сәгатьтә үк Ашлы каласыннан еландай шуып чыгып, рус гаскәре хәзәр даласына төбәп китте. Әмирләр, бәкләр Мөхәммәт ханга шундук шөбһә белдерделәр.

—Йортларны, сарайларны да жимермәде бу кенәз, кала диварларына да ут төртмәде. Әй-яй, шикле! Берәр нинди мәкер-хәйлә корып, безне тәп башына утыртырга жыенмый микән бу?

—Мин дә шикләнәм,—дип кушылды Мөхәммәт хан, бераз көттеребрәк.— Артыннан күзәтмичә, сакланмыйча булмас. Идел буйлап бер мең кешелек

* Тәпси—ризык ташый торган таба, поднос.

иравыл җибәрегез. Башка алайларны да таратмыйбыз, һәрбер яугир сәфәргә чыгарга әзер торсын...

Рус гаскәре бер фәрсах арасы узып күздән югалгач та, ике җайдак Мөхәммәт хан каршына зур күн капчык китереп ташлады. Капчык җир буйлап тәгәри, улый, чәбәләнә, моны нindидер гадәти ау эте яки лачындыр дип кенә кабул итеп булмый иде инде.

—Сезнең түшкәдән кисеп ташланган үт безнең ашның да тәмен боза, каһәр!—диде капчыкны озата килгән сап-сары сакаллы җайдакларның берсе.—Этләр авызына үзегез ыргытыгыз.

Хан әмерен көтеп тормадылар. Ике сакчы иярдән сикереп төшеп капчык авызындагы элмәкне кисеп атты. Капчык эченнән ярга ыргытылган балык сыман хап-хоп сулый-сулый атылып килеп чыккан карачкыны шәйләп алуга ук һәммә яугир кылыч сабын кысты. Шик юк, аяк асларына сасы көзән сыман китереп ташланган бәндә заманында ил тоткан, аннары үләт чирле эт урынына читкә куылган сатлык вәзир Нуретдин үзе иде.

Элеккеге кәпрәю-көрпәләнүнең эзе дә юк монда. Вәзир чакта көн саен ялтыратып кырылган яңаклар, түгәрәк пөхтә сакал урынына йонын коя башлаган сарык йоны сыман мунчала. Өстендә терсәкләре бәсәреп, итәкләре чукланып беткән чапан, аякларында авызын ачкан кәвеш. Билендә мунчаладан үргән юкә бау аламасы, чапан эчендә көл-корымга буялып беткән шәп-шәрә тән. Шушы карачкы да җир йөзендә адәм булып исәпләнә диген!

Сорау бирүче түгел, хәтта мәсхәрәләп сызгыручы кеше дә табылмады.

—Күземә күрсәтмәгез,—диде Мөхәммәт хан, кичәге вәзир ягына борылып та карамыйча гына.—Моны Борак сәрдәр сымак зинданга ташлаттырсаң таман булыр иде дә бит. Мәгәр Борак сымак печән биреп, ачка интектереп түгел, ә хан өстәлендәге ризыкны ташыттырып, дөмегергә ирек бирми газапласаң шәбрәк булыр иде. Әмма без ялгыз түгел шул, күршеләр күзе дә бар. Дөрес аңламаслар. Ике атка иярләгез моны. Урыс баскыннары да сабак алып китсен...

Берничә минуттан соң болгар җайдаклары сафыннан Святослав чатырына таба пар ат чабып китте. Ике ияр уртасында сугым пычагыннан качарга омтылган мал шикелле бер сын бәргәләнә. Юк, хәзер үкереп елардай куәте дә калмаган инде аның, каргаган яки ялварган тавышлары да бөтенләй ишетелми. Ул әле бер, әле икенче ияр аелына үрелеп, үзен бәйләгән элмәкләрне тешләре белән чәйнәмәкче була. Яшисе килә шушындый мескен, хөрәсән, беткән бәндәнең дә.

Пар ат кашанлылар чатырына таба якынайган иде, җиде-сигез ир сөңгеләрен һавага күтәреп усал болгадылар да, бүре тавышлары чыгарып улый башладылар. Өннәре алынган атлар бер мизгелдә кыяга килеп бәрелгән дингез дулкыны сыман өскә сикерделәр, икенче мизгелдә икесе ике якка аерылып та китте. Яшел чирәмдә, кышкы кар өстенә сибелгән ап-ал миләш тәлгәшләре шикелле янып, кан тамчылары гына чәчрәп калды.

## 35

Әтил каласына төбәп юлга чыккач, Святослав кенәз әүвәл бер генә кыек адым да ясамады. Гаскәре ике канатка бүленгән, берсе Жигүле тау ягына кыйбла тотып бара, берсе дала тарафын, очсыз-кырыйсыз ялан-далаларны каплап төшә. Җайдакларның күпчелеге уяулык дигән бишмәтне салып аткан, хәзер ияр өстендә йокымсырап баралар. Боярлар өсте ябулы арбалар эченә, ышыкка кереп качкан. Күзәтү булмагач, аларның яраннары да пар ат иярләре арасына тарттырылган ятьмәләргә

сузылып, гырлый-гырлый йоклый. Сафлар сүтелгән бау сыман таралып беткән, алай-нөгәрләрнең рәте-чираты юк. Болар яу сәфәренә чыккан булуларын бөтенләй оныткан сыман, сак-иравыл йөзләрен дә куеп тормаганнар. Суга салган юкә шикелле мәлжерәгән гаскәр хәрби көчтән бигрәк сәүдә юлына чыккан кәрванны хәтерләтә. Шушы таркау, үшән ташкыннарга карап алдануың мөмкин.

Ике елга булып сузылган гаскәрнең фәкать бер төенендә генә уяулык, җанлану, бәхәс ишетелә. Бу—болгар кызлары утыртылган олау. Кайнар кочак, иркә-наз шикелле җәннәт, мондый тәм-том төнлә белән гади сугышчыга гына түгел, йөзбашларга да эләкми. Төн—ул боярлар, наиблар, меңбашларның туе. Алар канизәкләрне кат-кат юындыра-юындыра, әче бал ташый-ташый, кичтән таңга кадәр рәхәт чигә. Ә йөзбашлар, ташбаш сугышчылар, иравыл, ганимәт, мөлкәт өчен җаваплы түрә-түмгәк җәннәт олавы янында көндез генә җай эзләргә, бәхетле ятак хакына гомере белән шаярырга мәҗбүр. Уен-муен түгел, бу кыйммәтле олау янына әледән-әле шәхси орыш өчен сайланган пәһлеваннар килеп чыгыштыра. Алар инде наибларны, меңбашларны да күз чалымына кертми. Аларның чүлмәктәй йодрыклары, тәртәдәй чукмарлары астына килеп эләктеңме, гарип калуың бар. Шуна күрә гади сугышчылар, сөяк өмет иткән эт көтүе шикелле, җәннәт олавы тирәсендә көндез генә бии.

Бүген бәхет Переяславльдан килгән Устин атлы егеткә эләккән иде. Ырдый-бырдый түгел, Ашлыда Святослав кенәз үзе иркәләгән яшь сылукай арбасына чуму насыйп булды ана. Әмма бөркәвеч астына эләккәч, болан баласыдай нәфис кыз өстенә котырган эт шикелле ак-караны күрми сикерә алмады ул. Кызый чибәр, аның карлыгандай кара күзләренә, чия төсле кызыл иреннәренә, алма кебек тыгыз, түгәрәк күкрәкләренә сокланып карап тормыйча түзеп булмый. Устин да, тәэсирләнеп-шашып, әнә шул алмадай күкрәкләрне учларына алды, аларның каен җиләге шикелле очларын иреннәре белән иркәләде, куллары нәфис ботлар арасына кереп оялады. Устинның әле озак, бик озак вакыт буена шушы җәннәт бакчасы эчендә йөзәсе килә иде.

Ләкин көтмәгәндә, арбаны дөбер-шатыр китереп, бөркәвеч астына Галич пәһлеваны Ермил килеп керде. Чүл бүресе сыман күзе-башы тонган, көрәктәй дәү кулларын уктай атылып чебеш алырга төшеп баручы карчыга канатлары шикелле ике якка җилпеп өскә килә. Алагаем чишенеп һәм озаклап кинәнергә ният иткән, ахры, чабата олтыракларын да бәйләп тормаган бу.

—Күз алдымнан олак, селәгәй!—дип кенә үкерде дә, Ермил гөнаһсыз Устинны канизәк кыз өстеннән тышка алып атты.

Арбаны тирәләп барган ач көндәшләр буш мичкә, бакыр ләгән дөмбердәткән тавышлар чыгара-чыгара, ихахайлап, котырып кешнәделәр.

—Нәрсә, авызыңнан майлы калҗаны тартып алдыларммы?

—Мәмиеннән аерылган сабый шикелле нәүмиз калдыңмы, егет?

Ат тояклары, тузан арасына иске кәвеш төсле килеп төшкән Устин яшьле күзләре белән сихерле арба ягына төбәлеп ысылдады.

—Ничава, ничава, сәфәр озын әле, син кабихтан үч алырга форсат чыкмый калмас.

*Дәвамы бар.*



## КАЗАН ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ

### Казан бәйете

**...Ике йөз алтмыш ике йыл Казан мөселман кулында,**
**Ахыры бары соңында урыс халкы алдыйа.**

**Газыйлары күп иде, меллалары чук иде,**
**Галимнәре күп иде, замана Йәдегәр ирдейә.**

**Бу җиһан мөнәүүәр иде, җәбер-җәфа йук иде,**
**Мөрит-мөршид күп иде, заманы хуп ирдейә.**

**Галимнәре дуст иде, мөршидләре хас иде,**
**Барча дошман пәст иде, заманы Йәдегәр ирдәйә.**

**Йәдегәр ханның бер кызы калды тугыз йәшендә,**
**Халык ишле эчендә күп гакыллы ирдейә.**

**Тугыз йөз илле җидедә Йәдегәр китте дөнйадан,**
**Атасының урынында хан булырсың тидейә.**

**Син мөэннәс дәгелмүсән, ханга лаикъ түгелмесең,**
**Монча ирләр барында хан булмасын тидейә.**

**Ошбу сүздән гыйбрәт алды, бу дөнйаны йукка санды,**
**Атасының соңында үз җанын үзе алдыйа.**

**Нәселендә бер ир бар ирде, исеме аның Шигали,**
**Шифаларга йар ирде, тоткын булмыш ирдейә.**

**Урыс халкы ишәйде, Шигалигә кушылды,**
**Шигалидән Иван урыс Казан шәһрен алдыйа.**

**Күп халаикъ бардылар, күп мал биреп алдылар,**
**Ошбу шәһре Казанга хан кылдылар ирдейә.**

**Шәһре Казан эчендә Шигали һәм хан булды,**
**Дөнйа дигән сарайга җәбер-җәфа тулдыйа.**

---

Газый — сугышчы, җиңүче.
Чук — күп.
Мөнәүүәр — нурлы, якты.
Мөрит — иярчен. Мөршид — туры юл күрсәтүче.
Хас — "затлы" мәгънәсендә. Пәст — түбән, әшәке, хурлыклы.

# Колшәриф

*(XVI йөзнең беренче яртысы)*

## “Зафәрнамәи вилаяти Казан” (1550) әсәреннән

**(Казанны мактау)**

**Гаҗәйеб бер җайы гыйшрәтдер җиһанда бу Казан шәһре,**
**Моның тик булмагай галәмдә, борадәр, әл-әман шәһре.**

**Казан тик шәһре мәгъмури (төзек) табылмас дөньяда һәргиз,**
**Казандин аш эчәдерләр ничаклы бу җиһан шәһре.**

**Бу бер мөлке ирер калмыш әбаэган җәдде ханлардин,**
**Ирер бу йир һәмишә (һәрчак) дөньяда хан бине хан шәһре.**

**Йирен-йортын сатып бирмәс атасының ясакыны,**
**Ничек (ни өчен?) килгән ушул (шушы) мәлгунь,—имәсдер бу Ибан шәһре?!**

**Шәрифи, китмә бу йирдин газат өмиде гәр булса,**
**Бу көндин соң дигәйләр кем,—будыр сахибе Казан шәһре.**

# Мөхәммәдьяр

*(XV йөз азагы — XVI йөзнең беренче яртысы шагыйре)*

## “Төхфәи мәрдан”нан

(Өзекләр)

•

**Бер гъәҗиб бу кем шәһрнең эче тулуг:**
**Шагъир улмыш барча кечек һәм олуг.**

•

**Ошбу “төхфә” тарихын гәр сурсайлар,**
**Тукуз йөз кырык алтыдыр, белсәйләр.**

**Башладык Газан шәһәрендә моны,**
**Шәгъбан айының унычы көне.**

**Һәм шәгъбан ахырында булды — тәмам**
**Әйләдек, моны белең сез, вәссәлам...**

---

Җайы гыйшрәт — хозур урын; күңелле (рәхәт) җир.
Борадәр — туган, кардәш.
Әл-әман — иминлек; игелек.
Һәргиз — һич тә; һичкайчан да.
Мөлке ирер — биләмәсе (мирасы) булыр.
Әбаэган җәдде ханлардин — ханнар нәселеннән.
Хан бине хан — “ханнар нәселе” мәгънәсендә.
Ясакыны — бурычын; салымын.
Имәсдер — түгелдер.
Биредә Явыз Иван (Иван) күздә тотыла.
Газат өмиде гәр булса — изге сугышка ышанычың булса.
Сахибе Казан — Казан хуҗасы.

### Нуры содур

**(Өзекләр)**

Тарихның тукыз йөз кырык сәкзендә,
Мөбарәк мөхәррәм айның уникесендә;

Болгар шәһре Казан дәруазәсендә,
Кеше күбдер хирә дәруазәсендә;

Мөхәммәд Әмин къэбрендә, и шәһриййар,
Мөҗаүер ирермән бәси булыб зар.

## Хөсәен бине Локман

*(XVIII йөз уртасы һәм ахыры)*

***

Казандин килгән солдатның
Сач кенәсе лә төрмәдер.
Казанда булган туфрак
Күз генәмә лә сөрмәдер...

## Габдулла Тукай

*(1886 — 1913)*

### Пар ат

**(Өзек)**

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап:
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап...

Бер тавыш килде колакка, яңгырады бер заман:
“Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдыбызда бит Казан”.

Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна;
“Әйдә чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на-на!”

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан, монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

---

Дәруазә — капка.
Мөҗаүер — изгеләр кабере янында торучы, сакчы.



Илүсә
Нәбиуллина

# МИЛӘШ ТӘМЕ

ПОВЕСТЬ

*Сугыштан соң туган асыл буын,*
*Без окоптан кайткан яралгы.*
*Шуңадырмы, замандашларымның*
*Туганчы ук җаны яралы.*
*Тамырларны пуля өзгәләгән,*
*Чәрдәкләгән мина ярчыгы,*
*Яраларны юган чагыбызда*
*Алсу төскә керә таң чыгы.*

Нур Әхмәди

***

...Әдибә йокысыннан матур төш күреп уянды. Имеш, өйләренең урам як тәрәзә төбендә гөл үсеп утыра. Гөлнең янып торган кып-кызыл ике чәчәге бар, өченчесе—бөредә, анысы менә-менә тажларын ачып җибәреп, көн яктысына үрелергә тора. Күргән төшеннән елмаеп-иркәләнеп ятты да таң беленә башлаган тәрәзәгә карап, уйларына чумды. Белә ул бөренең нәрсә икәнен... Ике кызыл чәчәкне дә белә.

Күкрәген тутырып торган куанычтан йөрәге дөп-дөп тибә башлады. Җәһәт кенә торып казан астына ягып җибәрде, самавырга ут салгач, тау астындагы чишмәгә суга төшеп китте. Адымнары дәртле иде яшь хатынның. Эчтән ургылып чыккан канәгатьлек хисе, бәхет нуры бөтен йөзен яктыртып-балкытып тора.

Бәхетле булу өчен күп кирәкме кешегә?

Бәхетле була белгәннәргә бер матур төш тә житә...

Көне дә көне! Иртәдән үк куанычлар, матурлык һәм серлелек вәгъдә итә. Кояшы да бүген гадәттәгедән ягымлырак булып тоелды. Тау астыннан балкып килеп чыкты да, әле йокыдан уянып бетә алмаган авылны нурга күмеп куйды. Таң белән торган җир кызы Әдибәне кая барса шунда озатып

---

Илүсә НӘБИУЛЛИНА – *яшь язучы-прозаик; хикәяләре вакытлы матбугатта даими басыла. Әлмәттә яши.*

йөрде: иртәнге чыктан күшеккән аркасына ягылып иркәләде, кулларын жылытты. Әдибә сыер саварга утыргач та, кичә генә Сарашлыда ком белән ышкып ялтыраткан чиләгенә кунып, нурларын биетте. Көтү куганда да кояш яшь хатынны каядыр чакырды, ымсындырды.

Сентябрь башы димәссең, көн жылы, матур. Үләннәр, агачлар, бар тереклек “Быел жирдә ике язмы әллә?” дигән кебек һаман саргаймый, ямь-яшел күлмәкләрен саклап, жылы кояш нурларына хозурланып утыра.

Тел бистәсе саесканга кадәр иртән-иртүк Әдибәгә нидер сөйләргә теләгәндәй, артыннан калмый, ияреп йөри. Ишек алдына чыкса, өй түрендә үсеп утырган агачка куныр берөзлексез шыкылдый, Әдибә каралты-кура янына килсә, абзар капкасына куна да, муенын суза-суза нидер “сөйли”. Кошкайның тәгаен генә ни әйтергә теләгәнен анламаса да, яшь хатын аның койрыгында куанычлы яналык, яхшы хәбәр алып килүен күңеле белән сизә. Сугыш беткәч, Солтаны кайтасы көнне дә шулай иртән-иртүк озынкойрык алып килгән хәбәрен өзгәләнеп-өзгәләнеп “сөйләгән” иде. Кичкә, жиде ел чит жирләрдә: башта солдат хезмәтендә, аннан сугышта йөргән, соңгы вакытларда хатлары да булмыйча, әнисен кара кайгыга, Әдибәне утка салган ире кайтып төшкән иде.

Саескан белми шыкылдамый ул.

* * *

Әдибәнең күңелен кытыклап торган рәхәтлекне чәй янында каенанасы белән сөйләшү дә бетерә алмады. Иртәнге эшләрне килене башкарса да, каенана кеше иртүк торган, намазын укыган, бик эшлекле кыяфәттә табын артына килеп утырган. Ул башта тәһарәтен ала, намазын укый, ишек алларын әйләнеп керә. Бу аның үзенчә бер иртәнге сәяхәте.

Мөгаллимә карчык килененең бик авырлык белән генә чәй табынын көйләгәнен карап торды. Аннан балаларының хәл-әхвәлләрен сорашып, бисмилласын әйтеп, чәйгә үрелде. Килен исә, самавыр өстендә биешкән кояш нурларына карый-карый, каенанасының озын сүзен тыңлады, ләм-мим каршы сүз әйтмәде.

—И-и, быелгы чикләвекнең унуы,—дип, көйли-көйли сөйли башлады Мөгаллимә карчык.—Кешеләр капчыклап ташый икән. Югары оч Хөснелнең хатыны Галия Сукыр тыкрык буендагы Мәгъдәнур белән кичә аны чүмләп, бер капчык жыйганнар ди. Тегеләр күтәреп кайта алмагач, Хөснел ат белән барып алган имеш. Хәйран тамаша инде менә, мондый хәлнең монарчы булганы юк иде әле.

Чәй эчә-эчә Мөгаллимә карчык Түбән оч хатыннарының күпме чикләвек жыйганнарын, Атау, Каз урамы хатыннарының ничә тапкыр урманга барып, ничә кайтканнарын, инде никадәр чикләвек киптереп чормага элгәннәрен санап китте. Түбән очтагыларның Сарсаз урманыннан ниндидер шәплек табуларын, андагы чикләвекләрнең башка урманнардагыга караганда эрелеге-күплеге, тәме белән дә аерылып торуын, шушы кадәр байлыкны кыш көне Бакалы базарына барып сатсаң, күпмеләп акча ясарга мөмкин икәнен, сатмаган очракта, шәһәрдәгеләргә жибәрергә нинди затлы күчтәнәч булачагын, тагын әллә нәрсәләр турында тәмләп-тәмләп сөйләде. Ана кушылып самавыр жырлады. Әдибә каенанасының: “Кызым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла”, —дигән кебек, башка килннәрне мактап, аның шушындый матур көннәрдә дә өй тирәсендә генә чуалуына, урманга чикләвеккә бармавына төрттерүе дип кабул итте. Бәлки каенанасының сүзләрендә бернинди яшерен мәгънә, төрттерү дә ятмагандыр. Башка хатыннар турында аның болай тәфсилләп сөйләве, бары тик бу кояшлы матур иртәдә килене белән сөйләшәсе, авыл яңалыклары белән уртаклашасы килүдән булгандыр. Килен кеше бу каләресен аңларга тырышмады, ләкин

каенанасының сүзләрен күңел түренә салып куйды. Өйдә чикләвеккә барырдай башка кеше юк бит. Солтан иртәдән алып кичкә кадәр басуда. Уллары әле кечкенә. Каенана үзе карт. Шулай булгач, бер Әдибә кала. Үртәлде. Үртәлүен сиздерми генә бүген урманга барып, бер капчык чикләвек алып кайтмаса да, аның быел шулай нык уңган булуын күреп кайтырга кирәк иде.

Мөгаллимә карчык белән Әдибә карап торышка әнисе белән газиз кызы кебек яшәсәләр дә, мулла кызларында да була торган кытыршылык алар мөнәсәбәтендә дә юк түгел иде. Ни генә әйтсән дә, чит кан бит. Әдибә чит кеше баласы. Кояш булып кояшта да тап бар диләр. Каенана белән килен арасында нигә әле берәр сер ятмаска тиеш?! Вакыты белән үз-үзеннән яшерердәй серләр дә була хәтта. Аннан килеп, үз әниен белән каенана арыш бөртеге кадәр генә аерылыр дигән әйтем дә бар. Бу халык сүзе, ә халык әйтсә хак әйтә инде ул. Димәк, аерма бар... Менә шул бөртек кадәр генә аерма булгангамы, Әдибә каенанасына үз әнисенә ачылып беткән кебек ачылып, бөтен серләрен сыйдырып, аның белән бар шатлыгын да уртаклаша алмый инде. Әллә нәрсә, үзе дә аңлата алмастай бер ужәтлек тотып торамы шунда. Ә бит аның каенанасы изге жаннардан. Беренчедән, ул игезәк малай анасы, игезәк тапкан хатынның теләгән теләге кабул була, өшкерүе-төкерүе килешә, күрәзәчелек кебек сыйфаты да була, диләр. Бу чыннан да шулай иде. Сирәк очрый торган зирәк акыллы аның каенанасы. Мәгънә, итагатьне аңа Ходай бернечә кешегә житәрлек итеп, мул биргән. Бервакытта да уйламыйча сөйләмәс, кеше күңеленә каты бәрелердәй сүз әйтмәс. Аны авылда балаларын якты дөньяга китерергә булышкан, жаннан жан яратылганда шаһит булып торган кендек әбисе буларак та яраталар. Олысы-кечесе бер-бер эшкә тотынганчы кинәшкә иң элек ана килә. Юлга чыгып китә башласа да, ерак юлдан кайтса да Мөгаллимә карчык янына кагылмый узмыйлар. Күпне күргән, дөньяның ачысын-төчесен шактый татыган карчык. Бала-чага авырып китсә дә Кендек әбисенең им-томы килешә. Кыскасы, авылның Ак әбисе ул.

Әдибә Мөгаллимә карчыкның бишенче килене—төпчек улының хатыны. Ир анасына, олы кешегә, кендек әбисенә нинди кадер-хөрмәт күрсәтелергә тиеш булса, барысын да күрсәтә. Каенанасының авызына гына карап тора, бик үртәлгән чакта да тавышын күтәрми. Иртән торуына комганга су салу, сөлге китереп бирү, чәйне ничә эчсә дә кайнарлап, ясап, алдына кую дисеңме, барысын да вакытында эшли. Өрмәгән жиргә дә утыртмас иде әле. Үзе белә-белгәннән бирле "Шушы Мөгаллимә карчыкның килене булмасам, исемем Әдибә булмасын", дип күңеленә беркетеп куйган иде бит. Уйлаган уе, теләгән теләге Ходайның һәм фәрештәләрнең "амин" дигән чагына туры килде. Менә ул Мөгаллимә карчыкның килене. Ходайның менә шушы рәхмәтенә шат. Мөгаллимә карчык өендә аткан һәр таң Әдибә өчен бәхет. Аның яраткан ирен дөньяга китергән кеше ләбаса ул.

Әдибәнең әтисе указлы булмаса да авылда мулла иде. Иман белән туган, дога тыңлап үскән бала. Яман белән яхшыны аера, рәхмәтле дә була белә. Гаиләдә алар өч бала үстеләр. Ике кыз да бер малай. Олы абыйлары сугышның беренче көнендә үк китте дә яшь хатынын, кечкенә генә ике кызын ятим калдырып, суга төшкән кебек хәбәрсез югалды. Сеңлесе авылда кияүдә...

* * *

Үзенең авырып торганын Әдибә иртән үк сизенде. Бу хакта беркемгә берни белдермәде, ни иренә, ни көтү куганда үз әнисенә теш агартмады. Каенанасының: "Килен, әллә авырып торасыңмы?"—дигән соравына да,

теге эчтә утырган арыш бөртеге кадәрле "шайтан": "Юк",—дип кенә җавап бирдерде. Эчтә утырган шайтанның гел кирегә котыртып торганын белә ул, тик шул мөртәтне җинә генә алмый.

Солтан исә иртәнге чәен эчте дә, ут күргән кебек басуга чыгып чапты. Урак бетмәгән. Рәис бүген-иртәгә бәбәйләргә торган хатынының агарган йөзен дә, аның шелтәле карашын да күрмәде, күтәрелеп тә карамады. Аның үз хәле хәл иде. Басуда никадәр җыелмаган иген ята. Хуҗалык житәкчесенең җаны шул икмәк амбарларга кайтып беткәч кенә тынычланыр тынычланса.

Рәис үзенә дә хуҗа кеше түгел. Ул хуҗалык белән, аның мәшәкатьләре белән янып яши. Вакытында яңгыр яумаса—аның җаны кибә, көннәр яңгырга китсә, аның да күңеле елый башлый. Рәиснең көне аптыраганнан бригадирларын тиргәүдән башлана. Бригадирларның исә үз чиратында бетмәс-төкәнмәс колхоз эшеннән тәмам җелекләре кипкән халыкны кайда тиргәп, кайда юмалап, авылда калган карт-коры һәм бала-чаганы, сугыштан исән-имин кайта алган бер-ике ирне эшкә куудан башлана. Сугыштан соң шактый вакыт узса да әле һаман авылның мантый алганы юк. Яу кырыннан әйләнеп кайткан гарип-гораба белән әллә ни кырып булмый шул. Сугыш елларын ерып чыккан хатын-кыз, бала-чага тәмам өшәнде. Ул дәһшәтле елларда түзмәделәр түгел, барысына да түзделәр. Житте, дип фикер йөртте хатыннар. Хәзер инде аларның үз вазифаларына кайтыр вакыт килде. Аларның эше бала табу, аларны багу, калганын ир-ат башкарсын. Ирләре фронтта чагында авырлыкка, сабырлыкка күнеккән хатыннар шул ук вакытта шактый гына этләшергә дә өйрәнгәннәр иде. Алар инде элеккеге кебек аттан да өркеп, үлән арасында кыштырдаган тычканнан да куркып, чырыйлап кычкыра торганнардан түгел. Дүрт ел буена үзләре ат җигеп, үзләре туарды. Чатнама суык кышларда, яңгырлы кара көзләрдә олау белән йөреп, шактый гына дөнья күреп, чарланып, усалландылар. Күз күрмәгән җирләргә олауга йөрергә туры килде шул аларга. Юл газаплары эзсез генә калмады, хатыннарның йөзләренә дә, йөрәкләренә дә буразналарын салды. Авыр эштән тәмам дорфаланып, ирдәүкәләнеп беттеләр алар. Соңгы елларда үзләре баш, үзләре түш булып өйрәнгән хатыннарны тыңлатып кара син! Моның никадәр авыр икәнен Солтан үзе генә белә. Җиде ел сугышта йөрү берни булмаган икән, дип уйлап та куйгалый кайчакларда. Шулай да Солтан хатыннар белән уртак тел табуның серен белә ахры. Хатыннар аны күрү белән майлаган кебек булалар. Тавышлары да ефәк кебек шома-йомшак чыга, үзләре дә ничектер балкып, калкынып китәләр. Рәис шулай кайсын үгетләп, кайсын тиргәп, кайсын майлап, ничек итсә итеп, җаен табып, эшен җайлап алып бара.

Җайламый кара, аның үзен районда җайлап-майлап тормыйлар шул.

* * *

Әдибә акрын гына чәй табынын җыйды, әле һаман таралып йоклап яткан улларын сөеп, чебен-мазар тимәсенгә өсләрен рәтләп япты. Ишек алдына чыгып кош-корт туйдырды. Юк инде, бүгенгедәй матур көнне кош-корт арасында гына йөреп уздырып булмас, чыннан да басу, урман хозурына чыгарга кирәк, дип фикер йөртте. Мондый көннәрне тагын берникадәр вакыттан соң эзләп тә табып булмас.

Өй эшләрен бер кат карап чыккач, урманга барырга җыенды. Ә эче бил турысыннан гына әрнеп-сыкрап тора. Билен уып та, сыпырып та карады, бетмәсме әле дип бераз ятып та торды. Авырту басылмады. Аллагы көннәрдә дә шулай иртәнге якта авырткалап тора иде дә, басыла торган иде, бүген дә басылыр, дип, капчыгын алып, урманга чыгып китте ул. Иптәш-мазар эзләп тормады, урманга барасы кеше бу вакытка кадәр калмый инде, көтүен куа да, тиз-тиз чәен эчеп, бакча артлап кына китә. Ул да шулай итте. Бәрәңге

бакчасына чыкты да, күршеләр белән ике арага салынган межадан үз жаена атлады.

Ямьле жәйнең гомере кыска. Ин элек һәр ихата артында жәйнең беткәнен белдерүче беренче билгеләр—печән кибәннәре калкып чыга. Кибәннәр бар инде. Әдибәләрнең бакча артында да мал-мазар тарткаламаслык итеп, бик пөхтәләп өеп куелган печән кибәннәре тора. Печән чабылгач көз үзенең төсләрен басу-кырларга сала башлый. Игене урылган, суктырып җыеп алынган басуларны сөрә башлыйлар. Сөрелгән кап-кара жир инде көз килгәнен, озакламый жиргә кыш хужа буласын искәртә. Бәрәңге сабаклары кибә башлаган, көн саен тавык-чебигә үлән йолкып керә торгач, бәрәңге арасында чүп тә күренми. Солтанга бәрәңге сабагын чабарга жинел булыр, дип уйлап куйды Әдибә. Шулай уйланып, планнар корып бара торгач, урманга барып житкәнен сизми дә калды.

Урманнарга керсәм, үлән сирәк,  
Сахраларга чыксам, жир жиләк.  
Эчемдә генә минем утлар яна,  
Ник жилкенә икән бу йөрәк?..

Тагын нинди шатлыгың бар дисәләр, Әдибә, жыр, дип жавап бирер иде. Жырларга ярата ул. Улларын йоклатканда да жырлый, ашарга пешергәндә дә жыр суза. Әллә шул жырлый-жырлый эшләгәнгә, күнел жылысы белән моң кушылганга, умачлы ашы да тәмле була анын. Чишмәгә суга төшсә дә, елгада кер чайкаганда да жырлый Әдибә. Ә ул жырлап жибәрсә яр буендагы талларда кошлар тынып кала. Авылның моңлы Сандугачы шул ул. Үзе турында шулай дип әйткәннәрен дә белә. Моның белән үтә нык горурлана, ләкин сиздерми. Солтаны да: "Шул жырларың белән сихерләдең бугай мине",—ди. Анын сүзләрендә дә хаклык бар... Сихерләгәндерме-юкмы, авылның иң чибәр егетен үзенә каратты, өйләндерде ул.

Кызыл төлке бармы, ай, жиреңдә,  
Матур ярлар бармы сон иленләә?  
Матур ярлар бармы үз иленлә,  
Сөюләрен бармы сон күнеленлә?

* * *

Жырчы Сандугач дип аны авылга теге Казан кешеләре килеп киткәннән соң атадылар бугай. Әдибәнең әле кияүгә дә чыкмаган, япь-яшь кыз чагы. Каһәр төшкән сугыш турында әле кеше уйлап та карамый. Күмәк хужалыклар төзеп, адәм балалары якты киләчәк көтеп, бар булганына куанып, бәрәңге ашап та жырлап-биеп йөргән чаклар. Тормыш та үз жае белән матур гына ага иде. Аларның авылына бер хатын белән ике ир-ат килде. Шулар өй борынча кереп, авыл халкын биетеп, жырлатып, такмак әйттереп, бәет укытып, фольклор дигән әйбер жыеп йөрделәр. Кулларындагы дәфтәрләре шактый калынайган иде инде, Казан кунаклары авылның жырчы Сандугачы яшәгән йортка да керделәр. Аны кат-кат жырлаттылар. Башларын чайкадылар, телләрен шартлаттылар, әле татарча, әле русча үзара кызып-кызып сөйләштеләр, сөйләшкәндә әллә нинди Әдибәгә аңлаешсыз сүзләр кыстырдылар. Аннан: "Кызым, син бит Казан сәхнәләрендә чыгыш ясый торган сәләткә ия, без сине үзебез белән шәһәргә алып китәбез, укырсың, авылда калсаң әрәм буласың, шушындый моңга ия Жырчы Сандугачлар көн саен туып тормый, алар фәлән елга бер генә туа",—диделәр. Кая ул. Моңлы бала бәхетсез була ул дип, Әдибәнең авыз

күтәреп җырлап йөрүен дә өнәмәгән, аны гел тыеп, тиргәп кенә торган әти-әнисе шәһәр кунакларының тәкъдименә теше-тырнагы белән, аяк терәп каршы килде.

—Бездә әллә кая читкә җибәрә торган бала юк,—диделәр алар бертавыштан.—Артист булмаса да ярар. Нинди уку инде ул тагын?! Җырлый беләме—белә. Житкән шул. Әнә авылда яшәр, колхозда эшләр. Нәселдә булмаганны, авыз күтәреп җырлап йөрү яхшы эшме инде? Нинди һөнәр инде ул җырлап йөрү? Кеше ни әйтер.

Казан кешеләре бу кадәр каршы торуга әзер түгелләр иде. Аптырадылар. Әти-әниләре белән аерым да сөйләшеп карадылар. Булмады. Әле киткәндә дә:

—Кызыгызны укытырга кирәк. Ул укып чыккач, танылган җырчы булгач, үзегез дә безгә рәхмәт әйтеп бетерә алмассыз әле... Әдибә, тавышың искиткеч матур, сиңа шәһәргә барырга, укырга кирәк, син танылган артист булачаксың,—диделәр.—Әти-әниең хәзер генә шулай каршы төшә, соңыннан синең белән горурланырлар, үзләренең дә тормышлары яхшырыр иде, әти-әниең өсләренә ишелеп төшкән бәхетне аңлап бетерми,—дип, кат-кат аны Казанга китәргә кыстадылар. Бәлки ниятләрсең, әти-әниеңне күндерерсең, дип киткәндә адресларын да калдырдылар.

Озак саклады ул язуны Әдибә. Йорт матчасының ярыгына кыстырган кәгазь саргаеп бетте. Кая инде ул шәһәргә чыгып китү! Үзен Казан кешесе итеп тә, артист итеп тә күз алдына китереп карады. Авылдан чыгып китеп, зимагурлыкта йөреп кайтканнарны да берәм-берәм күз алдыннан үткәрде. Ул аларның авылныкыннан аерылып торган киемнәренә, өс-башларына кызыга иде. Ул да шулай баштанаяк киенеп, бөтен кешенең күзен кыздырып кайтып төшәр иде каладан. Юк инде, китә алмады ул туган авылыннан. Әти-әнидән, туганнарыннан, Солтаннан башка ничек яшәсен ул чит җирләрдә. Җырсыз яши алмаган кебек, Солтансыз да яши алмый бит ул. Җырлый башласа әле иртән генә эшкә озаткан ирен сагына, ирен уйласа—моңланып җырлый башлый. Шулай тилмереп, сагынып, ул аны башта армиядән көтте, солдат хезмәте генә беткән иде, бүген-иртәгә кайта дип көткәндә, сугыш башланды. Аннан исәнлеген тели-тели сугыштан көтеп алды. Җиде елның ни икәнен көткән кеше үзе генә белә. Солтан сугышта чакта ул гел бер җыр кабатлап йөрде.

Каен ауган, каен ауган,
Каен ауган аркылы.
Дөньясына утлар капты,
Миңа тиде ялкыны...

Сугыш елларында кайгы-сагыш утында янучылар ул гына түгел иде. Кеше итәгенә төшкән ут яндырмый бит. Аңа үз йөрәгендәге ялкын кайнарырак тоелды.

Сагынды ул ирен.

Сагыну саргайта ул...

Сагынуның ни икәнен сагынганнар гына белә...

Бигрәк тә аз яшәделәр алар. Солтан армиягә китәр алдыннан гына өйләнешкәннәр иде. Менә шушы аерылу җиде елга сузылды. Карында гына калган улы әтисе кайтуына җиде яшьлек егет булды. Яшь хатын суга төшсә суга, кичкә керсә айга карап, Солтанының исән-имин кайтуын теләде. Теләгән теләкләре кабул булды, шөкер, ире исән-имин кайтты.

Нигә сагышның төсен сары диләр?

Аның төсен кем күргән?

Сандугач та сары.

Әллә аларның берсе моннан, икенчесе сагыштан булганга, икесе дә сары төстәме?

* * *

Көзге урман. Монда нинди генә төсләр юк. Әнә, "...ничек безнен күлмәк?" дигән кебек, көязләнеп, ап-ак күлмәкләре белән бөдрә каеннар балкып тора. Аллы-гөлле төсләргә манылган күлмәкле көяз усаклар утыра. Урман тынган, нәфис гөлләр сулган, яфрак коелмаган бер мәлләр бу. Җәй китәргә өлгермәгән, көз килеп житәлмәгән вакытлар. Һавасын гына әйт син аның — шагыйрь әйтмешли, кара икмәккә ягып ашарга була. Каймак кебек йомшак, шундый тын, йомшак һаваны кисеп алып булыр кебек. Әллә кайдан, еракган ук: "Менә бит без, нишләп күрмисез сон?" дигән кебек, кып-кызыл миләшләр елмаеп үзләре янына чакырып тора.

Сезне күрмәү мөмкинме сон, миләшләр!

Һәрберегез кечкенә генә кояш бит сез.

Кояшны күрми мөмкин түгел.

Миләш карап торуга нинди матур, ә үзе нинди әче. Матурлыгына алданып капсаң, әчелектән бөтен авызың бөрешә. Менә шушы әче миләштә никадәрле дәва бар. Тормышны әчеле мунчага тинлиләр. Әдибә аны миләш белән чагыштырыр иде. Тормышның үзе кебек үк матурлыгы да, әчесе дә, дәвалы рәхәте дә бар миләшнең. Кара инде син аның тәлгәшләрен — матур чәчәк бәйләмнәрен бер читтә торсын! Көзгә керсәң авылның купшы кызлары миләштән төймә ясап, яшьтәшләре арасында тагын да матуррак булып, мутланышып-шукланышып йөриләр.

Миләш төймә. Үскәндә кайсы гына кыз миләшләрне жепкә тезми дә, кайсы гына аны муенына тагып көязләнеп йөрми икән.

Миләштән ясалган как нинди әче дә, татлы да. Миләш кагы авызына тәм кертә, күнеленне ача, мен дә бер авыруга дәва бит. Мунчада ис тисә дә берничә миләш кабып куйсаң, баш авыртуың юып алгандай була. Аның тагын әллә никадәрле файдасы, шифасы бар әле.

Миләшне ярата Әдибә. Әнә шул әчеле булганы өчен ярата да инде. Тәмне таба белергә кирәк бит. Яшәү яме дә аның тәмен таба белүдә. Әдибә миләш белән үзенең тормышында уртаклык тоя. Аның тормышы нәкъ менә миләш кебек әче дә, татлы да, карап торуга матур да.

Быел чикләвек кенә түгел, миләш тә унган икән. Урман кырые кызыл миләш белән чуарланган. И, гомерләр, шушындый матурлыкка сокланырга да вакыт юк бит. Ярый әле бала табар вакыты җәй ахырына, аның да иң мул, иң матур чорына туры килгән.

Авыл хатыннарының күбесе баланы кырда, урак урган жирләрендә дә тапты инде. Ул вакытта сугыш иде. Беркем дә зарланмады. Ял итәргә аларга бер көн дә бирелмәде. Хәзер сугыш беткәч хәл бераз гына жиңеләйде. Әдибә бит әле рәис хатыны да. Аның борынына житкән корсагын күрә торып бригадир эшкә әйтергә керми. Мин рәис хатыны дип тормады, Әдибә эшкә йөрде. Туктаганына да әле бер-ике генә көн, анысы да бала туу вакытының уйлаганнан соңгарак калуыннан гына. Монысы да малайдыр инде. Тик абыйлары кебек тынгысыз түгел, берөзлексез тибенеп ятмый. Көнгә бер-ике тапкыр салмак кына әйләнеп ята да тына. Сабыр бала булыр ахры...

Вакыты әле атна-ун көннән соң элек дип торса да, бүгеннән калмас кебек. Юкка гынамы шулай үзсүзләнеп чикләвеккә дип чыгып китте соң ул. Юк инде, мондый урманны, мондый матурлыкны күрми калу ярамас. Урманның һавасын сулап, матурлыкка хозурланып кайту үзе ни тора. Бәләкәч тугач болай йөреп булмас. Аннан соң чикләвекнең вакыты да узып китеп бара. Һәр нәрсәнең үз вакыты. Вакыт көтми. Ул ашыга. Вакыт белән бергә чапсаң гына. Өлгерсән—өлгерәсен, өлгермәсән — юк!

Урманда ара-тирә бала-чага кычкырган, бер-берсен барлаган тавышлар

ишетелә. Кыш көне кар астында карга эзе дә табып булмый. Менә хәзер җыярга кирәк табигать ниггъмәтләрен. Үләне дә, җимеше дә, хәтта яфраклар да кыш көне дәва.

Чикләвек чыннан да күп икән быел. Әдибәнең кызы туса хәл белергә кергән бала-чагага, менә кызыбыз чикләвек җыеп кайткан, дип бирергә күчтәнәч була инде. Тагын өченчегә малай булса? Ходай Тәгаләнең рәхмәте белән быел авылда малай туа да, малай туа. Кичә түбән оч Хөршидә белән Зифа да малай тапканнар. Атаудагы Гөлҗәннәтнең дә малае бар диделәр. Сукыр урамдагы Тәкмилә дә бер-ике көн элек кенә малай тапты. Әдибә малай тапса улына дуслар, кыз тапса—кияүләр күп булачак. Бәби алып кайтучылар күп. Каенанасы авылда бердәнбер кендек әбисе, көн димиләр, төн димиләр, киләләр дә җитәләр. Мөгаллимә карчык һич авырыксынмый, тиз-тиз җыена да чыгып китә. Капкада тавыш булса киенә үк башлый, белә үзен алырга килгәннәрен. Кичә дә соң гына кайтты. Кайткач яңа туган малайлар турында бик тәмләп сөйли. Таза, шәп малайлар тапкан икән түбән оч хатыннары. Кендек әбиләре аларга дөньяга килергә булыша да, аннан әлеге балаларның тәпи басканнарын, йөреп киткәннәрен, үскәннәрен күзәтеп, шулар белән горурланып, шатланып йөри. Аларны үз балаларыдай якын күрә.

Чикләвекне эзлисе дә юк. Сап-сары булып, тәмам өлгергән, кишәнкесеннән коелам дип торган чикләвекләр капчыкка үзләре тулам дип тора. Монда шул Галияләр кебек җиккән ат белән генә киләсе калган икән. Табигать байлыгына сокланып, урманның саф һавасына исерердәй булып, әле җыр сузып, әле татлы уй-хыялларга чумып, Әдибә мавыгыбрак та китте бугай. Көн күптән инде икенче яртысына авышып, агачлардан җиргә озын-озын күләгәләр яткан.

Капчык күзгә күренеп арта, сизелеп авырая. Әдибә утырып, бер-ике тапкыр чикләвекләрен чүмләштереп тә карады. Капчыкта урын артса да, авырлык кимемәде. Гәрәбә кебек сап-сары, тәмам төше тулган чикләвекләр авыр иде. Житмәсә эче авырта, бил турыннан гына аркасы сызлый. Авыртуны ул башта ук капчык күтәрүдән күрде. Юк. Бу авырту авыр күтәргәннән генә түгел иде. Авырту ешая башлады. Болай авыртса, өйгә дә кайтып житешеп булмас. "Әнкәй генә өйдә булса ярар иде,—дип бүген беренче тапкыр каенанасын исенә төшерде.—Ярабби, әнкәй генә өйдә булсын иде".

Әдибәнең капчыкны да ташлыйсы килми. Үзенчә йөгергәндәй итсә дә, өй белән урман арасын якынайта алмый. Бик каты авыртканда туктап торып та карый, бераз гына басылган кебек була да, ул тураеп басуга, түзә алмаслык булып тагын көчәя. Әнә, югыйсә авыл күренеп кенә тора. Кайтып житәргә иде бит. Баланы басуда бер ялгызы табасы булса нишләрмен дигән куркыныч уйдан Әдибәнең йөрәге дөп-дөп типте. Кайтып кына житеп булса икән... Менә шушы тауны гына төшәсе, аннан соң тагын аз гына барасы. Үзенең әнисе ничә тапкыр: "Кызым, тулгак тотканда теләгән теләк кабул була, тулгак вакытында матур теләкләреңне онытма",—дисә дә, аның башына бернинди теләк, бер уй да килмәде.

Әдибә берни уйлый алмас булды.

Авырту үзәкләрне өзде.

Жир дә, һава да алсу томан белән капланды.

Жан ашыга. Жиргә яңа жан килә.

Тизрәк...

"Әбиләрен эзләтергә балалар өйдә булса ярар иде. Әнкәй генә өйдә булсын иде..."

Урылмаган иген кыры, чокыр-чакырлар аша турыдан гына атласа да авылга житкәндә авырту тоташка әйләнде.

—Әнкәй генә өйдә булса ярар иде...

Әдибә бу сүзләрне дога кебек кабатлады. Ул догасының кабул буласына шулкадәр ышанды ки, бер мәлгә хәле жиңеләйгәндәй булды.

* * *

Каенана. Иренең әнисе. Авыл халкы өчен Кендек әби, Ак әби. Әдибә өчен әнкәй.

Мөгаллимә карчык заманында авылда иң чибәр кызларның берсе булган. Ул әле хәзер дә төз гәүдәсен, зифалыгын, матурлыгын югалтмаган. Ачык зәңгәр күзе дә төсен жуймаган. Ике тапкыр кияүгә чыккан. Ике ирен дә жирләгән. Ике ирдән жиде бала тапкан, беренче иренең беренче хатыныннан калган балаларга да әни булган. Үзенекеләре алты малай, бер кыз. Инде төпчекләре игезәк булган. Игезәкнең сынары ундүрт яшендә кызамыктан үлеп киткән. Әнә шул баласын— Закиржанын жирләү бик авыр тоела яшь хатынга. Ул вакытларда, үсеп буйга житкән гөрнәдирдәй дүрт улын сугышта югалтырмын, үлгән гәүдәләрен, барып еларга каберләрен дә таба алмам дип башына да кертми.

Кайгы агач башыннан түгел, адәм башыннан йөри. Ләкин кайгы кайгыга ошамый. Мөгаллимә беренче ирен күмгәндә моннан да авыррак кайгы булмас дип уйлаган иде.

Ирен күмеп, Мөгаллимәнең кара кайгыда йөргән көннәре иде. Жәйге эссе бер көндә аларга әллә чегән, әллә жылы яктан кайткан кара хатын тукталды. Мөгаллимә бакчада чүп утап йөри иде, эшен ташлап өйгә керде. Эсседән теле генә түгел, жаны көйгән хатынга, кар базыннан катык алып чыгып, әйрән ясап эчертте. Тәмам әлсерәгән, хәле беткән хатын бераз тын алгач, Мөгаллимәгә карап:

—Чибәр хатын син,—диде.—Ләкин, чибәркәй, юкка яшь түгәсең, сина әле күз яшьләре күп кирәк булыр. Иренне күмгәнсең, син ирсез озак тормыйсың, тагын кияүгә чыгасың. Янадан да, илдә ирләргә кытлык булганда да, сине сорап килүче күп була, ләкин башкача өстеңдә никахың юк. Икенче иреннән тагын балаларың була. Ә хәзергә елама, бу ул кадәр кайнар яшь түгә торган кайгы түгел... Үзенне зуррак сынауларга сакла.

Хатын шулай авылдан-авылга йөреп өйрәнгәнме, татарчаны яхшы гына сукалый, аны Мөгаллимә бик яхшы аңлады. Тик ул вакытта аның нинди зур кайгы турында сөйләгәнен генә аңлап бетермәде. Дүрт улың сугыштан әйләнеп кайтмый дип әйтәсе килгән икән юлаучының. Зур зәңгәр күзле, ак йөзле, сызылып киткән кыйгач кара кашлы, сирәк очрый торган чибәр, яшь хатынны жәлләде мосафир, әлегә күрәчәген белми торсын дип уйлады ахры. Белгәнен әйтеп бетермәде.

Кайгыны кара була диләр.

Кайгылар төрле була.

Кайгы кайгыга ошамый...

Аллаһ Тәгалә бәндәсенә күтәрә алмас йөк бирмәс ди. Әллә үлчәү тәлинкәсендә хилафлыклар китә микән?

Озак та көттермәде, теге чегән хатынының әйткән сүзләре рас килде. Күрде Мөгаллимә авырлыкны да, кайгыны да. Ирләрен дә күмде. Уллары да югалтты. Тик үзе югалмады. Югалырга аның ике оядан калган, ана карап торган балалары бар иде. Менә хәзер оныклар дип яши.

Яшәр өчен һәрвакыт сәбәп табып була.

Бәхет өчен урын табарга була...

Бәхетле яшәр өчен көч табарга кирәк...

Уналты яшьлек каенана белән бер түбә астында да яшәде ул. Менә шуларның барысын кеше язмышын сөйләгән кебек, матурлап сөйли дә

белә. Кышкы озын төннәрдә Әдибә дә Мөгаллимә карчыктан каенанасы турында сөйләтергә ярата. Тегесе исә ул вакытларда күкрәге дә чыкмаган каенанасы Нурлыбаянның (авылда аны Нурлы дип тә, Баяна дип тә йөрттеләр, сабый гына иде бит әле) суга төшеп киткән җирдән тау шууын, күршегә керсә күз бәйләп уйнаганнарын, күзләренә яшь килгәнче көлә-көлә сөйли.

Чегән хатыны әйткәнчә, озак та тормый Мөгаллимә икенче иргә чыга. Дөресрәге, каенатасы килене—баладан үлеп киткән кызы Һаҗәрнең кияве Хәлиулланы өйләндерә. Матур итеп никах укыта, ике ояны кушып, балаларны ятимлек ачысыннан коткара. Кызганычка каршы, Хәлиулланың да гомере озын булмый. Бу озын буйлы, чегән кебек кара тутлы, зур кара, сөрмәле күзле, чибәр ир, тирләп печән чабып, арып-талып, җиргә ятып йоклап, салкын тидереп, тиз арада гүр иясе була. Бу вакытта инде беренче никахтан туган балалар үскән, бары игезәк төпчекләре Солтан белән Закирҗанга гына дүрт яшь була. Шуннан бәхетен кабат сынамаска була Мөгаллимә. Күрше авыллардан яучылар да килеп карый югыйсә. Үз ятимнәрен үзе үстерергә була. Аннан олы улларыннан да кыенсына.

Мөгаллимә карчыкның балалары барысы да эре сөякле, олпат гәүдәле, бик мәһабәт ирләр иде. Кая гына барма, алар кеше төркеме эчендә бер башка озын булырлар, әллә кайдан күренеп торырлар иде. Эшкә тотынсалар да ут уйнаттылар. Без ике оя балалары дип тормадылар, бер-берсен бик якын күрделәр, ярдәмчел булдылар. Бер-бер артлы барысы да йорт җиткезеп башка чыктылар. Биш малайга урман кисү, бура бурау, йорт күтәрү берни тормый иде. Алар эштән түгел, эш алардан куркып торды. Менә шул яңа йортларына балалар алып кайтып, матур гына яшәрбез дип өметләнгәндә сугыш башланды.

Мөгаллимә эчендәге ут тышка чыкса, бөтен җирне чормап алырга җитәр иде. Ләкин аның кайгысы үз эчендә генә дөрләде.

* * *

Әдибә бакча артыннан гына ихатага керде, өйгә узды. Өйдә бер кеше дә юк. Каенанасы әле килендәшләреннән кайтып җитмәгән, уллары уянгач, әниләре өстәл өстендә калдырган сөтне генә эчкәннәр дә, үзләренең малайлар эшенә чыгып киткәннәр. Су буенда балаклары белән балык тота торганнардыр. Көннәр җылы торгач аларны Сарашлыдан алып кайтып та булмый. Инде үзләре каралып, тәпиләре чебиләп беткән, яңа көн туды исә су буена йөгерәләр. Бу вакытка кадәр карыннары да ачмаган микәнни? Эшләре катыдыр инде... Бу уйлар Әдибәнең миен яндырып кына узды. Аның башка берни уйларлыгы да, кемдер өчен кайгырырлык хәле дә юк иде. Кирәге чыгар дип, үз әнисе биргән күлмәкнең гәүдә ягын кул астынарак куйды. Ул аны кичә генә әнисеннән алып чыкты. Юды, бәләкләп, киштәгә алып куйды. Әнисенә ул күлмәкнең гәүдә өлешен түгел, итәген сорарга кергән иде дә, әнисе бирмәде:

—Маһигөл белән алмашлап бала ташыйсыз, сезгә күлмәк итәге житкерерлекме,—диде ул, тавышына үртәү һәм горурлану хисе чыгарырга тырышып.—Итәгеннән мин алъяпкыч тегәм, менә сиңа гәүдә ягы, аңысы да ярап торыр әле,—диде әни кеше кырыс кыланып. Әни кеше кызының авыр сулавына да, инде бала табар вакыты җиткәнен дә, корсакның бик аска төшкәнен дә абайлады. Чыгып киткәндә дә артыннан:

—Гел чабулап, ихатадан ерак чыгып йөрмәскә тырыш. Үзеңне дә, баланны да сакла,—диде.

Күлмәкнең гәүдә өлеше дә ярап тора инде, нигә ярамасын ди. Метр-метр тауар каян аласың. Авыл кибетендә түгел, дөньясында да тауары юк

бит анын. Читтән, зимагурлыктан кайтканнар гына бүләккә авылдагы якыннарына күлмәклек тауар алып кайта. Әдибәнен андый туганнары юк. Уллары әле кечкенә. Алар үсеп житәр, шәһәргә китәрләр, әниләренә кайткан саен күлмәклек алып кайтырлар. Ул вакытларда инде ил-көн дә ныгыр. Сугыш бетте бит инде. Гел болай өзеклек, гел юклык булып тормас, иншалла.

Әдибәнен шундый уйлардан күнеле күтәрелеп китте. Ә хәзергә әнисе биргән жинле күлмәкнең әнә шул гәүдә өлеше дә ярап торыр. Тигез канатлы бала шәрә булмас әле. Булмас...

Әнисен ничек гаепләсен инде, анын да булса-калса, ике-өч күлмәге бар, ул күлмәкләргә күз атып торучылар житәрлек. Мәһигөл дә өченчегә авырлы, вакытын бүген-иртәгә дип тора. Әнисе янында ике бала белән килен бар бит әле. Яшь кенә килеш ирсез калган киленен Сәрбижамал түти бик жәлли. Бер тамчы су кебек улына охшаган оныкларына янгыр түгел, жил дә тидерми. Күлмәк итәкләреннән кызларга бөтерелеп торган кечкенә күлмәкләр тегеп бирә. Шул күлмәкләрне кигән кызларны күргәч, үзенен кызлары булмаган Әдибә, аларны Бакалыдагы кибеттә күргән курчакларга охшата. Бигрәкләр дә матурлар инде. Бөдрә чәчләрен селки-селки, абыйлары кебек салмак хәрәкәтләр белән уйнап йөриләр кызлар.

Нәкъ Фәрхетдин абыйсы төслеләр.

Сугыш беткәнгә дә ничә ел, ә абыйсыннан бернинди хәбәр юк. Үлгәннәр арасында да, тереләр арасында да исеме табылмый. Шулай булгач, килен белән ана кайтып керер дип көтәләр Фәрхетдинне. Ә ул юк та юк.

...Әдибә унайлы булсынга идәнгә ятты. Йә Хода, жинеллекләренне бир. Жаннан жан ярату диләр аны. Бала тапканда хатын-кызнын житмеш жиде тамыры өзелә икән, кырык көн буена кабере ачык торыр, ди. Жинел эш булса алай әйтмәсләр иде. Моны үзе татыган кеше генә әйтергә мөмкин. Менә шул газаплар эчендә ул япа-ялгыз.

Ул үзенен тешләк булып, каенанасыннан тел яшерүенен газабын татыды. Жан газабы авыр иде.

Әнисенең житмеш тамырын өзеп, жиргә яна жан килә.

Кычкырып кеше көлдерер хәл юк инде. Беренче баласы түгел. Яшь хатын тешләрен кысты, кычкырмас өченгә иреннәрен тешләде. Тешләнгән иреннән саркып чыккан кан башта иренгә, аннан иягенә агып төште. Каннын тозлы тәмен татып, ул йөзен чытып куйды, эченнән генә жинеллек сорап Ходайга ялварды. Әнисенен тагын: "Бала тапканда теләгән теләк кабул була ул",—дигән сүзләрен исенә төшерде. Ни сорарга да белмәде. Бу минутта ана баладан исән-имин котылырга, әнә шул баланың үзен дә исән-имин табып, кулына алу гына кирәк. Болай да бик бәхетле бит инде ул. Бәхетле...

Бәхетле...

Авырып торганын, бүгеннән дә калмасын, йә әнисенә, йә каенанасына әйтмәгәненә үкенә башлады. Чикләвектән кайткач су жылытып, чүпрәк барлап та йөрде бит әле. Баланын туар чагы тәмам житкән иде.

Унайлап ятуны гына көткән икән — бераздан бала, әнисенен жан газапларына чик куеп, дөньяга аваз салды.

Бала...

Балам.

Нинди якын син. Синен тавышын нинди матур. Мондый матур тавышны әле минем ишеткәнем юк, бүтән ишетәсем дә юк.

Син ин матур бала...

Әдибә мангаена бәреп чыккан жан тирләрен сөртте. Мангае гына түгел, өстендәге күлмәге дә манма су иде. Тәненә ябышкан күлмәген рәтләгәндәй итеп, ачык тәрәзәдән тышка карады. Өй түрендәге шомырт агачын күрде,

агач ботаклары арасына кереп чәбәләнгән кояш нурларына елмайды. Шуннан соң гына баланың кендеген кисте.

Малай...

Өченче малай...

Дөньядагы иң матур малай...

Бала таза иде, аның кул-аяклары буынланып тора. Ул аны кулына алды. Бала бик шома иде, кулдан шуып төшеп китте. Яткан җирдән генә кармаланып, баланы тагын кулына алды, тагын төшеп китте. Яткан җирдән булганга баланы кая төшергәнен дә күрә алмады. Өченче тапкырга акыллырак булды, баланы алдан әзерләп куйган чүпрәк белән тотты. Екканга үпкәләпме, бала туктаусыз елый. Нәрсәдер эшләргә кирәк иде.

Әдибә торды. Нәниен күкрәгенә кысып, үзенекеләргә, җирдәге барлык балаларга бәхет тели башлады. "Бәхетле балалар булсыннар иде, сугышлар күрмәсеннәр иде. Йә Ходаем, балаларны күмәргә язмасын..."

Баланы коендырырга гына йөргәндә кайнанасы кайтып керде. Килеп керү белән, нәкъ аңа хас булганча, кулларын белән ике ботына шап итеп сугып, кычкырып җибәрде:

—Киленкәем, авырып торасыңмы әллә, дип, иртән сорадым. Сорамасам ярар иде. Әллә мин синең авырып торганыңны, вакытың җиткәнен белмимме? Ә син нәрсә дидең? "Юк, әнкәй, авырмыйм", дидең. Син дидең. Мин ышандым. Ышандым шул... Синең сүзгә ышанмаска, үз күзләремә ышанырга кирәк булган да бит, ярар инде, буласы булган, буявы уңган,— дип, туктаусыз такмаклады.

Шулай сөйләнә-сөйләнә Мөгаллимә карчык килене янына килде, аның башыннан сыйпады.

—И, и киленкәем, тешләк тә инде син. Бу кадәр дә тешләк булырсың икән. Уйлаган идем аны бала табып ята торгандыр дип. Уйлаганым рас килде. Мин бит сине югалттым. Иртән мин Фатихаларга киткәндә өйдә калган идең. Кайтсам, син юк. Кая китте икән бу дип баш ватам, ә ул бер кешегә бер сүз әйтми-нитми чикләвеккә киткән. Урман белән авыл арасы синең кебек корсагы борынына җиткән кеше өчен бик якын түгел лә. Ни йөрәгең белән урманга япа-ялгызың чыгып киттең? Барып җитәрлек тә, кайтып җитәрлек тә түгел бит.

Ул идәндә яткан капчыкка бер-ике тибеп тә алды. Авырлыгын белергә теләгәндәй чамалап күтәреп карады. Башын чайкап, тагын тезеп китте.

—Моны ничекләр күтәреп кайттың соң син? Әле ярый баланы юлда тапмагансың. Чикләвеккә барган бит, вәт син аны... Тиз генә кайта алмадым шул. Әмирҗанның хатыны Асия да дүртенчегә малай тапты. Олы уллары Фатихалардан барып алды. Малае алагаем зур, Асия өзлекмәсә генә ярар инде.

Каенана сөйләнә-сөйләнә баланы алды, әзерләп куелган су белән аны юындыра башлады.

—Нишләп соң бу бала гел елап тора? Әллә кара елак буласымы?

Әдибә каенанасының кинәт кычкырып җибәрүеннән сискәнеп китте.

—Килен, баланы үтерә язгансың бит. Кара әле башында нинди зур тишеге бар. Арт чүмечендә биш тиен акча зурлыгында башы чокыраеп кергән, әллә тишелгән дә инде, Ходаем?!

Яшь хатын шунда гына үзенең баз капкачы өстендә ятканын, ике тапкырында да баланы баз капкачын ача торган тоткага төшереп җибәргәнен аңлады. Менә нәрсәгә бала туктаусыз елый икән. Куркудан тәне чемердәп китте. Ярый әле ул-бу булмады, Ходаем.

Өстен алыштырып, ул урын-җиргә барып ятты. Каенанасы килеп җәһәт кенә ястыгын күпертте, өстенә япты. Әдибәнең күңеле каенанасына карата рәхмәт хисе белән тулды. Ишелеп төшкән бәхет тә жанына гына сыярлык

түгел иде. Ул елап җибәрде. Үзе бертуктаусыз: "Шөкер, шөкер...",—дип кабатлады.

Бәхеткә түзеп кара...

Кайнар күз яшьләре белән күлмәк якалары, түше чыланып бетте.

* * *

Иң элек коймак салынган савытын күтәреп Сәрбиҗамал карчык килеп керде. Аларның йортлары ике өй аша гына. Солтан сугышта чакта, Әдибә тау башындагы ялгыз йортын ташлап, авыл уртасындагы туган нигезенә якынрак йортка күченде. Аны сипләтте, ныгытты. Солтан кайткач йортны тагын янартып, алты почмаклы иттеләр.

Менә оя да тула башлады. Әле кичә генә сезнең атна саен тапкан балаларыгызга күлмәк җиткереп булмый, дип тузынган әни кеше кызының исән-имин баладан котылуына шатланды. Оныгына карап куанды.

Әдибә белән бала арасында йөргән каенанасы кинәт исенә төшереп, капыл гына әйтеп куйды:

—Зәкия кайткан бит...

Кинәт әйтелгән бу сүзләр Әдибәне тетрәндерде.

Кошлар да оя типкән җирләренә кайта. Канаты каерылган кошчык—Зәкия дә кайткан.

Оясы туздырылса да, барыбер кайткан. Тузган ояны рәтли алырмы ул бала?

Кошлар да кире кайта...

Кайткан...

Зәкия—канатсыз кош кайткан...

И гомерләр...

Әле кичә генә булган кебек күңелдә кырык беренче елгы вакыйгалар калыкты.

* * *

Зәкия урамның каршы ягында гына торучы күрше Галимҗан ага белән Гөлҗинанның кызы. Солтан ягыннан кардәш тә тиеш әле алар. Тирә-якта бер чибәр кыз, чәчәк таҗы. Аны да күрер көннәр бар икән. Әдибәнең күз кабаклары авырайганнан-авырая башлады. Авыр газаплардан котылган бәхетле хатын татлы йокыга талганын үзе дә сизми калды.

Ике кодагый шыпырт кына чәй эчтеләр, дөнья хәлләрен пышылдаштылар. Сүз гел Зәкия тирәсендә барды.

Күрше кызы Зәкия Әдибәдән кече, сеңлесе Мәһигөл белән бер яшьтә иде. Ике кызлы өйгә Зәкия еш керә. Бала чакта көне буе уйнап, кунарга да калгалаганы булды. Авылның иң чибәр, иң затлы гүзәле иде ул. Аныкы кебек кап-кара чәч, икедән үреп салган озын толым, кыйгач кара каш, сөрмәле зур кара күзләр беркемдә дә юк. Бала чактан ук бик чибәр кыз, үсеп буй җиткергәч бигрәк тә сылуланып китте. Сылу гәүдәсенә сыландырып дүртәр бәбәй итәк белән күлмәк тегеп җибәрә. Аны чигелгән ап-ак алъяпкыч белән кия. Чигү җепләрен каян ала диген син аны. Аныкы кебек мулинеләр беркемдә дә булмас. Зәкия төсләрне оста яраклаштырып чигә белә иде, чәчәкләре болыннан өзелеп төшкән кебек янып, "мин монда", дип кычкырып торырлар. Аныкыдай ак тула оек, килешле күлмәк авылда гына түгел, сабан туена җыелган күрше авыл кызларында да булмый. Шул зифа сынын, килешле күлмәген, озын чәчләренә тагылган чулпыларын күрсәтергә чыккан кебек, көнгә әллә ничә тапкыр чишмәгә суга төшә. Аның артыннан авылның өйләнгән-өйләнмәгән ир-атлары карап кала, авылда ни тыйнак саналган мулла агай да кәвешен рәтләгән булып иелеп, култык астыннан гына Зәкияне күзәтә иде. Кыз моны борылып карамаса да сизә. Алымы

тагын да җәһәтләнә, инсәләре, тулы күкрәкләре тагын да кабара төшә. Зәкия көлеп җибәрсә бер уч көмеш акча сибеп җибәрәләрмени, бөтен дөньяны матур чынга күмеп, челтерәтеп көлә. Үзенең чибәр булганын белеп, яратып һәм текәлеп караган карашларны туя-туя, ләззәтләнеп, эчендәге шатлыгын тыя алмыйча, рәхәтләнеп көлә.

Менә шул сылуга күз тиде ахры. Әллә барысына да шул сугышны гаепләргәме? Зәкиянең йөргән егетен дә сугышның беренче көненнән үк алдылар. Әле егермесе яңа тулып килгән Зәкия кияүгә чыгарга ашыкмады, житешермен дип йөрде. Сугыш башлангач соңгы төнне ябышып булса да чыгып, ир хатыны булып калса ярар иде дә бит, юк шул. Насыйп булмагандыр инде. Закиры аның чиккән кулъяулыгын гына алып китте. Китеп бер хаты гына да килмәде, үле хәбәрен алдылар. Солдат хезмәтендә булган, читтә йөреп шомарган егетне башта ук утның уртасына кертканнәрдер. Анысы да пуля дигәннәреннән качып ятмагандыр, гел алда, беренче йөргәндер.

Закирдан кара кәгазь килгәч кыз сулды. Сулса да гүзәл иде ул. Чәчәк кипсә дә чәчәк булып калган кебек, кыз ябыгып, бераз тартыла төшсә дә, карап кына тормалы иде. Яңгыратып көлеп җибәрмәс кенә булды. Менә шушы гүзәлгә кемнәр генә кызыкмагандыр. Ә берсе кызыгып кына да калмаган булып чыкты.

Гөлне үстерүче сирәк, кызыгучы күп...

Гөл сабагы нечкә, кагылсаң, сынарга гына тора...

Миңлебануның йөргән егете Шәрифулла да сугышка Закир белән бер көнне китте. Аларны менә шушы дуслаштырдымы, икесе ике камырдан ясалган кызлар шул көннән аерылмас ахирәт булып киттеләр. Миңлебану ипсез, иләмсез, абагы да җабагы, ятимлектә үскән, әти-әни тәрбиясе күрмәгән, шулар өстенә авызлыга сүз бирмәс, җәяүлегә юл бирмәс, мәгънәсез дә кыз. Рәтләп сөйли белмәсә дә, ир-аттан яман сүгенер. Иләмсез итеп, авызын күтәреп көләр. Кыскасы, Зәкиягә ахирәт булырдай кыз түгел иде Миңлебану. Берара, әле кияүгә чыкканчы ук, Әдибә белән ахирәтләшмәкче иде ул. Кичке уенга чыкканда, өс-башы начар, ятим Миңлебануны кызганып, ул аңа күлмәген биреп тора. Ятим кызны кеше арасына кертәсе килә, жәлли иде. Бервакыт кичке уенга җыендылар. Әдибә Миңлебануга үзе дә кияргә кызганган, биш бәбәй итәкле, “теш сызлаганда” гына кия торган, акка бик матур вак зәңгәр чәчәк төшкән күлмәген кидерде. Тәртәсе кыска, үтә көнчел Миңлебану, су буена төшкәндә чыгымлап китте дә яңа гына явып узган яңгырдан пычранган җиргә шап итеп утырды. Ахирәтенә ул кадәр ачуы килмәсә дә күлмәкне эштән чыгару иде аның уе. Үзе житмәсә:

—Менә синең күлмәгеңә, менә-менә,—дип, бераз калкына да шап итеп утыра, бераз калкына да шап итеп тагын утыра.

Әдибә бу кадәр оятсызлыктан хәйран калып, бер сүз әйтә алмады. Әдибәнең жир төсенә кергән күлмәкне җәлләүдән, ахирәтенең оятсызлыгыннан күзләренә яшь бәреп чыкты, ә Миңлебану шаркылдап көлде. Ул күлмәкне селте белән кайнатып та, су буена алып төшеп бәләкләп тә юды, тапларын бетерә алмады. Шуннан бирле Миңлебанудан җаны бизде, ятим кыз дип җәлләми, иярми, җае туры килгән саен сыйламый башлады. Аннан шулай тиз котылуга сәбәп чыкканга сөенеп тә йөрде әле.

Зәкиягә серен сөйләргә, эчендәге уты белән уртаклашырга, үзе кебек бер үк кичерешләр белән янган кыз кирәк булды. Андый кыз тиз табылды. Сугышка китүчеләрне олы юлдан озатып кайтканда Миңлебану белән сөйләшә-сөйләшә, елаша-елаша кайттылар да, сөйгәннәренә бергә-бергә хатлар язарга, аларның хатларын бергә-бергә укырга килештеләр, шуннан аерылмас сердәшләргә әйләнделәр.

Сугыш үзе белән авыл тормышына үзгәрешләр алып килде. Еллар атналар, көннәр белән түгел, ә авылга фронттан килгән хәбәрләр белән исәпләнә башлады. Берәрсеннән хәбәр килсә, исән икән дип сөенешә авыл халкы. Кырык ямаулы өс-баш та, ачлы-туклы йөрү дә ул кадәр мөһим түгел иде. Кешеләр җину көнен көтеп яшәделәр. Җину көнен һәм язны көтте халык. Яз үзе белән җылылык, үлән, аннан икмәк, яхшыга өмет алып килә. Менә ямьле яз житәр дә, сугыш та бетәр. Сугыш беткән көнне үк дөньядагы барлык михнәтләр тәмамланыр, тамак тук, өс бөтен булыр, тормыш тоташ бәйрәмгә әйләнер кебек иде. Сугышка киткәннәр генә исән-имин әйләнеп кайтсыннар, алар кайткач бар да яхшырыр, бар да әйбәтләнер, диделәр.

Җәйнен эссе бер көнендә, моңа кадәр тавышсыз-өнсез яшәгән авыл, корт аерган умарта оясы кебек гөж килде.

...Зәкия баласын үтергән...

Зәкия?

Үтерүчеме?

Таштa гөл үскәненә тизрәк ышанырмын...

Булмас...

Нинди баласын?

Бу сүзләр Зәкия белән беррәттән акылга сыя торган түгел иде. Әдибәнең иң беренче уе: “Булмас, Зәкия андый кыз түгел, исемен пычрату, начар данын чыгару өчен дошманнар чыгарган сүздер”,—дип уйлады. Коточкыч бәхетсезлек килгәнен сизенеп, Әдибәнең күнелен әйтеп бетергесез курку чолгап алды. Зәкия белән нәрсә булыр? Әти-әнисе бу хурлыкны ничекләр күтәрер?

Адәм баласын бәхетсез итәргә күп кирәкме?

Бер яман сүз житә...

Бөтен кеше колхоз амбары янына жыелган.

Әдибә дә барды ул колхоз амбары янына. Ул килеп житкәндә бөтен авыл халкы шунда жыелган иде инде. Андагы хәлне күреп, ул хәйран калды. Яңа туган бала малай кеше иде. Ап-ак тәнле, кул-аяклары буынланып торган таза сабый. Әле жаны чыгып, тәне суынырга да өлгермәгән, чүпрәккә-мазарга төрелмәгән баланың биленнән мунчала бау белән бәйләгәннәр. Аны бөтен кешегә күренеп торырлык итеп, гыйбрәт өчендер инде, амбарның матчасына асып куйганнар. Әллә куркудан, әллә бала белән аның әнисен жәлләүдән, Әдибәнең бөтен тәне өзлексез калтырый башлады. Ярый әле өч бәбәй итәкле күлмәк озын, тезләрне дә, тубыкларны да каплап тора. Әдибә тырнаклары зәңгәрләнеп чыккан, калтыранган кулларын алъяпкыч астына тыкты. Шулай калтыранып, өнсез басып торганда, кемдер аның колак төбендә генә пышылдап диярлек:

—Йә Ходаǃ—дип куйды.—Нинди вәхшиенең баланы шулай асарга кулы күтәрелде икән? Аның соң монда ни гаебе бар? Бер кат үлгән баланы тагын шулай асалармы инде?

Әдибә, әллә куркудан инде, тавышны танымады, борылып карыйсы итте. Авылда иң усал саналган Мәрвәр атлы хатын икән. Зәһәр Мәрвәр булып ул да бу күренешкә хәйран калган.

- Ерткычлар,—дип тиргәнүен дәвам итте Мәрвәр,—ерткычлар,—дип тагын кабатлап, бу юлы тавышын күтәрә төште,—баланың бит тәне дә суынмаган, ничекләр кулыгыз күтәрелде?

Аңа игътибар итүче булмады.

Әдибәнең исә бер сорау миен бораулый иде. Кем булыр бу баланың атасы? Кем? Авылда бит юньле-башлы ир-ат та юк. Аннан соң авылда Зәкиягә аерым бер мөнәсәбәт. Әтисе Галимҗан картны бер яктан олылап хөрмәт итсәләр, икенче яктан шушындый матур авылдаш кыз белән үзләре

дә горурлана иделәр. Юк, авыл кешесе түгелдер. Теге пулнамуч эше булса гына инде.

Сугыш башланган елның үтеп китмәс кебек тоелган озын кышы башланмаган иде әле. Битенә чиртсәң кан чыгардай тук чырайлы, әзмәвердәй пулнамуч килде.Әнә шул тук чырай, авыл кешеләрен куркыта-куркыта заемга язып йөрде. Карт əти-әнисе белән яшәгән Зәкиягә дә зур суммага язылырга диделәр. Менә шул кәгазьгә кул куйдыру өчен, теге адәм актыгы Зәкияне ничә көн кәнсәдә ябып тотты. Галимҗан карт карчыгы белән үрсәләнеп, кәнсә тирәсендә ничә төн уздырдылар. Шул козгын гына башына җиткәндер баланың. Тагын кем булсын инде. Алак-шалак йөри торган кыз түгел, ул-бу була калса авылда ишетелми калмас иде.

Авылда җир астыннан йөргән еланны да сизәләр.

Авылда таяктан төз булсаң гына телгә кермисең.

Әдибә җыелган халык арасыннан күзләре белән Галимҗан картны эзләде. Карт халык арасында юк иде. Иң соңыннан, авыр атлап, ул килеп җитте. Күз карасы кебек саклап үстергән бердәнбер кызына, аннан үле балага бик озак итеп карап торды. Ул түбән очтан амбарга кадәр менеп җиткәнче бу сүзләрнең хак түгел, бары тик усал гайбәт кенә булуын теләгәндер. Менә ул амбар янында. Менә авыл халкы, әнә аның елый-елый шешенеп беткән, чәчләре тузгыган, танымаслык булып үзгәргән кызы. Галимҗан карт әлеге хәлләрнең үзе һәм аның яраткан кызы белән булуына ышана алмады.

Бу хәл карт атаның гына түгел, авыл халкының да башына сыймый иде ахры. Җыелган халык ләм-мим бер авыз сүз әйтми. Авылның иң зәһәр хатыннары да тугыз ай буе шушы хәлне белми йөргәннәренә үртәлепме, ачуданмы, аңлашылмый торган авыр тынлыкта иреннәрен кысканнар. Гайбәт сөйләргә нинди җайлы мөмкинлек кулдан ычкынган иде. Үле бала, районнан килгән форма кигән кешеләр, елап шешенеп беткән Зәкия кешеләрнең җанын изә. Берсенең дә тынлыкны бозасы килми. Ә нәрсә әйтеп була соң? Тагын шул нәләт төшкән фашистны каргаргамы? Зәкия пычрак йога торган кыз түгел иде бит. Аларның нәселләре тирә-якта дәрәҗәле булды.

Авыр тынлыкны Галимҗан карт бозды.

- И-и-и, бала-бала,—дип суздьі ул.—Мондый хурлыкны күргәнче, синең үле гәүдәнне күрү җиңелрәк булыр иде. Үзең генә үлгән булсаңчы...

Зәкия тагын да бөрешә төште. Аның инде еларга да хәле калмаган иде.

Кайгыдан бөкрәйгән, кечерәеп калган Галимҗан карт бер утырды, бер торды, үзе туктаусыз калтыранды, кулларын уды, йөрәк тирәсенә дә тотынып алды. Ни эшләргә белмәгәннән гаҗиз булып, җыелган халык өстенә карады. Күзе беркемгә дә тукталмады. Кешеләрдән ниндидер ярдәм көткән кебек карап торды да, авыр сулап, тагын башын иде. Үзенең күзеннән туктаусыз яшь коелды.

Чарасызлык яшьләре...

Ир-ат күзендәге яшь бөтенләй башка ул. Аның һәр тамчысының авырлыгын үлчәү күтәрәлмәслек.

Ир-ат елавын күреп торуы икеләтә-өчләтә авыр.

Галимҗан карт кайтып китәргә дип борылган иде, нидер уйлап, туктап калды. Аннан, кайгыдан авырайган башын күтәрмичә генә, беренче һәм соңгы оныгы янына килде. Аны эленгән җирдән алды, юка мунчала бавын чиште, шундагы агач тартма өстенә ап-ак киндер күлмәген салып җәйде дә, баланы күлмәгенә төрде. Төргәкне тартма өстенә куеп, авыз эченнән генә нидер укыды. Әллә хушлашты, әллә гафу үтенде. Шунда гына:

—Баланы җир куенына салырга кирәк,—дип, каршы килергә урын калдырмаслык итеп, кистереп әйтте. Ни районнан, ни авыл Советыннан

килгәннәр бер сүз әйтмәде. Шуннан соң, аз гына башын күтәргәндәй итеп, карт жыелган халыкка карады. Аңа шунда ук түгәрәккә жыелган халык икегә аерылып юл бирде. Кемдер инсәсеннән күлмәген салып, картның иненә куйды. Карт авыр атлап, тигез җирдә дә сөрлегә-сөрлегә, авылга таба кайтып китте.

Халык тынсыз иде.

* * *

Галимжан олы гәүдәле, бик олпат карт. Заманында ул берүзе ат дагалаган, нәсел үгезләрен буйсындыра алган. Тирә-якта көрәштә аның белән алучы булмаган. Хәмер-тәмәкене авызына да алган кеше түгел. Сабантуй батыры. Әдибә белә-белгәннән бирле Галимжан карт кешеләргә "туган" дип кенә эндәште. Үзләренә йомыш белән кергән күрше-күләнне, авылдашларын мәхрүм итеп кире бормады.

—Йомыш-гозерне үтәү, бурычка биреп тору, хәер бирүдән дә саваплы,— ди торган иде карт.

Авылда иң яхшы йөгән-дилбегә анда булыр иде, иң яхшы чалгы янаучы да ул. Балта, пычкы кебек әйберләре һәрвакыт яхшылап үткенләнгән, синең сорап кергәненне генә көтеп торган кебек, кыстырып куелган булыр. Әдибә аның бер кеше белән телгә килгәнен, нидер бүлешкәнен хәтерләми. Карчыгы да аның үзе кебек. Кеше белән елмаеп, йомшак кына сөйләшә. Идән-сәкеләре ничә керсәң дә комлап, ышкып юылган, чиста, сап-сары була.

Галимжан карт теге кара көндә нәрсәләр уйлагандыр, билгесез. Аңа авылдашлары күзенә күренеп, озак йөрергә язмады. Амбар яныннан кайту белән урын өстенә ятты. Галимжан картның хәле бик авыр икән дигәч, Әдибә дә кергән иде кардәш тиешле күршеләренә. Карт танымаслык булып кибеп-корыган. Ашамый-эчми берничә көн сызып ятты-ятты да, йоклап киткән кебек кенә мәңгегә күзен йомды.

Зәкия турында авылда сүз сөйләп йөрүче булмады. Галимжан карт үлгәч тә авыл кешеләре үзләрен ничектер гаепле кеше сыман тоттылар. Авылда калган картлар жыелып, тавыш-тынсыз гына кабер казыдылар да, белгәннәрен укып, җиргә иңдерделәр.

* * *

Әлегә кадәр авыл тыныч яшәгән икән. Кызлар туа, үсә торды, вакытлары житкәч аларга бөтен шартына туры китереп яучы жибәрелде, матур итеп туйлар ясалды, туй ясарга хәле булмаганнар никах укытты. Бөтен нәрсә үз тәртибе, үз чираты белән барды. Тормыш гел шулай жайлы-унай гына барыр кебек иде. Юк икән. Колхозлашу дигән шау-шаудан авыл тынып кына яши башлагач, сугыш чыкты. Бөтен дөнья асты-өскә килгән кебек булды. Йорт салу, кыз бирү, ул өйләндерү кебек матур гадәтләр бетте. Авыл күз яше белән уянып, күз яше белән йокларга ятты. Өйләрдә еллар буе ут алынмады, халык көн яктысы белән генә яшәде. Авыр иде. Бөтен нәрсә йөрәк маен кимерде. Тимер юлга түгел, олы юлга да ерак утырган авылга ил-көн хәбәре сирәк килде, озак килде. Билгесезлек тынгы бирми әрнетте. Бераздан Зәкия дә, аның улы да, Галимжан карт та, карчыгы да онытылды. Аларны шул уйласа бер Әдибә генә уйлагандыр. Теге шомлы көндә, Зәкияне богаулап алып киткәч тә, бик озак колагына кызның әле көлгән, әле елаган тавышы килгән кебек тоелып йөрде. Елап шешенеп беткән кызның ялварулы карашы төшенә кереп, тирләп-пешеп уянып китә торган булды.

Ул жәйге көн төзәлмәс жәрәхәт булып йөрәктә калды.

* * *

Зәкиянең кемнән, кайчан авырга узганы авыл халкына сер булып калды. Теге вакытта бит аны кулларына богау салып, беркем белән сөйләштермичә, районга алып киттеләр. Әнисе Гөлҗинан апа амбар янына да килмәде. Әдибә ул карчыкның Галимҗаны сүзеннән чыкканын, аннан узып берәр эш башкарганын бөтенләй хәтерләми. Сабыр Гөлҗинанның барысы да, уты-ялкыны, эчендә булгандыр инде.

Зәкиянең соңгы вакытларда тагын да тулыланып, матурланып киткәнен сизделәр, ләкин Галимҗан картның кызы авырлыдыр дип беркемнең дә башына килмәде. Кабартып тегелгән бәбәй итәкле күлмәк, күлмәк өстеннән чигешле алъяпкыч бәйли иде. Менә хәзер генә Зәкиянең сөйләшкәндә кулын алъяпкыч астында тотуын исенә төшерде Әдибә. Алай итмәсә дә барыбер шикләнмәсләр иде аннан. Зәкия белән андый гөнаһлы эшләр гел икесе ике нәрсә кебек, бер-берсенә йокмый иде бит.

Кыз үзе дә серен соңгы көнгә кадәр саклаган икән. Әгәр Миңлебануга алдан сөйләгән булса, бу хакта бөтен авыл белер иде. Бала табар вакыты җиткәч кенә, Зәкия ахирәт саналган Миңлебануны чакырып чыгарып, серен әйткән. Тегесе ишеткән хәбәрдән башта телсез калган. Аннан беркемгә дә сөйләмим дип ипи тотып ант иткән.

—Миңлебану, зинһар өчен мине мунчагызга алып бар,—дигән кайгыдан тәмам аптыраган Зәкия.—Син ишек төбендә саклап торырсың, кеше-мазар килеп чыкмасын. Әгәр берәрсе килеп чыкса, сөйләндереп тор, аны мунча яныннан алып китәргә тырыш. Бала тугач берәр җае чыгар әле. Ахирәтем, син миңа ярдәм итәрсең бит?

—Сорап торасың тагын, итәм-итәм. Борчылма, борчылма. Кеше түгел, эт тә сизмәс,—дип юата аны Миңлебану.

Зәкия мунчага кереп китә. Хуҗабикә кыз Миңлебану ишек алдында кала. Авыл халкының бөтенесе диярлек басуда. Сак куймаса да килеп чыгучы булмас иде дә бит. Зәкия мунчага кереп китү белән, Миңлебану авыл буйлап йөгерә. Авылда кемне таба, барысына сөйләп, бөтен халыкны җыеп өлгерә. Кулына бала тотып чыккан Зәкияне шунда ук алалар. Кулларына богау салалар. Бала үле була. Әллә ул кысып йөрүдән үле туган, әллә аны Зәкия берәр нәрсә эшләткән, билгесез... Аннан: "Нишләттең балаңны?" —дип сораучы да булмады.

Үтергән. Бетте-китте.

Миңлебану гына, итәгенә ут капкандай үрле-кырлы сикеренгәләп, берөзлексез такмаклады:

—Тугач суга батырам мин аны, диде. Мунчадагы суга батырып үтергән ул аны. Баласын үтергән. Үзе үтергән. Үтерәм диде... Үтергән...

Кара мунчадан да кара көннәреңне каралтырдай кешеләр була.

Бу Миңлебану инде...

Юкка гына дус—башка, дошман — аякка, димиләр икән. Миңлебану кебек дус кирәкме?

Күрәчәген күрәсе булганга Зәкия Миңлебану белән дуслашкандыр инде.

Шөкер, андыйлар сирәк. Сирәк булсалар да, бер мичкә балны бозарга бер кашык дегет җиткән кебек, авыл халкының канын бозарга берәү дә җитә...

Әле яңа гына җан газабыннан котылган, өстенә ишелеп төшкән хурлыктан, тормышындагы көтелмәгән бу борылыштан тәмам акылдан шашарга житешкән Зәкия, ул вакытта үзен яклап бер сүз дә әйтә алмады. Әтисе белән әнисенә хурлык ясамаска теләп, ул башта баланы чыннан да тугач үтерермен дип уйлады. Аннан соң башына мондый уй килүенә үзе дә куркып йөрде. Зәкия аны ярата башлаган, ни булса да булыр, баламны

беркемгә дә кактырмам, үзем үстерермен дип, күнеленә беркетеп куйган иде. Бала үле туды.

Иртән авылның гына түгел, тирә-якның да горурлыгы саналган гүзәл кош, бер тын эчендә жинаятьчегә әйләнде. Сугыштан килеп торган хәбәрләрдән алжыган, күнелен курку чолгап алган, рәхәт һәм шатлыкның ни икәнен оныткан авыл халкы көтелмәгән бу хәлдән ни кайгырырга, ни шатланырга белмәде. Авылда һәр кеше кадерле чак иде шул.

Эшне куркытырдай булып, жир жимертеп эшләгән Зәкиянең авылдан китүе куаныч түгел иде. Зәкия өй юышырга чакырсаң да килеп житә, көлләп-комлап идән-түшәмне дә юа, идәнне булсын, керне булсын, аннан да агартып юган кыз юк. Кич утырганда да ул өенне ямьләп утыра... Зәкиянең бишмәтен, күлмәген киеп, ни пешерсәләр гел шунда ашап яткан Минлебануның Зәкияне чагуы ошамады авыл халкына. Куендагы елан. Кем уйлаган инде ятим Минлебануның эчендә шулкадәр көнчеллек, шулкадәр ачу булыр дип. Ә ул бөтен үчен эчендә тотты. Килбәтсез гәүдәле Минлебану чибәр Зәкияне бала чактан ук яратмады. Матур кием Зәкиядә. Сабан туенда ул мәйдан уртасында. Менә бәйрәм Минлебану урамына да килде. Бер минутта ул Зәкияне юк итте. Авылның йөзек кашы саналган Зәкиянең кикриге шинде, ул авыл урамы уртасыннан да, койма буйлап та бүтән йөри алмаячак. Аның матур башы Себер китәчәк. Бәлки бүтән кайтмас та әле. Минлебану тантана итте. Ләкин аңа борылып караучы булмады. Авылның усал хатыннары да, итәгем тимәсен дигән кебек, аны урап уздылар. Шуннан бирле Минлебану белән авылда рәтләп сөйләшкән кеше юк та бугай. Әдибә аны күрмәмешкә салыша. Шөкер, аңа эше дә, йомышы да төшкәне юк. Зәкиянең башын ашаган ул адәм көеген онытамы соң инде ул.

* * *

Зәкиянең киткәненә ничә ел булды соң? Аның Зәкия белән бер вакыттарак тапкан улы егет булып бетте бит инде. Әтисе сугыштан кайткач туган икенче улы тәпи басканга да никадәр. Әйтергә генә ансат, иректәге гомер узган да киткән. Зәкия утырмага китмәде, кунакта да түгел. Кайларда гына булып, ниләр генә күрмәде икән бахыр. Ел түгел, чит-ят жирләрдә минутың да ел кебек озын тоела торгандыр. Инде шушы яшенә житеп ни гаиләсе, ни баласы юк...

Әдибә янында месләп йоклап яткан жылы төргәкне капшап, эчендәге шатлыгын тыеп кына көлемсерәп, аны назлап сыйпап куйды. Ходаем, биргәненә мен шөкер. Ул кайчагында үзенең бәхетеннән үзе куркып куя. Яраткан ире янында, менә өч улы бар. Каенанасы аның өчен үлеп тора, әти-әнисе бүгенгә тигезләр. Биш килендәш арасында берүзе ир белән тора. Иренең туганнары дүртесе тин сугыштан әйләнеп кайтмады. Авылның кайсы гына өенә кагылма, сугыштан кайтмаган кешесе бар. Яралар яңа гына каплана башлады. Ә өметнең сүрелгәне юк. Әле тегендә, әле монда сугыш вакытында югалган яки үле хәбәре килгән солдат кайткан икән, пленда булган икән дип сөйләделәр. Шул имеш-мимешләр, әллә кайсысының гына колагына ияреп кайткан хәбәрләр, солдаткалар күнеленә янә өмет уты сала. Янә менә кайтыр, менә кайтыр, дип, ышаныч тулы көннәр ага башлый. Әдибәнең үзенең бәхете түгәрәк. Дөрес, бертуган абыйсының гына хәбәрсез югалуы, әнисенең аның өчен өзгәләнүләре күнелен әрнетә-әрнетүен. Юк, ул үз әрнешләрен кешенеке белән чагыштырырга жыенмый. Һәркемгә үз кайгысы башкаларныкыннан әчерәк тоела. Үзе теләп алганча, тормышының әче урыннарына бал кушардай балалары бар. Шулай булса да, аның ятим калган Зәкия өчен жаны әрнеде. Туганымның тормышында миләш ачысы гына түгел, әрем тәмнәре бардыр дип уйлады.

Бу тормышлар әче миләш...

Зәкияне богаулап алып киткән көндә Әдибә жирдә дуслык белән дошманлыкның арасы бик кыска булуын аңлады...

Шул көндә ул сүзнең көчен тойды.

Бер сүз белән кешене юкка чыгарып буласына инанды.

Зәкиянең башын ашарга бер сүз җитте.

* * *

Ул вакытларда Зәкияне җинаятьче ясасалар да, тора-бара андый эшләр гаепкә саналмый башлады. Сугыш вакытында, сугыштан соң халык үзгәрде. Ирсез бала табу, качып-посып күрше урыс авылында бала төшерү гаеп эш саналмый башлады. Сугыш вакыты иде. Ул вакытларда бер генә гамәл дә ирекле баштан эшләнмәгәндер.

Сугыш вакытында авылның иң асыл кызларын урман кисәргә алып киттеләр. Өс-башлары начар гына булган авыл кызлары кар ерып, урман кисеп йөрделәр. Үз-үзләрен тота белгәннәре авыр эштә озаклап эшләп, юка гына сырма белән салкын тигезеп кайтып, сызып-кибеп үлделәр. Салкын тиеп, сызып үлгән кызлар арасында Фатыйма килендәшенең кызы Салиха, күрше Маһикамал апаның кызы Галимә дә бар иде. Үзләрен саклый, яклый алмаганнары берничә айдан авырлы булып, корсак күтәреп кайтып, авыр эштән котылып калдылар.

Ничә кызны торф чыгарырга алып киттеләр. Алары да бала күтәреп кайтты авылга. Авылдашларының сораулы карашларына: "Кияүгә чыккан идем, баламның әтисе үлеп китте шул",—дип кенә җавап бирделәр. Нишләптер аларның барысының да ирләре бер үк төслерәк үлем белән вафат булганнар иде. Кайсысыныңдыр йөк төягәндә өстенә мичкә төшкән, кайсы машина астында калып тапталган... Авыл халкы төпченеп тормады. Шулай бәбәй күтәреп кайтмасалар, кыз килеш картаерлар иде, болай ичмаса иптәшле булдылар, дип сөйләделәр. Шул балалары белән гомер итәләр менә. Аларның яшьтәшләре сугышта үлеп бетте шул. Хәзер менә шул бала табып калган хатыннар "Ярый әле ул чакта бала тапканбыз, үзебезгә иптәш ичмаса" дип шатланалар. Авыр тормышларыннан да ямь табарга тырышалар.

Читтән бала күтәреп кайтучылар бер Баекта гына түгел, андыйлар авыл саен булды. Сугыш югалтулар гына түгел, менә шушындый табышлар да алып килде. Күп яклы иде сугыш. Кара яклары шушындый иде. Бөтенесен Гитлерга яктылар, сугышка сылтадылар. Сугыш бетте. Авыл саен кимсетелгән хатыннар, аларның ятим, әтилеләрдән яшерен көнләшеп яши торган, китек күңелле балалары калды. Бу күз яшьләре кайчан кибәр икән соң? Моның өчен сугыш күрмәгән әллә ничә буынның үсүе кирәк әле. Ярый, чит җирләрдә йөргәннәренә ни әйтерсең, авыл капкасыннан ары китмәгән кызлар да бала тапты—ялгыз каласылары килми иде. Авыл халкы аларның атасы кем икәнен дә тикшермәде. Ирләр авылда санаулы гына бит. Тикшерә башласаң таякның авыр башы үз башыңа төшүе бар.

Зәкия сугыш башланган беренче көннәрнең корбаны булды. Кыз сугыштан ак билет белән калган, йөгәнсезләнгән ирләрнең берсе булган пулнамуч гөнаһын бишләтә, унлата артыгы белән түләде.

* * *

Әдибә пулнамучларның барысы да кеше башын ашар өчен генә районнан җибәреләдер, әгәр алар авылга килеп тә, бер-бер кешедән гаеп-кыек тапмасалар, аларга хезмәт хакы бирелмидер дип уйлый иде. Аларның барысын да Зәкиянең башын ашаганы кебек симез, ялтырап торган битле, иләмсез зур борынлы итеп күз алдына китерә иде. Алай түгел икән лә дөнья. Яхшы кешеләр дә бар икән. Әле ниндиләре генә.

Кырык өченче елның кышы иде. Халык сугыштан тәмам өшәнеп беткән чак. Кешеләрнең йөзеннән елмаю качкан вакыт. Шул елны аларның авылына районнан тагын бер пулнамуч килде. Әлеге вәкил күрше кызы Мәүлиханы төрмәдән алып калды. Аны хәзер дә бөтен авыл халкы рәхмәт сүзләре белән искә ала. Әгәр исән булса, рәхәт яшәсен, мәрхүм икән—бу уйлар ана дога булып барсын. Хөсетле, тар күңеллеләрне, явыз көнчеләрне акылга утыртып, аларның колакларын киртләп, дөньяның әләк белән түгел, яхшылык белән баруын бик каты анлатып китте. Ике дөньяның рәхәте насыйп булсын ана. Балаларының рәхәтен күреп яшәсен.

Анисының күзендә үк иман нуры бар иде. Авылга килде. Халыкны авыл клубына җыйдырды. Сугыштан яраланып кайткан солдат иде ул.

—Иптәшләр,—диде ул,—мин районнан килгән вәкил булам. Вакытлыча туган авырлыкларны бергә-бергә чишәрбез.

Аның сүз сөйләвендә, кешеләргә каравында, эндәшүендә үк өмет бар иде. Ачлыктан, билгесезлектән, кайгы күреп куркып беткән күңелләргә җылы йөгерде шунда. Яхшы ата-ана баласы, тәрбияле кеше икәне күренеп тора иде аның.

Ул җыелышны Мәүлиха гына түгел, бөтен авыл халкы исендә калдырды.

Мәүлиха сугыш башланганда тугыз классны гына тәмамлаган зәңгәр күзле, сары чәчле, озын толымлы, юка гына бер кыз иде. Мәктәптә гел яхшы укыды. Алга таба укыса әллә кем булып, авылның данын күтәрер иде дә, сугыш башланып планнарын җимерде.

Менә шул Мәүлиханы "укыган, белемең җитәрлек" дип колхозга кладовщик итеп куйдылар. Бөтен колхоз байлыгын ышанып яшь кызның кулына тапшырдылар. Яшь булса да бик акыллы бала булып чыкты. Итәк-чабуын да җыя белде, халыкны да ач итмәде.

Һәр авылның бер әләкчесе, әтрәк әләме, бетле хәерчесе була бит. Әдибәләр авылында да андый "чир" бар иде. Үзе гарип, шуның аркасында сугыштан калган Фәтхетдин үзе дә рәхәт күрмәде, кешеләргә дә тынгы бирмәде. Өе тулы бала-чага. Ни үзе, ни хатыны колхоз эшендә батырып эшли торганнардан түгел. Яхшы тормышка да, яхшы мөнәсәбәткә дә лаек булмаган әнә шул әтрәк әләмнең гаиләсе бик ачка интеккәч, Мәүлиха аларга сигез кило икмәк биргән. Вакытында наряд яздырттырып алмаган. Вакыт үткәч онытылган. Тегесе елап килгәч, олы кешенең коры сүзенә кыз бала ышангандыр инде. Абыйсының үле хәбәрен алгач, дөнья мәшәкате белән Фәтхетдингә икмәк биргәнен дә оныткандыр Мәүлиха. Ә мәкерле Фәтхетдин яшь кызның башын ашарга җай эзләп кенә йөргән икән. Районнан вәкил килгәч, клубта башта авыл хәлләрен сөйләштеләр. Чәчүгә орлыкларның җитәрлеген барладылар. Мәүлиханың да эшен карадылар, ул бала отчет сыман нәрсә ясады. Аны мактадылар, җитмәүчелеге юк, эшне төгәл, намус белән алып бара, диделәр. Менә шунда нәсел күркәсе кебек кабарынып, Фәтхетдин торып басты.

—Кәк тәк Мәүлиханың җитмәүчелеге юк? Кәк тәк ул яхшы эшли, панимаеш?! Мин аннан яз көне бернинди язусыз-сызусыз сигез кило икмәк алган идем, ә аның бернинди җитмәүчелеге юк имеш! Бар да яхшы, төп-төгәл дә, ялт иткәнме? Шалиш, брат, алай булмый ул! Аның сигез килограмм икмәге чыкмаска тиеш. Бүтән бер җитмәүчелеге булмаса да, мин алган сигез килограмм чыкмаска тиеш.

Зал сулыш алырга да куркып, телсез калды. Бер кесә бодай өчен җидешәр-сигезәр елга төрмәгә алып киткән вакытлар бит. Ә монда сүз сигез кило турында бара. Бу башка сыя торган нәрсә түгел! Клубка җыелган халык, яшь кызның язмышы хәл ителгәнен аңлап, бу чыгышның азагын көтте. Авылның усал саналган телчән хатыннары булып алар да, бер-берсенә астан гына карап, тавыш-тынсыз утыра бирделәр. Мәүлиханың яхшылыгы

авылда бик күпләргә тиде, ләкин аны яклап чыгарга ашыгучы күренмәде. Әдибә үзенең күкрәк читлегенә ут капкан кебек хис итте. Мәүлиха аңа җиде ят түгел, күрше кызы гына. Балаларга кирәк чакта күз-колак булу дисенме, яккан мунчаларына чакыру дисенме, гел бергә. Күршеләр моңа кадәр яхшы яшәделәр. Мөхәммәтзакир ага да, Мәүлиханың әтисе, яхшы кеше. Гражданнар сугышы инвалиды. Бик төпле акыллы карт. Күрше кызы яшь булса да ана сер сыя, Әдибә белән алар ничәмә-ничә кичләр җеп эрләп, бияләй-оекбаш бәйләп уздырдылар.

Кызның башы аска иелгән. Аның кайнар күз яшьләре белән томаланган күзләре идән ярыгын эзли. Менә шушында идән, җир ярылса, ул шунда төшеп китәр иде. Ярыкка төшеп китәр иде дә, хөсет Фәтхетдин белән бергә башкаларны да күрмәс иде. Мине алып китсәләр карт әни, гарип әти ничек яшәрләр дип уйлады ул. Мәхмүт абыйсының үле хәбәре килде. Олы абыйсының бернинди хәбәре дә юк. Әдибә күршесенең башына төшкән бу авырлыкны бүлеп алырдай утырганда, әтисе Кашафетдиннең әйткән сүзләрен исенә төшерде: "Кызым, кешеләргә яхшылык эшләмә, аның сиңа явызлык булып кайтуы бар. Кеше каргышын аласың, рәнҗеш-үпкә сүзләре ишетәсең килмәсә, син бары тик начарлык кына эшләмә",—дигән иде. Кара әле, әтисе ничек дөрес әйткән бит. Әдибәнең уйларын, залдагы авыр тынлыкны районнан килгән вәкил бозды. Ул иннәрен йөк басып торгандай, авырлык белән генә торды. Бик озак залны сөзеп, кешеләргә сынап карап торды. Аннан соң һәр сүзен өзеп-өзеп, һәр сүзе баш миен бораулап керерлек итеп, сеңдереп кенә ярып салды:

—Син, Фәтхетдин ага, үзеңне бик зур батырлык эшләдем дип уйлыйсыңдыр инде. Мин сезнең авыл өчен ят, килгән кеше. Сез бит бер авылдан, бертугандай кешеләр. Ярый, сиңа Мәүлиха яшьлеге белән ышанып, гаиләң ачка интеккәч, икмәк биргән. Син аны алгансың, ашагансың. Шушы авыр елларда гаиләң исән калган. Ә син беләсенме, башка авылларда кешеләр гаиләләре белән ачка үләләр. Кан чире дигән әйберне ишеткәнсездер? Кар астында калган башакларны җыеп, шуның бөртеген ашаган кешеләр агуланып, кан косып үләләр. Сезнең авыл андый афәтне күрмәгән! Синең гаиләң исән калган өчен шушы баланың башын төрмәдә черетикмени? Сигез килограмм бөртекне аны тычкан да ашап бетерә, чөнки ул җан ияләренең авызларын бәйләп куеп булмый. Сугыш елы, ачлык дип тормыйлар, кумак-тычканның да җан асрасы бар. Алай ярамый, Фәтхетдин абый, икмәк ашаган авызың белән кеше башын ашама. Син бит олы кеше, ярамый алай...

Фәтхетдин арты өзелгән таракан кебек әрле-бирле килде. Төртеп кенә тишкән кебек бәләкәй күзләре урыныннан чыгып китәрдәй булып йөгереште, күзләрен челт-мелт йомгалап, тамагын кырган булды:

—Мин бит, теге... ни бит... Дөреслек өчен генә, калхуз малы әрәм-шәрәм ителмәсен дип кенә әйткән идем.

Вәкил аңа каш астыннан шундый нәфрәт белән карады ки, әгәр нәфрәттән генә үлә торган хәл булса, куркак Фәтхетдин әллә кайчан янып көл булыр иде. Вәкилнең карашында боз салкыны булса, тавышында тимер чыңнары янгырады.

—Утыр, ага, әләк-чәләк белән моннан ары йөрмә. Кеше башы ашыйм дип, үз башыңны югалта күрмә...

Клуб эчендәге халык җинел сулап куйды. Әйтерсең лә, ишек-тәрәзәләрне ачып, клуб эченә ургылып саф һава керде. Бугазны буып торган авыр тынлык югалды, сулыш алуы иркенәйде. Авылдашлар бер-берсе белән сөйләшә, гапләшә башладылар. Әдибә дә үзен читлектән котылган кош кебек хис итте.

Бар бит дөньяда яхшы кешеләр. Бар. Шундыйлар тотып торадыр бу

дөньяны. Хәзер вәкилнең үзенә генә авырлык килмәсен инде.

Карангы төндә дә кояш чыгарырдай кешеләр була икән.

Тормышынны якты нурга күмәрдәй кешеләр була.

Мәүлиханың язмышы хәл ителгәндә нәкъ менә шундый яхшы кешенең алар авылында булуын әйт син. Бәхете бар икән баланың. Әгәр шушы минутта теге кырык беренче елдагы пулнамуч булса. Ул хакта уйлавы да куркыныч.

Мәүлиха вәкил чыгышыннан калкынып куйды. Озак вакытлар суга тилмереп утырып, тәмам шинеп беткән гөл, яңгырдан соң күтәрелеп киткән кебек, кыз да күтәрелде. Көз алдында аның салынып төшкән инсәләре турайды, башы горур калыкты, үзен олыгаеп киткәндәй хис итте, бит алмалары кызарып чыкты.

Ярый әле җирдә районнан килгән вәкил кебек акыллы башлар бар, юкса дөнья әллә кайчан бетәр иде...

Бу хәлне авыл кешеләре эчләренә генә салып куйдылар. Күп сөйләшергә, уйлаган һәр уенны кешегә белдерергә ярамаган вакыт иде.

Сугыш башланыр алдыннан гына шушы Фәтхетдин Сәләхетдиннең башын ашаган иде бит. Ындыр табагында ашлык сукканда ул каяндыр очып килгән ап-ак казларга карап:

—Карагыз әле, кара, аклар килә,—дигән. Эченә бернинди мәгънә салынмаган берничә сүз. Шул төнне үк, район үзәгеннән шактый ерак, тып-тыныч саналган, телефоны-ние булмаган авылдагы шушы хәл район кешеләренә мәгълүм була. Төн уртасында авылга районнан атка атланган кешеләр килеп:

—Нәрсә, Сәләхетдин, акларны сагындыңмыни? Контра. Белербез без сине нишләтергә. Акларны сагынган...—дип, кыйный-кыйный алып киткәннәр. Шул китүдән Сәләхетдин юкка чыкты. Хатыны бер көтү баласы белән калды. Ана авылда "контр хатыны" дип кенә җиппәрделәр, үзенең дә, балаларының да күзен ачырмадылар. Балакайлар урамга уйнарга да чыга алмады, аларны куып кертә торган булдылар. Сәләхетдин хатыны Жамал кешеләргә күтәрелеп карамас, гел сөйләшмәс, көлмәс булды. Авылда нинди кара эш бар, ана куштылар. Шаярып әйткән берничә сүз Сәләхетдиннең үзен, хатынын, балаларын харап итте.

Ходай хагыннан-нахагыннан сакласын.

Әләкчеләрдән, куштаннардан, хөсетлектән сакласын...

* * *

Әдибә сискәнеп китте, әллә инде төшләнеп ята. Күзләрен бер ачты, бер йомды. Аның аяк очында бер йомгак кебек йомарланып, бераз гына бөкрәя төшкән, Зәкия утыра. Әдибә аны зур күзләреннән генә таныды. Элеккеге чәчәк тажы кебек чибәр кыздан әнә шул монсу күзләр генә калган. Ул күршесенең уянып, бик гаҗәпләнеп ана карап торуын күреп, нәкъ элеккечә көмеш акча сибеп җибәргән кебек зенгелдәтеп, ап-ак тешләрен күрсәтеп көлеп җибәрде.

—Уяндыңмы?—диде ул, моның төш түгел, өн икәнен раслагандай.

Әдибәнең аптыраулы карашыннан тагын рәхәтләнеп көлде.

Әдибә төш белән өнне аерырлык булып исенә килгәч кенә:

—Бик аз, шулай да бик тәмле итеп йокладың. Улың да мес-мес килеп йоклый. Мин әйләнеп кайтканчы өйне малайлар белән тутыргансың бит, әй,—дип, Әдибәне яратып сөеп куйды.

Зәкия, әйтерсең лә Әдибә белән ул йокыга киткәнче генә сөйләшеп утырган, уянгач, өзелеп калган сүзне ялгап алып китте. Әдибәнең аптыраулы карашына игътибар да итмичә һаман сөйләнә дә сөйләнә. Әдибә сораулар биреп, кан саркып торган җәрәхәтен яңартмасын ди торгандыр. Күзгатамы

соң инде. Аның үзенең дә бүген караңгы уйларга бирелеп, кара көннәр турында исенә төшерәсе килми. Бүген гел көләсе, гел елмаясы, эчендәге шатлыгы белән уртаклашасы килеп тора. Ә шатлыгы чыннан да зур. Әйе, бала белән өй тутырасы килә аның. Солтаны сугышта чакта ул төнгә керсә айга, суга төшсә агымсуга карап гел бер теләк теләде:

—Солтаным исән-имин генә әйләнеп кайтсын да, зур өстәл әйләнәсен тутырып утырырлык балаларым күп булсын иде.

Теләге кабул булды. Солтаны исән-имин сугыштан әйләнеп кайтты. Әтисе армиягә киткәндә карында гына калган Гарифҗаны янында менә тагын ике малай. Уллары берсеннән-берсе таза, берсеннән-берсе матур. Әни кешегә бәхетле булу өчен тагын ни кирәк.

Зәкия аның уллары турында сөйли икән:

- Әле су буена төшкән идем. Синекеләр ыштан балакларын бәйләп балык сөзә. Икенчесен күргәнем юк иде бит әле. Хәер, беренчесен дә тугач кына күргән килеш инде. Әтиләренә охшатып таныдым. Сез Әдибә малайларымы дигән идем, юк, без Солтан малайлары диләр. Кечесен әйтәм, үзе кәтүк хәтле генә, чєтердәп тора. Анысы бигрәк матур, кызлар кебек. Теле дә бигрәк иртә ачылган. Чыннан да Солтан малае булган анысы. Әтисе ярата торгандыр. Олысы үзе юкта туды бит, анысын чит итмәдеме, какмадымы диюем?

Әдибә эндәшмәде. Бу сүзләр аның хәтер яраларын яңартты.

Какмадымы соң... Олы улы белән Солтан арасында беркемгә аңлатып булмаслык мөнәсәбәт урнашты. Әтисе сугыштан кайтканда Гарифҗанга җиде яшь иде. Әнисе белән генә торып өйрәнгән малай әтисен чит итте. Солтанга да улы ят иде. Мондый заманда әтиле булу зур байлык булса да, Гарифҗан әтисеннән ятсынды. Тора-бара ияләнсәләр дә, араларында салкынлык калды.

Күрешми торган җиде ел араларына боз булып ятты.

Имеш, бала әтисе юкта туса, иң элек әтисенең күлмәгенә төрәләр, шулай иткәндә баланы ир какмый икән. Бу хакта ул соңрак белде. Бала тапканда ни әйтүче, ни өйрәтүче булмады.

Сугыштан Солтан төп йортка түгел, нишләптер әнисе янында яшәгән олы абыйсы Гәрәйләр өенә кайтты. Бу хакта аңа чатнама суык кышкы төндә Фирдәүсә килеп әйтте.

—Җинги, сөенче, абзыкай кайтты.

Сөенче алучыга дип Әдибәнең матча ярыгына кыстырып куйган йөзлек акчасы бар иде. Ул аны ялт кына алып, Фирдәүсәгә бирде. Ул гына аз сыман тоелды, муенынна зәңгәр төймәсен дә салды.

—Менә сиңа акча, менә сиңа төймә, рәхәтен күр, рәхмәт, туганым.

Аның соңгы сүзләрен Фирдәүсә ишетмәде дә, ул инде кабат өйләренә чапкан иде.

Әдибә таралып йоклап яткан улын паласка төрде дә килендәшләренә чапты. Шатлыгы чиксез иде, иренең туры өйгә кайтмыйча килендәшләренә кайтуы да сагайтмады аны. Солтан бит мине тау башында тора дип белә, мин бит күчендем, шуңа күрә Гәрәйләргә кайткандыр, дип үз-үзен юатты. Әле Солтанның улын күргәне юк бит. Аның тизрәк улын әтисенә күрсәтәсе, шатлыгы белән уртаклашасы, ире белән бергә сөенәсе килде. Йоклаган баланың салкынга чыгасы килмәде, киреләнде, шыңшыды.

—Әтиең кайткан бит, улым, әтиең кайткан! Сине күргәч шаккатыр, минем улым нинди дәү үскән дияр.

Ир хатынын да, җиде яшькә җиткән зур улын да, өзелеп төшеп кочаклап алмады. Салкын иде аның кочагы. Җиде ел чит-ят җирләрдә йөреп ятсынган иде ир хатыныннан. Башта армиядә, аннан сугышта булды. Сугыш беткәч тә Новосибирск якларында әсирләр саклады ул. Өстендә яхшы шинель.

Башында бик килешле бүрек. Аякларында яхшы хром итекләр. Ул перчаткаларын гына ни әйтерсен—шыгырдап торган куннән. Озын буйлы, кап-кара чәчле, зур кара күзле ир бик чибәр, бик мәһабәт иде. Ул чит җирләрдә озак йөреп гаиләдән бизгән, солдаткалар кочагында булгалаган, өйдә хатыны барын оныта башлаган, иләсләнгән иде. Ярый әле күнелен Новосибирскида калдырып кайткан Солтанны һавадан җиргә төшерергә әнисе булды.

—Улым,—диде Мөгаллимә карчык.—Мин сугышка лачын кебек биш баламны озаттым. Менә, Ходайга шөкер, бишегездән хет сине күрү бәхетенә ирештем. Дүрт абыенның гүргә сыймас гәүдәләрен дә күрмәдем, кара кәгазьләрен генә алдым. Читкә чыгарып җибәреп сине дә югалтасым юк. Биш ояга ничә ятим калды. Әниләрен санап та тормыйм, әле балалар яшь. Син шул шәһит киткән абыйларынның ятим балалары һәм үзеңнең улың бәхетенә исән калгансыңдыр, әгәр чыгып китсән, әтиле килеш улынны ятим итсән, бәхиллегем юк. Бер-бер фикергә килгәнче башта ныклап уйла, соңыннан үкенерлек булмасын.

Күнеле алгысыган ир шым булды. Кая ул, әнисенең сүзе анын өчен закон! Үз улын тынлату Ак әби өчен дә берни түгел иде. Ул авыл ирләрен гел йөгәнләп, тынлатып торды.

Сугыш бетеп бер елмы, икеме узгандыр, авылга көтмәгәндә, сугышта алган яраларыннан тәмам бетеренгән, хастаханәләрдә ята-ята ябыгып, кечерәеп калган түбән очтагы Әхәт кайтты. Ул сугышка кадәр дә бик таза ир түгел иде.Үзе юаш, күзгә бәрелеп торучылардан түгел. Башта Әхәт күзгә-башка күренмәде. Күпмедер вакыттан соң сөт эчеп, бәрәнге ашап, көрәеп, матураеп киткән шул ир Мөгаллимә карчыкларга килеп керде. Сүзне боргалап-сыргалап тормыйча гына турыдан ярып салды:

—Ак Әби,—диде ул, кулларын уа-уа,—минем Гөлнисаны теге бригадир булып эшләгән, чулак Шагали белән чуалган дип сөйлиләр. Урамга чыгар хәлем юк, шуның белән төрттереп җанымны кыйныйлар. Балаларны ятим итәсе дә килми, түзәр чамам да юк. Әллә аерылыйм микән?

—Әхәт, син минем дүртенче улым белән бер елгы, шуна күрә сине улым кебек якын күрәм,—диде Ак Әби, бераз уйланып торгач.—Аерылу озак эш түгел ул, җаның тартмаса аерылырсың да, тик башта уйлап кара. Гөлниса акылсыз бала түгел, юкка-барга вакланмас. Син аннан кайтып: " Карчык, бу гарасатта балаларны ничек исән алып кала алдың?"—дип сора. Ирләрен көтеп ала алмыйча балаларын җирләгән, үзләре дә гүр иясе булган хатыннар бар. Авылларда халык ачтан кырылды. Синең дә минем улымныкы кебек өч балаң бар. Гөлниса уйламыйча эш эшләмәс, балалары хакына абынса гына инде, атын синең кулда чакта аксамасын. Кеше сүзенә карама, кеше сүзе кеше үтерә, барысын да онытта, хатының белән балаларына куанып яшә.

Тынлады Әхәт Мөгаллимә карчыкның сүзен. Әнә хәзер Гөлнисасы белән ничек матур яшиләр.

Солтан ничек итеп әнисе сүзеннән чыксын ди. Әйе, ул авылга әнисен, туганнарын тиз генә күреп, янадан Новосибирск якларына чыгып китү уе белән кайтты. Шәм кебек төз гәүдәле, чибәр Солтанга авыл саен, шәһәр саен яшь кыз табылыр иде. Хәзер гарип булмаган ирләр санга сирәк кенә. Ә Солтан тап-таза, әз-мәз яраларын санамаганда, таш кисәрлек, җигелеп сабан сөрерлек. Ә яралар төзәлә ул, сөяге булса ите дә куна. Солтанның сөякләре үз урынында...

Әнисе белән сөйләшкәннән соң күнеле утырган кебек булса да ир алга таба хатынын утларга салгалады. Вакыты шундый иде шул. Яшь, чибәр һәм сәламәт иргә авылда кызыгучылар күп булды. Үз ишләрен сугышта югалткан кызлар тәмам тулышкан, дәртләрен кая куярга белми йөриләр.

Алар янында бер-ике бала белән генә калган яшь хатыннар да арба-тәртәгә, йөгәнгә иярләштерелмәгән шәпле яшь ат кебек тупырдап торалар. Аларның сарыф ителмәгән дәрт-дәрманнары аяк атлап йөрүләренә чыккан. Карашлары көйдереп ала. Йөргәндә табан асларыннан ут чыга. Үзләре дә ут. Кагылсаң—янасыңны көт тә тор. Көне буе авыр эш башкарып, бөтен хәлне алырдай эштән онытылып торсалар да, озын төннәр яшь хатыннарныкы иде. Менә шунда инде алар үзләренең әче язмышларын уйлап, кайнар күз яшьләренә ирек бирәләр. Шунда алар үзләрен тол калдырган, бала табу бәхетеннән, ир назыннан мәхрүм иткән Гитлерны каргыйлар. Анысы бик ерак, аның ни кыяфәттә икәнен дә күргәннәре юк. Исән кайткан ир-егетләр менә генә. Аларның газизләре әллә кайда башларын салды, ә монда кемнәрнеңдер сөйгәннәре тап-таза кайткан, хатыны янында бөркет кебек йөри. Ирләре сугыштан кайткан хатыннарга толлар ниндидер яшерен үпкә саклаган кебек, кырын карый башладылар. Парлыларның язмышларына шундый бәхет төшкән дә, нишләп алар шундый бәхетсез соң? Толлар җае чыккан саен парлыларны кимсетергә тырыштылар, аларның бәхетләрен күпсенделәр.

Авылның Җәмилә дигән солдаткасы Әдибәнең дә тормышына кара таракан булып төште. Җәмилә аларның сугышка кадәр туган уллары барлыгын белә. Икенчегә авырлы булгач та һаман Солтан тирәсендә бөтерелүен дәвам итте. Боларны Әдибә үз күзләре белән күрмәсә дә тоемлап, сизенеп йөрде. Белми калмасын әле бу дигәндәй, "яхшы" кешеләр бу хакта ана җиткерә тордылар. Ә ул түзде, сабыр итте. Җай көтте. Җае үзеннән-үзе килеп чыкты. Бер көнне ул суга төшеп бара иде. Чишмә биек тау астында. Менә шул таудан ул төшә, ә теге чибәркәй менеп килә. Аны күреп Әдибә адымын акрынайтты, оекбашларын рәтләгәндәй итеп, көндәшен көтеп алды. Тегесенең бер нәрсәдән хәбәре юк, арт якларын уйната-уйната кайтып килә. Чибәр иде Җәмилә. Бала-чагасы юк, каенана-каената белән тормый. Бер башы да, бер бите, дигәндәй. Үзен карап, төзәтенеп-ясанып кына тора. Ул иреннән бала таба алмый калды. Яшь хатынның авыл кибетендәге сатучы кыз белән дә борчаклары пешә, кибеткә кайткан бөтен әйберне иң элек кибетче белән Җәмилә карый, кирәклеләрен бүлешәләр. Авылда беркемдә дә юк чагында үкчәле түфлиләрне ул киде, итәк, пинжәк ише әйберләр анда булды. Күлмәкләрен алыштырып кына тора. Әле Солтан белән чуала башлагач бигрәк көязләнеп йөри башлады. Күлмәк кисәң ки аклысын, ука-чуклы, затлысын, диләр. Бу сүзләрне кайсыдыр шаяны әнә шушы чибәркәйгә атап әйткән дә инде. Көяз Җәмиләгә күлмәкне апасы Мөнҗия тегә. Шуңа күрә аныкы кебек күлмәк беркемдә дә юк, укасы да, чугы да була. Чулпысы да әллә ничә кат. Урамнан узганын әллә каян белеп була, чулпыларын чеңләтеп, кәс-кәс басып йөри ул.

"Көязләндерермен әле мин сине,— дип усалланып уйлады Әдибә,—арт ягына ут ягармын. Ир бирмәк, җан бирмәк дигәнне ишеткәнең юктыр синең. Ишетмәсәң – күрерсең! Укалы күлмәк кидем дигәч тә Солтанны ала алмассың".

Әдибә авылда усал хатыннардан саналмый, кеше белән ызгышканы-талашканы юк. Үзенекен бирә торганнардан да түгел. Кыз булып буйга җиткәч тә абруен саклый белде. Җырга осталыгы өчен клубта урыны һәрвакыт түрдә булды. Менә шушындый, беренче карашка фәрештәдәй хатыннан Җәмилә этлек көтмәгән идеме— белмәссең. Ләкин ул ныклы адымнар белән көндәшенә таба якынлашты. Юк инде, чибәркәй, сүз минем улларымның атасы турында барганда, кәнфитләнеп булмас,—дигәндәй, һаман үз-үзен юатырга, гамәлен акларга тырышты Әдибә. Кеше бакчасына кермәслек итеп ант иттерергә теләде.

Хатынның йөрәге читлегеннән чыгардай булып тыпырчынды. Еш-еш

сулаганын, бик нык дулкынланганын күрергә үк була иде хәтта, ләкин Җәмилә сизенмәде. Әдибә як-ягына карады. Ни су буенда, ни тау астында бер кеше дә күренми. Елганың югары башында ук итәкләрен кыстырып, елга эченә үк кереп баскан килеш ике хатын кер чайкый. Аларның исә уртак ирне бүлешүче ике хатында эшләре юк. Бик аулак чак туры килде. Моннан да унайлырак вакыт та, урын да башка булмаячак.

Их, җыры да бар бит әле аның. Ничек кенә җырлыйлар соң әле?

Кара урманга кергәндә,
Атың куркак булмасын.
Атың куркак берни түгел,
Ярың уртак булмасын...

Юк инде, Әдибә уртак яр белән яшәмәс, биздерер ул Җәмиләне Солтаныннан.

Мөгаллимәнең килене булмасам, исемем Әдибә булмасын дигән иде. Барыбер Солтанны үзенеке итте. Хәзер ирен Җәмиләгә биреп исемен бозаргамы? Юк.

Җәмилә таудан менеп житкәндә, боргаланып, көндәшен күрмәмешкә салышып кына узып китмәкче иде, Әдибә аның каршысына чыкты. Әкрен генә килде дә, Җәмиләнең ике аягына басып, күкрәгенә китереп төртте. Бар ачуын шушы сынар кулга салгангамы, төртү бик каты килеп чыкты, тегесе нәрсә булганын анларга өлгергәнче, тигезлеген югалтып, аягында басып кала алмады, сулы чиләкләре-ниләре белән тау астына мәтәлде.

Әдибә, берни булмагандай, чишмәгә төшеп китте. Җырлый-җырлый чиләкләрен тутырып су алды да, як-ягына, һаман мүкәләп өс-башын рәтләп маташкан Җәмиләгә карамыйча гына кайтып китте.

Ай-ли, Җәмилә,
Җәй көннәре ямьле лә...

Ачуым юк минем сиңа, Җәмилә, юлыма гына чыкма.

Юлыма гына чыкма...

Су буенда булган әлеге хәл турында бер кешегә ләм-мим бер сүз әйтмәде. Җәмиләнең үзенә исә бу хакта сөйләп йөрү бөтенләй кулай түгел иде. Шуна күрә авылда бу хакта сүз-мазар чыкмады. Ужымга кергән хатын ничек итеп өч бәбәй итәкле күлмәге, чигешле ак алъяпкычы, штиблетлары, шулар өстенә сулы чиләкләре белән тау астына мәтәлеп төшеп, балчыкка буялып, тезләрен канатып бетерүләре хакында мактанып сөйли алмый бит инде.

Ул да төшеп калганнардан түгел. Юашлардан да саналмый. Башка вакыт булса сикереп торып, рәнжетүчесенең чәченә ябышыр иде дә бит, тик үз гонаһын үзе белмимени?! Эчтән тынды Җәмилә. Шул вакыйганы уйласа Әдибәнең хәзер дә көләсе килә, үз батырлыгына үзе шакката. Каян башына килгән дә, каян көч алган диген син! Кешегә сөйләсән, юаш хатынның кыланышын үз күзләре белән күрмәгәч, ышанмаслар да. Җәмилә аннан бер башка калку да, тазарак та. Аннан соң балта остасы Әгъзәм кызының тамагы ипидән өзелгәне юк. Алар нәселләре белән шундый. Кеше өчен бил бөкмәсләр, кирәкмәгән җирдә сынып су да эчмәсләр, колхозга батырып эшләмәсләр. Әтиләре Әгъзәм, адәм сизмәс, эт өрмәс—астыртын жан, мыштым гына күрше өлкә ягында кемгә өй сала, кемгә мунча житкерә. Акчасы бара, тамагы тук, өйгә балаларга да алып кайта. Үзе ни элек, ни хәзер колхозга рәхәт күрсәткән кеше түгел. Икмәккә дә тилмермиләр, акчалары да өзелеп тормый. Кызлары да өстән ямап, астан кисеп йөри. Кеше бакчасына кереп, җәзасыз гына калмакчы. Апасы Мөнҗия Газизҗанны Хәтимәдән тартып алмадымыни? Алды. Ике кыз белән

калдымы Хәтимә? Калды. Баскан саен бакыр булмаган кебек, һәр хатын да Хәтимә түгел. Монысына да ир кирәк булган. Алмый гына тор әле. Ачның күзе икмәктә, тукның күзе хикмәттәме?! Тамагы туйгач Жәмилә маена чыдый алмый башлаган, чит бакчага кермәкче иде. Әдибә аны тиз акылга утыртты, ничек кенә таудан тәгәрәтте әле. Икенче юлы хатынлы ирләрне аздырганда уйлар. Бу юлы кайдан мәтәлермен микән дияр.

Шул вакыттан соң Жәмилә Ташкент ягындагы апалары янына чыгып китте. Әдибәнең үз бәхетен үз кулы белән читләргә бирә торганнардан түгел икәненә ышангач өметен өзгәндер инде. Солтанның да гаиләсен ташларга исәбе юк, ул яңа йорт җиткерергә ниятләп, бура бурата башлады. Жәмилә үз өметенең кысыр хәсрәт икәнен, бу сукмакта эше пешмәслеген аңлады. Авылдан чыгып китте дә югалды. Кай вакытлардан бирле кайтып күренгәне юк әле.

Исән йөрсен. Минем сукмакка гына чыкмасын, ди Әдибә.

Берәү дә сизми калды дип уйласа да, каенанасы белеп, күреп йөргән ахры. Беркөнне ул:

—Киленкәем, түз, балалар хакына сабыр бул,—диде.—Ирең сугыштан әйләнеп кайткан икән, бу—бәхет. Үзең беләсең, мондый бәхет авылдагы ничә хатынның яртысына да тәтемәде. Биш килендәштән бер син ир белән торасың. Дөрес, килендәшләрең белән араң яхшы. Булышырга дигәндә авырыксынмыйсың, ашыңнан калдырмыйсың. Монысы өчен рәхмәт. Мин шәһит киткән улларым өчен бер өзелсәм, ятим киленнәрем, аларның ятим балалары өчен икенче өзеләм. Син язмышыңны аларныкы белән чагыштырып кара. Үзеңне бәхетсез дип әйтә алмассың. Сакла бәхетеңне. Ычкындырма син аны үз кулыңнан. Әгәр Солтан сине ташласа, минем аңа бәхиллегем юк. Минем хәер-догамнан башка әллә кая китә алмас, рәнҗешем тотар. Солтан минем сүздән чыгуын-чыкмас, калганы—синең кулда.

Әллә каенанасы Солтанның тагын берәр эшен белеп сөйләнде, әллә сүз шул Жәмилә турында гына барды, Әдибә аңлап та бетермәде. Ирнең кайда йөргәнен иң соңыннан хатыны белер ди. Әдибәгә Солтанның Жәмилә белән булган хәлләре генә мәгълүм иде, башкасын сизмәде.

* * *

Әдибәнең чуалган уйларын тагын Зәкия бүлде.

—Кара әле, туганым, минем дә улым синең Гарифҗаның кадәр булыр иде бит, әйеме?

Әйе. Әдибә Гарифҗанын сугыш башланыр алдыннан тапты.

Зәкия һаман Әдибәнең аяк очында утыра. Аның күзләреннән аккан кайнар күз яшьләре тезенә капланган итәген чылатып бетергән. Үзе дога кебек шигырь укый!

> Хәлең ничек?—диючем юк,
> Сыйпап йомшак чәчемнән.
> Миндәй сары сагышлылар
> Җиргә күпме чәчелгән.

—Әллә шигырьләр дә язасыңмы, Зәкия?

—Юк ла, кеше язганны гына укыйм. Тегендә бит төрле кеше бар иде: талантлылары да, эт кебек явызлары да... Нинди генә булсалар да, бәхетсезләр инде, Әдибә. Бәхетле хатын-кыз анда эләкми. Менә шуларның кайсысыннан нәрсә өйрәнеп каласың инде. Күп нәрсәгә өйрәтәләр... Сина сөйләсәм моннан ары йокың йокы, ашың аш булмас. Белмәвең хәерле. Мин бары тик бер нәрсә белән генә исән калдым. Беләсеңме, Әдибә, гел улымны гына уйладым. Аннан әти белән әнинең алларына тезләнеп бәхиллекләрен алу уе яшәтте мине. Ә алар юк. Алар минем хәсрәтемне

күтәрә алмаганнар. Син минем баламны үтергәнемә ышандыңмы?

—Юк, Зәкия, ана мин генә түгел, беркем дә ышанмады.

Яратусыз яралган бала, яратып көтеп тормаганнарын белеп, бу дөньяга килгәнче үк китеп барган, дип уйлады Әдибә. Ләкин уйлаган уен туганына әйтмәде. Болай да яралы йөрәген тагын җәрәхәтләмәскә булды.

—Балам исән туса мин аны беркемнән дә рәнҗеттермәгән булыр идем. Әти белән әни дә яшәрләр иде әле. Мин аларны вакытсыз кара гүргә керттем. Кайткач булса да үземнең гаепсез икәнемне әйтермен дигән идем. Хәзер кемгә кирәк инде ул дөреслек. Буласы булган, буявы—унган. Балам да, әти-әни дә юк. Ярый әле бу хакта Закир белмәде. Аның газиз башкайлары кайда ятадыр инде.

Юлда кайтуым төрмәдә утырганнан да авыррак булды. Кайтып керсәм, өйнең тәрәзәләре кагылган, ишектә йозак. Тагын үзәкләрем өзелеп куйды.

Күңел елый... Җан телгәләнә...

Аккан сулар кебек никадәрле гомер узган...

Кыендыр ул көтәр кешең булмаса.

Әдибәнең Зәкияне юатасы, аңа берсеннән-берсе матур, җылы сүзләр әйтәсе килде, тик матур сүзләр тел төбендә калды.

—Син кайчан кайттың соң, Зәкия?

—Ике көн инде.

—Соң, тәрәзәләреңдә кичә генә такта иде бит әле.

—Мин аларны бүген алдым. Ике төн, ике көн өйдән чыкмый елап яттым. Төнлә белән Сарашлыдан су ташып, өемне юып чыгардым. Әти белән әнинең кабере янына барып, озаклап утырдым. Бәхиллек сорадым. Ничек уйлыйсың, алар миңа бәхил микән?

—Ата-анага баланың начары юк диләр бит, Зәкия...

— Әтинең теге вакытта миңа әйткән сүзләре һаман колак төбендә тора: "Мондый хурлыкны күргәнче, үзеңнең үле гәүдәңне күрү җиңелрәк булыр иде",—диде бит әти. Гөнаһым зур минем, туганым...

Гөнаһларны кемнәр үлчәгән?!

Бала бавыр ите...

Баласын кичермәгән әти-әни булмас...

—Сиңа бит әле утыз да тулмаган. Кияүгә чыгарсың, балалар табарсың. Вакыт дәвалар әле. Сабыр бул, Зәкия!

—Кияү миңа түгел, яшь кызларга да юк бит. Китәм мин, туганым, күз күрмәгән якка, этләр олаккан җиргә чыгып китәм. Барысын да онытасым килә. Авылда кала алмыйм инде мин.

—Соң, шул этләр олаккан яктан кайттың түгелме?

—Әйе шул,—диде дә, Зәкия үз сүзеннән үзе кызык табып, рәхәтләнеп көлә башлады. Бу минутларда ул элеккеге ваемсыз, үтә сөйкемле Зәкия иде.—Ә син, туганым, һаман да шулай җор телле, уен сүзле икәнсең. Элек мин синең җырлавыңа, аннан да битәр матур итеп, сырлый-сырлый сөйли белүеңә соклана идем. Синең кебек җанга май сөртеп сөйли белүче юк авылда. Һаман шулай шигырь-җыр сүзләре кыстырып сөйлисеңме, һаман да җырлыйсыңмы?

—Менә бу сыбызгы борыннарны йоклатканда гына җырлыйм. Алар минем үзләре әртист-җырчы, үзләре тыңлаучы. Хәзер кечкә уеннарга төшүләр бетте бит инде.

—Бәхетлеме син, Әдибә?

Әдибә шактый вакыт дәшмәде. Бераз тын утыргач кына:

—Андый сүзне кычкырып әйтмиләр, туганым, яманның колагы озын, тиз ишетә, ишетә дә күз тия,—дип куйды. Үзе шаярам гына дигән кебек, рәхәт итеп елмайды.

Ничә еллар бер кешегә ачыла алмыйча җанын кыйнап яшәгән Зәкиянең

туганына сөйләр сүзе жыелган иде. Менә, ниһаять, туган авылында, туганы тиешле кеше янында ул. Әдибә аны аңлап, ышанып карый. Зәкия сөйләде дә сөйләде. Бер елады, бер тыелып кына, тавышын күтәрми генә, жырлады.

Бу дөньялар әче миләш...

Шулай да ул туганы янында үзен бәхетлерәк хис итте. Үзен кирәкле кеше итеп тойды. Аңа ышаналар, аны яраталар, аны сагынып торганнар бит.

Бу дөньялар әче миләш...

* * *

Солтан өйләр ут алгач кына, арып-талып кайтып керде. Анда да кайтмаган булыр иде әле, күрше малае күреп, сөенче алган. Әти кеше кайтып керү белән:

—Улым,—дип, бала өстенә иелде. Бала да якын кешесен күреп таныгандай кыймылдап, мекердәп куйды, авызларын очлайтып чапылдатты, ашарга әнисенең күкрәген эзләде, төрелгән чүпрәгеннән кулларын чыгарды.

—Кара, кара, минем улымның карыны ачкан,—дип куанды Солтан. Баланың мендәрен, чүпрәген рәтләгәндәй итте. Кулына бер алырга, бер алмаска белмәде. Бала шундый кечкенә тоелды аңа, көрәктәй куллары белән тотса, улы уалып китәр кебек тоелды.

—Бала күрмәгән кеше кебек каушатып та жибәрде әле,—дигән булды, үзенең чыннан да каушавын, дулкынлануын яшерергә теләп. Бишек янында таптанды.

Әдибә әле иренә, әле бала бишеге янында кайнашкан улларына яратып карады. Уллары кечкенә энеләренең кемгә охшаган икәнлеген тикшерә.

- Борыны минеке кебек,—диде Гарифжан.

Закиржан аның сүзен жөпләп баш какты.

—Ы-ы. Минеке дә.

—Юк, минеке кебек кенә.

—Ату сәсе минеке,—диде Закиржан, бирешәсе килмичә.

—Әһе,—диде Гарифжан бүтән бәхәсләшәсе килмәгәннән генә.

Малайлар шунда ук килешеп, энеләренең әле кулларын, әле аякларын тотып карадылар, шулай бәләкәй булуына аптырадылар, аның белән уйнап та булмаячагын уйлап борчылдылар. Яңа туган энеләренә әбиләре пешергән коймакны бик ашатасылары килде, әниләре генә рөхсәт итмәде.

Әдибә бәхетле иде. Тормышыннан канәгать иде ул.

Яшәү яме—әче миләш тәме, миләш эчләрендә дәва бар.

Әчесе дә, җиләге дә—яшәүдә.

Яшәргә кирәк.

* * *

Авыл күптән йоклый. Тик бер өйдә ут яна. Анда барысын да йоклатып, белгән догалары белән балаларына бәхетле тормыш тели-тели Әдибә улын имезә.



## КАЗАН ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬЛӘРЕБЕЗ

### Сибгат Хәким
*(1911 — 1986)*

**Без Казаннан, Иделдән**

—Сез кайдан?—дип сорыйсыз.
—Без Казаннан, Иделдән.
Идел — эчкән су булыр.
Иделдә иген иккән,
Яшәгән, көнен иткән
Татарстан шул булыр.

—Сез кайдан?—дип сорыйсыз.
—Без Казаннан. Казанны
Идел кичкән—шул белер.
Урамнары ак ташлы,
Җырлый Сәйдәш, Такташны —
Татарстан шул булыр.

### Нури Арслан
*(1912 — 1991)*

**Казан кызы**

Казан кызы, сылуым, иркәм,
Иделдәге акчарлак.
Уйнап очкан акчарлактай
Син барасың уйнаклап ла,
Җилфердәп, вак-вак атлап.

Атлыйсың тиз-тиз генә,
Аякларың төз генә,
Үкчәләрең без генә,
Тимәс микән күз генә...
Үзәкләрем өзелә лә,
Әйтсәнә бер сүз генә.

Үзе чая, үзе тыйнак—
Бер сүз әйтсәң кызара...
Кемнәр генә гашыйк түгел
Безнең матур кызларга ла,
Синең кебек кызларга!

Чибәрләр күп безнең илдә,
Әгәр санап карасаң...
Мин шулай да татар кызын—
Казан кызын яратам ла,
Иркәм, сине яратам.

## Әнвәр Давыдов
*(1919—1968)*

### Казаным

Казаным, Казаным!
Җир йөзендә синнән
Матуррак калалар
Күп алар! Мин беләм
Рим, Парижлар данын...
Күңелем аларның
Берсенә генә дә
Алыштырмас сине,
И минем Казаным!

Казаным, Казаным!
Болгаһың, Болгарың,
Чокырлы юлларың
Тыңлаган Тукайның
Ютәлләп узганын...
Ул бүген бакчада,
Металлга төренеп,
Киләчәкне күзли—
Бу минем Казаным!

Казаным, Казаным!
Яңарган урамың...
Татар һәм рус сүзе
Һәр якта яңгыравын
Мин тыңлап барамын,
Кремль диварын
Сәламләп Иделем
Дулкынын уйната—
Бу минем Казаным!

## Гөлшат Зәйнашева
*(1928—2005)*

### Туган җирем Татарстан

Идел ярына нурлар сибеп,
Матур булып ата бездә таң.
Таң шикелле якты Туган илем,
Бәхет биргән җирем—Татарстан.
Кая гына китеп,
Кайларга бармадым,
Сагынып кайттым Иделем таңнарын.

Биш диңгезгә карап елмайгандай,
Балкый безнең Казан ерактан.
Коры җирне шаулы диңгез итә
Хезмәт сөйгән халкың, Татарстан
Кая гына китеп,
Кайларга бармадым,
Сагынып кайттым Иделем таңнарын.

Күпме җырлар җырлый халкым бүген,
Туган җирем, синең турында.
Мин бәхетле сине сөюемне
Әйтә алсам шушы җырымда.
Кая гына китеп,
Кайларга бармадым,
Сагынып кайттым Иделем таңнарын.

## Рәшит Әхмәтҗан
*(1941—1995)*

***

Артка чигенмәдек дияр идем,
Килде яулар... Без дә чигендек.
Илне сөю гомерлеккә булгач—
Ул чигенү булды бер көнлек.

Җиңеп үлдек, җиңеп исән калдык!
Чигенүләр булмас кабаттан.
Коллар баш күтәргән көннән бирле
Мәңгелеккә азат бу Ватан.

## Разил Вәлиев

### Ватаным

Инде мин ничәнче мәртәбә
Гасырлар китабын актардым.
Күпме яу, сугышлар аркылы
Син җиңеп чыккансың, Ватаным.

Сез кайсы халыктан?—дисәләр,
Батырлар исемен атадым.
Батырлар утларга керделәр
Тик исән булсын, дип, Ватаным.

Илемнең хуҗасы булганга,
Мин җиргә нык басып атладым.
Кешеләр күтәрде Ватанны,
Кешене күтәрде Ватаным.

Мин күрдем, төннәрне таратып,
Дөньяда алсу таң атканын.
Яктыра, аллана җир йөзе...
Таң булып нур сибә Ватаным.

*Әнәс Исхаковка 60 яшь*

# ҖЫР УЛ—ҖАН АЗЫГЫ

Казан дәүләт университетында укыганда без Әнәс белән бер фатирда тордык, лекцияләрдән буш вакытларда еш кына киләчәк хыялларыбыз турында уртаклаша идек. Шул вакытта ул миңа ничек шигырь яза башлавы турында сөйләде. Үсмер чакта ук яза башлаган икән ул шигырьләр. Һәм, ни гаҗәп, беренче шигыре атлар турында була. Атларны ярата үсмер Әнәс. Бервакыт аңа атка атланырга җай чыга. Кулына йөгән ала да иплəп кенә утлап йөргән ат янына килә. Дога укыгандай матур сүзләр тезә-тезә җай гына ат башына йөгән сала. Кулына каеш тезгенне ала, ләкин сикереп атланасы ат кисәктән алга ыргыла, тезгенгә ябышкан малай унбиш-егерме метрлар сөйрәлеп бара. Шул вакыт ат, үзенең гаебен аңлапмы, кисәк туктап кала. Ачуы кабарган Әнәс йөгән тезгене белән атка сыдырырга итә, ләкин куркынып калган атның дерелдәп торган тәнен күреп, ял төбен сыйпарга керешә, ахыр атның башын кочаклый да, гарьләнепме, күз яше белән елап җибәрә. Ни өчен елый? Үзе дә белми. Туры айгыр, үсмерне кызганыпмы, хәленә керепме, башын чайкап куя һәм атлансаң атлан инде дигәндәй, юашланып кала. Әнәс батыраеп китә, атны аңлагандай, очып диярлек ат сыртына менә. Ә тулпар исә тезгенне тотар-тотмас үсмергә гелән игътибар итми, кузгалган җиреннән җилле генә берара әйләнеп килә. Кисәк туктый һәм янә башын чайкап куя. Шушы хәлдән соң, кайта-кайтуга, үсмер Әнәс атлар турында беренче шигырен яза. Шул шигырен ул миңа еш кына ялкынланып сөйли иде. Әнәс, илһамланып, әлгеге шигырьне укыганда, күз алдыма болын буйлап ялларын чайкый-чайкый, күктәге ак болытларны куып җитәрдәй ярсынып чапкан тулпар күз алдына килә иде.

Әнәснең әнә шул шигырен башта район газетасында басалар, ахыр, бик ихтимал, шигъри хыялы аны да университетка алып килгәндер. Минем дә аның кебек язучы булырга хыялланып йөргән чагым иде. Казан дәүләт университетын тәмамлагач та язмыш безне — икебезне дә республикабызның иң матур табигатьле, татарлыкның каймагы булган Азнакайга алып килде. Башта мин шофер, ахыр "Маяк" газетасында журналист булып эшләдем, ә Әнәс яшьләр белән идарә итәргә райкомга эшкә килде. Ләкин кайда гына эшләсәк тә ул да, мин дә җан азыгыбызга тугры булып калдык. Әнәс Исхаков татар шагыйрьләре арасында кабатланмас үзгә бер шагыйрь буларак үз укучыларын тапты. Чөнки ул соңгы елларда Азнакай шәһәре һәм районының хакимият башлыгы булып китсә дә, үсмер чакта башлаган, җан азыгы булган шигърият турында да онытмады, онытмады гына түгел, аның шигырьләренә Г. Сәйфуллина, Ф. Әхмәтшин, Т. Хөсәенов, Т. Кәлимуллин кебек танылган композиторлар көйләр яздылар. Ә җырларны беренче башкаручы — шул ук Азнакай кызы, халык мәхәббәтен казанган Зәйнәп Фәрхетдинова булса, тәүгеләре янында танылган җырчы Фердинанд Сәләхов та бар. Мин белмим, Әнәс минем китапларымны укыйдырмы, вә ләкин мин аның һәр басылып чыккан шигырен тәфсилләп укып чыгам һәм аның шигъриятtә үсә баруын күреп, ихлас күңелдән кинәнәм. Никадәр фидакарьлек, шул ук вакытта нәфислек, моң-аһәң белән тәңгәл килгән хис ташкыны ята Әнәс шигырьләрендә һәм җырга салынган шигырь юлларында! Шигърияттә сәнгати сурәтләүгә ирешү зур талант ул — шагыйрьнең сихри куәте кеше күңеленә бәлзәм булып төшкән йөрәк җылысыдыр, мөгаен. Шагыйрь сүзләренә тәңгәл килгән көй яңгыраганда мин һәрвакыт беренче кояш нурларын күтеп алган кебек тынып калам. Сабакташым Әнәс Исхаковның шигъри юлларында сихри куәт ята һәм анда алтын җепләрдәй чәчәкләргә, чишмәләргә сузылган кояш нурлары чалымлана. Шагыйрьләр картаймыйлар, шагыйрь йөрәге һәрвакыт яшь кала, шагыйрь әүлия дә ул, философ та, шул ук вакытта кеше йөрәгенә

дәрт вә гайрәт бирә алган илаһи көчкә ия зат та кебек тоела миңа. Яман сугыш елларының авырлыгын татыган сабакташлар идек без. Булачак әдипләр – Әнәс Исхаков, мин, Әсрар Галиев, Кадыйр Сибгатуллиннар бер группада укыдык. (Соңгы икесе вафат инде.) Безне, соңгарыбрак югары уку йортына килгән "бәлигъларны", университетның олуг мөгаллимнәре Хатип Госман, Диләрә Тумашева, Мостафа Ногман, Сәгадәт Ибраһимов, Флера Сафиуллина кебек үз эшләренә тугрылыклы булган остазлар укытты. Һәм без аларның йөзләренә кызыллык китерергә тырышмадык. Алар безнең белән горурлана алалар. Мең рәхмәт аларга, безне, авыл балаларын, серле әдәбият дөньясына алып кергәннәре өчен...

Сабакташым Әнәс, ниһаять, Сиңа да алтмыш яшь. Ләкин бит шагыйрьләр картаймый да, якты дөньядан да китмиләр, алар халык күңелендә калалар, аларның рухи хәзинәләре – ак кәгазь битләре мәңгелеккә йөз тота.

**Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН**

---



# Әнәс Исхаков

## И ГОМЕР АГЫШЛАРЫ...

***

**Тауларга менеп, тауларча**
**Офыкларны күзәттек.**
**Яңгыр явар болытларны**
**Сезнең якка озаттык.**
**Аяк-кулларны сыдыртып,**
**Омтылдык биеклеккә.**
**Изге максатлар этәрде**
**Табынган бөеклеккә.**
**Җитте таудан төшәр вакыт.**
**И гомер агышлары...**
**Узган юлда сызылып калды**
**Күңелнең ак эшләре.**
**Таудан төшү җиңел түгел,**
**"Ах, авыр..." дип әйтмичә.**
**Өлкәнлекне узасы бар**
**Күңелне имгәтмичә.**

### Игенченең йөрәге

**Басуда туа, картая,**
**Гомере шулай уза.**
**Бу җиһанда ул берүзе**
**Буразналарга хуҗа.**
**Сабый сымак ул гөнаһсыз,**
**Эше тора хикмәттән,**
**Патшалар да кече кала**
**Ул пешергән икмәктән.**

Туганын күтәп алгандай
Каршылый ел фасылын.
Күңелендә кояш аның
Тәшкил итә асылын;
Күктә янган кояшка да
Иярер кебек кеше:
Ике кояшның җимеше
Гәрәбәдәй бу көшел...
Басуда туа, картая.
Юк, картаймый, яшь кала.
Игенченең йөрәге ул—
Әйтерсең лә яшь бала...

## Ничек йоклап калсын бу җаның...

Тымызык Ыкның уйчан болынында
Йокымсырап калган күл буе.
Томан күтәрелә, әйтерсең лә,
Яңа сауган сөтнең күбеге.
Әллә шашкан, иске Тымытыкның
Әтәчләре ярсый, ярышып.
Әзерләнә челлә уртасында
Серкә очырырга арышы...
Чатыр тауны урап кояш чыга,
Буйый-буйый күкне ал төскә.
Бер ваемсыз изри сабый бала,
Ак мендәрдә күреп ак төшләр.
Көтү чыга басу капкасыннан,
Чыбыркысы шартлый хуҗаның.
Ярты авыл уяу инде таңда,
Ничек йоклап калсын бу җаның?!.
Моңсу җилләр назлар эш кешесен...
Җәй уртасы—гомер уртасы.
Авыл яши икән—без яшибез,
Авыл бит ул—җирнең тоткасы.

## Юкә урманнары

Кыл уртасы җиткәч җәйләрнең,
Шау чәчәккә юкә күмелә...
Ду китереп килеп керде бит
Юкә урманнары күңелгә...
Хискә сеңгән урман һавасы
Әйләндерер хәтта хур башын.
Карурманда йөрим исәреп,
Сандугачлар белән җырлашып.
Кайдан алыр идем җанга көч,
Күңелләрем җырга тулмаса?
...Мин шулкадәр моңлы булмас идем,
Юкә урманнары булмаса.

## Онытмаган...

Онытмадыңмы җырчыңны,
Туган авылым Чыршылы?
Инешләрең Шушмаларга
Төбәп ага күзләрен.
Басуыңда—ялан тәпи
Балачагым эзләре...
Дукын-дулкын Әби тавы
Кылган чәчләре белән.
Яңгырдан соң күңел җилси
Калган яшьләре белән...
Куркаклар адашып кала
Көрә урманнарында.
Беренче батыр булгандыр
Чәшең* корганнарында...
Салкын чишмә җыр чыгарган
Белик дип кадерләрен.
Җил канатлары сәламли
Яудагы каберләрнең...
Бәпкә үләнен уйнатып
Чаба бала-чагасы.
Капка төбенә утырып
Күзәтә ил агасы...
Сагынгансың бит җырчыңны,
Туган авылым Чыршылы?

## Уйларым дулкын кебек

Җилләр исми көн бозылмый,
Үзгәрми тора һава...
Зилзиләдәй кубармын күк
Сезнең якларга таба.
Хатлар язмыйм, сөйләмим сүз,
Уйларым дулкын кебек:
Сагыну көен җырлый күңел,
Сагышларыма төреп.

***

Гел мактыйбыз
Җирнең хуҗасын.
Ә ул "эчә"...
Күбрәк нужасын.

***

"Хәлең ничек?"—дип сорасаң,—
Ничек дип, синең эшең?"
Шигыремдә, рифмаларда
Йөрәгемнең тибеше.

---

*Чәше—авылның беренче исеме. Чәшеле. Күчеп килүче Колмакт бабам чәше корып авылга нигез салган.

***

Саубуллашты минем белән
Мәхәббәтең, дуслыгың,
Җан очты йөрәк түреннән,
Калды күңел бушлыгы.

***

Якыннарың, дусларың
Кичерерләр, мин беләм.
Явызлар ачуы яман—
Кичерер алар, димәм...

***

Серен чишеп абага да
Елга бер чәчәк ата...
Йөрәгемне аңламыйча
Гомер буе баш ватам.

***

Санаулы вакытлар уза,
Санасаң-санамасаң...
Җир үзе тигезләп куя,
Тормышка ярамасаң...

***

*Бер шагыйрьгә*

Имеш, халкы, милләте өчен
Янучы юк аннан яман...
Күз явын алса да сүзең,
Һәр сүзең саен шул... ялган.

***

Бер көн яшел әләм тоткан
Бүген кызылга күчкән:
Тик файда эзләп интегә
Сәясәт дигән эштән...

***

Кеше яхшы була,
Үзең булсаң әйбәт.
...Начар дигән сүзләр
Ишетсәң—ул гайбәт!

*Шигырьләре журналыбызда беренче тапкыр тәкъдим ителсә дә, Римзил Вәли—укучыларыбыз өчен ят исем түгел. Ул җитмешенче-сиксәненче елларда ук илгә танылган журналист; "Комсомольская правда", "Советская культура" кебек үзәк газеталарның Идел буе регионында үз корреспонденты булды. 1988—1992 елларда исә Римзил Вәли—татар яшьләре "Идел" журналының төп оештыручысы, аның беренче баш мөхәррире; шул ук вакытта "Ватан" җәмгыятен төзүчеләрнең берсе, ә 1995—2000 елларда—аның президенты иде. Читтәге милләттәшләребез өчен латин имлясында "Дөнья" исемле газетаны оештыручы һәм баш мөхәррире дә булды ул.*

*1992 елдан башлап, Римзил Вәли—Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты рәисе урынбасары; ә 2002 елның августыннан —татарларның Бөтенроссия федераль милли-мәдәни мохтарияте Совет рәисе. Бу илкүләм дәрәҗәдәге җаваплы эшләрен ул киң билгеле "Азатлык" радиосының Казандагы вәкиллеге директоры вазифасы белән бергә алып бара.*

*Шигърияткә ул бөтен гомере буе мөкиббән шәхес. Беренче шигырьләре Башкортстанның Бишбүләк районында Аеп мәктәбендә укыганда район газетасында басылып чыга. Уфада университетта укыган елларында "Акчарлаклар" әдәби берләшмәсенә җитәкчелек итә, үз шигырьләре көндәлек матбугатта басыла; Римзил Вәли сүзләренә җырлар да язылып, бүген дә радиофондларда кулланыла.*

*Бу санда тәкъдим ителә торган шәлкем—төрле елларда язылган милли рухтагы шигырьләреннән сайлап алынды.*



**Римзил Вәли**

## ТАТАР ГЕОГРАФИЯСЕ

***

**Ак диңгез, Кара диңгез,**
**Балтыйкның дулкыннары,**
**Аму-Дәрья, Хазар диңгез,**
**Енисей упкыннары...**

**Байкал күлләренә чумдык,**
**Ангарага ташландык.**
**Амурларда балык тоттык,**
**Бозлы суда батмадык.**

**Дунай, Одер безгә таныш,**
**Гудзон, Сена калмады.**
**Ком чүлендә кипмәдек без,**
**Котыпта да катмадык.**

Үрмәләдек Уралларга,
Мендек Тянь-Шань тавына,
Кавказ, Памирларны күрдек,
Түздек шәһәр шавына.

Камчатканың вулканында
Каушамадык, янмадык.
Сагыш җебен яшькә манып,
Җан ярасын ямадык.

Адаштырмады халкымны
Себернең урманнары.
Далада да, калада да
Татарлар югалмады!

Һәрчак күз алдында торды
Дим буе тугайлары,
Идел, Чулман, Агыйделкәй,
Зөя, Танып буйлары.

"...Өй артындагы шомыртым",
"Тәрәзәдә чия гөл"...—
Туган җирен, җырын шулай
Татар гына сөядер...

## Кыңгыраулар

Сөлге таккан кызыл дуга,
Дугада—кыңгыраулар.
Ак каеннар хэйран калып,
Тып-тын тыңлап торалар.

Кыңгыраулар, кыңгыраулар...
Сөлгегә чигелгәннәр.
Сөлгедән юл читендәге
Үләнгә сибелгәннәр...

Кыңгыраулы таңнар белән
Кыңгыраулы атларда,
Туйга түгел, яуга киткән
Ирләр илне сакларга!

Киткәннәр дә, кайтмаганнар—
Яу бит ул, уенмыни!
...Кыңгыраулы тайлар гына
Яланда чабып йөри...

Киткәннәр дә, кайтмаганнар
Туган җир, туган якка...
Аларның юллары мине
Илттеләр Бухенвальдка.

...Адәм яга торган мичләр...
Таш каланча каршымда.
Каланчада—зур кыңгырау
Даң-даң итеп сөрән сала
Канлы үткән хакында...

Күз алдымда—кызыл дуга,
Колагымда—чыңлаулар.
Туганнар каберлегендә
Зәп-зәңгәр кыңгыраулар...

***

Зирәккә—белем баскычы,
Гашыйкка—сагыш ачысы.
Ахмакка—мыскыл кайчысы,
Явызга—ятим каргышы,
Хаинга—тәмуг ачкычы,
Кәнтәйгә—кәнтәй язмышы...

## Ул хис...

*Р.гә. шаярып*

Ул хис—
        язмышыңа нур сибүче,
мәрмәр ташка җан өрүче...

Ул хис—чәчәк тамырына
тамчы булып сеңде,
дусларыңнан ваз кичтерде—
күп нәрсәне җиңде.

Кичтерде ул дарьяларны,
оныттырды ул ярларны,
канат бирде, богау салды,
шайтанны да дустың итеп,
кайчакларда кочаклатты...
Үрмәләтте кыяларның текәсенә,
илһам учакларын ул дөрләтте,
Нюанслар иленә сәяхәткә илтте...

"Кем кабызган яну-көю?"—дисең.
Барысын бирә чын мәхәббәткә тиң—
үз-үзеңне сөю хисе!...

***

"Синең өчен яшәмәскә!"—дидем.
Дөнья болай да буталчык—
Чуалган гомер җебенең
Нигә очын эзләмәскә?—
        "Синең өчен яшәмәскә!"

Аерылгач—юксынмаска,
Очрашканда—сөенмәскә,
Сиңа бәлаләр килгәндә
Борчылмаска, көенмәскә...
        "Синең өчен яшәмәскә!"

**...Төштә күрергә "теләмим",**
**Һич кирәкми**
**өннәреңдә эндәшергә,**
**Таң атканда**
**чык тамчысын бүлешергә—**
**һич кирәкми...**
**Синең өчен яшәмәскә!**
**Зәңгәр күккә исемеңне пышылдарга—**
**ярамый!**
**Шул исемне үләннәргә, агачларга кушу—**
**ярамый!**
**Үрелергә,**
**хәтта күренергә—**
**ярамый!**
**...Нинди гөнаһларым өчен**
**Язмыш мине җәзалый?**

**...Йөз көн шакыдым йөрәк ишекләреҥ,**
**йөз көн шакыдым.**
**Җавап ишетмәдем...**
**Каһарманмы мин бер?**
**Әллә мескен?**
**Йөз көн шакыдым йөрәк ишекләреҥ,**
**йөз көн...**
**Синең өчен яшәмәскә!**
**Яшәмәскә синең өчен.**
**Яшәмәскә. Яшәмәскә!**

**...Зәхмәт суккан бөкре сукбай булып**
**чиркандырмам.**
**Хөкем көткән мәхбүс булып,**
**көлке мәхлук булып калмам...**
**"Синең өчен яшәмәскә!"**
**Тыңла, җаным, чыда, йөрәк!**

**Синең өчен яшәмәвем**
**Булсын сиңа миннән бүләк!**

**...Синең өчен яшәмәгәч,**
**Беркем өчен яшәмәгәч,**
**Яшәү миңа нигә кирәк?**



**Индүс Таһиров**

ТАТАРСТАННЫҢ ДӘҮЛӘТ СУВЕРЕНИТЕТЫ ТУРЫНДАГЫ ДЕКЛАРАЦИЯ ИГЪЛАН ИТЕЛҮГӘ 15 ЕЛ

# ТАТАР ДӘҮЛӘТИ ХАЛЫК УЛ

Тарихчыларның ике йөз илле елдан артык вакыт дәвамында рус тарихында—татар тарихы, ә татар тарихында рус тарихы яшәп килгән дигән фаразлары белән килешмәү мөмкин түгел. Мондый фаразлар күренекле евразияче П.Н. Савицкийның, татарчылыктан башка рус тарихын күзаллау мөмкин булмас иде, дигән сүзен раслый.[1] Чыннан да, яшәү куәте зур булган, башкаларга үрнәк халык кына теләсә нинди шартларда да, һичкем йогынтысына бирелмәстән, киресенчә, башкаларга үзе йогынты ясап яши ала. Һәм шуның белән бөек тә була.

Әйе, татар ул дәүләтләрен югалтканнан соң да, кайгы белән үлем арасында да бөек булып кала алган халык. Миссионерларның, татарлар өч йөз ел буена руслар белән бергә яшәүләренә дә карамастан руслашмыйлар, киресенчә, башкаларны татарлаштыралар, дигән сүзе бар. Аларның иң күренеклеләреннән берсе булган Ильминский "Татарлар үзләрен һәрвакыт дәүләти халык итеп хис итәләр",—дигән. Миссионер галим Евфимий Малов тарафыннан 1904 елның 30 сентябрь—14 октябрь чорындагы көндәлек язмалары арасында уфтанып язылган мондый юллар да бар: *"Без, руслар, ун гына түгел, йөзләгән еллар дәвамында татарлар өстеннән хаким сыйныф булып яшибез. Инде Казан алынганнан соң да өч йөз елдан артык вакыт үтте, тик менә без аларны күпме дәрәҗәдә генә руслаштыра алдык икән соң?Тагын да өч-дүрт йөз ел күтәрбезме икәнни?"*

Моның ише фикерләр аз түгел. Аларның кайберләре татарларга карата—нәфрәт белән, кайберләре исә соклану хисе белән өртелгән. Ләкин ничек кенә булмасын, аларда чын хакыйкать тупланган. Татар һәрвакыт татар булып кала алган. Дәрдемәнд юкка гына, халык сүзенә таянып, "сөт калыр, ватан китәр", дип язмагандыр ул. Татарлар чыннан да дәүләтләрен җуюга да карамастан дәүләти халык булып кала алдылар. Аларның тарихи хәтерләренә, каннарына һәм хәтта яшәү рәвешләренә дә дәүләтчелек сеңгән.

Нәкъ менә шул дәүләти куәт—татарның сөте, ана көч, дәрт һәм дәрман бирә торган каймагы.

Бүтәнчә булса, Татарстанның 1990 елның 30 августында кабул ителгән, дәүләтчелек рухы белән сугарылган суверенлык декларациясе дә барлыкка килмәс иде. Әлеге Декларация Татарстанның Югары Советы кабул иткән гади бер документ кына түгел. Татарның әнә шул асыл сыйфатын туплаган, халык таләбе буенча кабул ителгән тарихи акт ул.

[1] Юрий Пивоваров, Андрей Фурсов. Русская система. Очерк четвертый.–Рубежи, 5/1995, с.30.

Әгәр дә төрле җирләргә сибелеп яшәгән татарлар һәрдаим дәүләтчелекләрен торгызу фикерен белдереп килмәгән булсалар, хакимияткә, шул исәптән, Татарстанның Югары Советына да басым ясап тормасалар, мөстәкыйльлек рухындагы мондый Декларация тумаган булыр иде. Мин моны кырт кисеп әйтәм. Чөнки кайберәүләр бу эштә халыкның ролен танымыйча, моны кайбер җитәкчеләр яки Югары Совет казанышы гына итеп күрсәтмәкче. Алар Декларация кабул итү алдыннан Югары Советка 685 документ ирешкәнлеген, шуларның 612се илнең 137 төбәгеннән килеп, бәйсезлек игълан итүне таләп иткән хат яки мөрәҗәгать булуын оныталар, ахрысы. Халыкның куәтле йогынтысыннан тыш безнен Декларациябез башка республикаларда кабул ителгән, бер-берсенә игезәктәй охшаш, игезәктәй төссез документлардан бернәрсәсе белән дә аерылып тормас иде. Бу хакыйкатьне инкар итүчеләр Декларацияне кабул итү алдыннан Югары Совет Президиумының Татарстан Россия составындагы суверен дәүләт итеп күрсәтелгән проекты басылып чыкканлыгын оныталар булса кирәк. Ул проект Александр Штанинның "Вечерняя Казань" газетасында басылган проектыннан асылда берничек тә аерылып тормый иде. Һәм шуна охшаш декларацияләрне башкортлар да, чуашлар да, якутлар да кабул итте. Әгәр дә шул проект Декларация рәвешендә кабул ителсә, Татарстан да шушы игезәк төссезләр исемлегендә булачак иде.



*Федераль үзәк белән шартнамә төзү процессы. Сулдан уңга: Индус Таһиров, ТР Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, ТР Россия Федерациясендәге тулы хокуклы вәкиле Назиф Мириханов.*

Ә безнең халык Декларациянең андый булуын теләмәде. Ул республиканың тулы суверенлыкка ия икәнлеген раслаган документ кабул итүне таләп итте. 1990 елның августында Казанга Татарстанның һәм гомумән илнең төрле почмакларыннан дистәләгән мең татар җыелды. Ирек мәйданы гөрләп торды. Анда бертуктаусыз митинглар дәвам итте. Мәйдан көне-төне умарта күчедәй шаулады. Югары Советка, аның депутатларына басым ясауның төрле-төрле ысуллары кулланылды.

1991 елның маенда Югары Совет депутаты Фәүзия Бәйрәмова ачлык игълан итте. Берничә көннән Ирек мәйданында Фәүзия янында дистәдән артык кеше утыра иде инде. Алар Татарстанны аның суверенитетына янаган яна бер куркынычтан саклап калырга омтылдылар. Шул елның 12 июненә билгеләнгән Россия Президентын сайлау бездә дә үтсә, бу хәл Татарстанны янә Россия составында дип санарга мөмкинлек бирә ала иде. Әлеге сәяси акция җиңү белән тәгәлләнде: Татарстан Югары Советы Татарстанда Россия Президентын сайлауны рәсми төстә үткәрмәү турында карар кабул итте.

Югары Совет Рәисе М. Ш. Шәймиев Башкортстан Югары Советы Рәисе М. Г. Рәхимов белән аралашып торды. Ул бер тапкыр шулай башкорт коллегасына Ирек мәйданы тулы халык икәнен әйткәч, Рәхимов: "Бу синең файдага" дигән һәм "эх, бездә дә шулай булса иде",—дип уфтанган. Әйе, ул көннәрдә халык һәм хакимият бер фикердә иделәр. Нәкъ менә шушы бердәмлек тиешле эчтәлектәге Декларация кабул итүгә төп этәргеч булды да инде. Мондый егетлекне бары тик дәүләти халык кына булдыра ала.

Чыннан да, әгәр дә Уфа мәйданнарын да халык каплап алган булса, һәм ул

тиешле эчтәлектәге Декларация таләп итсә, бәлки Башкортстанда да безнекенә охшаш Декларация кабул ителер иде.

Ә бит мондый мөмкинлек чыннан да бар иде. Бу очракта Казанга Башкортстанның Россия составында икәнлеге күрсәтелмәгән, тулы суверенлыкны теркәгән декларация проекты килеп ирешкәнлеген әйтеп китү урынлы булыр. Аның эчтәлеге хәтта безнең проекттан тулырак та иде.

Үз Декларациябез кабул ителгәч, М. Ш. Шәймиев Татарстан өлкә комитетының идеология буенча секретаре Р. Р. Идиятуллинны һәм мине Уфага җибәрде. "Татарстанга көрәштәшләр кирәк",—диде ул. Һәм без Уфага барып, анда Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары Мансур Әюпов, Башкортстан Өлкә комитетенең идеология буенча секретаре Роберт Янбарисов белән очраштык. Башкортларның шундый Декларациягә хаклы икәнлекләре турында фикер алыштык. Бу эш чыннан да барып чыкса, ул бары тик гаделлекне торгызу гына булыр иде. Эш менә нәрсәдән гыйбарәт.

Башкорт республикасы 1917 елның декабрендә үк игълан ителә. Шушы республиканың хөкүмәте 1919 елның мартында Совет хөкүмәте белән килешү төзи. Аның нигезендә Башкортстанның үз гаскәре, башка илләр белән аралашу ведомствосы булуы һәм аның яшәешнең бик күп өлкәләрендәге мөстәкыйльлеге таныла. Бу килешү Совет хөкүмәтенә гражданнар сугышы вакытында Колчак ягындагы шактый оешкан һәм шактый көчле башкорт гаскәрен үз ягына күчерү өчен кирәк була. Чыннан да, башкорт гаскәре гражданнар сугышындагы җиңүгә зур өлеш кертә. Тик менә күп тә үтмәстән Совет хөкүмәте шушы документны бер яклы рәвештә юкка чыгара.



*Бөтентатар Иҗтимагый үзәгенең беренче президенты Марат Мөлеков.*

Менә шуңа тулы канлы Декларация кабул итү башкортлар өчен гаделлекне торгызу гына булган булыр иде. Ләкин, ни кызганыч, бу эш барып чыкмады. Башкортстан Татарстанныкы кебек Декларация кабул итә алмады. Чөнки бу эштә халык катнашмады. Мәйданнар кайнап тормады, Югары Совет исеменә бәйсезлекне таләп иткән мөрәҗәгатьләр һәм хатлар яумады.

Ә без ялгыз калдык. Бер вакытны Минтимер Шәрипович, уфтанып: "Эх, союзникларсыз калдык бит",—диде. Мин аңа: "Минтимер Шәрипович, башкортлар моның белән берни дә югалтмадылар",—дидем. Ул: "Ничек югалтмасыннар?",—диде. Мин аның Башкортстанның һәм башка республикаларның Россия составына ирекле рәвештә керүләренең 400 еллыгын тантаналы төстә билгеләп үтүләрен исенә төшердем. "Алар шул көннәрне орден-медальләр һәм тагын әллә нинди өстенлекләр алдылар",—дидем.

—Ә без? ,—диде ул.

—Татарлар беркайчан да Россиягә ирекле рәвештә керүләрен танымадылар. Әгәр без Татарстанның Россия составында икәнлеген күрсәткән декларация кабул итсәк, бу шундый беренче документ булачак иде,—дидем мин. Болай дип тә өстәдем: "Юк, сез бәхетле кеше, Минтимер Шәрипович. Сез имзалаган документ чын-чынлап халык теләгән документ".

Минтимер Шәрипович сискәнеп киткәндәй булды. Һәм "Татарстанның Россиягә керүе турында бер генә документ та юк мени?"—дип сорады.—Бәлки 1922 елны берәр документ булгандыр?".

Ләкин андый документ юк иде. 1922 елдан башлап Татарстан берничә мәртәбә үзен СССРга суверен дәүләт буларак кабул итүне сорап ялвара. Ләкин ул СССР төзү договорын мөстәкыйль рәвештә имзалау хокукыннан мәхрүм ителә. Бу очракта Мирсәет Солтангалиевне искә төшермичә булмый. Ул РСФСР ның Милләтләр

эшләре буенча Халык Комиссариатының кече коллегиясе әгъзасы, Федераль җир комитеты рәисе, кыскасы, Совет хөкүмәтенең җаваплы хезмәткәре була. Төньяк Кавказ республикаларын төзү комиссияләренең дә башында ул тора. Солтангалиев Совет җитәкчелеге алдында СССРда барлык республикалар да бертигез хокукта булырга тиешлеген исбатларга тырыша. Ләкин җитәкчеләр тарафыннан мона уңай караш очратмый. Бу вакытны Ленин инде хәлсезләнгән, үлем түшәгендә ята, ә Сталин исә, киресенчә, тулы көчкә кереп килә. Ул, Ленин сүзләре белән әйткәндә, үз кулында иксез-чиксез власть туплый. Хакимият дилбегәсен ныклап үз кулына ала. Аның өчен берәү дә авторитет түгел. Ул хәтта Лениннын үзен дә, аның "К вопросу о национальностях или об автономизации" исемле хатындагы Солтангалиев фикерләренә аваздаш булган тәкъдимнәрен дә РКП(б) нын XII съезды делегатлары алдында мыскыллап тәнкыйтьли. Әлбәттә инде, Сталин Солтангалиевнең тәкъдимен катгый рәвештә кире кага. Аның җене котыра. Алай гына да түгел, Сталин шушы гаделлек сакчысы вазифаларын башкаручы шәхесне эзәрлекләү юлына баса. Аны үзенең иң беренче сәяси корбаны итә.

Ә 1936 елның декабрендә СССР нын яңа Конституциясе проекты буенча ясаган докладында Сталин Татарстан һәм Башкортстан союздашлык статусын үз колакларын күрә алмаган кук күрә алмаслар, дип көлә. ("Татарии и Башкирии не видать союзности как своих ушей"). Шулай итеп, монарчы ике халык, ике республика арасына чөй кагып килгән Сталин аларны бер җепкә тезеп, икесен дә союздаш республика статусыннан мәхрүм итә. Ә бит Татарстан бу статуска тулысы белән өлгергән, дәүләт булу өчен җитлеккән республика иде. Шушы уңайдан РСФСР Халык Комиссарлары Советының рәисе булган казакъ Тырар Рыскуловның 1926 елны бер киңәшмәдә әйткән, Россия составында ике төрле республикалар бар, дигән сүзен искә төшерәсем килә. Ул аларның беренче төренә бары тик Татарстанны гына кертә. Чөнки Татарстан, аның әйтүенчә, тулысы белән үз мөмкинлекләренә таянып яши. Аның алга киткән язма культурасы бар, дәүләт теле дәрәҗәсендәге теле, тиешле дәрәҗәдәге кадрлары бар. Аның өчен татар телен гамәлләштерү—җиңел хәл ителә торган проблема. Ә инде икенче төр республикалар бары тик Совет хөкүмәтенең мәрхәмәте аркасында гына яшиләр. Бу чыгышында Тырар Рыскулов, татарларны бик үк өнәми торган кеше булуына да карамастан, аларның дәүләти халык икәнлегенә басым ясаган.

Тик менә "өлгергән" Татарстан 1936 ел Конституциясе нигезендә элеккеге статусында калды, ә "өлгермәгән" республикалар СССР га кабул ителделәр. Алай гына да түгел, Татарстан автономиясенең исеме генә сакланды, җисеме исә бөтенләе белән диярлек юкка чыгарылды. Ул өлкә һәм крайлар белән тигезләштерелде. Дөрес, союздаш республикаларның хокукларын да көннән көн киметә тордылар. Алар да өлкәләр белән тигезләштерүдән ерак түгел иде. СССР таркалу сәбәпләренең иң мөһимнәреннән берсе дә менә шул. Хәер, монысы аның бүтән, махсус тема инде.

Үзгәртеп кору сәясәте Татарстан белән Башкортстан өчен суверен республикага әверелү мөмкинлеген тудырды. Ләкин шул ук вакытта бу мөмкинлектән ялгызын гына файдаланып булмаячагы да көн кебек ачык иде. Россиядәй Җир шарының җиделән бер өлешен биләп торган империяне унитар рельслардан тартып төшереп, демократик, федератив рельсларга бастыру—Татарстанның үзе өчен генә күтәрә алмастай йөк. Максатка ирешүнең шарты—республикаларның бердәмлеге. Һәм шушы бердәмлекнең нигезе Татарстан булса, анын иң якын аркадашы Башкортстан булырга тиеш иде. Бу ике республика тарихларынын иң җаваплы көннәрендә кулга кул тотынышып эш алып барырга тиеш иделәр.

Менә ни өчен Шәймиев ил буенча көрәштәшләр эзләде. Һәм шулар рәвешендә иң әүвәл тугандаш башкорт халкын, аның республикасын күздә тотты.

Әйе, эзләде. Таптымы сон? Бу сорауга җавап бер генә төрле була алмый. Инде әйткәнемчә, декларацияләр кабул иткән көннәрдә бу эшне тулысы белән башкарып булмады. Ләкин бу җиңелү түгел иде әле. Туплану мөмкинлекләре калган иде.

Декларация кабул ителгәч, яңа Союз договоры төзү алдыннан, Татарстан үзенең махсус позициясен билгеләрде. Бу позиция кабул ителгән Декларациягә ни-

гезләнгән һәм шушы договорга РСФСР Делегациясе составында тугел, мөстәкыйль рәвештә кул кую ниятеннән гыйбарәт иде.

Әлеге позиция Россия житәкчелеген бик нык борчыды. Шунлыктан Россия һәм Татарстан арасында ике яклы сөйләшүләр ихтыяжы барлыкка килде. Сөйләшүләрнең беренче өлеше 1991 елның 12 августы көнне Россиянең Ак йортында башланды, һәм 15 август көнне уртак беркетмә имзалау белән тәмамланды. Бу документның иң әһәмиятле өлеше безнең суверенлык декларациясенә ихтирам белдерүдән һәм инде моннан соң Россия белән Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләр ике яклы шартнамә нигезендә генә алып барылырга тиешлекне танудан гыйбарәт иде.

Мәгълүм ки, шул елның 19 —21 августында булып үткән ГКЧП фетнәсе Россия белән Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләрне катлауландырды, хәтта ки кискенләштерде. Шуннан файдаланып Россия житәкчелеге Татарстанны өр-яңадан үз урынына утыртырга тырышты. Минтимер Шәймиевкә һәм КПССның республика комитеты беренче секретаре Рево Идиатуллинга карата жинаять эше кузгатылды. Татарстанның үзендә яшәүче кайберәүләр, шул исәптән, прокуратура хезмәткәрләре, Югары Совет һәм Казан Советы депутатларының бер өлеше бу гамәлне кул чабып каршы алдылар. Алар Шәймиевне урыныннан алуны таләп иттеләр.



Ләкин шушы авыр шартларда да халык үз Президентына кул тидертмәде. Аның иминлегенә гарант булды. Һәм Татарстан үзе сайлаган юлдан тайпылмады. Аның житәкчелеге артка чигенмәде.

Моңа иң ныклы дәлил—Татарстанның статусы буенча үткәрелгән референдум. Шунысын әйтергә кирәк, баштарак Россия житәкчелеге аны үткәртү ягында иде. 1991 елның августындагы сөйләшүләр вакытында Россия делегациясенең житәкчесе Бурбулис, Декларация белән танышкач: “Декларациягез яхшы, дөрес тә төзелгән. Ләкин сез аның урынына референдум үткәреп, шуның нәтижәләре белән килгән булсагыз, бигрәк тә шәп булыр иде”,—диде. Бу—Татарстанның 48 процентын гына татарлар тәшкил иткәнлегеннән һәм аларның да шактые Татарстанның суверен статусына каршы булу ихтималыгыннан, шунлыктан референдум тискәре нәтижә бирәчәгенә ышанудан чыккан сүзләр иде.

Ә инде менә Татарстан житәкчелеге бу эшкә жиң сызганып тотынгач, Мәскәүдәгеләрне шом басты. Алар референдумны үткәртмәү чараларын күрә башладылар. Бигрәк тә РСФСР Югары Советы Рәисе Руслан Хасбулатов котырды. Гомумән, бу кеше һәрвакыт Татарстанга каршы һөжүм ясап торды. Ул радио-телевидениедән дисеңме, газета-журналларда дисеңме, бертуктаусыз Татарстанның суверен статусына каршы чыга килде. Референдум алдыннан Россиия Югары Советының машиналары Татарстан районнарына референдумга каршы өндәмәләр, плакатлар, листовкалар ташыдылар. Референдумны өзү, үткәрелгән хәлдә тискәре нәтижәгә ирешү өчен киң колачлы коткы кампаниясе жәелдерелде.

Мәскүнең Ак йорты һәм Кремле тарафыннан Татарстандагы суверенлыкка каршы көчләргә ярдәм күрсәтелде. Татарстан прокурорларына барлык сайлау участокларын да ябарга дигән әмер бирелгән. Кайбер район прокурорлары бу әмерне кирәгеннән артык итеп үтәргә тырышты. Мәсәлән, Лениногорскида хәтта Татарстан Президенты яки Югары Совет исеменә юнәлтелгән хатларны да тоткарлый килгәннәр. Россия демократик партиясенең жирле оешмасын житәкләгән проку-

рор Гринь шул хатларның авторларын чакыртып аңлатмалар яздыра торган булган. Ләкин мондыйлар сирәк. Күпчелек прокурорлар законга һәм республикага турылыклы булып калалар. Татарстанда бер генә сайлау участогы да ябылмый.

Референдумга каршы эшкә Россия президенты Б. Н. Ельцин турыдан-туры үзе катнашты. Ул телевидение аша сайлаучыларга мөрәҗәгать белән чыкты. Рус сайлаучыларын ул, әгәр дә сез референдум соравына "әйе" дип җавап бирәсез икән, иртәгесен икенче сортлы гражданнар булып уяначаксыз, дип куркытты.

Ельциннан соң Татарстан халкына Шәймиев мөрәҗәгать итте. Ул телевизор караучыларга Татарстан позициясенең асылын һәм референдумның максатын аңлатты. Аларны референдумда актив катнашырга һәм аның соравына уңай җавап бирергә чакырды. Бу, һичшиксез, аның тарафыннан ясалган батыр адым иде. Чөнки картага Президентның үз язмышы куелган иде. Референдум алдыннан Мари республикасының Татарстанга терәлеп торган Волжск шәһәренә Хасбулатов килә. Референдум тискәре нәтиҗә бирсә, ул Шәймиевне кулга алып Мәскәүгә алып китәргә тиеш була.

Бу батырлык сайлаучылар тарафыннан югары бәяләнә. Ф. Х. Мөхәммәтшин, М. Г. Сабиров һәм М. Ш. Шәймиев исеменә язылган хатында казанлы Н. Степанов, "Безнең гаилә референдум соравына "әйе" дип җавап бирде",—дип яза. Ул үзенең 21 март көнне бары тик җиңү турында гына уйлаганлыгын хәбәр итә һәм Шәймиевкә "Сезнең сайлаучыларга мөрәҗәгатегез бик нык ярдәм итте" дигән сүзләрен юллый.

Татарлар курыкмады. Алар Татарстан җитәкчеләренә көч-куәт һәм дәрт-дәрмән өстәп тордылар. "Тимер бул, Минтимер!"—дип мәйданнарга чыктылар.

Референдум көннәрендә республиканың Югары Советы исеменә хатлар, телеграммалар, мөрәҗәгатьләр ява. Аларның күпчелеге референдумны яклый, халкыбызга теләктәшлек белдерә. Шулар ук республикада Мәскәү тарафыннан ясалган басымга каршы протест хәрәкәтенең көннән көн ныгырак җәелгәнлеген дә дәлилләр. Бер хатта "Без Президент М. Ш. Шәймиевкә аның ныклыгы һәм суверенлыкны тормышка ашырудагы тәвәкәллеге өчен рәхмәт белдерәбез",—диелә. Ф. Мөхәммәтшин исеменә язылган хатында, сайлаучы К. Нуретдинов: "Әгәр дә Татарстан җитәкчеләре Мәскәүдән куркып Федератив договорга кул куйсалар, халык аларны беркайчан да гафу итмәс, аларны һәрбер татар беренче номерлы мөртәт итеп санар", - диелгән. Бу хатның ахырында мондый сүзләр дә бар: "Әгәр дә сез бер җебек яки империячел рухтагы кеше икәнсез, отставкага китегез, татар халкын хурлыкка төшермәгез!".

БДБ илләрендә һәм Россиядә көн күреп яткан татарлар да ул көннәрне Татарстанга теләктәш булды. Безнең кулыбызда Үзбәкстан, Таҗикстан, Мәскәү, Әстерхан, Екатеринбург, Чиләбе, Красноярск шәһәрләрендә яшәүчеләрнең күп санлы хатлары. Аларның авторлары үзләрен Татарстанның суверенлыгын яклаучылар исемлегенә кертүне сорыйлар. Казанга хәтта референдум соравына "әйе" дип җавап бирүчеләрнең имзалары куелган һәм рәсми рәвештә расланган исемлекләр дә җибәрелде.

Кайберәүләрнең татар булмаган гражданнар референдумда барсы да тискәре җавап бирер дигән өметләре дә чәлпәрәмә килде. Референдумда катнашу хокукына ия татарстанлыларның яртысыннан күбрәге безнең суверенлыкны яклап тавыш биргән икән, алар арасында руслар да, чуашлар да, удмуртлар да, башка милләт кешеләре дә шактый. М. Ш. Шәймиевкә юллаган хатында чуаш А. Степанов болай дип яза: "Шушы Татарстан өчен авыр көннәрдә Татарстанның суверен программасын тулысы белән яклыйм, чуаш булсам да, Татарстанда туып үстем һәм аның өчен көрәшкә әзермен".

Шәймиевкә, Мөхәммәтшинга һәм Сабировка юллаган хатында ике солдат анасы Т. Володина референдумны тулысы белән яклавы хакында хәбәр итә. Ул болай дип яза: "Алла хакына моннан болай Грозныйлар да, Годуновлар да, Берия лә, Сталин да, Жириновскийлар да булмасын. Хасбулатов, Травкин, Грачев, Хафизов һ. б. радио, телевидение, матбугат чаралары аркылы безгә янамасыннар. Күп милләтле Татарстан халкы үз юлын билгеләде. ...Безнең җитәкчеләргә тимәгез, аларны пычратмагыз".

Күп кенә хатларда Россиядә яшәүче руслар һәм башка милләт вәкилләре Мәскәүнең Татарстанга басымына ризасызлык белдерә. Мин Ырынбурда яшәүче бер рус хатынының хатын тәрҗемәсез, оригиналда килеш бирәм:

"Здравствуйте, милые татары!

Слушаю каждый день гавканье ТВ и радио России (менә сиңа "настоящее радио".—И. Т.) по поводу референдума в Татарстане. Да плюньте вы на них и на их продажные суды и обязательно отделитесь от России. Правительство России ведет политику геноцида против народа. Если вы отделитесь от России, может быть, и выживете. А нам русским не привыкать подыхать под игом наших царьков. Я считаю, что всем нужно отделиться от России—и мордве, и чувашам, и всем народам, а нам так и надо, чтобы впредь немного думали, кого в цари выбирали. Мне даже смешно как депутаты России пыжатся, осуждая вас. Да какое им дело до Татарстана, если все они колышутся под одной дирижерской палочкой как болванчики.

Только одно надо помнить. Если для Татарстана все народы, живущие на этой территории, будут родными детьми, вы достигнете огромных высот, если же нет, то вы будете не лучше русских царьков.

С уважением, Дубровская Ольга Андреевна".

Референдумның нәтиҗәләре һәркемгә мәгълүм: сайлаучыларның 61,4 проценты Татарстанның суверенлыгын яклап чыкты. Бу тарихи җиңү иде. Россия Конституцион судының рәисе В. Д. Зорькин референдум алдыннан РСФСР Югары Советы утырышында болай дигән иде: "Әгәр дә референдум соравына "әйе" дигән җавап алынса, бу бәйсезлек игълан итү өчен юридик нигез булачак. Моны һәрбер юрист шулай дип санар, һәм хаклы да булыр".

Бәлки соңрак ул бу сүзләрне әйткәненә үкенгәндер дә. Тик бит менә, халык әйтмешли, " Әйткән сүз — аткан ук". Аны кире кайтарып алып булмый.

Референдум татар халкының дәүләти халык икәнлеген тагын бер кат раслады. Декларациябез халык фикере белән ныгытылды.

Россия җитәкчелеге Федератив договор исемле документ әзерләп, аны тантаналы рәвештә имзалау көнен билгеләде. Әлбәттә, Татарстан аңа кул куюдан баш тартты. Чөнки аның өчен Россия белән ике яклы, тигез хокуклы шартнамә төзеп, махсус статуска ия булу мөмкинлеге ачылган иде.

Ләкин Татарстан бу очракта да үзенә көрәштәшләр эзләде. Һәм тапты да сыман. Башкортстан белән Саха-Якутия Федератив договорга шулай ук тискәре мөнәсәбәт белдерделәр. Тик бу юлы да эш башкачарак булды...

Федератив договорны имзалау көне итеп 1992 елның 31 март билгеләнгән иде. Россия белән Татарстан арасындагы сөйләшүнең чираттагы утырышы да нәкъ шул көнгә туры китерелгән. Ул иртәнге сәгать 10 да, Россия хөкүмәте урнашкан бинада ачылырга тиеш иде. Без җыелышып Россия делегациясенең җитәкчесе, РСФСР Дәүләт секретаре Г. Э. Бурбулисны көтәбез. Ун минут үтте инде, ә ул һаман юк әле. Без делегациябез җитәкчесе, Татарстанның вице-президенты В. Н. Лихачев белән икәү (мин—делегация җитәкчесе урынбасары) коридорга чыктык та Бурбулис кабинеты ягына юнәлдек. Аның ишеге төбендә кемнәрдер утырып тора. Лихачев аларны белә икән: болар Башкортстан җитәкчеләре булып чыкты. Ни көтеп торганнары исә бераз соңрак мәгълүм булды.

Бурбулис боларны Федератив договорга кул куярга күндерү өчен чакырган булган икән. Максатына ирешкән: Башкортстан кул куйды. Кичен безгә Федератив договорга Башкортстан өчен генә эшләнгән, ике як та имзалаган кушымта килеп ирешә. Шушы документ нигезендә җир асты байлыклары—Башкортстанныкы, хокук саклау органнары да бары тик аның карамагында. Башкортстан Федератив договорны шушы ташламалар бәрабәренә имзалаган булып чыга.

Сөйләшүләрне алып баруда Бурбулисның урынбасары, Милләтләр эшләре буенча дәүләт комитеты рәисе В. А. Тишков безгә: "Сез дә имзалагыз Федератив договорны! Сезгә дә шундый ук ташламалар бирербез",—дип, безнең дә кылны тартып караган иде. Ләкин инде ул турыда сүз дә булуы мөмкин түгел иде. Татарстан үз позициясендә нык торды. Тишков безнең ныклыкны чакматаш белән чагыштырды.

Ишетүебезчә, Саха-Якутияне дә аның җир байлыкларын үзенеке итеп тану шарты белән күндергәннәр. Аерылганны аю ашый, бүленгәнне бүре ашый, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Россия җитәкчелеге борынгы Римның бүлгәләп хакимлек итү традициясен уңышлы кулланды. Башкорстан белән Якутия-Саханы Татарстаннан читләштерә алды. Вакыты җиткәч исә бу республикалар өчен ясалган ташлама вәгъдәләрен юкка чыгарды. Якутиягә дә, Башкортстанга да җир асты байлыклары тәтемәде, аларның хуҗасы булу насыйп булмады. Бүгенге көнне төбәкләр, һәм иң беренче чиратта Башкортстан белән Саха, табышларының 70 процентын Мәскәүгә җибәреп торалар.

Ә Татарстан, Бурбулис әйтмешли, башкалар өчен әхлакый мисал була алды. Ул, 1994 елның 15 февралендә ике яклы Шартнамә төзүгә ирешеп, Россияне федератив рельсларга бастыра алды. Аның артыннан башкалар иярде. Россиянең кырыктан артык төбәге Федератив үзәк белән ике яклы шартнамәләр төзеде, вәкаләтләр бүлеште. Ә инде әгәр дә Үзәк үзенең төбәкләре белән вәкаләтләр бүлеп яшәү юлына баса икән, бу дәүләт чын мәгънәсендә федератив дәүләт булып аталырга хаклы.

Татарстан тәҗрибәсе дөнья тарафыннан да танылды. Ул Үзәк белән милли республика арасындагы конфликтны тыныч юл белән хәл итү мисалын булдырды. Рамбуе шәһәрендә Косово проблемасы тикшерелгән вакытта, сөйләшүләр алып баручыларның өстәленә Татарстан белән Россия арасында төзелгән Шартнамә дә куела.

Бүген исә Татарстанга ирешелгән позицияләренең кайберләреннән баш тартырга туры килә. Бу аңлашыла да. Чөнки Россиядә империалистик көчләрнең позициясе шактый нык. Алар Россиянең кайбер төбәкләрен моңа кадәр төзелгән шартнамәләреннән баш тартырга мәҗбүр иттеләр. Һәм әле дә булса "Бүлгәләп хаким ит!" принцибын алга сөрәләр. Татарстанны ялгызлыкта калдырырга тырышалар. Шулай булгач, чигенми мөмкин түгел. Дөрес, хаталар да җибәргәләдек. Алары да булды. Ләкин төп плацдармнарыбызны саклап калдык.

Чигенүләр бер тукталыр. Чөнки Россиянең, әгәр дә ул Татарстан тәкъдим иткән демократик федерация төзү юлын дәвам итмәсә, бербөтен дәүләт буларак яшәвенә чик куелуы бар.

Ә Татарстан өчен, аның киләчәген тәэмин итүнең төп базасы булып, халкыбызның дәүләтилеген раслаган, 1990 елның 30 августында кабул ителгән Декларация һәм 1992 елның 21 мартында үткәрелгән референдум калачак.

Аллага шөкер, сөтебез куе. Без дәүләти халык. Вакыты җиткәч, ватаныбыз кайтыр. Моңа нинди дә булса шик булуы мөмкин түгел.

# ТАТАРНЫҢ ИЛЕ КАЙДА?

*Ринат Зиннур улы Закиров 1948 елда Чистай районы Нарат-Елга авылында туган. 1972 елда Казан химия-технология институтын тәмамлаган. Фәнни дәрәҗәсе—педагогия фәннәре кандидаты. Ун еллап дәверен ул комсомолның Татарстан өлкә комитетында (инструктор, бүлек мөдире) һәм аннары КПСС өлкә комитетында (инструктор, бүлек мөдире урынбасары ) эшли. Бүгенге көндә ул—Казан милли мәдәният үзәге директоры, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе.*

*Журналыбыз өчен Ринат Зиннур улы Закиров белән әңгәмәне язучы Марсель Галиев әзерләде.*

***—Белгәнебезчә, татар халкы Карпаттан алып Татар бугазынача киңлекләрдә таралып яши. Һәр төбәктә булып, елга-күлләрен, тау-урманнарын, дала-кырларын үз күзләре белән күрмәгән, андагы халык белән якыннан аралашмаган кеше өчен бу киңлекләр географик билгеләр төшерелгән картага карап кына күзалларлык абстракт төшенчә булып тоела. Сезгә, Ринат әфәнде, Татар конгрессын житәкләгән кешегә, күп төбәкләрдә булырга, йорт-кура житкереп, ут-учак тергезеп яшәгән халкыбызның уйдык-уйдык ватаннарын күрергә туры киләдер. Шушы тәэсирләр белән уртаклашсагыз иде.***

—Татар ул Сахалиндамы яки Уралдамы, Америкадамы яки Төркиядәме —беркайда да югалып калмый; үҗәт, тәвәккәл, чыдам, булдыра торган, үз көнен үзе күрә белгән эшчән халык ул. Тормыш итүгә килгәндә башка халыклар арасында бер дә ким-хур түгел. Әмма, үз-үзен саклау мәгънәсендә, күп кенә объектив сәбәпләр аркасында бүген теле, моңы, тарихи хәтере, рухи көче бетә барган авыру хәлендә. Без генә шундый халәттә дип әйтергә җыенмыйм. Совет чорынын милләтләрне корыткан идеологиясе аркасында күп кенә милләтләр нык авыруга сабыштылар. Әмма чир белән чирнең аермасы бар. Безнең милләттә дәвалап булмаслык чир түгел әлегә. Сонга калмыйча, көч-дәрманы какшаган милләтебезне савыктырырга кирәк. Бу эшкә барыбыз да бергә тотынсак кына унай нәтиҗәсе булачак. Аерым-аерым алганда бик бәхетле, житеш, канәгать яшәргә мөмкинсен, ләкин милләтеннен ерак гасырлардан килгән рухи байлыгын, иманын байрак итеп күтәрә алмыйсын икән, син, кеше буларак, гади бер жан асраучы мисалында каласын. Дин әһелләре әйтә бит әле: "Без—Аллаһнын кальбендә", дип. Шунын кебек, һәммә шәхес үз милләтенен кальбендә булырга тиеш...



*Милли моңнар... Сулдан уңга: скрипкачы Рөстәм Абязов, Татарстан Фәннәр академиясе президенты М. Хәсәнов, Президентыбыз М. Шәймиев һәм Р. Закиров. 2003 ел.*

***—Милләтебез авыру хәлендә...—дигәнне, ничектер, кабул итүе авыр. Акыл-зиһен бу ачы хакыйкатьне сизенсә дә, җан, сыкрап, карыша...***

—Нишлисең, дөреслекне яшереп яшәргә безнең вакыт калмаган. Тукаебыз әйткән бит әле: "Татар үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?"—дип. Әйе, милләтебез кайда таркау, кайда көчсез, кайда—үлеп бара. Казаннан торып, безнең халык бөек, дип, узган дәверләр белән мактанып ваемсыз яшәү җиңел дә бит. Ә урыннарда—аяусыз хакыйкать ачыла... Без бит ничә дистә еллар буена үз Казаныбызда гына кайнап, республикадан еракларгы татарларга карата битараф хәлдә яшәдек, дөресрәге, рәсми идеология шулай яшәргә өйрәтте. Эчтән, йөрәктән борчылсак та араларыбызны якынайтырга мөмкинлекләребез юк иде. Шулай итеп, туганлык җепләре әкренләп өзелә торды. Миңа моның аяныч нәтиҗәләрен, төбәкләргә баргач, үз күзләрем белән күрергә туры килә. Мисалга, Кузбасс яки Донбасс шахталарына китеп урнашкан милләттәшләребез язмышын алыйк. Кайчандыр милләтебезнең меңнәрләгән сау-сәламәт асыл егетләре махсус юллама белән, илнең чакыруы буенча шул якларга барып урнашканнар, җир астында күмер чапканнар. Донбасста "Пролетар" дигән татар газетасы чыккан. Сугышка кадәр язучылардан Шәйхи Маннур монда балалар укыткан, газетада эшләгән. Нәби Дәүли, Зариф Бәшири, Максуд Сөндекләр шул газета тирәсенә тупланган булган. Әле 50-60 елларда да һәр татар авылының, күп татар гаиләләренең шушы шахталарда эшләүчеләр белән элемтәләре нык иде. Татар театры сәхнәсендә бүген дә йөзек кашы булган "Зәңгәр шәл" спектаклендә дә үзәктә шахтада эшләп авылга кайткан егет образы бит. Хәзер инде бар да беткән... Донбасс татарлары өченче буында телсез, хәтерсез калган кавемгә әверелеп бара...




*Санкт-Петербургта татар җәмәгатьчелеге белән очрашу. 2004 ел.*

Конгресста эшли башлаган 2002 елны миңа Татарстан Президенты Минтимер Шәрипович җитәкчелегендәге зур делегация белән Чиләбедә булырга туры килде. Губернатор сараена махсус очрашуга Чиләбе өлкәсенең күренекле татарлары җыелган иде. Бар да тук кыяфәтлеләр, ләкин татар рухы юк. Ә бит дәрәҗәләре кечкенә дип әйтеп булмый, кайсы генераль директор, кайсы бизнесмен, кыскасы, зур урыннар биләгән шәхесләр. Шунысы гаҗәп: алар губернаторга мәдхия җырлаудан ары уза алмадылар. Боларда милли рух тамчы да калмаган, өлкәдә йөзмеңнәрчә татарның, милләт буларак, үз йөзе бетеп барганлыгын уйлаудан бик өстен иде шул алар. Шуна күрә губернатор каршында, Президентыбыз каршында бер генә проблема да күтәрә алмадылар. Барыбызның да йөрәген әрнеткән хәл иде бу. Мин үзем бу өлкәне эчтән уятып булмасмы дигән уй белән гаҗизләнеп кайттым. Эш башлап җибәрдек. Менә хәзер, өч елга якын вакыт эчендә Чиләбе төбәгендә зур җанлану сизелә. Димәк, үз милләте өчен җан атып йөргән шәхесләр бар, аларны эзләп табарга, аларга өметләнергә була икән әле. Өметсез шайтан диме. Узган ел Донбасс җирендә дә 20 елдан соң беренче тапкыр Сабантуй бәйрәмен оештырдылар.

***—Матбугатта, радио-телевидениедә күбрәк төрле төбәкләрдә узган тантаналар, җыр-биюле кичәләр хакында хәбәрләр бирелә, үзебезнең иҗат көчләре дә төрле тарафларга барып, шаулы кичәләр үткәрү белән генә мавыгалар шикелле. Татарның яралы бәгырен ачып күрсәтмәс өчен игътибарны читкә юнәлтү, хәлиткеч мәсьәләләрдән читләштерү, тынычландыру алымы түгелме бу дип шикләнүчеләр дә күп...***

—Кешене усал кычкырып яисә шомландырып уятмыйлар, шулай бит. Күпме гореф-гадәтләре җуелган, рухы сүнә башлаган халыкны да йокыдан сак кына уяту кулайрактыр. Зур эшләр, гадәттә, бәләкәй эшләрдән башлана. Узган ел гына без Россия һәм БДБ илләренә 90 иҗади төркем оештырып җибәрдек. Анда язучылар да, журналистлар да, галимнәр дә, артистлар да бар иде. Алар халык белән очрашуга, андагы мәсьәләләрне өйрәнүгә җәмгысе 1109 көн сарыф иттеләр. Кемгәдер бу җыр-бию белән мавыгу кебек кенә тоеладыр. Әмма шушы очрашуларда күзләренә яшь тулган ил агаларын күргәч, бер дә алай уйлыйсы килми.Үз милләтен яратудан, аның моңын сагынудан сыкраган йөрәкләргә митингта сөйләнгән дөрес сүзләргә караганда сәнгать осталары алып килгән җылы хисләр юлны әле тизрәк тә таба торганнардыр, бәлки.

Ә инде Сабантуйларга килсәк... Татарның бу тарихи бәйрәмен дөнья мәйданына чыгаруга Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең әчке сизгерлеге һәм көчле рухлылыгы зур ярдәм итте. Узган ел илебезнең 53 төбәгендә, 11 чит илнең 30 шәһәрендә татар бәйрәме зур күтәренкелек белән узды. Шулай итеп, без Америка, Австралия, Азия, Европа кыйтгаларына түбәтәй кигездек.

Сабантуй—шаулы бәйрәм генә түгел, ул—фәлсәфи мәгънәгә ия, тарихи тамырлары тирәндә яткан ярыш мәйданы; ул—бердәмләшү, туганлашу, көч сынашу, батырыңны ачыклау, сәнгатеңне күрсәтү, гыйбрәт алу, бу дөньяда барлыгыңны раслау бәйрәме! Шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның яшьлегендә язган шигыре бар бит әле:

Сөлгеләр тотыла, һәр авыл
Батырын күзәтә, билгеле.
Мәйдан күк кысыла йөрәкләр:
—Бирмә, билеңне!
Бирмә!

Шулай, без, Сабантуй мәйданында гына түгел, бу шаулы-даулы дөньяда милләт буларак та, билебезне бирмәскә, егылмаска тиешбез.

***—Татар холкының башкалар алдында нинди сыйфатлары калку чагылырга тиеш?***

—Сабырлык һәм тәвәккәллек. Татарның әчке омтылышы кайнар, аңа тиз булсын, әкияттәге кебек: ыргыттың таракны—урман булып калка, ыргыттың көзгене—күл булып җәелә, ыргыттың картузыңны—тау булып чөелә. Тормышта алай булмый шул. Әйе, Россиянең Екатеринбург, Санкт-Петербург, Төмән, Чиләбе, Ырынбур, Әстерхан, Ульян кебек татарлар күпләп яшәгән төбәкләрендә милләттәшләребез өчен милли мәктәпләр, класслар, тел курсларын, якшәмбе мәктәпләрен кичекмәстән ачу кирәк. Бу—безнең төп бурычыбыз, алга куйган олы максатыбыз. Нәкъ менә шундый хәлиткеч мәсьәләләрне гамәлгә ашыруга карап, без киләчәктә Конгресска кергән оешмаларның эшчәнлегенә бәя бирәчәкбез. Бу очракта, чыннан да, җыр-бию оештырган өчен генә түгел. Әмма мәктәпләр булдыру коточкыч авыр мәсьәлә. Без туктаусыз көрәшә, сөйләшүләр алып бара торгач, ниһаять, узган ел Димитровград шәһәрендә (Ульянов өлкәсе) татар гимназиясе ачуга ирештек. Бу юлдагы киртәләрне саный китсәң кеше ышанмас. Юкса ирекле илдә, ирекле халыклар гаиләсендә яшибез түгелме соң? Чиләбе шәһәрендә дә бу яктан эш кузгалды. Чит өлкәләр дибез, ә үзебездә... Татарстанның 16 район үзәгендә бүгенге көнгә хәтле татар мәктәбе яңадан торгызылмаган. Дөрес, кайбер мәктәпләрдә татар класслары эшли, әмма бу бармы-бар өчен генә. Ата-аналар ягыннан да каршылык зур. Аларның күбесе татар мәктәбен тәмамлаган балам надан калачак дип совет чорында баш калкыткан курку өянәгеннән интегә. Шунысын да онытмаска иде: заманында чын татар мәктәпләре бетереп, төрле югары уку йортларына кереп, хәтта Сорбонна университетын тәмамлап, дипломат, фән эшлеклесе, академик, генерал дәрәҗәсенә җиткән йөзләгән татар зыялылары барлыгын да беләбез, көлеп әйтәләр бит әле: русча укудан гына торса, һәр урыс академик булыр иде, дип. Әмма эш кем булуда гына түгел шул. Телеңне, рухыңны саклауда, аны алдагы буыннарга тапшыра баруда...

Соңгы елларда без Татарстанда урнашкан югары уку йортларына Россия һәм БДБ илләреннән абитуриентлар кабул итүне оештырабыз. Әйтергә кирәк, бу киләчәктә чит җирләрдә татар телен саклауның төп чарасы булачак. Быел ачылачак Татар дәүләт гуманитар университеты да бу эшне һичшиксез күпкә җанландырыр.

Әзерлек курсларына кереп бер ел буена татар һәм рус телләренә өйрәнергә мөмкинлек бар. Яшәр өчен унайлы кунакханәсе дә әзер. Бу араларда без хәтта ерак Кытайдан килгән 30дан артык татар абитуриентларын кабул итәргә әзерләнәбез. Алар татар телен Казан дәүләт технология университеты базасында оешкан курсларда өйрәнәчәк. Ә бер елдан Татарстанның төрле вузларына укырга керәчәкләр.

Узган ел шаулатып Бөтендөнья татар яшьләре форумы үткәргән идек. Дөньяның кайсы гына почмагыннан килмәгәннәр иде. Казанны, Татарстанны күрделәр, өйрәнделәр, таныштылар. Без элек татар булып саналган гына икәнбез, менә хәзер инде үзебезнең нинди халыктан булуыбызны анлап китәбез, диделәр. Күбесе югары уку йортларына Казаныбызга укырга килергә дигән ныклы ният белән киттеләр.

***—Россия төбәкләрендә таяныр шәхесләр күпме?***

—Аз, әмма бәрәкәтле эшләребез ныклап кузгалган урыннарда көчле шәхесләр үзеннән-үзе калкып чыга. Бүгенге көндә татар дөньясында милләт өчен игелекле эшләре белән дан казанган шәхесләрдән мин Рәсим Акчурин(Мәскәү), Камил Аблязов (Сарытау), Фәнис Гатауллин (Ханты-Манси), Фәрит Ляпин (Иваново), Жәмил Вәлиуллин (Тольятти), Кязим Дебердиев (Пенза), Шамил Бикмаев (Саранск), Рамил Вафин (Йошкар-Ола), Фәрит Гыйбатдинов (Чувашия), Мөдәррис Әбакиров (Новосибирск) исемнәрен атар идем.

Татар матбугаты да жанланып килә. Мактап телгән алырлык татар журналистларының исемнәрен дә әйтеп китәргә була: Ильяс Мөслимов ("Татарские новости" газетасы, Мәскәү), Фәвия Сафиуллина ("Медия-Холдинг", Екатеринбург), Исхак Хәлимов ("Өмет" газетасы, Ульяновск), Рәмис Сафин ("Чишмә" телетапшыруы, Ульяновск), Рәфгат Әһлиуллин ("Бердәмлек" газетасы, Самара), Тамир Әлимбаев ("Татар дөньясы" газетасы, Омск), Ирек Шәрипов (Удмуртия, "Янарыш" матбугат үзәге), Нургали Яруллин( "Төп йорт", Магнитогорск), Рәүф Абдуллин ("Туган як", Түбән Новгород өлкәсе).

Соңгы елларда Бөтендөнья татар конгрессы тирәсендә төрле буын галимнәре тупланып, милләтебез өчен байтак эшләр эшләп киләләр. Әле күптән түгел генә Конгресста Төмәндә яшәүче милләттәшебез галимә, фәннәр докторы Халисә Алишинаның Себер татарларына багышланган монографиясен, танылган галимебез Илбарис Надыйровның "Татарстан-Төркия" бәйләнешләре турында язылган китабын тәкъдир итү булды. Чит төбәкләрдә дә татар галимнәре актив эшли. Сарытау эшмәкәре Камил Аблязов татар дини мәктәпләре турында бик кызыклы диссертация яклады. Шулай ук Мәскәүдә, Уфада, Төмәндә, Ырынбурда, Самарада яшәүче галимнәребез шул төбәкләрдә яшәгән татар тарихын өйрәнеп, фәнни хезмәтләр чыгаралар. Шулар арасыннан күптән түгел генә бик вакытсыз арабыздан киткән хөрмәтле татар галиме, профессор Радик Сибагатов исемен искә алып аның якты истәлегенә баш иясе килә. Ул язган китаплардагы милләтебез тарихы, аның нәфрәт тулы ачы жан авазы әле күп еллар халкыбызга маяк булып хезмәт итәр, аны нык булырга өйрәтер.

Берлинда яшәүче ватандашыбыз татар-башкорт мәдәни үзәгенең рәисе урынбасары Венера Вәгыйзова-Герасимоффны күпләргә үрнәк итеп куярлык. Ул анда милләтебезгә кагылышлы күп чаралар үткәрә, татар тарихын чагылдырган хезмәтләрне алман теленнән русчага тәржемә итә. Белгәнебезчә, рус белгечләре, галимнәре чит илдә сакланган күп төрле чыганакларның татар тарихын бәян иткән мөһим урыннарын үзләренә яраклаштырып тәржемә иткәннәр. Шуңа күрә, чыганаклар белән турыдан-туры эш итүче белгечләребез Гөлсара ханым Исмаилова (Канада), Жүнәйт әфәнде Чапаноглы, Рокыя ханым Сафа, Вил әфәнде Мирзаяновларның (АКШ) гадел тарихыбызны дөньяга чыгарудагы эшчәнлеген аерым бәяләргә кирәк.

***—Матбугат дигәч, без инде беренче чиратта газеталарны күз алдына китерәбез, аннары журналлар, китапларны... Кайчандыр, иң күп укучы ил, дип мактана идек. Хәзер укучы елдан ел кими бара, дип уфтанабыз. Шушындый, сүз кодрәте бетә барган шартларда төбәкләрдәге тернәкләнеп кенә килгән татар матбугаты нишләр?***

—Телибезме-теләмибезме, татар матбугат чаралары бүтән информация чыганаклары белән ярыш шартларына килеп керә. Әйтик, газета кыюсыз, сай фикерле икән, аны татарча басылган өчен генә алмаячаклар. Шуңа күрә безгә матбугат органнарының саны белән түгел, сыйфаты, тиражы белән мактанырга кирәк.

Соңгы өч елда без тагын бер шундый игелекле эшкә алындык: Россия төбәкләрендә татарлар тупланып яшәгән җирләрдә спутник тәлинкәләре аркылы "Татарстан- Яңа гасыр" телевидениесен карау мөмкинлеген булдырдык. 2004 ел дәвамында Свердловск өлкәсенә—31, Курган өлкәсенә—2, Ульянов өлкәсенә—5, Махачкалага—1, Волгоград өлкәсенә—2, Башкортстанга—10, Чиләбегә—3, Иваново каласына—1 спутник тәлинкәсе куелды. Болар төбәкләрдәге татарларны мәгълүмат белән тәэмин итеп тора. Беренчедән, бу татар телевидениесенең техник яктан галәм югарылыгына күтәрелүен күрсәтсә, икенчедән, бөтен татар дөньясы өчен үз телендә мәгълүмат кыры барлыкка килүе турында сөйли. Хәзер инде Казаннан таралган милли тапшыруларыбызның да эчтәлеге, сыйфаты, фикри байлыгы, зәвыгы ягыннан шулай югары дәрәҗәгә күтәрелүен телисе кала...

***—Без бәләкәйдән, мәктәптән үк тоеп үстек: кая бармашунда берәр энтузиаст, башлап йөрүче, бөтен коллективны кузгатып, үз-үзен аямыйча эшләүче фидакарь зат була торган иде. Байга, ярлыга—социаль катлауларга аерылган җәмгыятьтә энтузиастлык та бетә бара түгелме?***



*Сулдан уңга: Ринат Закиров, Илъяр Габитов (Кытай татары), Минтимер Шәймиев, Турсунтай Габитов, Рабит Батулла. 2003 ел.*

—Әйе, безнең татар дөньясында энтузиастлык һәрчак милләтне алга алып баруда зур көч булды. Киләчәктә дә андый куәткә ия шәхесләр, сирәк булса да, калка торыр дип уйлыйм. Әлбәттә, һәр хәрәкәтең финанска корылган җәмгыятьтә үзешчәнлек белән генә алга китеп булмый. Безнең конгрессның башкарма комитеты үзенең эшчәнлеген фәнни нигезгә корырга тырыша, замана шуны таләп итә. Менә ничә ел инде башкарма комитетыбыз һәм Тарих институты каршында этнологик мониторинг үзәге (милли проблемаларны өйрәнә торган структура) эшләп килә.

Бер төркем татар галимнәре милләтебезне үстерү концепциясен төзергә алындылар. Бу эш уңышлы тәмамланса, татар корабы хәвефле океанда җилкәнсез, кыйблясыз калмас иде, бәлки. Шулай ук без башкарма комитет каршында юридик төркем булдырдык. Монда галимнәр, халыкара хокук белгечләре, юристлар тупланды. Алар күп игелекле эшләр башкардылар. Алда да эшләр байтак: латин алфавитына күчү буенча да, дәүләтчелегебезне саклауда да, Башкортстандагы кыерсытылган милләттәшләребезнең мәнфәгатен яклауда да зур тырышлыклар куярга туры киләчәк әле.

Әлбәттә, бу гамәлләрдән республикабызның дәүләт структуралары—ягъни министрлыклар да читтә калмаска тиеш. Төрле төбәкләр белән икътисадый элемтәләрне ныгытуда, татар эшкуарларына аякка басарга ярдәм итүдә сәүдә министрлыгы аеруча нәтиҗәле эшләп килә.

Мәгариф өлкәсендә дә төрле җирдә яшәүче татарлар турында кайгырту, федераль үзәк белән Россия төбәкләрендә татар мәктәпләре ачуга кагылышлы мәсьәләләр әлеге министрлыкның төп эшләреннән саналмый бугай. Юкса яңа министрның әлегә бу турыда фикерен ишетергә насыйп булмады.

Ә менә Мәдәният министрлыгы гомумән әкрен кыймылдады. Татарстаннан читтә яшәгән талантларны барлау, укыту, үстерү әлегә аларның беренче чираттагы эшләре рәтендә йөрми әлегә. Шуна да нәтиҗәләр әлләни мактанырлык түгел. Икенче тапкыр уздырылган Илһам Шакиров конкурсына да чит төбәкләрдән килгән кат-

нашучылар санаулы гына иде. Шуңа да биредә җинүче исеменә лаек булырлык җырчы да табылмады.

Хәзерге көндә Мәдәният министрлыгына яна җитәкче килде. Ниһаять, бу өлкәдә эшләр алга китәр дигән өметтә калыйк.

***—Шәхсән үзем, Татар конгрессы делегациясе белән Төмәндә берничә мәртәбә булып, Себер татарларын якыннан күрдем. Телләре бетеп бара. Җир шарында төрки халыкларның ыруы Себер җиреннән башланган, без аерым милләт дип саташып йөрүчеләре, идеологлары да юк түгел. Мин боларга карап, безгә кирәкме соң бу кавем, татарның саф, көчле буыны боларсыз да берни дә югалтмый бит, дигән уйга килгән идем.***

—Тамырдан ялгыш фикер бу. Милләтнең үзәге, төше—фәкать Татарстанда яшәгән татарларда дигән, тәкәбберлектән туган уйлар бу... Чынбарлыкта исә халыкның яшәеше, үсеш менталитеты—татар яшәгән бөтен җирдә, һәм моны Казаннан еракта яшәгән милләттәшләребез, минемчә, көчлерәк тоялар. Татарның көче—Казанга карап, шуннан бөтенесен көтеп ятуда түгел, ә киресенчә, кайда яшәсә дә тулып торган татар тормышы белән гомер итүдән килеп чыга. Халкыбызны диалектларга яисә географик төпләнүгә бүлгәләмичә, бербөтен итеп карау йөз еллар элек кенә дә аңыбызда табигый төшенчә булган. Тукайны гына мисалга китерик: япь-яшь үсмер егет еракка—Уральскига китеп типографиядә эшли, иҗат итә. Ул дәверләрдәге чыганаклардан Уральск татар зыялылары тупланган шәһәр булып тоела. Казанда гына түгел, С. Петербургта, Ырынбурда, Әстерханда, Уфада—һәр җирдә татар тормышы кайный. Тукай әдәбият-сәнгать мәнфәгатьләре белән төрле төбәкләргә бара. Чит-ят җирләрдә түгел, үз өендә йөри Тукай.

Хәтерләсәгез, узган гасырның сиксәненче елларында әдәбият-сәнгатькә чит өлкәләрдән килүче яшь талантларның бик нык сирәгәюе турында борчылып өлкән әдипләребез чаң кага башлаганнар иде. Уйлаган кешегә уйланырлык иде шул. Унтугызынчы гасыр азагында, егерменче гасыр башында шаулап күтәрелгән татар дөньясы искиткеч уңышларга ирешкән. Уфа, Ташкент, Ырынбур, Баку, Әстерхан, Мәскәү һәм тагын күпме шәһәрләрдә татар театрлары гөрләп эшләгән. Табигый сайланыш булган: сәләтледән сәләтлеләрен Казан үзенә тарта белгән.

Заманында әдәбият мәйданына кайлардан гына килмиләр: Заһир һәм Муса Бигиевлар (Ростов-Дон), Кәрим Тинчурин, Һади Такташ, Шәриф Камаллар (Пенза өлкәсе), Газиз Иделле, Габдрахман Минский, Газизә Сәмитовалар (Әстерхан), Гадел Кутуй (Саратов өлкәсе), Муса Җәлил (Ырынбур өлкәсе), мин инде Уфа-Урал якларыннан килгән ут күршеләребезне әйтеп тә тормыйм.

Күрәсез, татар әдәбиятының, җыр сәнгатенең үзәге булган Казанга тартылып, халкыбызның алтын баганаларына әверелгән шәхесләребез бихисап булган. Шулар арасыннан Рәшит Ваһапов исемен генә дә искә төшереп китү җитәдер. Шушы бәрәкәтле ташкынның күзгә күренеп сүнә бару сәбәпләрен, әлбәттә, XX гасырның сиксәненче елларында ачыктан-ачык күтәреп чыгу мөмкин түгел иде әле. Бу аяныч хәлнең асылы төрле төбәкләрдә татар мәктәпләренең ябылуы, телнең, милли антойгының бетә баруы икәнен күпләребез белә, эчтән генә сызлана идек югыйсә. Кызганыч, милләтебезнең күп кенә бөек шәхесләре безнең күз алдында шушы сызлану хисләре белән мәңгелек йортларына күчтеләр. Шушы татар баласы өчен язылган китапларының беркемгә дә кирәге калмавын күреп, гомерләрен багышлаган иҗат эшенең мәгънәсе калмавын белү алар өчен бик авыр булгандыр. Менә шулай дистә еллар буена өзелә килгән кан тамырларын ялгау бүгенге көндә дә бик авыр бара.

***—Өстән, Мәскәү тарафыннан кискен каршылыклар юкмы?***

—Аллага шөкер, бүгенге көндә без демократик үзгәрешләрнең уңай йогынтысын тоеп яшибез һәм эш итәбез, федераль үзәктән ачыктан-ачык каршылыклар юк дәрәҗәсендә. Әлбәттә, сез татарлар Россиядә сан ягыннан икенче урында торасыз, зур халык сез дип, Урта гасырлардан килгән мөнәсәбәт, мәктәп дәреслекләреннән ялган тарих белән сеңдерелә килгән караш тиз генә үзгәрер дә безне учта гына күтәреп йөртерләр дип уйламыйм. Күп нәрсә үзебездән тора!

Бөтендөнья татар конгрессының II корылтаенда милли автономияләр төзү мәсьәләсе күтәрелгән иде. 1988 елда федераль татар милли-мәдәни мохтарияте оештырылды. Ләкин әлегә аның эше мактанырлык түгел. Россиядә бүгенге көндә 20

төбәк һәм 7 шәһәрдә милли-мәдәни автономия булуы шул турыда сөйли. Россиянең 89 төбәге өчен бу, әлбәттә, бик аз. Кызганыч, эш авыр бара. Бүгенге көндә жирле үзидарә системасы төзелеп килгән чорда, һәр төбәк бюджетының 30 процентын шул структураларга юнәлдерү мөмкинлеге ачылган дәвердә бу эшкә тәвәккәлрәк тотынырга кирәк иде. Татарлар тупланып яшәгән төбәкләрдә, жирле үзидарә структураларына үтеп кереп, бик күп мәсьәләләрне үз көчең белән чишәргә мөмкинлекләр туа.

***—Элекке елларда Илһам Шакиров, халкыбызның илчесе кебек, бөтен ил буйлап концертлар куеп йөри, татарларның яшәү шартларын кайтып сөйли иде. Кайда авыр эш—шунда татарлар, дип әйтә иде. Хәзерге көндә ничек икән; белемгә омтылу, дәүләт структураларында урын билән, өскә калкырга омтылу сизеләме?***

—Бу процесс көчле бара. Күрше-тирә республика парламентларында һәм хөкүмәт даирәләрендә, төрле төбәкләрнең жирле үзидарәләрендә, сайлаулар юлы белән, шактый милләттәшләребез депутат мандатлары алды. Шәһәр администрацияләрендә дә жаваплы эшләрне житәклиләр.

Шулай да Мәскәү сагаеп һәр адымны күзәтеп тора, федераль үзәктә төрле көчләр бар: Жириновский, Рогозин кебекләрнең партияләре милләтләрнең үсешенә кул чабып тормаслар. Сайлауларга реформалар кертү нәкъ менә шул милли кадрларның көчәюен, активлыгын туктату өчен түгел микән әле. Аларга бирешмәү, астыртын көчләрне фаш итү, милли кысуларга каршы тору—үзебезнең фидакарьлеккә бәйләнгән.

***—Эшлекле сәяхәтләрнең төрлесе булгандыр. Их, дип, очынып, жанга рухи егәр алган мизгелләр дә булгандыр бит?..***

—Әйе, булды. Чит өлкәләрдә биш, жиде, ун мең кеше яшәгән гажәеп зур, саллы татар авылларын күргәч шундый хисләр кичерергә туры килде. Шаккаткыч хәл! Үзе бер феномен! Мондый авыллар—океан уртасында бернинди цунами да алалмый торган гранит кыялар кебек. Гөр килеп яшиләр. Берничә мәчет эшләп тора. Борынгыдан килгән гореф-гадәтләр, тел-логать сакланган. Байлар да, авылны кулда тоткан хужалар да өлкәннәргә, аксакалларга буйсына. Һәр эшне алар белән киңәш-табыш итешеп башкарып чыгалар. Һәркайда—тәртип, олыны олы, кечене кече итү; буыннар арасында итагатьле бәйләнеш, рухи бергәлек. Аларның яшәү рәвешен, ата-бабаларның тәрбия алымнарын бүгенге галимнәргә өйрәнергә дә өйрәнергә әле... Тагын бер мисал: узган ел Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин житәкчелегендә без (галимнәр, язучы-журналистлар, эшмәкәрләр сәнгать көчләреннән торган зур бер төркем) Алтай өлкәсендә булдык. Алтай—Саян төбәге... Халкыбызның кояш чыгышы... Карпатка кадәрге кыйтгаларга жәелгән төрки дөньясының кайнап чыккан бишеге. Анда, тарихыбызның чишмә башында нинди гаярь, мәртәбәле халык булуыбызны бөтен тән күзәнәге белән сизәсең. Дөрес, күп кенә курганнар таланган, борынгы истәлекләр юк ителгән, урланган. Әмма исән калган тарихи ядкәрьләрдән генә дә дөньяви халык икәнебезне күзалларга була. Шуңа күрә, инкыйразга житкәнче, бүгенге көнгә исән калган тарихи жәүһәрләрне торгызырга, сакларга, аларның иминлеген кайгыртырга кирәк. Үткән зурлыкларыбызны бүгенге заманга тәңгәл куеп карый алганда гына без халык буларак үзебезне раслый алабыз.

***—Казанның мең еллык бәйрәме якынлаша. Конгресс күпмерәк, ниндирәк кунаклар чакырырга уйлый?***

—Казан каласы—ул бөтен татар галәменә башкала. Бу олуг бәйрәм чорында без тагын, зурлап, халкыбызның барлыгын, аның яшәвен дөньяга бәян итәчәкбез. Татар мохитен саклауда, яшәү көче, рухи этәреш бирүдә Татарстанның роле бик зур. Гадәттә цивилизацияле илләр үзләренең дәүләт башлыгы тирәсендә туплана, аны шәхес буларак күтәрә, хөрмәтли белә. Без дә әкренләп шундый мәдәни итагатьлелеккә өйрәнеп киләбез. Президентыбызны татар халкының яклаучысы, лидеры итеп тану, аны шәхес буларак олылау—безне бермә-бер көчлерәк итә. Ә бу тарихи бәйрәм халкыбыз өчен бердәмлек тантанасы булсын иде!

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

# ӘЛЛӘ КАЯН ЭЗЛӘП ЙӨРИСЕ ЮК...

"Безнең заман герое" дип исемләнгән бу дискуссия унаеннан язылган мәкаләләр заман герое хакында гына булып калмыйча, гомумән әдәбиятыбыз торышына, аның бүгенге хәл-халәтенә кагыла. Әлбәттә, шунсыз мөмкин дә түгел. Чөнки әдәбият мәсьәләләре хакында язучыларның "Ел йомгаклары"нда, съездларда сүз кузгатып кына төпле-ныклы фикерне әйтеп тә бетереп булмый, анда бүтәнчәрәк мәсьәләләр калкып чыга. Ә инде нәкъ менә әдәбиятның үзенә, аның төрле жанрларына карата кызыклы һәм гыйбрәтле генә фикерләр еш кына онытыла да куя. Дөрес, сөйләгәндә әйтелгән фикер-сүзләр дә кемнеңдер колагына-күңеленә керәдер (аралашу үзе бер мәктәп бит ул!), әмма журнал битләрендә ике ел буе саннан-санга, бер темага җентекле сөйләшү алып бару, әңгәмә кору—монысы инде бөтенләй икенче төрле хәл, эзлеклелекне һәм бер-береңне ныклап "тыңлый", аңлый алуны тәэмин иткән фал. Әш инде монда, бер уйласаң, бары тик шушы бәхәстә катнашучы авторларның ни дәрәҗәдә әзерлекле, үз фикерләрендә ни дәрәҗәдә эчкерсез булуыннан, мәсьәләнең җитди булуын ни дәрәҗәдә аңлавыннан һәм тоюыннан тора кебек. Нәкъ менә шунысы, соңгысы, минем үземне, шәхсән, шактый борчыган, шикләндергән бер нәрсә булды. Журнал алып барган бу дискуссиягә башта ук кушылмавыма, мөгаен, шул хәл бер сәбәп тә булгандыр...

Әйе, сүз бүгенге чорның геройлары, безнең заман геройлары турында бара. Барырга тиеш. Тик шуңа да игътибар итик: соңгы елларда бик күп әсәрләр—тарихка күз һәм йөз багып язылган романнар, повестьлар, хикәяләр, шигырь һәм поэмалар туды. Бу әсәрләр бүгенге көнгә үткән чорларның бик күп геройларын "алып кайтты", аларны, әгәр шулай әйтергә ярса, бүгенге заман геройлары ясады. Әмма бүгенге көннең герое... Ул үзе нинди соң? Кайсы әсәрләрдә? Кайда ул? Менә шушы сорауга җавап эзләгәндә безнең бу дискуссиядә катнашучы каләмдәшләребез темадан бераз читләшебрәк китте кебек. Дөресрәге, заман герое турында, әдәбияттагы бүгенге тема, проблема, жанр мәсьәләләре турында уйлануга караганда, күбрәк үткәнрәк чордагы әсәрләргә, аларның авторларына бәя бирү өстенлек ала башлады кебек. Без "Совет чоры" дип атаган гаҗәеп бер чорны тәнкыйтьләү, ул чорда туган әсәрләрдән "йөз чөерү", ничектер, кайбер язмаларда үзмаксат булып әверелде. Бәлкем, шулайдыр: бәхәс жанры, дискуссия жанры шундый "кискенлек"не таләп итәдер. Әмма без, заман герое хакында уйланганда үткән чорда язылган әсәрләргә мөрәҗәгать итәбез икән, иң беренче чиратта шул чорның үзенә бәя бирә белергә, шул чорның характерын истә тотарга тиешбез. Әдәби процесс—үсештәге процесс, аның тулы бер тарихыннан аерым-аерым өлешләрне йолкып алып та, өзеп ташлап та булмый. Шул ук вакытта әдәби процесс—җәмгыятьтәге үзгәрешләргә аеруча бәйле бер процесс, әдәбият үзе үк, әгәр дә инде бик фәлсәфи итеп әйтергә тырышсак, җәмгыять белән диалектик бәйләнештә яши. Димәк, иҗтимагый формация—әдәбиятка тәэсир иткән кебек үк, әдәбият та җәмгыятькә тәэсир итә һәм бу "тәэсир итешү" заманның характерына турыдан-туры бәйле бит! Йәгез, кайбер каләмдәшләребезгә ияреп, аларга кушылып без бүген "совет чоры"нда язылган (татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган!) әсәрләрдән йөз чөерсәк, бүгенге көннең геройларын тиешенчә күзаллый алырбызмы? Әгәр дә безнең сүз "коммунистик режим"ны тәнкыйтьләүгә генә кайтып калса, без әдәбиятның үзенә, әдәби әсәрләргә төпле, нигезле бәя бирә алырбызмы?

Менә шул җәһәттән минем дә бер язмага, танылган каләмдәшебез Айдар Хәлимнең "Беләмсез кая барганны?" дип исемләнгән ("Казан утлары", 2005, 2 нче сан) мәкаләсенә игътибар итәсем килә. Нәкъ менә югарыда әйтелгәнчә, Айдар Хәлим сүзне "совет чоры әсәрләренә ревизия" рәвешендә алып барырга тырыша. Аяз Гыйләҗев кебек әдипләрнең кайсыдыр әсәрләрен "30 елга сонарып язылган", "рус әдәбиятында бу тема күтәрелгәннән соң гына язылган" әсәрләр итеп бәяли, Әмирхан Еники кебекләрне исә "артык сак, сабыр" булуда тәнкыйтьли. Йа Хода, безнең әдәбиятның үз тарихы бар лабаса! Әдәбиятның гына түгел, һәр авторның әле әдәбиятка бәйле үз язмышы—тарихы бар.

"Казан утлары" журналына Ибраһим Салаховның "Колыма хикәяләре" килеп кергәнен хәтерлим. Бу әсәрнең басылачагын ишеткән Ибраһим аганың башта ни әйтергә белми каушап-аптырап калганын, аннан соң күзләреннән яшь бәреп чыкканын, елаганын хәтерлим. Бу әсәрне нинди икеләнүләр белән алып килгәнен, аны роман итеп түгел, хикәяләр итеп махсус язганын сөйләде ул һәм соңыннан бу хакта матбугатта да язып чыкты. Дөресрәге, инде бу әсәр "Тайгак кичү" исеме белән—"Казан утлары"нда, "Колыма хикәяләре" исеме белән аерым китап булып басылып чыккач, Бөтендөнья татарларының II Конгрессына кунак буларак килгәч, үзе урнашкан фатирда миңа әңгәмә-интервьюда сөйләгән иде моны Ибраһим ага. Лагерьдан котылып, Казакъстанга "спецпоселение"гә җибәрелгәч, "надзор" астында яшәп көн иткән чакларында шушы әсәренә тотынган Ибраһим ага аларны махсус "хикәя" дип атап яза. Теләсә кайсы вакытта—көндезен һәм төнлә—тентү белән килүләре мөмкин! Язылганнарны пыяла банкага салып, агач төбенә күмеп барганнарын сөйләгән иде Ибраһим Салахов. Колыма лагерьларының барлык "сынау"ларын үткән, дус-дошманның хыянәтен татыган шушы кешене, язучыны "соңга калып" язуда яки әсәрен сагаеп-сонарып бастыруда гаепләргә мөмкинме? Әле шул вакытта, "үзгәртеп кору"лар башланган, демократия һәм милли азатлык хәрәкәте үсеш алган көннәрдә дә Ибраһим ага бу әсәрен бик икеләнеп-сагаеп кына алып килгән иде, миңа калса!

Әлеге мәкаләсендә Айдар Хәлим әле аксакал әдибебез Әмирхан Еникине дә, кайбер рус әдипләре белән чагыштырып, шул ук "артык сак" булуда тәнкыйтьли. Мондый "саклык-сабырлык" характердан да, еллар буе тупланган тәҗрибәдән дә киләдер. Ничә кат үзебезнең авыз пешкән бар, җәмәгать: кайчак—уйнап, кайчак һаваланып, дигәндәй, бер-бер сүз әйтеп ташлыйсың, ә аннан соң ул сүз сиңа, синең саллы сүзең булып, үзенә килеп ишетелә. "Ah, без үзебез дә инде шактый еллар яшәгәнбез, безнең сүзне күпләр инде бик җитди кабул итә икән бит!"—дисең шуннан соң. Әйе, Әмирхан ага сак кеше—сүздә сак, иҗатында сак, язган мәкаләләрендә сак иде. Әле дә хәтерлим, аның белән газета өчен бер-бер әңгәмә оештырсаң, ул үзе мин эшләгән "Мәдәни җомга"га бер-бер мәкалә язса, әле шул язма чыкканчы бер ике-өч тапкыр шалтыратмый калмас иде. "Менә фәләненче биттә, фәләненче юлдагы шундый-шундый сүзне менә шундыйрак сүз белән алыштырып булмас микән?"—дигәндәйрәк итеп әйтер иде. Әле тагын кайбер урыннарда өтерне үзгәрттереп-алыштырып "җәфалар" иде. Сак кеше иде Әмирхан ага! Олпатларча сабыр, салмак, сак иде. Әмма, аңлавымча, Айдар Хәлим үз мәкаләсендә әдипнең үз характеры турында түгел, ә иҗатындагы сыйфаты турында сүз алып бара! Монда инде, минемчә, уйларга кирәк. Нигә без Әмирхан Еникинең "Әйтелмәгән васыят"ен генә телгә алабыз? Нигә без аның атаклы "Рәшә"сен, әле совет чорында чыккан һәм "сабитовщина" дигән исемнәр-ярлыклар барлыкка килүенә сәбәп булган, бәхәсләр тудырган әсәре турында онытабыз?

Татар әдәбиятының бүгенге көнен, хәл-халәтен, аның геройларын тарихи күзлектән чыгып бәяләү зарур, дидек. Бу мәкаләдә генә барысын да әйтеп бетерү, әдәбиятның узган гасырдагы аерым күренешләренә генә дә бәя биреп чыгу мөмкин түгел.

Әмма узган гасыр башында гына барлыкка килгән басма матбугатыбыз (ни өчен шулай икәнен беләбез бит!) ул чордагы милли азатлык хәрәкәте рус социал-демократларына никадәр ышанып-инанып кушылуын, моның тарихи сәбәпләрен аңламау артык беркатлылык булыр иде. Беренче татар газеталарыннан булган "Фикер"не, "Әлгасрелҗәдит", "Уклар" кебек журналларны чыгарган, Тукайның могаллиме-остазы булган, аның "Пар ат" шигыренә көй язган Камил Мотыйгыйның язмышы, мәсәлән, безнең ул чордагы, узган гасыр башындагы матбугатның һәм әдәбиятның язмышын да ачык чагылдыра кебек:матбага өчен көрәш, социал-демократларга, большевикларга кушылу, партиядән чыгарылу, репрессияләр... Әмма

шунысын да истә тотыйк: әле басма матбугаты туып кына килгән бер вакытта ук татарда әдәби хәрәкәт нинди зур күтәрелеш алган?! Сүз уңаеннан гына булса да әйтеп-билгеләп, янә бер кат раслап үтик: безнең татар халкы басма матбугат, басма әдәбият тыелган, рус патшалыгы басымы шартларында көн иткән чорларда да үзенең әкиятләрен, авыз иҗатын, гарәп һәм фарсы телләреннән кергән хикәятләрне телдән-телгә йөрткән, кулъязма китаплар итеп күчереп язган, бәет-мөнәҗәтләр әйткән. Безнең әдәбият үз геройларын үзенең авыз иҗатында саклаган, димәк, әдәби традицияләрне дә буыннан-буынга тапшыра килгән. Басма матбугат туугa ук үсеш алган әдәбиятның нигезе әнә шундый! Әмма эш бары тик шунда гынамы соң әле?! Ягез, шул ук репрессияләрне, Сталин чоры репрессияләрен, гомумән тоталитар режим шартларын искә төшерик. Шундый шартларда да яши алган әдәбиятта җирлек, таяныр нигез ничек яши алган? Йә, әйтегез: чорның үзен, аның барлык нечкәлекләрен ачык аңламыйча торып аерым бер шәхескә, бигрәк тә язучы кебек катлаулы шәхескә бәя биреп, объектив бәя биреп буламы? Татар халкы үзе, татар әдәбияты үзе үк рус халкыннан һәм рус әдәбиятыннан күбрәк кысылганлыгын кабатлап тору монда инде кирәкми дә кебек! Шуңа күрә, кабатлап әйтәм, "рус әдәбиятыннан соңга калып язылган" дигән сүзләр аша түгел, татар әдәбияты тарихында нинди әсәр тууы, нинди геройлар тууы хакында сүз йөртеп бирү кирәк бәяне—бигрәк тә үткәндә язылган әсәрләр хакында сүз йөрткәндә! Югыйсә, Айдар Хәлимчә яки башка кайбер авторларча фикер йөртсәк, безгә татар әдәбиятының тарихыннан ук ваз кичәргә туры киләчәк.

Әйтегез, әгәр дә татар әдәбияты үзенең "совет чорындагы әсәрләре" белән һәр өзеклекне ялгап килмәсә, Айдар Хәлим "шик белдергән" "Намус", "Алтын йолдыз", "Газинур" кебек әсәрләр, "соңга калып" язылган романнар булмаса, безнең бүгенге әдәбият туа һәм үсә алыр идеме, аның таяну ноктасы булыр идеме?

Айдар Хәлимнең мәкаләсендә, бүгенге заман герое турында бәхәс-дискуссия уңаеннан бирелгән язмасында, тагын бер урынсыз "дәгъва" бар. Монысы диссидентлык мәсьәләсе. Бу хакта аның ни өчен болай сүз куерткаНын да аңлау мөмкин түгел кебек. Әмма бер нәрсә аңлашыла: ул үзен шундый бер язучы, диссидент язучы итеп танытмакчы. Имеш, анда Мансур Барҗылы—Аяз Гыйләҗев, Мөдәррис Әгъләмовны заманындагы диссидентлар белән тиңләштереп язган да, "тоталитар режим һәм шовинизм белән аяусыз көрәшүче" Айдар Хәлимне әйтми калдырган. Әйтерсең, халкың өчен, милләтең өчен көрәшү дә, әдәбиятка хезмәт итүдә диссидент булу үзмаксат! Белмим, диссидент сүзенә билгеләмәне ул мәкаләсенә Айдар Хәлим нинди энциклопедиядән алгандыр, ә менә "Большая Российская энциклопедия" гыйльми нәшрияты, "Экономическая газета" нәшрияты йөрты 1995 елда чыгарган "Иллюстрированный энциклопедический словарь"да әйтелгән: "Диссидент—латин сүзеннән алынган (dissidentes), аның беренче мәгънәсе католик һәм протестант диннәре хакимлек кылган дәүләтләрдә христианнарның шушы диннәргә табынмавын чагылдыра, ягъни хакимияттә канунлаштырылган күренешләргә карата үзгә карашта торуны аңлата; икенче мәгънәсе исә болай: диссидентлар дип 1950 еллар азагыннан алып 80 нче еллар уртасына кадәр элекке социалистик илләрдә тоталитар режимга каршы чыккан, төрле юллар белән кешенең һәм гражданның ирегe һәм хокуклары өчен көрәшкән, Чехословакиягә (1968) һәм Әфганстанга (1979) совет гаскәрләренең кертелүен кискен тәнкыйтьләгән кешеләрне атыйлар. Аларны йә илдән куганнар, йә үзләре чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр булганнар, күпләре шпионлыкта гаепләнеп хөкем ителгән, кайберәүләрен мәҗбүри рәвештә психиатрик хастаханәләргә япканнар."

Ярар, бу соңгысы—56-80 еллар турындагысы—билгеләмә була алмый дип карыйк. Монысы энциклопедик сүзлекне төзегән авторлар һәм галимнәр ихтыярында калсын. Ә менә хакимияткә карата үзгә караштa тору мәсьәләсендә алар дөрес билгеләмә бирә. Һәм моның өчен һич тә чит илгә качып китү, яки ачлык игълан итү мәҗбүри түгел. Менә шулай уйласак, бездә диссидент дигән проблеманы куерту бөтенләй дә кирәкмәс күренеш дип әйтергә була. Ә чын әдип, чын шагыйрь—тарих мона шаһит—һәрчак хакимият белән бәхәстә булган. Һәм бу табигый күренеш. Кабатлап әйтәм: үз халкыңның бәхете өчен көрәштә үзенне диссидент дип атау һич тә мәҗбүри түгел!

Әлбәттә, соңгы вакытта модага кереп китте: кем теге, совет вакытында чит илгә чыгып качкан, дөресрәге, чит илгә "кунакка", гастрольләргә баргач шунда торып калган, ягъни сәяси качак статусын сорап алган—шулар диссидентлар, халык өчен көрәшчеләр. Рудольф Нуриевны әнә без ничек хөрмәт иттек, татар егете

Бөекбританиянен Корольлек балетында бии дип мактандык. Йә, шуннан ни?!.

Зур гына бер язучыбызның... ярар, исемен үк әйтеп сөйләшик—Рабит Батулланың—сөйләгәне бар: үзенә бик авыр елларда, бик тә кысылган бер вакытларда ул (70 нче еллар булгандыр) Яна елны каршылау төнендә Илһам Шакировның өенә килеп керә. Жырчы да берьялгызы, аның да эше-тормышы гел унай гына бармый. "Илһам, әллә син берәр чит илгә чыгып тайыйкмы?"—дигән сүздән соң Илһам абый, башын учларына салып, бик озак тын утыра һәм әйтә: "Монда да эшлисе эшләр күп бит әле",—ди. Менә шулай... Әлбәттә, Илһам Шакиров чит илгә чыгып качкан булса, ул инде бүген, мөгаен, дөньяның иң бай кешеләреннән саналыр иде. Әмма Илһам абый илен-халкын ташламады, ул милләт бәхете өчен шушы милләтнең янәшәсендә торып көрәште.

Әйе, татар әдәбияты зур тарихлы әдәбият. Аллага шөкер, 60 нчы еллар шигъриятенең бөтен егәрен күнелдән җуймаган шагыйрьләребез, аларның күбесе әле дә иҗат итә. Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Роберт Әхмәтҗанов, Рәдиф Гаташ, Гәрәй Рәхим... Юк, исемнәр санау үзмаксат түгел, ә бәлки аларның иҗат мәйданы үзәгендә булуына соклану һәм рәхәтлек хисе кичерүдән бу. Аллага шөкер, татар прозасы тарихи романнар белән баеды, хак тарихка сусап яшәгән халык, чыннан да, бу өлкәдә менә дигән "ликбез" мәктәпләре үтте. Мөсәгыйт Хәбибуллин, Флүс Латыйфи, Вахит Имамов... Аллага шөкер, драматургиядә без һич тә башка халыклар, башка әдәбиятлар арасында йолкыш хәлдә түгел! Юк, һич кенә дә.

Исемнәрне атау үзмаксат түгел. Әмма мин бүген заманның катлаулы образларын, геройларын—типик геройларын—үз поэмаларында аеруча табып ала белгән, калку итеп күрсәтә алган Ренат Харисны билгеләп узу кирәктер дип уйлыйм. Аның "Исемсезләр" шигъри романы бүгенге көннең сурәтен, әнә, сурәтләде дә салды.

Ә шулай да, "Казан утлары"ның бүгенге заман герое турында зур сөйләшү, бәхәс башлавы юкка гына түгел бит! Заман герое турында сүз башланган икән, димәк, сорау әдәбият алдында, бүгенге көн әдәбияты алдында куелган. Ә татар халкының бүгенге әдәбияты (матбугатлы һәм матбагалы әдәбият—тарихын җуймый саклый белгән әдәбият!) заманның башка халыклары әдәбияты белән ярышырдай әдәбият. Димәк, таләпләр зурдан. Әмма... Әйткәнемчә, бер татар әдәбияты гына түгел, башка халыкларның әдәбияты, сәнгате бүгенге чорда зур кризис кичерә. Аурупа мәдәнияте исә, шул ук АКШларның рухи дөньясы тотнаксызлыкның иң хәвефле бер өзегенә килеп керде. Алай гына булса бер хәл, бу әхлаксыз мәдәният, "базар шартлары" булып, безнең мәдәниятка дә өлге тага, өлге-калып булып килеп керә. Мондый өлгегә бары тик безнең мәдәният, безнең әдәбият, үзенең тарихи тәҗрибәсенә, үзенең рухи тәҗрибәсенә таянган, таяна белгән, һәр үткән чордан йөз чөерергә һәвәсләнмәгән әдәбият кына каршы тора ала.

Күпме сүз, күпме вакыт "әрәм китте", ә "бүгенге заман герое" турында әйтеп бетереп булмады кебек. Кайда соң ул, безнең заманның герое? Кайда ул? Бәлки ул, әнә, Балтачтан язып яткан Әхәт Фазылҗанов дигән авторыбызның "Флюгер" дигән хикәясендәдер? Әйе, мәктәп балаларына физика дәресендә Флюгер ясаткан (жил искән якка борылучы прибормы әле ул?!) укытучының—ураза тоткан бер баланы бөтен класс алдында кимсеткән-рәнҗеткән укытучының—бүген мәчет карты булуын хикәяләгән вакыйгадамы ул герой?.. Йә булмаса... Әлеге дә баягы, матбугатта шактый макталган, дөресрәге, "макталырга хөкем ителгән" әсәр—Мөслимдә яшәп ятучы, язучы Фоат Садриевның "Бәхетсезләр бәхете" романындамы? Әмма, ни гаҗәп, Ф. Садриевның ни макталган шушы романындагы проблемалар һәм геройлар да бер нәрсәдән—"Коммунистик җәмгыятьне сугү"дән уза алмады. Заманның герое, минемчә, кабатланмас язмышлар, кабатланмас характерлар аша ачылырга, табылырга тиеш. Ана, әлбәттә, төртеп күрсәтеп тә, "Әнә ул, Заман герое!" дип әйтеп тә булмаячак. Ул герой безнең арабызда йөри, яши, матбугатта, телевидениедә чыгыш ясый, безнең белән бер табын янында утыра—аны таба белергә, таный белергә, образлы итеп сурәтли белергә һәм, заманның типик герое итеп, әдәбият тарихына "чәпеп" куя белү генә кирәк. Ә монысы инде, гафу итәсез, теләсә кемнең кулыннан килмәскә мөмкин. Без заман героен шуңа күрә эзлибез дә. Югыйсә, әйткәнемчә, алар безнең арада яши, әллә кая китеп эзлисе юк, барысы да монда янәшәдә...

**Нияз АКМАЛ**

Хәтер
Хәтер

Равил
Фәйзуллин

# БАТМАСКА ТУГАН БАТТАЛ

Яңа салынган күпер аша Каманы чыгып, Биләр якларындагы атаклы Изгеләр тавына бару юлында Зур Тигәнәле авылы кала. Исеме—Шәле, Әлдермеш, Кырлай кебек телдә гел яңгырап тормаса да, үзенчә данлы авыл ул. Ерак тарихи тамырларны барлап тормыйча, бер генә факт та шуңа дәлил була ала: биредә, үткән гасыр башында Вазих исемле агайның өч угъланы туган—Салих, Абдулла, Мөбарәк. Соңрак татар халкына дан китерә торган шәхесләр—шагыйрь, музыкант, каһарман солдат (һәр өчесе дә заманында солдат булып сугышта катнашкан, Абдулла дигәне Җәлилләр белән көрәштәш булып һәлак була). Тигәнәлене үтеп киткәндә миндә һәрчак сораулы уйлар туа: авыл халкы үзенең данлыклы уллары белән тиеш дәрәҗәдә горурлана микән? Без—язучы-сәнгать кешеләре—аларны тиешенчә зурлый-бәяли алдыкмы? Һәм, ниһаять, яшь буыннар алар турында яхшы беләме? Сорауның беренчесе турында кистереп әйтә алмыйм, әмма соңгы икесенә җавабым шул: юк, тиешенчә бәһали дә



алмадык, алар турында килер буыннар аңына тиешенчә сеңдерә дә алмыйбыз шикелле. Бу сүзләрне иң элек Салих Баттал мисалын күз алдында тотып әйтүем, утыз елдан артык әдип белән азмы-күпме аралашып, иҗатын беркадәр белгән каләмдәше буларак фикер йөртүем.

Исән булса, быел аңа йөз яшь тулган булыр иде. Салих ага Баттал туксан ел яшәп, моннан ун ел элек гүр иясе булды (хезмәттәшебез, шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов белән бер көннәрдә вафат булды ул). Салих Баттал гомере буе кабатланмас зур шәхес булып яшәде, зур шәхес булып иҗат итте, соңгы көннәренә кадәр үз вөҗданына, үз иманына тугрылыклы булып кала алды. Бездә Ходайдан талант бирелгән каләм ияләре шактый, әмма аларның һәммәсен дә зур шәхес дип тану кыен. Асылда, фәкать зур шәхес кенә тормышта тарихи эз калдыра аладыр ул. Салих Баттал, әйтелгәнчә, XX йөз башында дөньяга килгән. Искә төшерик: әдәбиятның киләчәген белдерәчәк кемнәр туган дәвер соң бу? Г. Бәширов, К. Нәҗми, М. Җәлил, Х. Туфан, А. Шамов, Ш. Маннур, Ә. Ерикәй... Болар—С. Батталның яшьтәшләре, чордашлары, буындашлары. Иҗатлары да саллы һәркайсының. Рәсми яктан да киң танылу алган (дөрес, кайберләре үлемнәре аша, төрмә-сөргеннәр аша...) әдипләр. Кайсы—герой-каһарман, кайсы—югары дәрәҗәдәге депутат, кайсы—лауреат, кайсы—рәис-житәкче, кайсы—яшьләй үк орденлы шагыйрь... Ә Салих Баттал? Ул да танылу алды. Шөһрәтле рәсми исемнәрсез, үзе булып, шәхес булып, Салих Баттал булып кала алды. Алмый ни! Ике метрлы мәхәббәт буй-сын, курку белмәс холык, халыкчан талант... Табигать аңа күпне биргән булган. Ул үзе дә бу дөньяга кем булып туганын яхшы белеп яшәгән, күрәсең. Кемгә дә баш

имәде, кеше ireгeн тыйган тәртип-кануннарга җайлашмады. Сирәк очрый торган шәхес. Яшәү рәвешендә һәм иҗатында төп сыйфат-билгеләрнең берсе—колачлылык, масштаблылык, туры сүзлек, хөрлек... Аңлашыла да, уналты яшеннән үк нык бәдәнле үсмер Мәскәү якларында батрак-зимагурлык мәктәбен үтә, егетлек чорында Ленинград, Оренбургларда укып, очучы-летчик була, әдәби иҗат белән актив шөгыльләнеп, әсәрләрен бастыра... Үзе яшь, үзе очучы, үзе язучы. Экзюперидән кай җире ким! Өстәвенә, беренче буын Совет язучысы, 1934 елдан СССР Язучылар Союзы әгъзасы.

Салих Баттал күпкырлы талант иясе. Ул—шагыйрь, прозаик, драматург, балалар язучысы, сатира-юмор остасы, тәрҗемәче. Шулай да, минемчә, әдәбият тарихында шагыйрь һәм прозаик булып калачак ул. Заманында пьесалары академия театрында спектакль итеп куелса да, аны драматург буларак яхшы беләм, дип әйтә алмыйм. Театр белгечләре төгәлрәк әйтер. Чәчмә әсәрләреннән иң билгеләләре—"Сигезенчесе кем?" һәм "Баштан үткәннәр" дигән повестьлары. Беренчесендә—беренче бишьеллыклар һәм Ватан сугышы чорында яшь очучының катлаулы язмышы сурәтләнсә (повесть детектив әсәрләргә хас мавыктыргыч сюжетка корылган), икенчесендә—"Баштан үткәннәр" дигән автобиографик әсәрдә, автор, гомеренең истәлекле, кызыклы вакыйгаларын искә төшереп, ил һәм чор турында уйлануларын, заманының атаклы шәхесләре В. Чкалов, А. Фадеев, Г. Ибраһимов белән очрашу тәэсирләрен бәян итә. Татар әдәбияты тарихында гыйбрәтле әсәрләр алар.



*Муса Җәлил һәм Салих Баттал. 1929 ел.*

Салих Баттал, беренче нәүбәттә, әлбәттә, шагыйрь, эпик жанрларны иярләргә сәләтле фикерле шагыйрь, халыкчан шагыйрь. Үткән гасыр урталарында ул үзен шулай итеп таныта алды да. Совет чорындагы шагыйрьләрдән беренчеләрдән булып бөтенсоюз масштабында яңгыраш алды. "Олы юл буйлап (икенче исеме "Газзә") шигъри повесте "Новый мир" журналында басылып чыкты (сирәк хәл!). Аның иҗаты турында А. Твардовский кебек олуг шагыйрьләр язып чыкты. 50 нче еллар башында ул, мөгаен, татар поэзиясенең иң алдынгы сафындагы кеше булгандыр. Шул чорны фаразлап карыйк: поэзиябезнең горурлыгы булачак С. Хәким, Н. Арслановларның чын талантлары ачылып кына килә; Х. Туфан, М. Җәлилләр халыкка әле кайтмаган... Дөрес, Ф. Кәрим иҗаты да бик популяр иде ул чорда.

С. Батталның иң күренекле әсәре, әлбәттә, "Чирмешән яклары" исемле шигъри романы. Соңгы дәвердә язылган беренче шигъри роман ул. Ни өчен соңгы дәвердә дим, чөнки ул рәткә борынгы чордагы "Кыйссаи Йосыф", "Идегәй"ләрне дә шигъри романнар рәтенә кертергә буладыр. Заманында шигъри повесть, шигъри роман дип аталган озын әсәрләр чыккалады бездә: Ш. Маннурның "Җир-әнкәнең сылу кызы", Ә. Давыдовның "Йокысыз төннән соң"... Әле күптән түгел генә Р. Харисның "Исемсезләр" дигән күләмле әсәре аерым китап булып дөнья күрде. Бу әсәрләрнең кайсы—әдәби факт, кайсы—вакыйга, кайсы—казаныш икәнен Вакыт галиҗәнапләре әйтә килә һәм әйтәчәк. С. Батталның "Чирмешән якларында", жанр ягыннан ничек кенә дип аталмасын, классик әсәрләр рәтенә керергә лаек, минемчә. Р. Даутов, Н. Нуруллиналар төзеп чыгарган "Совет Татарстаны язучылары" дигән белешмәдә (1986) бу әсәр турында мондый юллар бар: "халык җырларының форма үзенчәлекләреннән оста файдаланып язылган, шигъри детальләргә, үзенчәлекле

күренешләргә, отышлы драматик ситуацияләргә бай булган бу әсәр 1905-1921 еллар арасындагы татар авылының катлаулы тормышын, кискен сыйнфый каршылыкларны, халык массаларының азатлык өчен көрәшен сурәтли". Дөрес әйтелгән. Шуны гына өстисе килә: бу әсәр яңа буын шагыйрьләренә осталык мәктәбен үтү өчен менә дигән кулланма да. Халык иҗатын үз әсәрләрендә менә ничек итеп оста файдаланып була икән! Мәңге өйрәнерлек "Идегәй" чалымнары бар бу әсәрдә.

Гомумән, Салих ага Батталның яшәү рәвеше дә, иҗат алымнары да, мирасы да гыйбрәт-сабаклар алырлык. Кодрәтле генга ия булып яратылу, җирне-күкне бер итеп дигәндәй Алыпларча яшәү, сөю-сөелү һәм гаилә фаҗигаләре, рухи маяк-ориентирлар билгеләгәндә ялгышулар, үзе инанган принциплар өчен кирәк-кирәкмәскә көч түгүләр... һәм финал—ялгыз картлык (ни кызганыч, күктә очып янмаган, җирдә батмаган Салих ага ятакта, җылыткыч рефлектордан одеалына ут кабып, ис һәм ялкыннан буылып үлде)...

50 нче елларда әдәбият каһарманы булган Салих Баттал, гомеренең икенче яртысында әлек алынган иҗади темпны саклый алмады. Совет-партия системасы корган күпсанлы барьерларны җиңәргә тырышып бихисап вакыты әрәмгә китте аның. Ахырда, Вакыт һәм Система баш бирмәс Батталны да "почмакка терәде". Бирелүен бирелмәде Баттал, әмма кирәкмәгән ыгы-зыгы аның иң кадерле вакытын ашады, иҗат көчен таркатты, талантының тиешенчә үсүенә ирек бирмәде... Ул гына да түгел, заман идеологиясе басымы сәбәпле, әдипнең иҗаты тиешенчә өйрәнелмәде һәм бәяләнмәде. Әдип иҗатын җитди өйрәнгән фәнни хезмәтләр юк дәрәҗәсендә.

Замандаш каләмдәшләренең күбесе аңа битараф булдылар. Күпләр әдип гамәлләрен эчтән генә хупласалар да, аның белән ачыктан-ачык фикердәш булудан курыктылар. Дөрес, бик сирәк булса да, үзе исән чакта ук аңа уңай мөнәсәбәт белдерүчеләр дә табылды. Мәсәлән, 1990 нчы елда А. Гыйлаҗев матбугатта язып чыкты: "Кичерә алсаң, кичер Салих ага! Без синең арттан килүче, аз-маз кыен ашаган кешеләр дә сиңа терәк була алмадык! Безгә сабак, бездән соң килүчеләргә акыл бу!" Икенче бер зур әдип—И. Нуруллин "Казан утлары"нда (1993 ел) болай дип чыгыш ясады: "Салих Батталның шагыйрь буларак, бүгенге көнгә кадәр тәнкыйтьтә үзенең тиешле бәһасен алганы юк. Мин, шәхсән, совет чоры поэзиясеннән өч шагыйрьнең исемен атагыз дисәләр, Такташ, Туфан, Салих Баттал дияр идем".

Үзе исән вакыттагы кебек, хәзер дә аның иҗаты турында каршылыклы фикерләр ишетелә. Менә кичә-бүген генә әйтелгән кайбер яңа искәртүләр. "Безнең заман герое" дигән бәхәс уңаеннан Айдар Хәлим болай яза: "Безнең диссидентыбыз, бердәнбер диссидентыбыз—бөек шагыйребез Салих Баттал иде... татар шагыйрьләренең Тукайдан кала беренче бишлегенә керә торган сирәктән-сирәк шагыйрь". Ә тәнкыйтьче Р. Мостафин аңа каршы килеп: "...һич тә бөек дип атап булмый. Шигъри осталыгы чамалы, метафоралары сай, поэмалары артык озын һәм күбесенчә коры сөйләмгә корылган. Беренче бишлеккә түгел, егерменче бишлеккә дә керүе шикле *("Казан утлары"". 2005 ел, 5 сан)*.

Менә шулай... Хәер, кем ни сөйләмәс! Атаклы җырчы Рафаэло турындагы фильм исеме искә төшә: русчасы "Пусть говорят". Сөйләнсеннәр сәнә! Әдәбиятчы галимнәргә кайсы киштәгә, кайсы бишлеккә кертәсе турында баш ватканчы, әдипнең мирасын җыеп тупларга, томлыкларын бастырып чыгарырга булышырга иде! Юбилей уңаеннан табигый бер сорау: кайда икән Салих Баттал архивы? Бармы ул? Булса, ышанычлы кулллардамы? Әйтик, шагыйрьнең "Батый ханга хат" дигән поэмасының тулы варианты кайда икән? 80 нче елларда Себердә чыга торган "Байкал" журналында кыскартылган, тәрҗемә варианты чыккан иде. Үз телебездә басыла алмады шикелле ул поэма. Гомумән, С. Баттал иҗаты белән бәйләнешле сораулар байтак һәм алар әледән-әле чыга тора. Яшәве галәти, иҗаты шома булса, бәлки, сораулар, каршылыклы фикерләр азрак булыр иде.

Алда әйтеп үткәнчә, С. Баттал иҗаты бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Төрле елларда аз-маз күренгәләгән мәкаләләр, нигездә, юбилей даталары уңае белән язылганнар. Р. Мостафинның шактый кискен сүзләреннән соң, мин кулым җиткән

кадәр С. Баттал турында монарчы язылганнарны барлап чыктым. Әллә мин әйтәм, шагыйрь иҗатын кирәгеннән артык бәялимме (чыннан да, С. Баттал иҗатында бәйләнерлек нәрсәләр җитәрлек!)? Бүтәннәр ни уйлый. Үзебезнең журналда моннан ун ел элек әдип турында мондый сүзләр укып тынычландым тагын: "Салих Баттал— егерменче гасыр татар әдәбиятының иң мәртәбәле олы исемнәреннән берсе саналырга хаклы... Ул—безнең чор тормышын бөтен каршылыклары белән тулы чагылдырган күпсанлы шигырьләр, поэмалар, шигъри һәм чәчмә повестьлар, драма әсәрләре авторы. Ул, барыннан да бигрәк, халкыбыз, аның милләт буларак яшәве өчен иң кыен чорларда да каһарманнарча көрәшкән бунтарь, үзе дә легендага әверелгән зур шәхес" *(редакцион кереш мәкаләдән өзек).*

Язмамны Вазыйх атлы агаиның Зур Тигәнәле (кайбер язмаларда Олы Тигәнәле дип йөртелә) авылында туып-үскән өч улы турында әйтеп башлаган идем. Алда искәрткәнчә, бер улы—Абдулла дигәненең 1944 елда Җәлилләр белән бергә башы киселә. Салих абый моннан ун ел элек вафат булды. Мөбарәк дигәне—татарның атаклы гобойчысы әле исән дип беләм. Күреп танысам да, уйнавын ләззәтләнеп тыңласам да, шәхсән таныш түгелмен. Азмы-күпме аралашканым Салих ага булды. Ул чак яшьрәк булганмынмы, әллә акыл шәрифләре җитеп бетмәгәнме, аның белән дә аз очрашылган. Күп нәрсәләрне сораштырасы калган да бит!.. Шулай да Салих ага Баттал турында кайта-кайта уйланылган икән! Аңа бәйләнешле моннан 12 ел элек язылган истәлек язмам да бар. Бүгенге сүзләремә өстәп, аңсын да укучыларга тәкъдим итәм. Кемнәргәдер, бәлки, гыйбрәтле булыр.

*Июнь, 2005 ел.*

---

## ТАЛАНТНЫҢ КОДРӘТЕ ЧИКСЕЗ...

"Мин монда бер булган идем күк..." дигән шикелле, бу кульязманың тулырак вариантын (беренче нөсхәсе иде шикелле) егерме еллар элек бер күреп калган идем инде. Ни өчен күреп кенә калганмын? Эш болай булды. 1973 елның мартлары. Язучылар союзында җаваплы сәркатип (хәзергечә—рәис урынбасары) булып яңа гына эшли башлаган көннәр. И. Гази кинәт үлеп киткәннән соң, идарә рәисе булып З. Нури эшләгән дәвер бу. Көннәрнең берендә Зәки абый: "Бу папканы син дә карап чык әле!"—дип кулыма шактый ук күләмле бер кульязма тоттырды. "Салих Батталныкы бу. Мәскәү редакциясеннән җибәргәннәр (кайсы редакциядәнлеге хәтердә калмаган). Әсәрне оешмада тикшереп, авторга фикер җиткерүебезне сораганнар, мондый әйберне без баса алмыйбыз, дигәннәр". Эш бүлмәмә алып чыгып карый башладым. Сәер язма. Урыс телендә. Титул биткә Салих Баттал дип түгел, Иванов Иван Иванович дип куелган. Исеме—"Я отрекаюсь (исповедь)". Кульязманың бер битендә гәзитә-журналлардан алынган вак-вак кисемтәләр җилемләнгән. Кызыксынып укып киттем. Бәй, без укып күнеккән публицистика түгел икән бит бу! Кайбер абзацлары сискәндереп үк җибәрә. Ай-һай хәтәр юллар, башкитәр фикерләр! Мондый уйлар күпмедер дәрәҗәдә безнең һәммәбездә дә бар барын... Тик болай итеп әйткән юк та, яза алган юк. Кара, без алтын манаралар итеп күргән офыклар, рәшә-мираж гына түгелме соң? "Безнең иман—коммунизм!" дип басып торган нигезебез, мәрмәрдәй нык өслелектән бигрәк, тымызык бер сазлык кына түгелме соң?

Шул ук көнне идарә утырышы булды, соңрак бүлмәмә Илгиз Хәйруллин килеп керде. Партия өлкә комитетының культура бүлеге инструкторы, бүлекнең иҗат оешмалары белән эш итүче кураторы иде ул. Әзрәк сөйләшеп утырдык. Минем "җаваплы урында яңа кеше буларак" эшләрем белән кызыксынды. Өстәлдә ачык килеш яткан кульязма да күзгә төртелде. (Ул вакытта андый әйбернең күз төшәрлек җирдә түгел, өстәл тартмалары тирәсендә торуы яхшырак булгандыр, бәлки.) Куль-

язманы кулына алып, кайбер битләренә күз салгач, ул да тәэсирләнеп, кызыксынып китте. Бәлки, З. Нури аңа әлеге әсәр турында алдан әйткән дә булгандыр? Тик анысын тәгаен белмим. "Кая, мин дә укып чыгыем әле!"—диде ул. Хәзер кайтып уйлап карыйм: бирергә тиеш идем микән мин ул кульязманы? Шунысы шиксез—әүвәл, әлбәттә, үземнең укып чыгуым кирәк иде! Партиянең өлкә комитеты вәкиле кызыксынгач, аның укып алуы ул заман этикасы өчен табигый нәрсә иде. Житмәсә, Илгиз—замандаш, күп нәрсәләрдә фикердәш, әдәбият-сәнгатьне, кешеләрне яхшы белә. Төрле оештыру эшләрендә гел кинәшеп эшлибез... Болары—шулай шулаен. Кызганычы шул: кульязма миңа бүтән әйләнеп кайтмады, 20-25 битен укыган килеш өзелеп калдым. Дөрес, атна-ун көннән соң кире сорап карадым мин аны. "Ул папка хәзер Вәлиевтә",—дип җавап кайтардылар. (М. Вәлиев—Брежнев хакимияте чорында байтак еллар Татарстан Партия өлкә комитетында идеология буенча секретарь булып эшләде. Тарих фәннәре кандидаты. 1993 елда вафат.) Укырлар да әсәрне Союзга кайтарырлар дип йөрдем. Әмма мондый наив ышанычым юкка булган. Кульязма КГБ киштәсенә барып кунаклаган икән. Берәр айдан соң Бауман урамындагы Союз катларында әлеге оешма хезмәткәре капитан Хужахмәтов пәйда булды. Базык гәүдәле, башкорт чырайлы, ипле генә татарча сөйләшә торган кеше иде ул. ("Иде" диюем дөрес үк булмас: ул соңрак Казаннан Түбән Камага китеп эшләде, хәзер, мөгаен, пенсиядәдер.) Хужахмәтов миңа турыдантуры болай диде: "Салих Батталның кульязмасын Язучылар союзы КГБ карамагына тапшыра" дигән белешмәне басып, кул куеп бирегез!". "Андый язуны бирә алмыйм, чөнки сез эшләгән оешмага бернинди кульязма биргәнем юк",—дидем. Ул кабат миңа нәрсәдер әйтте, аннары дивана затка караган кебек карап торды да беркавым, күршедәге рәис бүлмәсенә кереп китте. З. Нури ялдамы, командировкадамы булып, аның вазифасын вакытлыча Гази Кашшаф башкара иде. Эшне тиз тоттылар алар, 15-20 минуттан кирәкле белешмәне машинистка ханым басып та бирде. Гази ага кушканны бик тиз үти белде. Авыр туфрагы җинел булсын!.. Шулай итеп, кем маллары кая китми дә, кемнәргә генә барып җитми икән... Күнелдә авыр тойгы калдырды бу вакыйга. Вакыт-вакыт гел искә төшеп җанымны кыйнады. Авторда яки дусларында берәр нөсхәсе сакланып калды микән? Бу аяныч вакыйга турында сер сыйган каләмдәшләремә дә әйткәләгән чаклар булды. Ни дисән дә, бу әсәрнең эзсез югалуында минем дә өлеш бар бит! Минем кулымнан да үтте бит ул. "Гаепсездән гаепле генә син", дип үземне юаткаласам да, әрнүле хис барыбер калды. 1989 елның ахырында бу әсәр турында Салих абыйның үзеннән дә сораштым, әмма ул, көлемсери төшеп, "кайчандыр бер язган идем бугай", дип кенә җавап бирде һәм сүзне бүтәнгә борды... Мин, ирексездән, 70 еллар ахырында аңа багышлап язган (соңрак китапларда да басылды) дүртьюллыгымны кабатлап куйдым:



*Салих Баттал «Казан утлары» журналы редакциясендә. 1991 ел.*

*...Бу дөньяда шуыша да*
*белми бит ул, булмаган!*
*Ул очар өчен туган шул,*
*сөйрәлергә тумаган!*

Шулай да моның белән генә бетмәде әле бу әсәр тарихы. Яшьлектә бер югалтып, сонрак янә табылган кадерле кеше шикелле, язмыш кабат очраштырды мине бу кульязма белән. 1993 елның сентябрь аенда, "Идел" журналында утырганда баш мөхәррире өстәлендә икенче данәсе ята иде. "Кайдан? Ничек? Кемнән?" кебек өзек-өзек дулкынланып әйткән сорауларыма Фәиз Зөлкарнәй тыныч кына: "1994 елның башында басып чыгарырга әзерлибез",—дип җавап бирде. Бу әсәрне мин моннан егерме еллар элек белгәнемне, югалту тарихына "өлеш керткән шаһит" булуымны ишеткәч, ул минем шул хакта кереш сүз итеп язып бирүемне үтенде. Бу юллар шуңа җавап рәвешендә язылдылар да инде.

Сүз уңаеннан өстәп шуны гына әйтәсе килә: ачылып, өйрәнелеп, бәһаләнеп бетмәгән олуг шәхес, олуг талант иясе ул Салих ага Баттал. Якты дөньяда 90 нарга хәтле камил акыл белән яшәп, шул гомереннән 60 елдан артыгын актив иҗатка багышласа да, аның иҗаты системалы рәвештә өйрәнелмәгән әле. Шагыйрь буларак та, проза остасы һәм драматург буларак та. Кем гаепле соң? Әлбәттә, үзе! Талант кадерен белә торган заманда туа белмәгән, тоталитар режимга яраша алмаган, вөҗданына хыянәт итмәгән, башын имәгән, сүзен бирмәгән... Ул заманның әдәби даирәсендә Ә. Еники "ялгыз каз" саналып йөртелсә, С. Баттал—үзе әйтмешли, "Тигәнәле тилесе" булып кала бирде. Замандаш каләмдәшләренә—ул заманның түрендә хөрмәттә йөргән чордашлары да, Салих ага башына хакимиятнең идеологик чукмарлары төшкән чакта, аны яклап, саклап кала алдылар, дип әйтмәс идем. Күбесе читтә торды, "диссидент корымы" тиюдән сакланды. Әмма яшьләр (70 елларда әдәбиятка килгән буынны әйтәм) арасында аның дәрәҗәсе һәрчак зур булды. Нәрсә генә димәсеннәр, ул безгә легендар шәхес булып тоела иде. Ике метрлы мәһабәт гәүдә, кыю очучы, оригиналь язучы, оратор, җыелышларда түрәләрдән Се—Ге—Бе (ТАССР Югары Советы Президиумы председателе С. Г. Батыев күздә тотыла) сүзләре белән көлә ала торган шәхес... Дөрес, үз заманының аерым бер рухи күзәнәге буларак, режим юлбашчылары чыгарган теорияләргә, тәгълиматларга ихлас ышанып, утопик хыяллар белән рухланып, артык мавыгып киткән чаклары да булды әдипнең. Мәсәлән, ул үзен партиядән чыгаруны бик авыр кичерде. "Коммунист" төшенчәсе аның өчен изге булган, күрәсең. Партия сафларына яңадан торгызылу артыннан байтак йөрде ул. Ленин хезмәтләрен яхшы белде. Цитаталарны яттан сибә генә иде. Гасырларның байтак акыллылары үз вакытында "яхшы патшага" ышанган кебек, Салих ага да Ленинга бик ышана, аның өйрәтмәләрен бозалар, шуңа күрә дә милли мәсьәлә дөрес бармый, дип еш кына тәкрарлый иде. Хәер, кем белә! Бәлкем, ялгышамдыр. Талантның кодрәте чиксез, диләр бит.

*1993.*

Гэп
Фэн

**Адлер Тимергалин**

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***МӘНЗИЛ*** *г.* — **1.**Туктап китә (төшә, иңә) торган урын, тукталыш, станция, бивак; утрак, этап. Мәсәлән, X-XI гасырларда кәрваннар йөреп торган Болгар-Киев юлында (1500 км) андый мәнзилләр 20 ләп булган дип уйлыйлар. Татарстандагы *Минзәлә* шәһәре атамасы да шушы "мәнзил" сүзеннән дип санаучы галимнәр бар, ләкин бу фикер тиешенчә нигезләнми сыман. Көнбатыш Себер татарлары Төмән тирәсендәге Ембай юрталарын *Малчын* (Малцын) дип атыйлар һәм бу атама таҗиклар һәм үзбәкләр аша килеп кергән мәнзил сүзенә барып тоташа. Төмән өлкәсендә Манҗил дигән авыл булуы турында Габдрахман Таһирҗанов та яза.

"Мәнзил" сүзе сәяхәтчеләр өчен кунакханә, отель мәгънәсендә көнбатыш Европа телләренә дә кергән булган.

**2**.Йорт, торак; квартира. // *Мәнзил әл-камәр*-Ай торагы (тукталышы, станы). Күк экваторы путасында Айның еллык эклиптикасында урнашкан 28 йолдызлар төркеме яки аерым йолдызлар. Аларның һәркайсында Ай 13 көн тора.

// *Савым сыер мәнзилендә*—савым сыер урынында ("төшемле" мәгънәсендә).

***МӘРАСИМ*** *г.* — Рәсмиләштерелгән йолалар, гадәтләр; ритуал, церемония; тантана. // *Мәрасим нә ирер, аны белеп кит, Гавам итмеш аны мәзһәб вә миллэт.* Утыз Имәни. *Мәрасим рәсүлия*-пәйгамбәр гадәте. *Дини мәрасимнәр* үтәү. *Татар мәктәбен ачу мәрасиме.*

***МӘСИХИ ЕЛЫ*** *гт.* — Христиан елы. // *Мәсихи ел исәбе. Тарихи мәсихийәтин сәнәти 1775 елда*—христиан елы исәбендә 1775 елда.

***МӘУЛА*** *г.* — **1**.Ия, хуҗа. **2.**Аллаһының эпитеты. 3.Дус.

Р.Әхмәтьяновның "Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге"ндә гарәпчә "мәүла" сүзенең "күп укыган, күкрәге гыйлем белән тулы" мәгънәсе дә теркәлгән.

Күплек саны шәкеле-*мәвәли*. Урта гасырларда Ислам хәлифәте киңәйгәч, күпсанлы халыклар мөселманлыкны кабул иткәннәр. Мөселманнарның менә шушы яңа сыйныфы *мәвәли* дип аталган. Алар гарәпләр белән тигез хокуклы дип саналсалар да, асылда икътисади яктан да, иҗтимагый яктан да түбәнрәк торганнар (аларга салым күбрәк салынган, хезмәт хакы да азрак булган).

*Мәүля, Мәүлә* язылышлары да очрый.

***МӘХӘЛЛӘ*** *г.* — Гадәттә берәр мәчет урнашкан һәм мөселманнар яши торган квартал, *балиг.* Хәзерге вакытта Татарстанда 1000 ләп мәхәллә бар дип исәпләнелә, ә 20 нче елларда 2 200 мәхәллә булган.

Киңрәк мәгънәдә башка дин кешеләре яки берәр груһ, төркем яшәгән урынга карата да мәхәллә дип әйтелергә мөмкин. // *Тәләбә мәхәлләсе*—студентлар кварталы.

Болгариядә һәм Югославиядә күп кенә авыллар *махала* (төрекчә *мәхәллә* сүзеннән) дип атала. "*Махал*" тамыры Испаниядәге күп кенә җирле атамаларга да керә (мәс., *Махалквивир, Махараталам*).

*Мәхәлләнең* күплек саны шәкеле — *мәхәллат.*

---

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2004 елның 1нче санында.*

***МӘХЛУК*** *г.* – Җан иясе; яратылмыш зат. Күплеге: *мәхлукат.*

Мәхлукат дигәндә гадәттә һәртөрле хайваннар, кош-кортлар вә җанварлар күздә тотыла. Адәм углы инсаннарга никадәр мәрхәмәтле булса, хайваннарга һәм кош-кортларга да мәрхәмәтле булырга тиешле. Тарта алмаслык рәвештә йөк төяү, арыган хайваннарны кыйнау, зарарсыз җанварларны сәбәпсез вә заруратсыз, бәлки кызык итеп кенә үтерү, колак вә борыннарын кисү, иреннәрен тунау, ут белән газап итү, кошларның канатларын йолку вә аякларына җеп тагып җибәрү, этләрне вә үгезләрне ирештереп сугыштыру кебек нәрсәләр һәрберсе Ислам дине каршында тыелган (Ризаэддин Фәхреддиннән). Хайваннарны рәнҗетеп вә газаплап ләззәтләнүләр адәмлек түгел, бәлки вәхшилектер.

***МЕҢУЗ-МЕҢУЗ*** *бор.төр.* – Мәхмүд Кашгарыйның "Диване лөгатет-төрк" сүзлегенә теркәлгән борынгы балалар уены – *мөгез-мөгез.* Балалар су буена чүгәләп утырганнар. Узаманнары: "Мөгез-мөгез", – дип, уенны башлап җибәргән. Калганнары: "Нәрсә мөгезе?" – дип сораганнар. Узаман мөгезле хайваннарны санап киткән, башкалар аның артыннан кабатлаганнар. Әгәр дә узаман берәр мөгезсез хайванны атап та уенчыларның берәрсе аны кабатлап әйтсә, аны суга төртеп төшергәннәр. Кыскасы, бу уен хәзерге "Очты-очты"га охшаган булган.

***МЕШЧАННАР*** – "Мешчан" (рус телендә *мещанин*) русча "место" сүзенә барып тоташа, ягъни асылда "бистәнекеләр" мәгънәсенә ия. 1775-1917 елларда Россиядә элекке бистә кешеләреннән торган ясаклылар катлавы (һөнәрчеләр, вак сәүдәгәрләр һәм йорт хуҗалары) шулай аталган. Мешчаннар торган урыннары буенча җәмгыятьләргә (общиналарга) бүленгәннәр, аларның билгеле бер дәрәҗәдә үзидарә хокукы булган. Мешчан исеме буыннан-буынга күчкән. 1897 елда Казанда мешчаннар 88 399 кеше булып, шуларның 62 818 е шәһәрдә яшәгән.

"Мещан" дип язу да гадәти күренеш. // *Тәтештә татар мещаннары гаед көннәрендә дә трактирларда җырлашып эчәләр, бәйрәмнәре исерү белән сугышудан гыйбарәт була.* Г.Әхмәрев ("Казан мөхбире" гәзите, 1906, 7 май.)

Татар телендә "мешчан" мәгънәсендә *чухур* сүзе дә кулланылган. // *Казан чухурлары* (Кәрим Әмири).

***МИЗАН*** *г.* – **1.**Үлчәү, бизмән; авырлык; баланс, тигезлек, тигезләнеш. 2.Зодиак йолдызлыгы исеме (*Үлчәү, Тәразу*) һәм игенчелек календарендә 7 нче ай. Исеме кайчагында *Коянтә* дип тә тәрҗемә ителә, ләкин татарларда Коянтә дип гадәттә *Орион* йолдызлыгын атыйлар (чуашта да шулай). Сәрйәни телендә – *Әйлул.* Кояш бу йолдызлыкта 24 сентябрьдән алып 23 октябрьгә кадәр була. **3.**Гаделлек.

Мизан сүзенең күплек саны шәкеле: *мәвазин.* // *әл-мәвазин* – кыямәт көнендә адәмнәрнең яхшылыклары һәм гөнаһлары үлчәнәчәк үлчәү. Аны *тәразу* дип тә әйтәләр. *Мизан пелләсе* – үлчәү тәлинкәсе.

***МИЛЛИЯТ(Ь)*** *г.* – **1**.Милләтнеке, халыкныкы; милләткә караган. 2.Миллилек. // *"Миллият тойгысының социологик әсаслары"* (Садри Максудиның соңгы китабы шулай атала). **3**.Динлелек.

Миллият сүзен русча *национальность* мәгънәсендә кулланып булыр иде.

***МИЛЯДИ, МИЛАДИ*** *г.* – Милядка караган, ягъни Христос туганнан башлап исәпләнә торган; христиан эрасы. Рус телендә: "эра от рождества Христова", кыскартып: Р.Х. Көнбатыш илләренең күпчелегендә ул Anna Domini атамасы белән билгеле ("алла елы" мәгънәсендә, кыскартып: A.D.). // *Миляди ел исәбе* яки *Тарих-и миляди*-Христос туган чордан башлана торган ел хисабы.

Миляди ел исәбе дөнья күләмендә таралган булса да, аның тарихи нигезе бик какшау. 525 еллар тирәсендә Кече Дионисий дигән бер монах Иисус Христосның туу датасын абсолют нигезсез рәвештә "хисаплап чыгара" һәм ел исәбен шул көннән башларга тәкъдим итә. Католик чиркәве Кече Дионисийның "хисабын" кабул итә һәм бу календарь

системасының таралуына булыша. XVI гасырда инде ул Европаның күпчелек илләрендә практикага керә. Россиядә исә ел исәбен Христос туган вакыттан башлау тәртибе Петр патша тарафыннан 1700 елда гына кертелә. Татар телендәге "гыйнвар" һәм "февраль" сүзләренең язылышы да Петр заманнарындагы русча язылышны кабатлый (дөресрәге *януар* һәм *фебруар* булыр иде).

***МИНБӘР*** *г.* — Башкача язылышта: *менбәр* (сөйләм телендә *мөнбәр* рәвешендә дә әйтелә). Мәчеттә имам-хатыйбның җомгада басып вәгазь сөйли торган баскычлы биек урыны, кафедра. Имам-хатыйб вәгазь сөйләгәндә минбәрнең иң өске баскычына басмый. Бу баскыч Пәйгамбәрнең өстенлеген тану билгесе буларак буш кала. Р.Фәхреддин Измир шәһәрендәге бер мәчеттә минбәрнең үндүрт баскычы булуы турында яза. Хатиб анда "баскычның яртысында басып, ике кулын ике як токтагага куеп" вәгазь укыган.

628-629 елларда вәгазь укыганда Мөхәммәд Пәйгамбәр утырган беренче минбәр биек утыргычтан гыйбарәт булып, аның ике басмалы гына баскычы булган. Беренче өч хәлифә шушы бердәнбер минбәрдән файдаланганнар. Гали хәлифә заманында гына икенче минбәр ясатылган, ә Могавия хакимлек иткәндә Дәмәшекъта тагын бер минбәр куйганнар. Башта ул сәяси хакимлекне белдергән, соңра исә сәяси хакимлек символы булудан туктаган.

Сәһел бине Сәгыйд әс Сәиди Пәйгамбәрнең беренче минбәргә менеп "Аллаһ әкбәр!" әйткәннән һәм сәҗдә кылганнан соң, минбәрдән төшкәндә, Кыйблага аркасы белән борылмас өчен, артка таба чигенеп кенә төшүе турында хәбәр итә. Ривайәткә караганда, Мәдинәдәге Пәйгамбәр мәчетендә торган минбәр Кыямәт көнендә җәннәт чишмәсе янына китереләчәк.

*Минбәр*нең күплек саны шәкеле — *мәнабир*.

***МИННӘТ*** *г.* — **1**.Иткән яхшылыкны гел искә төшереп сөйләү; битәрләү, табалау. */ / Бирәү бирәүгә иткән ихсанын вә изгелеген миннәт кылса, аның шөкере сакыйт булыр, яки савабы сакыйт булыр.* К.Насыйри. *Кыл гыйлаҗын сән Хода чөн, Кылма әсла миннәтен.* Борынгы шигырьдән. **2**.Яхшылыкка каршы яхшылык кылу. **3**.Булышлык, ярдәм.

Тагын кара: ***ӘЗӘ.***

***МИҢ*** — "Тәндә тумыштан була торган тап яки төерчек" ("Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"). Төрки телләрдә киң таралган сүз. Электә миңне "бәхет тамгасы", "тәңре тамгасы" дип юраганнар. Татар исемнәрендәге "Миң", "миңле" компоненты да "тәңре тамгалаган", "бәхетле" мәгънәсендә килә (Р.Әхмәтьянов). Шулай да балага миң чыкса, аны төрле ырымнар белән бетерергә тырышканнар, хәтта баланың исемен вакытлыча алмаштырып торганнар. Мәс., Казан арты — Дөбьяз якларында мондый сүз язып алынган: "Миң чыкса симйәдә морҗадан кашык төшерә, пич алдына табак белән ботка куйып шул боткага кашык төшерә. Менә шуның кашыгы дип шул кашык белән ашаталар. Шуның миңе беткәнче дип исем алмаштырганнар. Аны вакыт белән алмаштыра, йә кар беткәнче, йә йаз җиткәнче дип алмаштыралар. Шулай исемен бозып бага торгалларыйы. Балада миң булса, Миннәхмәт, Минсылу исемнәре кушкаллар." ("Гомернең өч туе" китабы буенча).

Исламда ясалма миңнәргә мөнәсәбәт тискәре.

Бер хәдистә:"...башкаларның йөзләренә вә тәннәренә энә белән тишеп миң ясаучы вә үзенең йөзенә вә тәненә миң ясатучы хатыннарга Аллаһы Тәгалә ләгънәт итсен,"— диелә. Мондый катгый тыюның гарәпләр дөньясында җитди сәбәбе булган. Әле хәзер дә Гыйракта авыл хатыннары, бигрәк тә анайза, дафир кабиләләрендә һәм сазлыклы төбәкләрдә яшәүчеләр арасында хатын-кызлар битләренә һәм хәтта тәннәренең иң гаурәт җирләренә энә белән кадап миңнәр ясаталар, бизәкләр төшертәләр. Ирләр исә беркайчан да татуировка ясамыйлар, моны хурлык дип саныйлар.

Чәч ялгау, каш йолку, тешләрне игәүләү, тырнак үстерү дә мөселман өчен гөнаһ эш санала.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Җәмил
Зәйнуллин

# ТЕЛЛӘРЕ ТӨРКИ, ДИННӘРЕ ЯҺҮДИ

Сүзебез караимнар хакында. Алар турында татар совет матбугатында беренче булып "Казан утлары" язып чыкты. Узган гасырның алтмышынчы еллары уртасы иде. Шагыйрь Мостафа Ногман гаиләсе белән җәйге ялга Литвага бара һәм шунда караимнар яшәгән Тракай шәһәрендә дә була. Соңыннан ул зур мәкалә язып, "Казан утлары"нда бастырып та чыгара.

Моннан соң күп вакыт узды, һәм миңа Финляндиядә яшәүче Кадрия ханым Бәдретдин бер аудиокассета җибәрде. Ул кассетада караимнарның изге китапларын көйләп укулары язылган. Бу миңа тагын бер этәргеч булды һәм миндә караимнар турында күбрәк мәгълүмат туплау теләге туды.

Караимнарның тарихы, мәдәнияте турында гыйльми хезмәтләр аз. Алар арасында зур әһәмияткә ия булганнары: И. Синанинның 1888 елда Симферопольда басылып чыккан "История возникновения и развития караимства"; профессор В. Д. Смирновның 1890 елда Петербургта нәшер ителгән "Сборник старинных грамот"; И. Дованның 1890 елда Петербургта дөнья күргән "Катехизис—основы караимского закона"; Н. А. Баскаковның "Введение в изучение тюркских языков". М. 1969. С. 275-278; академик Бартольдның : Сочинения, т. V. 1968. 64-65 б.. К. М. Мусаевның "Грамматика караимского языка". М. 1964, "Краткий грамматический очерк караимского языка". "Наука". М. 1977, "Синтаксис караимского языка". М., 2004 һ. б.

Караимнар кемнәр алар? Патша Россиясенең Новороссийск генерал-губернаторы Воронцовка да бу сорау тынгылык бирмәгән. Шуңа күрәдерме, ул 1839 елның 31 гыйнварында Таврия губернасындагы караимнарның дини идарәсе җитәкчесеннән алты сорауга җавап бирүне таләп итә:

Караимнар кайсы халыкның варислары һәм бу якларга кайдан килеп урнашканнар?

Кайчан һәм нинди сәбәпләр аларны монда китергән?

Аларның шөгыльләре нинди, үзләрен ничек тоталар?

Караимнардан нинди күренекле кешеләр үсеп чыкканнар һәм аларның ил күләмендә танылган иҗтимагый хәрәкәт лидерлары бармы?

Аларның килеп чыгышларын, диннәренең бик борынгы булуын дәлилли торган тарихи чыганаклар бармы?

Ни сәбәпле һәм кайчан алар раввинчылардан аерылганнар; бу мәзһәбләр арасында нинди аерымлык бар?

Караимнарның баш руханилары гаһам Бабович, баштагы ике сорауга җавап табалмагач, үлгәннәргә "мөрәҗәгать итәргә кирәк" дигән карарга килә. Караимнарда бик борынгы бер гадәт сакланган: берәр зур галим яисә зур түрә үлгәч, гүргә иңдергәндә аның баш астына дини китаплар куеп калдыра торган булганнар. Изге китаплар нәҗес урынга эләкмәсен дип шулай эшләгәннәр.

Яһүдиләрнең изге Тәлмуд китабы ике төргә бүленгән: Кодес (Иерусалим) һәм Бабил тәлмудлары. Тәлмудиларның иң үсеш кичергән заманнары габбасыйларның Багдад шәһәрен Гарәп хәлифәлеге башкаласы иткән чорга, һиҗри исәп белән 145, милади исәп белән 762 елга туры килә.

Яһүдиләр өчен Тәлмуд – изге Тәүраттан соң икенче китап. Ул Тәүраттан соң гына пәйдә була, аның беренчесе "Мишна" (яһүди дине кануннары тупламы), икенче кисәге "Гимара" ("Мишна" китабының тәфсире) исемле. Тәлмуд шулай ук ике төрдән гыйбарәт: беренчесе IV гасырда Фәләстыйн җирендә язылганы булса, икенчесе V гасырда Бабил шәһәрендә тупланганы. Монысы иң зурысы һәм иң әһәмиятле булып санала торганы. Ул милади исәп белән 380 елда языла башлый һәм 130 елдан язылып бетә. Бабил шәһәре исраиллеләрнең Фәләстыйн җиреннән киткәннән соң зур кабилә булып оешып яшәгән урыннары да әле ул.

---

* Бу турыда яһүд галиме А.Гаркави үзенең "Хазарлар вә хазар дәүләте турында яһүди галимнәрнең риваятьләре" китабында бәян итә. СПб. 1874. 280 б.

Караим гыйбадәтханәсенең михрабы Кодес (Иерусалим) шәһәрендәге Мәсҗиде Әкъсага каратып, ә башка яһүдиләрнең көнчыгышка таба юнәлдереп төзелгән. Тарихтан билгеле булганча, Һарун әр-Рәшид заманында мусавилык ике мәзһәбтән торган: берсе тәлмуди, икенчесе караим мәзһәбе.*

Хазарларга мусавилыкның үтеп керүен Византиядә яшәгән мусави төрекләренең тырышлыгы белән бәйле дип аңлатучылар да бар (мәс. әл-Мәсгуди). Византиядә яшәүче мусавиларның барысы да караимнар булган дигән фаразлар да бар.

Әхмәт Жәүдәт исемле бер төрек тарихчысы "Караимнарның гаиләдәге теле төрекчә яисә татарча... Караимнарның Кырым шивәсендә сөйләшкәннәрен ишеткән кеше аларны Кырым татары дип уйлаячак" дип язган иде. («Әкъдам» газетасы, 22 июнь).

1843 елда Парижда "Караимнар" исемле сәяхәтнамә китабы басылып чыга. Аның авторы Хаммер де-Голь исемле француз Кырым буйлап сәяхәт итә һәм үзенең күргәннәрен бер китапка туплый. Караимнар тормышына караган кызыклы гына мәгълүматлар мавыктыргыч итеп бирелгән булса да, фәнни дәлилләнгән яңалыклар бу китапта юк.

Галимнәр караимнарны хазарлардан калган кавем түгел дип белдерсәләр дә*, халык әдәбиятында һәм кайбер йолаларда хазарлар искә алына.

Арби баба куй суя
Байларымыз той чәлә
Хазар оглы ат чапа
Ате мендем сагдагым бар
Сагдагымде өч окум бар
Өче белен өч йат орсам
Хазар бикден тартылгым бар...**

Күренә ки, гарәп, фарсы сүзләре кулланылмаган, теле асылда төркичә. Караимнар кайгы кичергәндә "хазар хәлвәсе" пешергәннәр. Мәетнең кырыгынчы көнен уздырганда пешерелә торган бу хәлвә каһва төсендә булса, елын үткәргәндә "ак хәлвә" пешерелгән. Караимнар телендә хәлвәне "канмаг" дип атап йөрткәннәр.

Дини әдәбиятта да гарәп, фарсы яки башка чит телләрдән кергән сүзләр кулланылмаганга охшый: караим телендәге Тәүраттан бер өзеккә игътибар итик:

**Теңренең олут да, айруг ады белен. Элек башда йаратды Теңре ол көкне даһа, ол йерне Караңголык йезляре эстене Теңренең даһа ... эсер даһа йезляре эстене соларың.. даһа айтды Теңре болсын йарык да болды йарык. Даһа ... кёрде Теңре ол йарыкны кем йахшыдыр ол караңгылыкның. Даһа атады Теңре йарыкга кин, даһ караңголыкга атады киче. Даһа болды икере, даһа болды эрте кён бер...**

Тәрҗемәсе: Тәңре иң элек күкне һәм җирне яратты. Һәм җир, су өсләрен караңгылык каплаган иде. Тәңренең рәхмәте белән җир йөзенә яктылык нурлары сирпелә башлаган иде. Һәм тәңре яктылык булсын, диде – яктылык туды. Һәм Тәңре яктылыкны – көн, караңгылыкны төн дип атады. Көн һәм төн яратылганнан соң беренче көн туды...

Караим телендәге Зәбурдан үрнәк:

**Сан ол кешеге кем йоромде йаманларның киняше белян де йазыклыларының йолында тормады... Анжак килеге бойуругында Теңрёнең даһа таныклык битиген окур көн, даһа киче. Орнатылган агач койук болур. Чириныклары йанына суларның кем йимешен бер йер чагында, даһа йапрагы опралмастыр даһа барча кылуы экарер. Алай декюлдер ол йаманлар. Анжак эчүн торалмасдыр йаманлар тынту соругунде даһа йазыклылер жыелынтысынде тогрыларның белер Теңрё йолун. Йаманларының йок болур.**

Тәрҗемәсе: шул кешегә мактау булыр кайсы кем явыз, бозыкларның коткысына бирелмәсә һәм алар юлына басмаса, һәм монафикъләр белән бергә утырмаса, һәм көнетөне Тәңресе кушканны күңелендә укып йөрсә, һәм игелекле гамәлләр кылса. Ул мул уңыш бирүче, бәрәкәт иңгән җимеш агачына охшар: су буендагы бу агачның җимешләре вакытында өлгерерләр, яфраклары саргаймас. Бу кешенең эшләре дә уңышлы булыр. Явыз, бозык юлдан баручыларның болай булмас. Аларның язмышлары җимерелер, челпәрәмә килер. Андыйлар каты хөкемгә тартылырлар. Гөнаһлыларга пакь җанлы, дөрес юлдан баручы кемсәләр янында урын булмас. Раббы үзе кушканча яшәгәннәрне дөрес юлга күндерер, әмма бозыкларны, явызларны һәлакәт юлына дучар итәр.

---

* Академик В.В.Бартольд. Сочинения. V. М. 1968. С. 64-65.
Баскаков Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М. 1969. С. 275-278.

** Арби баба – раввин ата, той чәлә –туй уйный, сагдагым – уклар сала торган букча сымак сумка, окум-угым, йат орсам –дошманга атсам, тартылгым бар – макталу, бүләк алу.

Караим фольклорында да гомумтөрки, Кырым татар әдәбиятындагы каһарманнар очрыйлар. Игелекле акыл иясе – олуг ата һәм капма-каршы образ каргаулы ата (ләгънәт төшкән карт) буларак сурәтләнә. Беренчесе яхшылыкның үрнәге булса, икенчесе усаллыкны эченә туплаган. Әмма бу ике гәүдәләнешне караимнарга хазарларның потларга табынган вакытында ук күчүе ихтимал дип санаучылар да булган.*

Караимнарда ел исәбе "олуг ата санавы" дип атала. Танылган төрек галиме Фуад Көпрелезадә команларда да "олухтан ата битекче"ләре булганлыгы турында "Төрек әдәбиятында беренче суфыйлар" исемле китабында искә ала (198 бит).

Йомак башы – (табышмак) караимнарда шулай ук Кырым татар әдәбиятына бик якын. Табышмакларны укып аңлау читен түгел.

**Заман-заман экечде, пире бер-бер экечде, деве деллек экечде, су сыгры назыр экенде, мен он йашынде экенде, бабам бешикде бала экенде, мен бабамның бешиген тыңгыр-мыңгыр тепреткенде, кабалу-кубалу бакалар канатланды очмага, деңизге бер ут тёшде, балыкларның сырты пеште, коркуден араба тотдылер Балаклауга качмага. Ак месҗиднең менарасы экилде салгырден су эчмеге, эски Кырымге кем йанашды каршы каршыге Истанбуле кечмеге, ойалан-бойалан тогру су филене йотды бер йылан, һинҗе боласын, минҗе боласын эгер бу йомакны тыңламасаң хаммам токмагы кадер чепан чыкара сың, бума кадер боның ады тыңламак белен келер дады. Азмы кетер озмы кетер алты ай йаз баһар бер көзме көтер, айланыб артына бакса, эйне бойы йер кетер. Багсарайда гёзел йар, кочар болсаң анда бар. Бер заманда бар экен бер заманда йок экен кыпчак олусында бер олухан бар экен.**

Тәрҗемә: борын-борын заманда дөя чүпне гизгән ди, су сыеры министр икән ди, мин ун яшемдә чагында әтием бишектә яткан икән ди. Әтиемнең бишеген шыңгым-мыңгыр тибрәткәндә бакалар өерләре белән очып киткәндә, диңгезгә бер ут төште, балыкларның сырты пеште, куркуларыннан арба туктаттылар, Балаклауга качып китмәгә. Акмәчетнең манарасы нелде улактан су (эчмәгә) эчәргә, кемдер иске Кырымга килде каршы яктагы Истанбулга китәргә, алаймы, болаймы итеп турылыклы су филен йотты ди бер елан, монда буласыңмы, анда буласыңмы, әгәр бу табышмакны тыңламасаң, мунча тукмагы зурлыгында бер чуан чыгар тәнеңдә, шуның кадәр моның исеме, тыңлар булсаң килер сиңа аның хикмәте. Аз киттеме, күп киттеме, алты ай җәй, яз, тагын бер көз үттеме, әйләнеп артка караса, энә буе җир киткән ди, тыңла шундый хикәятне.

Караим халык мәсәлләрен һәм аталар сүзен борынгы татар әдәбияты үрнәкләре итеп кабул итәргә дә мөмкин.

**Бер алчечек отурган, бөтен эвне** буллурган.**

**Ай без эдек без эдек, отуз ике кыз эдик,**
**Эки техтге төзелдек, берер берер өзелдек.**

**Торды йёрек кетди баш**
**Кайтды йёрек кайда баш?**

**Кеми су тапмай эчмеге**
**Кеми кёпер тапмай кичмеге**

**Ат белян егетнең башына неляр келмез**

**Анаң тат, бабаң тат, неге керек сеңа өксек ат!**
**Кызың коңшу эвинде йатмасун, оглың базар ашы татымасун.**

**Эве йасаган балта тышда калыр һ. б.**

Бик борынгы заманнарда ук караимнарда Акбикә, Айтулы, Мамук, бәклек, ханакә, Алтынкыз, Сәвәр килен, Бәк ана, Тансык кебек исемнәр һәм атамалар гамәлдә булган. Бу исемнәрне галимнәр Кырымда Чефткала янындагы кабер ташларыннан күчереп алганнар.

Караимнар XIX йөз башларына кадәр ел календарен үзләренчә "Олуг ата санавы"

---

* Бу турыда: Кырым карай түркләре. "Түрк йулы". Истанбул. Мәкаләнең авторы: Санкт-Петербург унив. шәрекъ факультеты укытучысы кырымлы Шабшал углы Нәрба.

** эвне - өйне, өксек ат – лаек булмаган исем, коңшу – күрше, эвенде - өендә

дип атап йөрткәннәр. Аларның ел исәбе апрель аенда башлана.

Кур алай – апрель
Баш коскан – май
Йаз ае – июнь
Олаг ай – июль
Чорук ай – август
Айруксы ай – сентябрь
(Изге ай мәгънәсендә)
Көз ае – октябрь
Согум ае – ноябрь
Кыш мае – декабрь
Коры кыш – гыйнвар
Соенеч ае – февраль
Арты арык – март

Көн исемнәре – атна башы караимнарда шимбә көннән башлана.

Шебат көне – шимбә
Йох көне – якшәмбе
Йох баш көн – дүшәмбе
Орта көне – сишәмбе
Кан көне – чәршәмбе
Киче айне көне – пәнҗешәмбе
Айне көне – җомга

Бу исемнәрнең берничәсе – "шебат" гыйбрани телендә, татар-мишәрләрдә "кич атна", балкар, карачайларда "орта көне", фарсыларда "азине" буларак гамәлдә булган.

Н. С. Хрущев вакытында СССРның хәрби (оборона) министры булган Родион Малиновский – караим халкының улы. Әмма ни өчендер аның милләтен поляк дип күрсәтәләр иде.

Югарыда Финляндиядән килгән кассета турында әйтеп узган идек. Бу кассетада берничә кешенең әкрен генә тавыш белән көйләп Тәүрат китабыннан өзек укулары язылган.

**Башлыгында йаратылмакның йаратты Теңре ол кеклерне даhа ол йерне...** (Дөнья яратылган чакта Тәңре күкне һәм җирне яратты...)

Шуннан соң кемнеңдер җырлавын сорыйлар... **Җырлайчы, йахшы җырла кыска йырча...** (Җырла әле, матур итеп кыска гына җырны...)

Ике генә юлдан торган кыска җыр башкарыла. Җырлаучы кеше **"Тезюде аны безнең север дедемез Семен Фиркович"**. (Аны безнең сөекле әтиебез Семен Фиркович язды) дип өстәп тә куя.

Соңыннан урыс телендә сөйләшә башлыйлар: Без үзебез дә бик тырышабыз, ләкин без теләгәнчә булмый. Һаман күчеп йөрибез, һәрвакыт юлда, әле ансын тикшерәләр, әле монсын ачыклыйлар. Хәзер менә Тракайда шимбә мәктәбен ачып җибәрдек. Анда безнең балалар йөриләр. Хатын-кызларыбыздан берәү, алар арасында минем хатыным да һәр шимбә көнне шул мәктәптә сәгать, сәгать ярым чамасы балалар белән караим телен өйрәнәләр, үзләре дә белгәннәрен балаларга өйрәтәләр... – Шул сүзләрдән соң тагын күмәкләп дога укырга керешәләр. Бу доганың бер өлешен алар караимча, ә икенче өлешен гыйбрани телендә укыйлар.

Кайчандыр зур мәдәнияткә ия булган бу кардәш телдә сөйләшүче халык саны күпме һәм бүген кайда яши соң? Мәскәүдә 30 лап кеше, Литваның Тракай шәһәрендә 200 чамасы һәм Польшада, Америкада бармак белән генә санарлык караимнар яши диләр. Төркиядә дә караимнарның зур булмаган төркемчәсе барлыгы мәгълүм.

Төрле илләрдә сибелеп-чәчелеп яшәгән караимнарның киләчәге нинди? Аларның язмышы ком чүленә сибелгән яңгыр тамчыларына охшап калыр кебек. Ни кызганыч, без бүген төрки телдә сөйләшүче кардәшләребездән тагын бер төркемнең эреп, югалып баруын күреп торабыз. Аларның тарихтагы эзләре зур архивларда, китапханәләрдә генә сакланыр, бәлки. Гыйбрәтләндерерлек хәл, тарихи фаҗига бу...

# *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# А

**АФОРИЗМ** (грек. aphorismos – ачыклау, кыска гыйбарә), төп контексттан тәэсир көче 6-н аерылып торган, кыска, гомумиләштерелгән фикер, гыйбарә. Шулай ук мөстәкыйль әдәбият һәм фольклор жанры буларак та яшәп килә. Әйтемнәр һәм мәкальләр дә А.га карый. Алар борынгы чорлардан ук билгеле. А. күләме буенча кыска булган саен тәэсирлерәк һәм мәгънәлерәк: мәс., "Ут – мут", "Күл – күз" мәкальләре ике сүздән генә тора. А.ның күпчелеге 3–4 сүздән тора, мәс.: С.Сараида "Йймеше күп агачка таш атарлар", Г.Тукайда "Эш беткәч уйнарга ярый", "Иң мөкатдәс нәрсә – эш". Халык А.ы мисаллары: "Усал булсаң – асарлар, юаш булсаң – басарлар", "Безнең урамда да бәйрәм булыр әле", "Кеше урыны белән күркәм түгел, ә урын кеше белән күрекле". Әдәби, фәнни һәм сәяси-публицистик әсәрләрдә тирән мәгънә белдерү һәм үткен сүз кертү өчен еш файдаланыла. Мәкальләрдән аермалы буларак, А.нар – танылган авторларның сүзләре. Дөнья әдәбиятында А. осталары – Ф.де Ларошфуко, И.В.Гёте, А.С.-Пушкин, И.А.Крылов. Татар әдәбиятында Кол Галинең "Кыйсса-и Йосыф"ында, Мөхәммәдьяр әсәрләрендә үк очрый. Соңрак А.ның күренекле осталары булып Г.Кандалый, Акмулла, Г.Тукай, Дәрдемәнд, М.Җәлил танылды.

Әд.: Мәхмүтов Х. Афористик иҗат төрләре // Жанры татарского фольклора. К., 1978; Литературный энциклопедический словарь. М., 1987; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*З.М.Мәҗитов.*

**АХМАДУЛИНА** Белла (Изабелла) Әхәт кызы (10.4.1937, Мәскәү), шагыйрә. Әдәбият ин-тын тәмамлый (1960, Мәскәү). Әсәрләре 1954 елда басыла башлый. А. шигъриятенә тирән фәлсәфилек, нечкә психологизм хас. Аның шигырьләрендә кеше җаны дөньявилык белән тыгыз һәм гаять дәрәҗәдә катлаулы мөнәсәбәттә бирелә. Иҗатында табигать зур акылга ия, үзе бер бөек дөнья булып килеп баса. Лирик герой ул табигатьне аңларга омтыла. А.ның поэзиясендә гармониягә омтылу көчле, бер үк вакытта аңа ирешүнең мөмкин булмавын аңлау сизелә. Аның шигъри фикерләвенә метафоралар байлыгы, музыкаль аһәңлелек хас. Бу үзенчәлекләр А.ның беренче шигъри җыентыкларында: "Кыл" ("Струна", 1962), "Дерелдәү" ("Озноб", 1968), "Музыка дәресләре" ("Уроки музыки", 1969), соңгы елларда чыккан җыентыкларында да ачык күренә: "Шәрехләүче аваз" ("Звук указующий", 1995), "Гомернең мизгелләре" ("Миг бытия", 1997). Казан белән А.ның туганнары тормышы бәйле. Әнисе ягыннан әбисе *А.М.Стопанин*ың кече сеңлесе. Әтисе ягыннан чыгышы казан татары Әхмәдулладан килә. Аның турында "Минем шәҗәрәм" ("Моя родословная") поэмасында: "кысык күзләләр кабиләсендә ул иң кысык күзлесе иде" ("в узкоглазом племени своём так узкоглаз, что все давались диву"), – диелә. Үзе турында ул: "миндә саф азия рухы кайный" ("Незапятнанный дух азиатства тяжело колобродит во мне"), – дип яза. Бөек Ватан сугышы елларында А. Казанда яши. Аерым шигырьләрендә шәрекъ традициясе сизелә.

Әсәр.: Собр. соч.: Т.1–3. М., 1977; Избранное: Стихи. М., 1988; Стихотворения. М., 1988.

Әд.: Мустафин Р. "Всем, кто есть, прихожусь близнецом": Мир поэзии Б.Ахмадулиной // Татарстан. 1992. N 5–6.

*Т.Г.Прохорова.*

**АХМАТОВА** (псевд., чын фамилиясе Горенко) Анна Андреевна (11.6.1889, Одесса ш.- 5.3.1966, Мәскәү өлкәсе, Домодедово ш., С.-Петербург тирәсендәге Комаровода җирләнгән), шагыйрә, тәрҗемәче. Псевдонимы чыгышы белән татар морзаларыннан булган әбисеннән алынган. Бу турыда А. "Көндәлек битләре"ндә

("Листки дневника") һәм "Кара балдак турындагы әкият"тә (1940) искә ала: "Әбием, татар карчыгыннан // Бүләк сирәк була иде кулларыннан // Зәһәрләнә иде кайвакытта // Чукындырылган булганымнан" ("Мне от бабушки татарки // Были редкостью подарки // И зачем я крещена // Горько гневалась она..."). Иҗатының төп үзенчәлекләре инде беренче җыентыкларында ук ("Кич" — "Вечер", 1912; "Дисбе" — "Чётки", 1914; "Ак көтү" — "Белая стая", 1917) барлыкка килә. Бу үзенчәлекләр: тасвирлауда төгәллек һәм аныклык, стильдә ачыклык һәм гадилек, шигырьнең сюжетка корылуы, сөйләм теле интонациясе, рухи кичерешләрнең ышандыру көче. 1910–20 елларда мәхәббәт темасы үзәк урынны ала. Алга таба тематик һәм жанр диапазоны киңәя, фәлсәфилек һәм гражданлык үзен нык сиздерә башлый ("Алты китаптан" — "Из шести книг", 1940; "Геройсыз поэма" — "Поэма без героя", 1940–62; "Вакыт чабышы" — "Бег времени", 1965). Гомумән, А. иҗатына дөньяны аңлауда драматик кискенлек хас. 1941 нең октябрендә Чистай ш.енә эвакуацияләнә (тиздән Ташкентка күчеп китә). 78 телдән 150 шагыйрьнең ш.и. Г.Тукай, М.Җәлил, Ф.Кәрим әсәрләрен, рус теленә тәрҗемә итә.

Әсәр.: Вечер. Стихи. М., 1988; Сочинения: Т.-2. М., 1990; Чётки. Стихи. М., 1990.

Әд.: Жирмунский В. Творчество Анны Ахматовой. Л., 1973; Павловский А. Анна Ахматова: Жизнь и творчество. М., 1991.

*Т.Г.Прохорова.*

**АХУНДОВ** Мирза Фәтхгали (тәхәллүсе Сәбухи) (30.6.1812, Шәке ш., хәзер Нуха ш., Әзербайҗан Рес-касы — 26.2.1878, Тифлис), әзәрбайҗан язучысы, мәгърифәтче, публицист, философ, җәмәгать эшлеклесе. Ганҗә шәһәрендә мәдрәсә тәмамлагач, укуын Шәке шәһәрендәге рус училищесендә дәвам иттерә. Төрки телләрдән тыш, гарәп, фарсы һәм рус телләрен яхшы белгән. Шәрекъ һәм Көнбатыш мәдәният дөньясының күп кенә күренекле шәхесләре б-н аралашкан, Казандагы татар укымышлылары б-н хатлар алышкан. Әдәби иҗат эшчәнлеге 1830 елларда башлана. Беренче иҗат җимеше — "Пушкинның үлеменә" (1837) дигән романтик поэма-мәрсиясе, урта гасыр Шәрекъ поэзиясе кануннарына таянып, фарсы телендә языла (мәрсия 1962 елда Зәки Нури тарафыннан татар теленә тәрҗемә ителде). А. төрки әдәбиятлар, Якын көнчыгыш әдәбиятлары тарихында европача типтагы драматургиягә нигез салучы булып тәкъдир ителә. 19 йөзнең урталарында А. патриархаль-феодал чынбарлыкны, артталыкны, искегә ябышып яту, иҗтиһадсызлыкны мәгърифәтчелек идеяләре күзлегеннән тәнкыйтьләгән 6 комедия иҗат итә: "Ибраһим Хәлил мулла, алхимик, фәлсәфә ташы иясе" (1850), "Мусье Жордан, ботаник вә дәрвиш Мәстәлишаһ, мәшһүр сихерче" (1850), "Ленкорань ханлыгының вәзире" (1850), "Юлбарысны җиңгән аю" (1851), "Карун мажаралары" (1852), "Газеллекне яклаучылар Тәбриз шәһәрендә" (1855). Комедияләрен А. рус теленә үзе тәрҗемә иткән, алар ш.у. француз, инглиз, немец, фарсы һ.б. телләргә дә тәрҗемә ителгәннәр. 1864–65 елларда А. Көнчыгыш халыкларының иҗтимагый-икътисади, рухи-мәдәни яктан артта калу сәбәпләрен ачуга багышланган "Һиндстан шаһзадәсе Кемал әл-Дәүләнең Персия шаһзадәсе Җәлал әл-Дәүләгә өч хаты һәм соңгысының ул хатларга җавабы" (1864–65) исемле фәлсәфи трактатын яза. А. әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеменә караган хезмәтләр авторы буларак та билгеле ("Тәнкыйди сәхифәләр", "Шигърият һәм чәчмә әдәбият турында" һ.б.). Халыкны мәгърифәткә якынайтуда аңа дөрес тәрбия бирүдә әдәби жанрлардан иң тәэсирлесе итеп ул романны һәм драманы саный; әдәби әсәрнең эчтәлеге б-н шәкли ягы бербөтен яңгыраште булырга тиеш дигән фикерне алга сөрә; иҗатта сюжетларны реаль тормыштан алырга чакыра, язу стилендә иске үрнәкләргә, традицион образларга ябышып ятуны, шигъриятгәге купшылыкны тәнкыйтьли. А. Төркия академиясендә гарәп алфавитын латин алфавитына алыштыру турында үзе эшләгән проектны игълан итә. А. иҗаты Идел төбәге, Урта һәм Кече Азиядәге төрки әдәбиятларның реалистик юлдан үсешенә уңай йогынты ясады. Г.Камал фикеренчә, А. әсәрләре яшь татар театры һәм драматургиясенең формалашуы процессында "озак вакытларга кадәр зур азык булып килде". Үз вакытында көндәлек татар матбугатында ("Вакыт", "Шура", "Совет әдәбияты" һ.б.) А.ның тормышы һәм иҗаты турында Р.Фәхретдин, Б.Шәрәф,

С.Рәмиев, Г.Камал, Н.Юзиев кебек күренекле әдип һәм галимнәрнең мәкаләләре басыла.

Әсәрләре: Избранные философские произведения. Баку, 1982; Комедии. Проза. Поэзия. Литературно-критические статьи. Баку, 1987.

*Әд.:* Азиз Шариф. Мирза Фатали Ахундов. Жизнь. Художественное творчество. Эстетика. // История литературы народов СССР. М., 1986; Камал Г. Әзәрбайҗан драматургы Мирза Фатали Ахундов // Кызыл Татарстан. 1928. 11 март; Юзиев Н. Высокая духовность писателей сближает народы // Әдәбият чыганаклары һәм текстология. К., 1982.

*Р.К.Ганиева.*

**АХУНҖАНОВ** Илдус Хәниф улы (23.4.1930, Ижевск ш. — 16.3.1990, Казан), әдәбият тәнкыйтьчесе. Казан ун-тын тәмамлый (1953). "Совет әдәбияты" ж-лында, 1958–64 елларда ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение комитетында, Казан кинохроника студиясендә эшли. Мәкаләләре 1950 елларда басыла башлый. Алар М.Җәлил, Ф.Кәрим, Ә.Фәйзи, С.Хәким, шулай ук Л.Н.Толстой, А.П.Чехов, В.Г.Короленко, Н.А.Островский, У.Шекспир, М.Сервантес һ.б. язучылар иҗатына багышлана. 1970 елларда Россия халыклары әдәбиятларының үзара бәйләнеше һәм йогынтысы проблемалары өстендә эшли. "Художник һәм аның сүзе" (1978) исемле мәкаләләр җыентыгында М.Рәфыйков, Ш.Анак, Р.Мостафин, Р.Кутуй, Д.Вәлиев, Р.Солнцев иҗатлары анализлана.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

**АХУНОВ** Гариф (Гарифҗан) Ахунҗан улы (18.9.1925, ТАССРның Арча кантоны Өчиле а. — 4.6.2000, Казан, Арча штп. нда күмелгән), язучы, җәмәгать эшлеклесе, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1985), ТРның халык язучысы (1993), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (1998). 1952 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1951-56 елларда "Совет әдәбияты" ж-лында, 1963-65 һәм 1967-68 — ТАССР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлегендә җаваплы сәркәтиб, 1971-74 — "Казан утлары" ж-лының баш мөхәррире, 1974-84 — ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, бер үк вакытта, 1975-84 елларда РСФСР Язучылар берлеге сәркәтибе. 1951 елда беренче язмасы басылып чыга. Беренче зур күләмле әсәре — студент яшьләр тормышыннан алынган "Яшьлек яме" повесте 1956 елда дөнья күрә. А. төрле жанрларда иҗат итте: ул романнар, повестьлар, пьесалар, хикәяләр, очерклар, публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, мемуарлар һәм документаль характердагы әсәрләр авторы. Аның әдәби геройлары — нефтьчеләр, авыл хезмәтчәннәре, хуҗалык җитәкчеләре, иҗат интеллигенциясе вәкилләре. 1956 елда А. республиканың нефть үзәге булган Әлмәт ш. енә китә. Ун елдан артык нефтьчеләр арасында яши, аларның тормыш — көнкүрешләрен, хезмәт казанышларын өйрәнә, аларга багышлап күп санлы очерклар, хикәяләр, повестьлар иҗат итә. Бигрәк тә "Хәзинә" (1963; русчага тәрҗемәсе "Клад", 1963; Свердловск киностудиясендә шул исемдә нәфис фильм, 1977) һәм "Хуҗалар" (1968) романнары популярлык казана. 1973 елда А.ка "Хәзинә" романы һәм "Чикләвек төше" (1973; русчага тәрҗемәсе "Ядро ореха", 1982; Татар акад. театры спектакле, 1974) повесте өчен ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе бирелде. Административ һәм җәмәгать эшләре белән даими мәшгуль булса да, А.ның иҗат активлыгы кимемәде, бер-бер артлы "И кадерле туган як" (1971, М.Зарипов белән бергә язылган), "Йолдызлар калка" (1980) исемле очерклар һәм документаль повестьлар, "Утлар яна учакта" (1976) дигән пьесалар, "Чишмәләр белән сөйләшү" (1985) кебек әдәби-тәнкыйть мәкаләләре җыентыклары басылып чыкты; хәзерге әдәби процесска багышланган аналитик мәкаләләре, язучылар һәм сәнгать эшлеклеләренең иҗат портретлары респ-ка матбугатында һәм үзәк басмаларда дөнья күрде. "Ардуан батыр" (1974; Минзәлә татар драма һәм комедия театры спектакле, 1982) документаль повесте, "Идел кызы" (1 нче китап 1978; 2 нче китап 1986) дилогиясе белән тарихи темаларга мөрәҗәгать итте: 20 гасырның беренче яртысында Урта Иделдә барган вакыйгаларның һәм иҗтимагый-социаль процессның җанлы картиналарын күз алдына китереп бастырды.

А. драма әсәрләре авторы буларак та

танылды. "Чулпы жыры" (1959; Әлмәт татар драма һәм комедия театры спектакле, 1959), "Тыңгысыз йөрәк" (1959, автордашы Ф.Мостафин; Татар акад. театры, 1959), Ш.Камалның "Акчарлаклар" повесте буенча (Татар акад. театры спектакле, 1971) драмалары сәхнәләштерелде. А. татар теленә М.А.Шолохов, А.Н.Островский, А.С.Макаренко, В.А.Закруткин әсәрләрен тәрҗемә итте. Аның повесть һәм хикәяләре рус, украин, әзербайҗан, үзбәк, кыргыз, казах, башкорт, удмурт, чуаш, мари, якут, даргин телләренә тәрҗемә ителде. 1974-84 елларда СССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар Дуслыгы орденнары белән бүләкләнде.

Әсәр.: Клад. М., 1963; Әсәрләр: 4 томда. К., 1981-84.

Әд.: Галимуллин Ф. Чишмә жыры // Инешләр Иделгә кушыла. К., 1985; Нуруллин И. Үз яктысы бар икән бит // Шәһри Казан. 1995. 11 авг.; Әхмәтҗанов М. Үзе тапкан хәзинә // Мирас. 1997. №12; 1998. №1.

**АЧКАСОВА** Людмила Сергеевна (28.9.1922, Тамбов губ-сы, Хлыстово а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1985), проф. (1986). Казан ун-тын тәмамлый (1945). 1948 елдан шунда ук укыта. Хезмәтләре рус совет әдәбияты, 20 йөз рус әдәбиятында романтизм тарихына, К.Г.Паустовский иҗатына карый.

Хезм.: О романтизме в советской литературе // Филологические науки. 1970. N2; Гуманизм в творчестве К.Паустовского. К., 1972; Человек как нравственная ценность в эстетике К.Паустовского. К., 1977.

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

*Берлекнең яңа әгъзалары*

## Дания Гыймранова



Гыймранова Дания Әхәт кызы—1937 елның 23 октябрендә Казан шәһәрендә туган. 1962 елны Мәскәүнең А.В.Луначарский исемендәге ГИТИСның театр белгечлеге бүлеген тәмамлаган.

Хезмәт юлын Татарстан радиосында режиссерлык эшеннән башлап җибәрә, ләкин фәнни эшкә булган кызыксыну үзенекен итә—1964 елны ул Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында башта фольклор аннан сәнгать бүлегенә лаборант булып эшкә урнаша, читтән торып "Театр белгече" буенча аспирантура тәмамлый. 1971 елдан фәнни хезмәткәр вазифасына күчерелә, ә 1992 елдан бүгенге көнгә кадәр сәнгать бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре. Монда эшләү дәверендә Д. Гыймранова татар театрының тарихын һәм аның бүгенге халәтен өйрәнү белән шөгыльләнә. Ул—институт планына кертелгән проблема-темалар өстендә эшләүче күмәк авторларның берсе. Шул рәвешле аңа "Мәскәү татар дәүләт эшче театры", "Татар театрының елъязмасы", "Революциягә кадәрге татар театрында актерлык сәнгате", "Республикабызда колхоз-совхоз театрлары" һәм башка темалар өстендә эшләргә туры килә. Аннан тыш театр тарихы, театр сәнгатенең бүгенге халәте, режиссерларыбыз һәм артистларыбызның иҗаты хакында Республикабызның вакытлы матбугатында, аерым тупланмаларда, энциклопедиядә, китапларда йөзләгән фәнни-популяр хезмәтләре басылды. Аерым алганда, 2 монография: "Гөлсем Болгарская" һәм "Габдулла Шамуков", "Татар совет театры" китабында "Мәскәү эшче һәм Республика дәүләт күчмә театрлары", "Халык артистлары" китабында бер төркем татар артистлары хакында һәм күп кенә фәнни басмаларда театр тарихына караган мәкаләләре дөнья күрде. Шул исәптән, ТР ФАсенең энциклопедия институтында аның 100 ләп мәгълүмати мәкаләләре тупланган. Шулай ук, ул Татарстан радио һәм телевидениясендә яңгыраган һәм күрсәтелгән күп кенә тапшыруларның авторы, режиссеры һәм алып баручысы да булып чыгышлар ясый. Аларның кайберләре бүген дә архив фондларында саклана.

Сәхнә сәнгате асылда драматург хезмәте белән нык бәйле. Шул сәбәпле ул бүгенге көн драматургларыбыз белән тыгыз элемтәдә тора. Алар язган пьесаларга бәяләмәләр бирә. Министрлык һәм Театрлар берлеге тарафыннан уздырыла торган семинар-киңәшмәләрдә, конкурсларда актив катнаша.

Г.Гыймранова, гомумән, республикабыздагы бөтен татар театрлары белән (Казаннан тыш Әлмәт, Минзәлә, Чаллы, Түбән Кама) тыгыз бәйләнештә торып, аларның репертуарлары, иҗади тормыш халәте турында фәнни анализлы мәкаләләр белән чыгышлар ясавын дәвам итә. Д.Гыймранова театр сәнгате өлкәсендәге эшчәнлеге һәм ирешкән уңышлары өчен 1997 елда "Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе" дигән мактаулы исемгә лаек булды Бүгенге көндә ул Әлмәт һәм Минзәлә дәүләт драма театрлары тарихын эзлекле өйрәнеп, алардагы сәнгать әһелләре һәм артистлары буенча китап язу белән мәшгуль. ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институтында өлкән фәнни хезмәткәрлек эшен дәвам итә.

*Котлыйбыз!*

## Мәдинә Маликовага 70 яшь



Күренекле язучы, актив җәмәгать эшлеклесе Мәдинә Габделхак кызы Маликова 1935 елның 5 августында Татарстанның Сарман районы Мортыш Тамагы авылында дөньяга килгән. Бала чагыннан әдәбиятка-сәнгатькә гашыйк булып үскән кыз, үз авылларындагы җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, башта Минзәлә педагогия училищесында, аннары исә Казан дәүләт педагогия институтында белем ала. Институтның тарих-филология факультетын уңышлы тәмамлаганнан соң, ул хезмәт юлын журналист буларак башлап җибәрә: 1959-1964 елларда "Чаян" журналында корректор, ә 1964 елдан "Азат хатын" (хәзерге—"Сөембикә") журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, 1978 елдан—җаваплы секретарь булып эшли. Нәкъ менә шул дәвердә журналист буларак та, язучы буларак та аның каләме чарлана. 1967 елда Татарстан китап нәшриятында беренче китабы—"Юлдашлар" исемле хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. Татар әдәбиятына әхлакый мәсьәләләрне тормышчан образларда чагылдыручы, язмышларны, шәхесләрне, аларның катлаулы эчке кичерешләрен тирәнгә үтеп тасвирлый белүче үткен вә сизгер каләмле язучы килгәнлеген хәбәр итүче китап була бу. Ә инде "Хөкем" (1969) һәм "Адашканга юл кайда?" (1971) исемле, жанр хасиятенчә мавыктыргыч, киеренке вакыйга-сюжетка корылган маҗаралы бәян-повестьлары Мәдинә Маликованың детектив жанрда да нәтиҗәле иҗат итә алуын күрсәтте.

1972 елда аны СССР Язучылар союзына кабул итәләр.

Алга таба да язучы яңадан-яңа иҗат үрләрен яулавын дәвам итә. Хәзер инде аны акыл хезмәте һәм иҗат белән шөгыльләнүчеләр кызыксындыра. "Кояш күпере" (1973), "Казан каласы—таш кала" (1967), "Янар таулар яктысында" (1977) әсәрләре—әнә шул кызыксынуның уңышлы нәтиҗәләре. "Язгы такыялар" (1974) повестенда исә заман зилзиләләренә сыгылмыйча, сынмыйча шуларны кичә алган татар хатыны образы сурәтләнә. Бу әсәрләр укучы һәм әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан бик җылы кабул ителә.

Мәдинә Маликовага тема һәм жанр төрлелегенә омтылу хас. Әнә шул юнәлештә эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, 1983 елда аның "Ак давылда—тал бөресе" ("Шәфкать") исемле романы "Казан утлары" журналында (№№ 4, 5) дөнья күрә. Гомумән, язучының күләмле вә күренекле әсәрләренең һәммәсе дә диярлек иң башта безнең журналда басыла килә.

Мәдинә Маликова, нәтиҗәле иҗатыннан тыш, җәмәгать эшләрен дә даими һәм актив башкара: ул байтак еллар дәвамында Татарстан Язучылар берлегенең идарә әгъзасы, идарә каршындагы Матур әдәбиятны тарату комиссиясе җитәкчесе булды. Аннары исә, Бөтентатар Кызыл Ай җәмгыятен оештырып, аның президенты буларак, хәзерге катлаулы дәвердә матди вә рухи яктан мохтаҗ калган бик күп кешеләргә ярдәм кулын сузды. Ә соңгы елларда ул Татарстан Язучылар берлегенең проза остаханәсе җитәкчесе вазыйфасын башкарды.

Әдибәнең бөтен әсәрләре дә диярлек әүвәл "Казан утлары"нда дөнья күрә, дигән идек. Әле яңа гасырыбызның берничә елында гына да аның "Өермә" детектив романы (2002, №№ 11, 12), "Мендем биек тауларга" повесте (2003, № 10), "Чәчкә балы" повесте (2005, №№ 1, 2) журналда басылып чыкты һәм укучылар тарафыннан бик җылы кабул ителде. Редакция папкасында янә бер кызыклы романы бар.

Мәдинә Маликова—Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге республика премиясе лауреаты.

## Наип Лаисовка 70 яшь



Наип Хәбибназар улы Лаисов 1935 елның 10 августында Татарстанның Актаныш районы Түбән Яхшый авылында колхозчы гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылы мәктәбендә ала, аннары, күрше Олы Имән авылындагы җидееллык мәктәпне тәмамлап, 1950-1954 елларда Минзәлә педагогия училищесында укый. 1954 елның көзеннән 1957 елның июленә кадәр Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

1957-1962 елларда Н. Лаисов—Алабуга педагогия институты студенты. Институтның рус-татар филология бүлеген тәмамлаганнан соң, аны рус һәм чит ил әдәбияты кафедрасында эшләргә калдыралар. Шунда ул 1967 елның көзенә кадәр башта ассистент, соңыннан өлкән укытучы булып эшли.

1967-1970 елларда Н. Лаисов Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы каршындагы аспирантурада укый һәм, аны уңышлы тәмамлагач, кандидатлык диссертациясе яклап, яңадан Алабуга педагогия институтына кайта. 1980-89 елларда уку-укыту эшләре буенча проректор, 1989-2000 елларда ректор булып эшли.

2000 елдан 2005 елга кадәр Н. Х. Лаисов институтның татар әдәбияты кафедрасын җитәкли. Ә хәзер ул шул ук кафедрада—профессор.

Язучы буларак, Н. Лаисов әдәбият белемена караган фәнни хезмәтләре һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән билгеле. Аның Тукай иҗатының лирик-эстетик хасиятләрен ачуга, анализлауга багышланган "Лирика Тукая (вопросы метода и жанра)" исемле (1976) һәм М. Мәһдиев, Ф. Ганиевалар белән берлектә язган "Әдәбият теориясе" дәреслек китабы (1979) матбугатта уңай бәя алды. Әдәби тәнкыйть өлкәсендә Н. Лаисовны күбрәк поэзия проблемалары кызыксындыра. Аның М. Җәлил, Х. Туфан, С. Хәким, Р. Харис, М. Шабаев һәм башка шагыйрьләр иҗаты турындагы мәкаләләре теоретик яктан нигезле, дәлилле һәм заманча гомумиләштерүләре белән кызыклылар.

Н. Лаисов—1984 елдан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Каләмдәшләребезне юбилейлары уңаеннан кайнар котлыйбыз, аларга яңа иҗади уңышлар, олы шатлыклар телибез.**

*Latin imlasında uqu künekmələre*

***

Mədəniətle hərber adəmnenٖ ike tərle tele bulır, berse anasınnan sət imgən məddəttə ügrəngən teleder. İkençese dəxi ber ostazğa təğlimgə birelgəç, ğilem wə fən ləğətləre belən açılğan teleder...

Adəmnenٖ başqa xəywannardan ayırması şundadır ki, adəmnenٖ aqılı bar—fikerli belə, tele bar – səyləşə belə. Uşbu tel wə səyləşü digənegez dəxi ğilem belən, wə belməgən nərsələrne belgən keşelərdən əyrənep belmək wə kitaptan uqıp fəhemləmək belən bulır.

**Qayum NASIYRİ**

***

Qayum Nasıyri—xəzerge tatar ədəbi telenenٖ berençe bayraqçısı həm nigez saluçısı. Bu—Nasıyrını tieşle dərəcəsennən yuğarı kütərü tügel. Bu isemne tarix anٖa terkəp quyğan. Bilgele, ədəbi tel təzü ber keşenenٖ eşe belən genə təmamlanmıy, anı zamannar eşli, bernicə buın talantlı yazuçılar zurlap kamilləşterə. Nasıyri bu yulda üzenenٖ qulınnan kilgənnərnenٖ barın da eşləgən, işeklərne yabıp kitməgən. Üzennən sonٖğılarğa tikşerü, ezlənü həm kamilləşterü əçen yullar sızğan, xəzinələr qaldırğan.

**Şihap RAMAZANOV**

***

"Tatar xalıq kəye "Təftiləw"... "İ məqətdəs monٖlı sazım! Uynadınٖ sin nik bik az?"... Bu kəynenٖ monٖın həm bu süzlərnenٖ məğnəsen teldən genə əytep birep betererlek tügel ide. Bu kəygə, bu süzlərgə bəten ber xalıqnınٖ güyə barlıq yərək zarı, saf wəcdanı, açı nujası, awır xezməte, qara bəxete, yaqtı əmete, qırları-yalannarı,tawları-urmannarı, küllərе-suları, sanduğaç-bılbılları, qarangı kəzlərе, yazğı tanٖnarı—barısı-barısı bergə cıyılğan, bergə ürelgən, ber kinٖ dəryəğa əwerelep ağa da ağa ide... Tamaşaçı da güyə menə şununٖ dulqınnarında tirbələ-tirbələ ağıp kitte. Barısı onıtıldı, barlıq fani uylar "dənya çitlegennən" qayadır bik biekkə, bik yıraqqa oçtı... Cırnınٖ berençe süzlərе ük inde tamaşaçı künٖelenenٖ inٖ neçkə qılına barıp qağıldı, isertte-sixerlədе, həm küplərnenٖ küzlərennən, üzlərе də sizməstən, cılı yəşlərе ağıp təşte. Bu ğadi yılaw tügel ide, bu künٖellər təbennən kütərelgən bik izge, bik qəderle olı ber xisnenٖ saf çişmədəy sarqıp çığuı ide.

**Əmirxan YENİKİ**

***

Atam-anam yortı əçen
Bulsa meņ canım fida,
Tuğan üskən cirem əçen
Soņ tamçı qanım fida.

**DƏRDMƏND**

***

Tatarnıņ ber sirək məqəle bar:
"Tozsıznı,—di,– küzsez də belə".
Turı kilmi barı tik bu məqəl
Mesken telneņ üzena genə:
"Tozsıznı küzsez də belə".
Yuq, belmi, bu süz xata!—
Telebez məs'ələsendə
Tozsızlıq tulıp yata.

**Xəsən TUFAN**

## Məqəllər həm əytemnər

Keşe—telennən, xaywan tezgenennən eləgə.
Keşeneņ küņele telennən tanıla.
Telgə kersəņ belerlər, ilgə çıqsaņ kürerlər.
Enə küzennən sına, çiçən süzennən sına.
Canı açığannıņ tele açı.
Caylı süz can eretə.
Cılı-cılı səyləsəņ yılan da ənennən çığa.
Dənyada iņ açı nərsə də tel, iņ təçe nərsə də tel.
Teş digən qoyma artında tel digən arıslan yəri.
Dənyada süzdan kəçle nərsə yuq.
Dəres süzgə cawap yuq.

*«Казан утлары» архивыннан*



*Республикабызның суверенитеты турында Декларация кабул иткән Татарстан халык депутатлары. 1990 ел.*



*Татар халкының мәшһүр рәссамы Илдар Зарипов. 2002 ел.*



*Кәефләр күтәренке минутлар. Сибгат Хәким белән Мәдинә Маликова. Язучыларның Тукай клубы. 70 еллар ахыры.*



*Үткән гасырның 70-80 нче елларында иҗат яшьләренең семинарлары даими үткәрелә иде. Казан. Яшьләр үзәге. 1977 ел.*



*Татар әдәбиятын пропагандалауда зур хезмәт куйган сәнгатькяребез—Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Луара Шакирҗанова. 1983 ел.*



*Төрле якларда тусак та, берләштерә авыллар. Сулдан уңга—Камил Кәримов, Рөстәм Мингалим, Илдар Юзеев, Мирсәет Яруллин. Мамадыш районы, Кече Сөн авылы. 1985 ел.*

# İctimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТАРИХИ КӨН

Бу көн татар халкы күнелендә мәңге онытылмас тарихи көн булып калыр. 2005 елның 24 июне—Җирдә гаделлек тантанасы булып, Кол Шәриф мәчетенең үз туфрагына янә кайткан көне. Ул татар мөселманнарының Баш гыйбадәтханәсе генә түгел, газиз Ватаныбыз азатлыгы өчен башларын салган батыр йөрәкле, какшамас иманлы борынгыларыбызның якты рухын олылаучы һәйкәл дә.

Шушы олуг вакыйга уңаеннан, бөтен ислам дөньясыннан 5 меңнән артык кунак җыелды. Алар арасында халыкара ислам оешмаларының җитәкчеләре, ике дистәгә якын мөселман иленнән илчеләр һәм дин эшләре министрлары, Көнчыгыштагы абруйлы университетларның ректорлары, дөньякүләм шөһрәтле мәчетләрнең имамнары, Россиянең барлык мөфтиләре бар иде. Мәскәүдән Татарстан халкын котлау өчен РФ Президенты Аппаратыннан һәм Идел буе федераль округыннан да вәкилләр килде.

Тантананы Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев ачты. *(Чыгыш тексты аерым бирелә.)* Аннары Ислам конференциясе оешмасы генераль сәркатибе Әкъмалетдин Ихсан улына сүз бирелде. Әкъмалетдин әфәнде үзенең чыгышында казанлыларны 1 миллиард 200 миллион әһле ислам исеменнән котлавын белдерде, үзенең бу олуг бәйрәмгә килеп безне котлый алуына бәхетле хисләр кичерүе турында әйтте. Үзләренең оешмасында 57 дәүләтнең әгъза булып торуын сөйләде һәм аңа Россия дәүләтенең дә керүе ихтимал булуын искәртте.

Бәйрәмдә чыгыш ясаучы Кувейт мәмләкәтендә вакыфлар һәм ислам эшләре министры Маатук-әл-Маатук Җир йөзендә Ислам дәүләтләренең үсештә булуын, шулай да аларны төрле террорлык актларында гаепләмәкче булучы көчләрнең барлыгын әйтте.

Россия Мөфтиләр шурасы рәисе Равил хәзрәт Гайнетдин үзенең чыгышында шушындый мәһабәт бина кыла алулары өчен Татарстан халкына, бигрәк тә аның Президенты Минтимер Шәймиевкә үзенең олуг рәхмәтләрен белдерде, аларга саулык-сәламәтлек, Аллаһының әҗер-савапларына ирешүләрен теләде. Ул М. Шәймиевне Ислам динен торгызудагы хезмәтләре өчен "Әл-Фәхер" дигән беренче дәрәҗәдә Мактау ордены, ә "Татнефть" оешмасы җитәкчесе Шәфәгат Тәхаутдиновны шушы ук орденның икенче дәрәҗәлесе белән бүләкләде.

Бәйрәмдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти, Россия Ислам университеты ректоры Госман хәзрәт Исхакыйга сүз бирелде. Ул үзенең кыска гына чыгышында шулай ук Кол Шәриф мәчетенә бүләкләр әзерләвен әйтеп узды.

Тантанада Коръән укучылар һәм хафизларның халыкара конкурсында җиңеп чыгучылар Коръән аятьләрен укыды.

Тәүге азанны моннан берничә ел элек азан әйтүчеләр конкурсында җиңеп чыккан Шәүкәт хәзрәт әйтте. Мөфти Госман хәзрәт Исхакый җомга вәгазен сөйләде. Ә аннары Кол Шәриф мәчетенең имам-хатибы Рамил хәзрәт Юныс тәүге җомга намазына имамлык кылды. Кол Шәрифнең эченә үткән халык бу гыйбадәтханәнең искитмәле матур төзелешенә, бизәлешенә таң калып намаз укыды. Бу вакытта күпләрнең күнелендә моннан 453 ел элек Казанны яклап шәһит киткән Кол Шәриф хәзрәтләрен һәм аның шәкертләрен олылап искә алу булгандыр.

Соңыннан Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев резиденциясендә журналистлар өчен халыкара матбугат конференциясе үткәрелде. Шул ук көнне Казанда "Идел-Урал төбәгендә ислам мәдәнияте" дигән халыкара конференция эшләде.

## ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ М. ШӘЙМИЕВНЕҢ КОЛ ШӘРИФ МӘЧЕТЕН АЧУ ТАНТАНАСЫНДА ЯСАГАН ЧЫГЫШЫ

Әс-сәләму-галәйкум, хөрмәтле ватандашлар һәм мөхтәрәм кунаклар!

Бүген халкыбызның гасырлар буе күңел түрендә йөргән иң изге хыялы

тормышка ашты. Без барыбыз да бу дулкынландыргыч вакыйганың шаһитлары, Кол Шәриф мәчете халкыбыз хозурына кире кайтарылды. 450 елдан артык вакыт узганнан соң, тарихның өзелерөзелмәс җебен ялгап җибәрү һәм аны мәңгеләштерү бәхете нәкъ менә безгә насыйп булды. Бу гамәлебез белән без үзебезнең горур, таза рухлы халык икәнлегебезне расладык.

Тугыз ел элек, 1996 елның февралендә, Татарстан Республикасы Президентының "Казан Кремле ансамблен саклау, үстерү һәм файдалану концепциясе турында" Указы нигезендә без Кол Шәриф мәчете төзеләчәк шушы урынга тантаналы төстә истәлекле таш салган идек. Шул ук Указда Благовещенье соборын төзекләндерү турында да карар кабул ителде. Бу—тарихи хакыйкать һәм диннәр арасында татулык урнаштыручы гамәл булды. Татарстан Республикасы хөкүмәте, Дәүләт Советы һәм шәхсән үз исемемнән сезне Кол Шәриф мәчете ачылу бәйрәме белән чын күңелдән котлыйм һәм шатланам.

Бүгенге истәлекле вакыйганың Казанның меңьеллык юбилеена туры килүе очраклы хәл түгел. Күренекле җәмәгать һәм дин эшлеклесе, Казан Кремле мәчетенең имамы Кол Шәриф—Казан тарихында тирән эз калдырган шәхес. Шагыйрь, көрәшче һәм акыл иясе, сәет Кол Шәриф үзенең шәкертләре, дәрвишләр һәм суфыйлар белән шәһәрне дошманнардан саклап сугышканда һәлак була. Ул үзенең бер хезмәтендә: "Мин яу кырын ташлап кача торган кеше түгелмен", дип язган. Һәм ул, нәкъ үзе язганча, гомеренең соңгы мизгелләренә кадәр үз мәчетен яклап яу кырында ятып калган.

Без тугыз ел элек Кол Шәриф мәчетенең иң яхшы проектына ачык конкурс игълан иттек. Анда архитекторлар Шамил Латыйпов, Искәндәр Сәйфуллин, Айвар Саттаров һәм Михаил Сафронов җиңеп чыкты. Алар борынгы мәчетебезнең тарихи дәлилләрен дә, дөнья тәҗрибәсен дә, җирле гореф-гадәтләрне дә исәпкә алып эшләделәр. Аларның осталыгы һәм олы хезмәте нәтиҗәсендә мәчет Кремль ансамблен тулыландырды һәм аны тагын да гүзәлрәк итте.

Бу күркәм бина Кремльгә дә, гомумән, Казанның тарихи үзәгенә, туган җиребезгә иман нуры сибеп тора. Мәчетнең күккә ашкан манаралары, күк төсендәге гөмбәзе тарихыбыз, рухи һәм матди хәзинәләребез турында тирәнтенрәк уйланырга кирәклеген искәртә кебек. Алар безнең үзаңыбызга унай йогынты ясый.

Кол Шәриф мәчете республикабыз мәркәзенең төп мәчете генә түгел. Ул—Казанның һәм Татарстанның яна символы, бөтен татар дөньясын үзенә җәлеп итүче рухи үзәк. Ул—безнең үткәнне киләчәгебезгә тоташтыручы рухият күпере.

Кайчандыр Кол Шәриф болай дип язган:

*Гаҗәеп бер җай—рәхәттер җиһанда*
*бу Казан шәһре!*
*Галәмдә юктыр бу тикле туганлык вә*
*иминлек шәһре.*
*Казандай төзек шәһри булмас дөньяда*
*һичвакыт.*
*Казаннан көч алалардыр ничаклы бу*
*җиһан шәһре.*

Янарып килүче Кремльне күрсә, ул бүген дә шушы юлларны кабатлар иде дип уйлыйм.

Мечеть Кул Шариф стоит рядом с Благовещенским Собором и в этом есть свой глубокий смысл, связанный с чаяниями многонационального народа республики жить в мире и дружбе. Они стоят рядом как символ взаимопонимания двух ведущих конфессий страны. Храмы республики должны привлекать внимание не только своим обликом, но образованными имамами, священнослужителями, несущими свет веры и оберегающие наши исконные традиции. Храмы важны как центры духовного сплочения людей, нравственного воспитания молодежи. Если после каждого посещения храма душа очищается, а нравственность укрепляется, значит, мечеть, церковь и другие религиозные храмы превращаются в важное звено в становлении цивилизованного демократического общества.

Кол Шәриф мәчетенең ишекләре иманга омтылган һәркемгә ачык булачак. Монда һәрберебез үзен борчыган сорауларга төгәл һәм дәлилле җаваплар табар дип ышанам. Шул ук вакытта бу гыйбадәт кылу урыны гына түгел. Кол Шәриф мәчете бик үзенчәлекле музейлар комплексына әйләнәчәк. Безнең бурыч—исламның тарихын гына түгел, аның сабыр холыклы, башка диннәргә ихтирамлы дин икәнен дә күрсәтү. Иманым камил: Кол Шәриф мәчете кешеләрне тынычлыкка, татулыкка, сабырлыкка, үзара ихтирамга өндәүче савапллы урын булыр. Без аны бөтендөнья ислам музее итеп күзаллыйбыз. Амин, шулай булсын.

Бу мәчетне чын мәгънәсендә бөтен халык төзеде. Иң беренче рәхмәтне мин авыл хезмәтчәннәренә әйтер идем. Мәчет төзелешенә үз өлешләрен башлап алар кертте: мул уңыш үстереп мәчет фондына тапшырдылар. Гомер-гомергә

изге саналган икмәк изге эшнең нигез ташы булды. Әлбәттә, бу мәһабәт мәчетне төзүдә төп спонсор "Татнефть" җәмгыяте хәлиткеч роль уйнады, күп кенә башка оешмалар һәм предприятиеләр, аерым гражданнар ихлас күңелләрен үз өлешләрен керттеләр. Кайбер чит илләр бу изге эштә эчкерсез катнаштылар. Мәсәлән, Иран келәмнәр бүләк итте, Гарәп Әмирлеге акчалата булышты, Төркия төзекләндерү эшендә катнашты. Төзүчеләргә һәм Кол Шәриф фонды хезмәткәрләренә аеруча зур рәхмәт белдерәм. Мәчет төзелешенә хәленнән килгәнчә үз өлешен керткән һәркемнең исеме "Изгелек" дигән истәлек китабында мәңгелеккә урын алачак. Бик зур рәхмәт үзегезгә, туганнар! Сезнең һәрберегез олы ихтирамга лаеклы. Барыгызга да Ходайның рәхмәте яусын, әҗер саваплары, ике дөнья рәхәте насыйп булсын сезгә, газиз кардәшләр!

Хөрмәтле ватандашлар! Кадерле кунаклар!

Сезне ихлас күңелемнән Кол Шәриф мәчете ачылу белән тәбрик итәм! Иншә Аллаһ, Кол Шәриф мәчетенең киләчәк язмышы бәхетле булыр, чөнки мәчетләр белән бергә тормышыбызга иман кайта, халкыбызның рухы ныгый һәм җир йөзендә мәрхәмәт артканнан-арта бара.

Сезгә сәламәтлек, җан тынычлыгы, иман ныклыгы телим. Мәчетебез рухи көч-куәте, иман нуры белән халыкны үзенә тартып торсын, тынычлык- тату-лык-гыйлем үзәге буларак даны еракларга таралсын! Иншә Аллаһ, ул шулай булыр да!

## МЕҢЬЕЛЛЫК МЕДАЛЕ

Россия Президенты Владимир Путин Указы нигезендә "Казанның 1000 еллыгы истәлегенә" медале булдырылды.

Медаль белән Казанда яшәүче Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш вакытында тылда—башкалада хезмәт итүчеләр, Бөек Ватан сугышында тырыш хезмәт өчен СССРның орден медальләренә лаек булучылар, шәһәр үсешенә зур өлеш кертүчеләр, хезмәт ветераннары бүләкләнәчәк.

Яна медаль күкрәкнең сул ягына тагылырга тиеш. Җиз медальнең диаметры 32 миллиметр булачак, ана Казан Кремле күренеше төшерелеп, "Казанның 1000 еллыгы истәлегенә" дигән сүзләр язылачак.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең XV корылтайдан соңгы беренче утырышы булды. Аны иҗат оешмасының яна рәисе Илфак Ибраһимов (Мөхәммәт Мирза) алып барды.

Язучылар берлеге идарәсе житәкчесе иң элек әдәбият өлкәсендә зур уңышларга ирешкән бертөркем язучыларга Татарстан Мәдәният министрлыгының "Мәдәнияттәге казанышлар өчен" дигән билгесен, Мактау грамоталарын тапшырды. Алар арасында Ләбибә Ихсанова, Мәгъсүм Насыйбуллин, Рифат Сверигин, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Лирон Хәмидуллин, Мәгъсүм Хужин, Мәдинә Маликова, Кыям Миннебаев, Вакыйф Нуруллин, Фарсель Зыятдинов, Борис Вайнер, Рәниф Шәрипов бар. Татарстан мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары Данил Мостафин исә Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бүлеге мөдире—драматург һәм прозаик Рәдиф Сәгъдигә "Мәгариф өлкәсендәге казанышлары өчен" дигән билге тапшырды.

Аннары идарә әгъзалары XV корылтайда кабул ителгән резолюцияне тормышка ашыру буенча нинди эшләр башкарырга кирәклеге турында сөйләште. Соңыннан оештыру эшләре каралды. Ачык тавыш бирү юлы белән идарә рәисенең ике урынбасары—монарчы "Мәйдан-Чаллы" журналының баш мөхәррире булып эшләгән Факил Сафин һәм Язучылар берлеге аппараты житәкчеләренең берсе булган Шаһинур Мостафин сайланды. Язучылар берлегенең Чаллы һәм Әлмәт бүлекләре җаваплы сәркәтипләре итеп Вахит Имамов һәм Зөфәр Дәүләтов кандидатуралары расланды. Идарә утырышында шулай ук иҗат остаханәләренең житәкчеләре тәгаенләнде. Бу вазыйфаларга Зиннур Мансуров (шигърият), Марсель Галиев (проза), Рабит Батулла (публицистика), Мансур Гыйләҗев (драматургия), Рафис Корбан (балалар әдәбияты), Мансур Вәлиев (әдәби тәнкыйть), Лилия Газизова (урыс әдәбияты) билгеләнде. Матур әдәбиятны пропагандалау бүлеге мөдире итеп Рәдиф Сәгъди расланды. Татарстан Язучылар берлегенә кабул итү Коллегиясе рәисе итеп янадан Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, ревизия комиссиясе рәисе итеп икътисад фәннәре докторы, язучы Фарсель Зыятдинов сайланды. Идарә утырышында "Казан утлары", "Идел", "Салават күпере", "Мәйдан" журналларының баш мөхәррирләрен раслау турындагы мәсьәлә дә каралды.

Быел да Г. Державинның туган көненә багышлап, Лаеш районында һәм Казанда Шигырь бәйрәме үтәчәк. Утырышта шул чараны үткәрүгә кагылышлы сөйләшү булды. Әлеге олуг шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе исемендәге премиянең быелгы лауреаты да ачыкланды. Ул—Чаллы каласында яшәп иҗат итүче шагыйрь Николай Алешков.

Идарә утырышында Казан шәһәренең 1000 еллыгына, "Казан утлары" журналының 1000 нче саны чыгуга багышланган тантаналарны һәм җәлилче каһарманнарны искә алуга кагылышлы "Хәтер җыены"н (25 август) үткәрү унаеннан идарә алдында торган бурычлар турында да сөйләшү булды.

## ЯҢА ҖИТӘКЧЕЛӘР

* * *

ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисади һәм социаль тикшеренүләр үзәге директоры урынбасары, танылган журналист Леонид Толчинский "Татар-информ" мәгълүмат агентлыгы генераль директоры итеп билгеләнде. ТР "Татмедиа" гаммәви коммуникацияләр агентлыгы генераль директоры Марат Моратов аны коллектив белән таныштырды. Ул агентлыкның элекке җитәкчесе Рәшит Галләмовка агентлык үсешенә керткән өлеше өчен рәхмәт белдерде һәм киләчәктә бизнес-проектларын тормышка ашыруда аңа уңышлар теләде.

* * *

Премьер-министр Р. Миңнеханов ТР Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсе коллективын яңа җитәкче белән таныштырды. Шушы вазыйфаны 12 ел башкарып, хәзер лаеклы ялга китүче Дамир Шәрәфетдиновны Данил Ибраһимов алыштырды. Р. Миңнеханов 20 ел гомерен архив хезмәтенә багышлаган Дамир Рәүф улына Министрлар Кабинетының Рәхмәт хатын, истәлек бүләген тапшырып, күпьеллык хезмәтенә хөрмәтен белдерде.

Дамир Шәрәфетдинов киләчәктә дә үзе яхшы белгән өлкәдә хезмәт тәчәк. Ул, "Гасырлар авазы"—Эхо веков" журналына җитәкчелек итү белән беррәттән, ТР Президенты каршындагы Геральдика советы рәисе вазыйфасын башкарачак.

## ИГЪТИБАР: ЯҢА КОНКУРС

ТР Мәдәният министрлыгы һәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры "Яңа татар пьесасы—2005 ел" дигән конкурс башлануны игълан иттеләр.

Быел ул "Иң яхшы музыкаль пьеса" һәм "Иң яхшы комедия" номинацияләрендә үткәрелә һәм татар театр сәнгатенең йөз еллык юбилеена багышлана. Җиңүчеләрнең исемнәре алдагы елның 27 мартында билгеле булачак. Ике номинация буенча да I, II һәм III урыннар билгеләнәчәк һәм җиңүчеләргә 100, 75 һәм 50 мең сум күләмендә премияләр тапшырылачак. Жюри әгъзалары, татар театры тарихын һәм бүгенгесен чагылдырган әсәрләргә өстенлек биреләчәк, диләр. Ә пьесалар мюзикл, рок-опера, водевиль, музыкаль драма һәм башка жанрларда язылырга мөмкин.

## РУС ПОЭЗИЯСЕ БӘЙРӘМЕ

Бөек рус шагыйре Александр Пушкинның тууына 206 ел тулуга багышланган Шигырь бәйрәме Казанда Г. Державин һәйкәле янында узды.

Билгеле булганча, бу бәйрәм шагыйрьнең туган көненә РФ Президентының 1997 ел, 22 май Указы нигезендә ел саен үткәрелә. Алай гына да түгел, Пушкинның туган көнен башка илләрдә дә билгеләп узалар.

Казанда Шигырь бәйрәмендә катнашучыларны ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, шагыйрь Илфак Ибраһимов котлады. "Александр Пушкинның шигырьләре һәр кешенең йөрәгендә яши, аны җылыта. Поэзия энергетикасының бөек көче шунда да инде",—диде ул үз чыгышында.

Мәдәният министры урынбасары Айрат Җаббаров, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис Пушкин иҗатының башка халыклар мәдәниятенә йогынтысы турында сөйләде.

Шигырь бәйрәмендә шулай ук Лилия Газизова, Ольга Левадная, Борис Вайнер, Наилә Ахунова, Альбина Әпсәләмова, Алексей Остудин, Тимур Кәримов, Полина Осипова һ. б. лар бөек шагыйрьгә багышланган шигырьләрен укыдылар.

## КОРЪӘН ХАФИЗЛАР БӘЙГЕСЕ

Г. Камал театрында Коръән укучылар һәм Коръән хафизларның халыкара бәйгесе үткәрелде. Ул Казанның меңьеллыгына һәм Кол Шәриф мәчете ачылуга багышланды. Әлеге бәйгедә 55 кеше катнашты. Катнашучылар республикабызның шәһәр-районнарыннан, Россиянең төрле төбәкләреннән, Украина, Кыргызстан, Үзбәкстан, Таҗикстан, Казакъстан, Әзәрбайҗан кебек илләрдән дә килгәннәр. Шулай ук бәйгедә Төркия, Кувейт, Согуд Гарәбстаны, Бахарейн, Иорданиядән дә кунаклар бар иде.

Беренче номинациядә Үзбәкстаннан Кадерҗан Хөсәенов җиңүче дип табылды. II—III урыннарны шул ук Үзбәкстаннан Баһадур Сәхипов һәм Казакъстаннан Ханнан Абдулла бүлеште. Коръәнне яттан белүчеләр арасында беренче урынны Чаллы шәһәреннән Алик Яушев яулады. Пенза өлкәсеннән килгән Ислам Дашкин II, Казаннан Әбделмәлик Сайдаргалиев III урынга ия булдылар.

### АРХИВЫБЫЗ ТУЛЫЛАНДЫ

Төркия Республикасы Министрлар Кабинеты Дәүләт архивлары Генераль идарәсе Татарстанның Баш архив идарәсенә "Госманлы документларында Казан" дигән җыентык тапшырды. Әлеге җыентыкта урын алган 240 тан артык тиңе булмаган документ Татарстан халыклары тарихын һәм татар-госманлы мөнәсәбәтләрен чагылдыра.

### "ИДЕЛ-ПРЕСС" БҮЛӘГЕ

"Идел-пресс" полиграфия-нәшрият комплексы коллективы Мәскәү шәһәренең Татар милли үзәге китапханәсенә татар телендә меңнән артык китап бүләк итте. Китапларның бер өлеше (алар арасында фәнни, әдәби әсәрләр, балалар әдәбияты да бар)—предприятие хезмәткәрләренең шәхси китапханәләреннән.

Бу—нәшриятның беренче тапкыр гына изге гамәл кылуы түгел инде. "Идел-пресс" соңгы берничә ай эчендә генә дә Казанның күп кенә оешмаларына: күп балалы аналар һәм балалар опекуннары берләшмәсенә, "Марина" приюты, Дәрвишләр бистәсенең балалар интернат-йорты, 19 нчы балалар китапханәсенә хәйрия ярдәме күрсәтте.

Узган ел предприятие җитәкчесе Ислам Әхмәтҗанов исә үзенең шәхси китапханәсеннән 2 меңгә якын китапны туган авылы—Буа районы Норлат авылының Мәдәният йортына бүләк иткән иде.

Предприятие әле моның белән генә туктап калырга җыенмый: ул инде киләсе акцияләргә китаплар әзерләүгә керешге.

### БАТЫРШАЛАР РУХЫ СҮНМӘСЕН

Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетында галим Фәйзелхак Исмаевның "Батырша восстаниесе. 1755 ел" дигән китап-монографиясен тәкъдим итү булды. Ул ТР Фәннәр академиясенең "Фән" нәшриятында рус телендә нәшер ителгән.

Бу очрашуда автор Батырша турында ничек итеп мәгълүмат җыюын сөйләде. Мәскәү архивларының берсендә Батырша восстаниесенә кагылышлы 5 томлык мәхкәмә эше бар икән.

Батырша—Габидулла Галиев (1700-1762) 10 елдан артык мәдрәсәләрдә укып мулла булган. 1755 елда Башкортстан җирендә аның җитәкчелегендә зур күтәрелеш була. Нәтиҗәдә, Урал һәм Себер төбәкләре мөселманнары чукындырылудан сакланып кала.

Тәкъдим итү кичәсендә катнашкан галим һәм әдипләр Батырша восстаниесенең тарихи нәтиҗәләрен билгеләп үттеләр. Санкт-Петербургтагы ул утырган һәм һәлак булган Шлиссельбург крепостена Батыршаның исеме язылган истәлекле такта кую тәкъдиме кертелде.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Фәнне, мәгарифне, мәдәниятне үстерүгә зур өлеш керткәне һәм актив җәмәгать эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе хакыйкый әгъзасы **Хәсәнов Мансур Хәсән улы** "Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен" ордены белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өлкәсендәге казанышлары өчен **Галиев Фәйзи Әхмәт улы** "Татарстан Республикасы каршындагы казанышлары өчен" ордены белән бүләкләнде.

* * *

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен шагыйрә **Шакирҗанова Лена Галимҗан кызы** (Лена Шагыйрьҗан) Татарстан Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

* * *

Әдәбиятны, журналистиканы үстерүгә зур өлеш керткән һәм Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президенты матбугат архивы мөдире, шагыйрь, прозаик **Хәсәнов Энәс Хәсән улы** Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Башкалам. ***С. Исхаков*** *фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә **Лилия Газизова**.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Равил Вәли. **Олуг хан ярлыгы.** Эсселар, тарихи повестьлар.—Казан: "Мәгариф" нәшр., 2005.—263 б. Тиражы—1000 данә.




Язучы Равил Вәли укучыларга күбрәк бүгенге көнгә багышланган документаль әсәрләр авторы буларак билгеле ("Шәһәр булсын бүләгем", "Таяну ноктасы", "Көчле агым" һ. б.). Соңгы елларда ул тарихи әсәрләр язу өлкәсендә дә уңышлы эшләп килә. "Олуг хан ярлыгы", "Тәхет күрке", "Үч" повестьлары шуның бер мисалы. Бу китапка кергән әсәрләрдә халкыбыз тарихының монарчы аз билгеле булган сәхифәләре яңача караштан чыгып бәян ителә. Китапның Казан шәһәренең 1000 еллык юбилее алдыннан дөнья күрүе дә аерым мәгънәгә ия.

Китапның мөхәррире—К. Кәримов, рәссамы—Р. Сәйфуллина.

Рәмзия Габделхакова. **Көзге яшен.** Шигырьләр.—Казан: "Рухият" нәшр., 2005.—224 б. Тиражы—500 данә.




Лениногорск шәһәрендә яшәп иҗат итүче Рәмзия Габделхакова әдәбиятка соңгы биш-алты елда ныклап аяк баскан язучыларның берсе. Кызыклы һәм гыйбрәтле хикәяләре, повестьлары көндәлек матбугатта еш басыла. Кайбер әсәрләре "Казан утлары" журналында да дөнья күрде. "Көзге яшен" китабында ул яңа яктан—кызыклы шагыйрә булып ачыла.

Китапның мөхәррире Г. Гыйльманов аның турында болай язган: "Бөтен күңелен иҗатка багышлаган, шәхес буларак та, язучы, шагыйрь буларак та өлгереп җиткән бу каләмдәшебез тормышка, иҗатка җитди мөнәсәбәте белән укучыларны үзенә җәлеп итә". Җыентыктагы шигырьләр чыннан да шуны раслый.

Китапның рәссамы—Р. Хәсәншин.

Индекс 73210



Лилия Газизова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)